ISSN 0206-4189
Индекс 73210
12+

# Казан утлары

5.2014



# №5 (1099) 2014 БУ САНДА:



*Фаил Шәфигуллинны соңгы юлга озату.*


**Камил КӘРИМОВ:**

«Үләр алдыннан Фаил берничә исем атаган. Әллә чынлап, әллә махсус, палатадагылар ул исемнәрне искә төшерә алмый: «Татар исемнәре иде, отып булмады, ләкин Резидә, Раушания, Эльмира да, Зөлфәт тә түгел», – дигәннәр».

117

## КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ

**Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА «Нурулла»**

«Менә шулай... Реанимациядән гомуми палатага чыгаргач, янәшә караваттагы абзый аңа:
— Ике тумыйбыз, ике үлмибез, иртән гел: «Бүген бәйрәм», — дип уян, — диде.
Искерсә дә, асыл хакыйкать иде бу.
Менә шулай... Уяна Нурулла. Үз жае, үз көе булган тормыш иртәсе, гәрчә йөз төрле мәшәкатьләре, аһ-зары, үкенеч-көенечләре белән бусага төбендә үк сагаласа да, ул разый иде. Яшәү — бәйрәм! Йөрәге бер туктап алган кеше моны бөтен вөҗүде, бөтен күзәнәкләре белән тоя иде».

43




# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур ХӨСНИЯР. Гарасат. *Роман.* .....3
Хисам КАМАЛ. Көн елмаеп атлый каршыга. *Шигырьләр.* .....23
Әмирхан ЕНИКИ. Кем җырлады? *Хикәя.* .....27
Михаил ВЕЛЛЕР. Байрак турында баллада. *Хикәя.* .....31
Дамир ГАРИФУЛЛИН. Робагыйлар өләшүдән ялыкмыйм. *Шигырьләр.* .....39
Таһир ШӘМСУАРОВ. Халкыма багышлана. *Шигырьләр.* .....87

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Нурулла. *Бәян.* .....43

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Ак бүре. *Татар халык әкиятләренә нигезләнеп язылган либретто.* .....90

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Айдар ХӘЛИМ. Туры тулпар кая чаба? .....107

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Камил КӘРИМОВ. Юморның соңгы төне. .....117
Фаил ШӘФИГУЛЛИН. *Хикәяләр.* .....126
Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА. Остаз. .....134
Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Әдәбият гаме — яшәү мәгънәсе. .....139

Рәфикъ ЮНЫС. Ул кургашын солдат булмаган. .....148

**СӘНГАТЬ**

Әхтәм ЗАРИПОВ. «Сагыну»ны сагынып... .....149
Гүзәл СӘГЫЙТОВА. Мәскәүдә туган җыр. .....158
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Ике халыкның былбылы. .....160

**ТАРИХ**

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре. .....167

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Кар кешеләре — арабызда... .....174

Шаян сәхифә. Уены-чыны бергә. *(Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде).* .....178

**«АК ҖИЛКӘН»**

Руслан РӘҮПОВ. Булганда — кадерен бел, югалткач – елама. *Бәян.* .....181
Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА. Һава торышы. *Хикәя.* .....185
Алинә САДЕРТДИНОВА. Фирүзә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. *Шигырьләр.* .....187

татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 222-05-50.*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 5).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.04.2014, график буенча 29.04.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1199. Тираж 3220.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Зиннур
Хөснияр

# ГАРАСАТ[1]

РОМАН[2]

*«Халыкка алдан хәбәр биреп торучы бул.*
*Җәбраил фәрештә сиңа ярдәм итәр».*
Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) бер таныш
шагыйренә бик еш шулай дия торган була.

*Борын-борын заманнарда Адәмнең балалары бик озын буйлы, алыптай зур булганнар. Карурманнарны алар үлән ерган кебек кенә аркылы чыкканнар. Ерганак, күл, елгаларны атлап кына узганнар. Бервакыт шундый алып адәмнең баласы кечкенә кешегә юлыккан. Ул ат белән җир сөрә икән. Малай аны, кесәсенә салып, өенә алып кайтып киткән һәм әтисенә күрсәткән. Атасы: «Улым, син моны алган җиреңә кире илтеп куя күр. Бу бездән соң яшәячәк кешеләрнең берсе булыр!» — дигән. Малай аны урынына кире илтеп куйган.*

*Ошбу Җиребезнең фәлсәфәсе –*
*Адәм пәйгамбәр шәҗәрәсе.*
*Туфрактан булгач аслы җирдәге, —*
*Ходай әмре илә Җир — бишектә, —*
*Йөридер лә Кояш әйләнәсе...*

## Коръән серләре...

Печән өсте килеп житкән бер матур көн иде. Яшүсмер чагыннан бирле кулына андый нәрсә тотып карамаган Байбулат ага сарайдан әтисеннән калган чалгыны эзләп тапты. Әлеге «жиделе» иске чалгыны сирәк булса да аннан башка тагын хатыны кулга алгалый һәм шуннан соң җәй буе лапастагы утын

[1] Ошбу роман 2013 елда Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Татарстан Язучылар берлеге уздырган конкурста беренче урынны яулады.
[2] Журнал варианты

Зиннур ХӨСНИЯР (1961) – *прозаик, шагыйрь, драматург. «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар», «Эттән туган», «Терсәк сугышы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

әрдәнәсенә кыстырып тота иде. Көз житкәч, Байбулат ага аны элеккеге урынына, печәнлектәге киштә арасына куя; хатыны тагын, печән өсте башланганчы ук, бакча буендагы кычытканнарны чабарга кирәк булгач, урыныннан эзләп таба. Шул рәвешле ничәмә-ничә еллар буе дәвам итте. Чалгының сабы инде кибеп, бушап беткән. Байбулат ага аны кичтән сулы тагаракка салып куйды, инде, таушалып, мунчалага әйләнгән юкә бау урынына капрон җеп бәйләп нығытты.

Быел яз җинел килде. Кара каргалар күренгәннән соң, нәкъ бер айдан кар китте. Тик шулай да яз озын булды. Элеккеге колхоз рәисенең сынамышларында хаклык бар: кара каргалар килүгә ояларына төштеләр. Ә җәй яхшы булырга охшап тора, чөнки торналар төркем-төркем булып түгел, аерым-аерым килделәр...

Бәрәңге бакчасының тимер челтәр коймасы буенда, печән өсте житкәнче үк, чытырман булып кычыткан үсә, электән чүп үләнен өнәмәгән Байбулат ага кычытканны да шулар рәтенә кертә һәм аның котырып үсүен җене сөйми иде. Яшь кычыткан ашын бик яратып ашаса да, печән өсте килеп җитүгә, кычыткан инде картайган була һәм һәрвакыттагыча картның эчен пошыра.

Бик биектә, кояш чыгышына таба, бер-бер артлы ике самолёт очканы күренде. «Кемнәрдер Себергә китте...» — дип куйды карт үзалдына һәм очкычлар турында шундук онытты да. Авыл өстендә беркавым тоныҡ гөрелте һәм ак төтен юллары эленеп торды әле.

Ул бүген дә чалгысын күтәреп бакчага узды. Үз артыннан лапас капкасын ябып бетермәгән иде, күрәсең, вакытсыз бер оя чеби чыгарган кызыл тавык сары йомгаклары белән ни ара артыннан иярде, алар шундук дәррәү бәрәңге буразнасы арасына таралдылар. Чебиләрне аннан «чүпләп» алганчы шактый вакыт узды, карт сары йомгакларны лапас эченә кире куып кертте. Чалгыны янап, кычытканны кабат чаба башлауга, бер чебинең шунда йөргәнен күргән шикелле булды, чалгы сабы белән кычытканнарны аралап карады, тик тегене таба алмады. Үзе килеп чыгар әле дигән уй белән чалгысын янә кулына алды. Беренче селтәнүендә үк аның тимере, чык итеп, нindидер каты нәрсәгә эләктеме — шул урында очкын чәчрәде. Әлеге ут көлтәсе дә, күзенә кабат чалынган теге адашкан чебеш тә «ә» дигәнче куе кычыткан арасына кереп югалдылар. Күз аллары караңгыланып китте: шул ук мәлдә теге мәхлук чебеш, сары ут йомарламына әверелеп, яшен тизлеге белән күк катына ашкан кебек булды!.. Карт, башын күтәреп, өскә карады. Анда исә авыл турысыннан узган тавышсыз самолётларның ак эзләре генә шәйләнә иде... «Казаннан Себер ягына юнәлгән самолётларның юлы безнең авыл өстеннән уза», — дигән иде бервакыт аның очучы улы Байтимер.

...Нәкъ шул көнне тәмуг капкасы ачылып китте... Байтимер Баймурзинны галәм бушлыгында тоткан теге зат ялкын бөркелеп торган капканы шапылдатып ябып куйды. «Төш түгелдер бит инде бу?! Юк! Юк! Төш түгел!» — дигән уй Баймурзинны инде тынычландырмый, киресенчә, куркыта башлаган иде. Соң?! Төш булмагач!!! Бу бит!.. Төш булса, уянуга арыныр идең, тынычланыр идең! «Беттем!» — дип уйлады Баймурзин, чарасызлыктан. Ләкин әлеге Зат, күрәсең, аның ниләр кичергәнен яхшы сизеп тора, ул Байтимерне скафандр белән бергә учлап диярлек (Әйтерсең, гулливер учына нәни бөҗәкне алды!) тотты да шулчак тәненә кайнар дулкын бәрелеп, аны әйтеп-аңлатып биреп булмаслык сәер җинеллек биләп алды. Хәзер манзара да башка! Тирә-юньнең матурлыгын, андагы якты төсләрне күреп исен-акылың китәрлек! Моны сөйләп тә, язып та аңлатып бетерерлек түгел! Тәнендә ничә миллиард күзәнәк булса, әлеге мизгелдә Баймурзин аларның һәммәсен дә тойды кебек. Ул үзен нindидер

бер кайнар ноктага әверелеп калган шикелле хис итте... Баймурзинга кадәр галәмгә чыккан космонавт егетләр аның гаҗәеп булуы хакында сөйләгәннәр иде сөйләвен! Тик үз күзең белән күрмәсәң, ишетеп кенә адәм ышанырлык манзара-тамаша түгел икән шул! Берәүнен дә, җирдән торып, андый ал, шәмәхә, кызыл, зәңгәр төсләрне дә, җиргә аркасы белән торган чакта, иксез-чиксез төпсез куркыныч караңгылыкны да күргәне юктыр әле!!! Галәм караңгылыгы бу!.. Җирдә караңгылык чиксез түгел... Монда ул чиксез, төпсез! Җирдә бер чарасыз калган вакытларында барыбер нинди дә булса ышаныч хисе була. Монда ул хис тулысы белән Илаһи көч карамагында бугай! Син аның барлыгына ышанасынмы, юкмы — анысы әһәмиятсез! Тегендә, җирдә, аягына басып торганлыгыңны тәгаен белсәң, монда Җир синең өчен Илаһият үзе!..

Баймурзин бу хакта ничәдер секунд эчендә генә уйлый алды. «Беттем!» — дип кычкырды — тавышы чыкмады... «Бетүемдер бу!» дигән уй кабат аның яндырып узды. Бетүе түгел икән, гаҗәп хәл булып алды шул мизгелдә: ниндидер серле, илаһи могҗиза-галәмәт көч (гәүдәсенә орынмады да!) кире караб эченә суырып алды!!! Иптәшләре дә аның коточкыч һәлакәттән котылганын аңлап алганнар һәм ул кире карабка кергәч, әүвәл исән калганлыгына ышанасылары килмәде, үзе исә сүз әйтерлек хәлдә түгел, чатырдап кипкән иреннәре белән бертуктаусыз: «Аллага шөкер! Аллага шөкер!» — дип пышылдаганын да соныннан гына сөйләделәр. Егет, күзгә күренеп, шул кыска гына мизгел эчендә, бөтенләй үзгәреп, икенче кеше кабыгына кереп утырды! Әмма ни булганын һаман аңларлык хәлдә түгел... Бәйләгән элмәгенә кадәр ычкынган иде бит, кем тотып алды соң, кем аны җил мамыкка өргән кебек кенә караб эченә кире очыртып кертте? Хәер, бу минутларда инде монысы да әһәмиятле түгел. Әлеге могҗизаны җирдә дә күзәтеп тордылар, алар да бик аптырашта, күрәсең, һаман аңнарына килеп җитә алмыйлар, юкса шундук хәбәргә чыгарлар иде. Әйе, бу вакытта Баймурзинны Җирдән күзәтеп торучылар аның үзенә караганда да ныграк гаҗәпләнә иделәр! Алар егет күрмәгәнне дә күрделәр бит! Космонавтны чолгап алган сәер яктылык, — әле кеше сурәтләренә керә торган, әле коточкыч ялкынга, әле гаҗәеп матур күренешкә әйләнгән ошбу сәер яктылык, могҗизалы яктылык! — монарчы галәмдә андый очракка тап булганнары юк иде! Бу сәер күренешне НАСА[3] да күзәтеп торган. Алар шундук Рәсәйдәге «йолдызлы» кулдашлары белән хәбәргә керделәр. Аралары тагын суынып бара торган (Аурупадагы ракеталар аркасында!) ике ил, гомуми гаҗәеп вакыйга каршында аерым-аерым көчсез икәнлекләрен таныдылар һәм шуна күрә, тиз генә берләшергә уйлап, уртак карарга киленде: карабны кичекмәстән Җиргә кайтарырга!

Баймурзин, Җиргә төшкәч тә, өч көн җыенлап аңына килә алмады. Шул өч көн эчендә кәгазь-каләм соратып алып, әллә чыннан да төшенеп, әллә ни язганын үзе дә белмичә яза башлады. Ни гаҗәп: монарчы бер авыз сүз дә гарәпчә белмәгән Баймурзин шул телдә сырлады. Икенче вакыт аңына килгәндә, «япономать»тан башка сүзне ишетмәгән кеше японча текстлар язды, әллә нинди африка телендәге — соңыннан ачыкланганча, шумер телендәге — сүзләр дә бар иде ак кәгазь битендә! Тик никтер русча һәм инглизчә язмады. Югыйсә икесен дә яхшы белә иде!

Аның язмалары кыска җөмлә-сүзләрдән генә торып, бер караганда, әллә ни әһәмияткә дә ия түгел кебек: «Ләә иләһә илләллаһү...» (Шунда өзелә.), аннан соң: «Әлиф. Ләм. Мим. Ра» кебек билгечләр дә аңламаслык сүзләр генә. Әмма

[3] НАСА (ингл.) — Национальное управление по воздухоплаванию и исследованию космического пространства.

аны старт алдыннан башкалар белән беррәттән чукындырган игумен Иофов бик акыллы рухани иде. Өч көннән соң, Баймурзин айнуга, рөхсәт сорап, чит кеше югында, шаһитларсыз гына сөйләшергә булды. Рухани нидер сизенә иде, күрәсең. Аннан соң ул Баймурзин язмаларын ислам дине белгеченә дә күрсәтеп өлгерде, «Ләә иләһә илләллаһү»ны яхшы белсә дә, «Әлиф. Ләм. Мим.», кызганычка каршы, аңа таныш түгел иде. Тик имамга бу язманы ник күрсәткәненә бик үкенде, шуңа күрә, бәхетенә каршы, алдан ни өчен икәнлеген әйтмәгәненә сөенеп бетә алмады. Поп атакайның куркырлыгы да бар иде шул: 1994 елда галәмгә очкан казакъ космоновты Тәлгать Мусабаев, карабтан чыккач, ниндидер көтелмәгән хәл булып, чак кына ачык галәмгә очып китмәде, менә-менә һәлак була дигәндә генә ниндидер могҗиза космонавтны әлеге бәладән йолып калган һәм, соңыннан үзе үк раславынча, ошбу гамәл Ходай Тәгалә эше булырга тиеш иде. Мусабаев шуннан соң Коръән-Кәримне өйрәнергә керешеп: «Мин Аллаһка ышанам!» — дип бөтен дөньяга аваз салды. Уен эшмени! Өстәвенә бу Ичкерия халкы шәригать байрагы астына тупланып яткан һәлакәтле, татарлар исә мөстәкыйльлек таләп икән тынгысыз вакытлар иде!

Әлеге вакыйганы тиз генә йомдылар да тынычланган кебек булдылар. Монысының җеп башын чуалту тагын да җиңелрәк: карабның галәмгә очуы план буенча түгел, ул штаттан тыш каралган иде. Әүвәл нигәдер аны НАСАдан бик нык яшерергә теләделәр. Соңыннан хисап төзелде: әлеге очыш булмаган һәм планлаштырылмаган да... Шул рәвешле татар егетенең галәмгә чыкканлыгын татарлар үзләре генә түгел, хәтта дөнья җәмәгатьчелеге дә белми калды...

Рухани Иофов кына тынычлана алмады. Ул көннәрен генә түгел, хәтта төннәрен дә Баймурзин янында үткәрә башлады. Исәбе тәре үптереп, аннан христиан динен кабул иттерү иде. Иофов кулына чын алтыннан коелган алагаем зур тәре тотты. Әгәр «барып чыкмаган» космонавт: «Христиан динен кабул итәм!» — дип рәсми рәвештә белдерсә, аңа тау-тау алтыннар да вәгъдә ителде. Шуңа өстәп ул күктә Христос белән очрашканлыгы хакында сөйләргә тиеш иде. Тик максатына ирешә алмагач, бу эшен ул да ташлады. Баймурзин очу үзәгеннән китеп, берничә ай вакыт узгач кына, поп терсәген тешләргә соң икәнлеген аңлады: Баймурзинны бернигә карамыйча сындырырга, алтын таулар вәгъдә итәргә яисә җитәкчелек тарафыннан шүрләттерергә кирәк булган икән! Шулай да ул Баймурзиннан әлеге вакыйга хакында 7 ел буе беркемгә сөйләмәскә дигән документка кул куйдырттыруга ирешә. Җиде елдан соң сөйләсә сөйләсен шунда! Аңа ул вакытта беркем дә ышанмаячак инде.

Әлбәттә, Байтимер Баймурзин бу хакта берәүгә дә сөйләмәде һәм сөйләргә исәбе дә, теләге дә юк иде. Тик дөнья бит бу. Әлеге хәлләр Байтимернең (аныкын гына түгел!) тормышын янә капылт кына үзгәртеп, айкап ташлар дип кем уйлаган да, кем фаразлаган диген?!

Йа, Аллаһым, бар да синең кодрәтеңдә!..

## Бу юлы җир йотармы?

Бер дә бер көнне тиктомалдан гына Әллүки күленең суы юкка чыкты!.. Шуның артыннан ук авылның үзен дә якын көннәрдә җир йотарга мөмкин дигән шомлы хәбәр таралды...

Бу яклардагы җирнең инде икенче мәртәбә убылып, авыл кадәрле авылны үзенә йотасына ышанмаган кеше булдымы икән, юкмы икән?..

Җир элеккеге Әллүки күленнән шактый ары — авылны чыгып, ярты чакрым ара мари ягына таба киткән төштә убылып, Аллага тапшырдык, кара авызлы төпсез упкын үзенә йотачак ди, имеш!.. Бу хәбәрдән соң, дөресрәге,

бер төн эчендә Әллүки күленен юкка чыкканлыгын үз күзе белән күргәч, ул көннәрдә олысы-кечесе җен-шайтанга каршы дога укыды, исенә төшкән саен, авыз эченнән белгәннәрен кабатлады, иреннәр кыймылдаудан туктап тормады... Ни әйтсән дә, адәм ышанмаслык хәл: бер төн эчендә күл чаклы күл юкка чыксын әле! Анын астында шаулап агып утырган чишмәләр дә, бу хәлгә куркып калгандай, кибеп корыган. Әбелхәят чишмәсе — Әллүки күле ай саен бер мәртәбә кимеп торган чагында гына үзенен Оҗмах суын — Кәүсәр кебек сихәтле тереклек тамчыларын кешеләргә бүләк итүче изге чыганак та челтерәвеннән туктап калган иде...

...Нәкъ шул төнгә каршы Борис Айсинны үтереп, авыл кырыендагы зират коймасы янында үскән куе кычыткан арасына китереп ыргытканнар.

Бу хәл дә Байтамак авылы халкын чалт аяз көнне яшен суккандай итте: анарчы мондый фаҗигане күргән-ишеткән авыл түгел иде ул... Түгел иде!..

Кем? Кемнәр?! Нигә?!!

Ошбу сорауларнын йомгагы турыдан-туры Байтимер Баймурзин буразнасына таба тәгәрәде. Менә берничә ел инде туган ягында агрофирма оештырган Баймурзин моннан берничә көн элек кенә Борисны эштән куып чыгарган иде. Борис шуннан сон өч көн, өч төн ләх булып исереп йөрде дә суга төшкәндәй юкка чыкты. Анарчы ике сүзнең берсендә бар авылга ишетелерлек итеп ул кемнәрнедер ин сонгы сүзләр белән сүкте, янады: «Күрсәтәм әле мин сезгә!!! Адәм актыклары! Ваххабитлар! Бэн Ладен калдыклары! Сталин кирәк сезгә!» — дип җикеренде ул. Тәмам исерүе житкәч, Сталинны чакырды. «Сталин! Кайда син?! Кил әле безнең авылга, ә! Пожалысты! Кил инде!! Өтерменгә олактыр әле шуларны!!!»

Борисның үле гәүдәсен зират коймасы янындагы куе кычыткан арасыннан тол хатын Саниянен чылбырыннан ычкынган Маһмай кушаматлы усал эте табып алды.

Мари авылыннан Байтамакка көтү көтәргә ялланган Кирәмәт шул көнне авылны тагын бер кат шаккатырды:

— Борис абыйны кем үтергәнен мин беләм! — диде ул. Аны шундук, читлекле машинага утыртып, районга алып киттеләр.

Бер килсә килә бит ул! Борһан шул төнне каравылдан кайтып килгәндә, Хөллиевнең ике катлы таш пулаты янында бер таныш шәүлә күргән. Ул шәүлә генә булмыйча, Альберт Хөллиев үзе булып чыккан икән, ди! Теге чакта билгесез кешеләр үтереп ташлаган авылдашлары, «олигарх» Хөлли малае!.. Монысы да адәм ышанырлык хәл түгел иде! Үлгән кеше, капылт терелеп, кабереннән купсын инде! Борһанның бу хәбәренә каршы: «Элек эчеп йөргәннәрең чыга! Ычкынгансың син! Түбәң чалшайган!!!» — диделәр. Әмма... ләкин Борһан бер дә ычкынмаган, капка түбәсе дә, баш түбәсе дә үз урынында, кыскасы, ул үз акылында иде: теге кешенең гәүдә-кыяфәте генә түгел, тавышына тиклем тач Хөллиевнеке иде ләбаса!..

Йә, менә шушы хәлләрдән соң авылны җир йотачак дигән хәбәргә ышанмый кара инде?!.

«Үзең ярлыкый күр төрле бәлаләрдән, йа, Әл-Хааликъ!» — дип җиде көн буена йөзәр мәртәбә кабатлады мәчет картлары. Атна буена йөз тапкыр иман әйтү, дисбе тартканда... сүз шул хакта! ун-дистә мәртәбә Аллаһы Тәгаләнең ошбу гүзәл исемен телгә алсаң, Ходай куркыныч казалардан саклар, ди. Ярдәменә мохтаҗ бәндәләре катына үзенең саклаучы фәрештәләрен җибәрер, ди Җәмил хәзрәт.

— Иннәә лилләһи үә иннәә иләйһи раажигуун. Аллаһүммә ин кәәнә һәзәәл мәйиитү мухсинән фәзид фи ихсәәниһи үә ин кәәнә мусизән фәтәәжәүәз ганһ,

— дип кабатлый һәр намазында Җәмил хәзрәт һәм мәгънәсен дә тәфсир кыла иде. — Әй, Раббым! Без — Аллаһы Тәгаләнекеләр. Сиңа әйләнеп кайтачакбыз. Шушы казаларның савабы әҗерен насыйп итче безгә! Шуларны кичерәсе хакына хәерле куанычлар насыйп ит!..

## Бакча каравылчысы

Байбулат ага пенсиягә чыккач, вакыт-көнне ничек уздырырмын дип борчылган иде. Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына дигәндәй, күңеле тарта торган эш килеп чыкты тагын: Кәрәкәле күл буенда хәзер «Байтамак» агрофирмасының элеккесенә караганда да зуррак алма бакчасы бар. Әйе, алма бакчасы электән — ул колхоз җитәкчесе булып эшләгәндә үк бар иде монда; соңгы елларда ташландык хәлгә килеп, аны инде ботарлап бетерергә өлгергәннәр иде. Кыскасы, Байбулат ага, үзе шаярып әйткәнчә, хәзер шунда «алма директоры». Бакчаны — алмагачларның күбесе электән утыртылган булса да, хуҗасыз торганлыктан, алар кыргыйлана башладылар — яңабаштан диярлек яңартып чыктылар. Карт көч-куәте ташып торган, тынгысыз бер кеше иде «Алма директоры» туган як музеен оештырырга да өлгерә, бакча үстерергә дә җитешә иде.

Мәгълүм ки, Байбулат агада музей оештыру теләге Себер якларын урап кайтканнан соң туды. Алма үстерүне исә ул, Байтимер белән Ходай эше дип, үзенчә шаяртып сөйләшергә ярата. Анын, дөресен генә әйткәндә, музее да улы Байтимер ихтыяры белән төзелә инде. Әүвәл исемен «Татар тарихы» музее дип атамакчы иде. Музей чаклы музейның бар мәгънә-асылын үз эченә сыйдырып бетерә алмый кебек. Башта ул моны күңеле белән сиземләде, әлеге фикер-хис тәмам әзер булгач кына, акыл шәрәфләренә килеп җитте: музейның исеме башкача булырга тиеш! Бәхеткә күрә, андый исем табылды тагын. Менә исә Байбулат аганың алма бакчасы «директоры» булуы ярдәм итте бугай: әлеге башлангыч «Алма музее» дигән атама алды! Әлбәттә, ошбу исемгә каршы килүчеләр баштарак күп булды. Аны авылда Камай атлы якташы белән читтән килеп урнашып, күрше Ябалак авылында тарих дәресләре укыткан (Байтимер аны мәктәпкә җитәкче итеп куярга да уйлый) Хәким тарихчы гына яклап чыкты. «Бу «Алма музее» булачак! — диде Баймурзин, ахыргы сүз барыбер аныкы иде. — Алмага музей ачабыз! Адәм балаларының Җирдәге тормышы алмадан башлана. Бу Ходай китабында әйтелгән! Шунысын да искәртергә кирәктер: Байтимернең «Ходай китабы» дип сөйләнүе, әлбәттә, беренче нәүбәттә атасы Байбулат агага ошап бетмәде. Ул төчелекне өнәми, әти кеше буларак, атеистик тәрбия алып үскән малаенын күңеле белән күкнең ничәнче катында икәнлеген дә белә ләбаса... Мәктәп балаларны «Дин — әфьюн! Алла юк!» дип өйрәтте. Байтимер очучылар мәктәбендә укыганда да әлеге тәрбия һәм гыйлем сәясәте артларыннан тагылып йөрде. Байбулат ага үзе дә коммунист. Партиягә кермәсә, аны берәү дә колхоз рәисе итеп куймый иде. Дөрес, әбисенең оныгына яшьтән үк догалар өйрәткәнен ул хәтерли, Байтимернең хәтере үткен булып, әбисе белгән дога-әфтиякләрне малай шунда ук эләктереп ала. Хәтта кечкенә вакытта бермәл: «Мин, зур үскәч, мулла булам!» — дип тә йөрде. «Улым, нишләп мулла булырга уйладың әле?» — дип шаяртып сорагач, Байтимер чатнатып: «Чөнки мулла бабай көн саен авылдагы иң биек урынга менә!» — дип балаларча җавап бирә торган иде. Ул вакытта тирә-юньдәге авылларның берсендә дә мәчет калмаган, теге елларда аларның барысының да диярлек манараларын кисеп чыкканнар, ә менә күршедәге Айбаш авылында һәм Байтамакта мәчетләр әлеге афәттән исән-сау котылып калганнар. Айбашта ул заманда хәзерге кебек җомга

намазларына йөрмәделәр бугай, ә менә Байтамакта мәчет беркайчан да «эштән» туктамады дисән дә була торгандыр. Дөрес, ул элегрәк колхозның суган складьы булып та хезмәт итте, соңрак аны, чүп-чардан аралап, юып, чистартып, колхозга төзелеш отряды белән килгән студент халкына торак урын да әмәлләделәр, тик соңыннан барыбер мәчет булып кала алды. Моның исә бик гыйбрәтле, үзен генә дә китап итеп язарлык могҗиза белән тулы кызыклы тарихы бар. Хрущёв хакимлек иткән чордагы «сәяси «яз» вакытында авылга Себер якларыннан элеккеге мулла малае Габдулла (халык телендәге исеме «Апуш») кайтып төшә. Шул Апуш үз беллеге һәм үз көче белән диярлек (төнлә ана кайбер авылдашлар да булыша!) манарасы киселмичә исән-имин калган Байтамак мәчетен чистартып чыгара һәм бер җомгада бөтен авылга ишетелерлек итеп (аның үзе белән алып кайткан тавыш көчәйткеч торбасы да булган дип сөйләделәр!) азан әйтә! Тыштан караганда гына Ходай Тәгаләне тану юлыннан читләшкән авыл әүвәл шаккатып, аннары елый-елый тыңлый бу азанны! Апуш мөәзин азанны әйтеп бетергәч, ул вакытта бердәнбер ябылмыйча калган Казандагы Мәрҗани мәчетендәге кебек вәгазь сөйләр дип көтәләр. Тик Апуш мөәзин вәгазь сөйләми, бөтен авылга яңгыратып, матур тавышы белән көйли-көйли, авыл халкына саулык, бәхет тели, дөресрәге, Ходайдан сорый. Авыл өстенә якты бер нур белән иман иңгәндәй була, күңелләр шатлык белән тула, хәтта кинәт кенә исә башлаган җил дә авыл өстенә таба шуышкан кургашын кебек болытларны кире якка кугандай була. Иң ахырда Апуш мөәзин, үзалдына сөйләнгәндәй генә, ошбу сүзләрне әйтә: «Колхоз председателе Баймурзинның тиздән ир баласы туачак, Байтимер атлы бу ир бала дөньяга якты нур белән киләчәк, бу бала, илаһи Күк баласы, Ходай Тәгалә баскычының иң югары катына менәр! Партком секретаре Аблаевның хатыны, печән өсте тәмамлангач та, корсакка узачак һәм дөньяга сау-сәламәт бала китерәчәк!» (Шуннан соң озак кына пауза булып тора.) Һәм монысын әйтим микән, юк микән дигәндәй генә сүзен болай тәмамлый: «Минем мәчеттә азан әйткәнне Байтамакның өч кешесе, кача-поса барып, райүзәккә җиткерерләр, райком секретаре Мостаев, җыелыш җыеп, тиз арада колхоз председателе белән партком секретарен партиядән чыгарттырачак! Һәм ошбу вакыйгадан соң нәкъ атна-ун көн булды дигәндә, райком секретаре Мостаев бу эшенә бик каты үкенәчәк! Мостаевның тәүбәгә килгәнен күкләрдә күреп торган Аллаһы Тәгалә аны гафу итәр! Киләчәктә мине мәчет манарасына менеп азан әйтүдән тыячак яки шул уй белән яшәгән Адәм пәйгамбәр балаларын үзең хөкем итәрсең, йа, Раббым! Калганы өчен мине җаваплы итмә, Ходаем! Сина каршы булган гамәлләре өчен Синең каршыңда бәгъзе адәмнәрең җавап бирсен! Аллаһы Әкбәр!»

Күп еллардан соң күккә ашачак, соңрак Җир йотачак авылны шул вакытта яшен суккан кебек була! Икенче көнне таң атканда, авылның хәтта әтәчләре дә кычкырмый, тавыклар капылт кына күкәй салудан туктый, сыерларның җиленнәре бушап кала. Ә халык нишли? Нишләсен — афәт йә могҗиза көтә!..

Бу вакыйга Байбулат Баймурзинның башына имән күсәк белән китереп суккандай итте. Апуш белән тиз арада берәр нәрсә хәл кылырга кирәк иде. Ул аны, гадәттәгечә, идарәгә чакыртып тормады, үзе барды. Тегесе, ул килгәндә, намаз укып маташа иде, гайрәтләнеп, шартлар дәрәҗәгә җитешеп килгән председатель, аның намазда утырганын күргәч, кинәт туктап калды, тункайган Апушны кирза итеге белән тибеп җибәрүдән аны ниндидер көч саклап калды шул чакта. Ул намаз беткәнен түземсезләнеп көтә башлады. Ни гаҗәп: шул кыска гына вакыт эчендә ярсулы председатель берчак тынычланырга да өлгергән, алай гына да түгел, чыраена нур да кунган кебек иде.

— Беләм, Байбулат туган, беләм! Тик ашыкма, ярсыма әле син, җәме! Мине тыңла. Борчылма, сиңа чуртым да булмаячак! Мостаевның малае, авариягә эләгеп, исән-сау калган дип ишеттем?

Ул җикеренәсе урынга бу Апушы, мулла калдыгы, аннан сорау алып маташа түгелме соң? Тик барыбер тыныч иде әле Байбулат председатель.

— Шуннан?!

— Шуннан шул: ул бала хәтерен югалткан дип ишеттем. Ата-анасын да танымый икән.

Баймурзин бу чаклысын гына үзе дә белә. Җыелыштан соң «беренче» Байбулатка әлеге кайгысы хакында күз яшьләре белән сөйләде. Нәкъ аны алып калып, кайгы уртаклашканына Баймурзин ул чакта бер дә аптырамады, чөнки ул райондагы иң алдынгы колхозның гаярь җитәкчесе, «беренче» белән алар дус-тату яшиләр иде.

Апуш сандык артыннан су тутырылган бер шешә алып, Баймурзинга сузды: «Менә бу чишмә суын Мостаевка илтеп бир әле! Кашыклап малаена эчерсеннәр. Аш кашыгы белән түлке. Атна-ун көннән соң бала ата-анасын таный башлаячак, Алла рәхмәте белән...»

Баймурзин бу юлы тагын да гаҗәпләнебрәк калды, һәм әлеге халәте аның ачуын тагын да көчәйтте:

— Нишләп мин синең бу әкиятеңә ышанырга тиеш ди әле?!

Апуш дәшмәде. Өстәл өстендәге ашъяулыкны кырыйга куеп, аннан агач кашык алды, ул кашыкка баягы шешәдән чак кына су тамызды һәм: «Мә, эч! — дип Баймурзинга сузды. — Теш сызлавыңны момент басачак!» Чынлап та, Байбулатның төне буе теше сызлап чыккан иде! «Кайдан белә мәлгунь бу турыда», — дип уйлады председатель. Тик ул, иртән көзгегә дә карарга вакыты булмаганлыктан, сызлаган теш турысындагы сул як яңагының шешеп чыкканлыгын тоймаган, сизмәгән иде. «Курыкма. Эч! Курыксаң, башта үзем эчеп куям!» — дип, Апуш җәһәт кенә аның кулындагы кашыкны алды да суны үзе эчте. Аннары теге шешәдән кашыкка тагын су салып, Баймурзинга сузды. Эчте Байбулат суны һәм шул мизгел эчендә үк сыкрап торган тешенең сызлавы да басылды.

Апуш:

—Дөресен әйтәм, мин шаяртмыйм! Илтеп бир бу суны Мостаевка! Әгәр дә мәгәр сүзем ялган була икән, Мостаевыгыз мине Себер җибәрсен! Әтине җибәргән кебек!

Бу сүзләргә каршы Баймурзин берни дә әйтә алмады, шешәне алып, урамга чыгып китте. Байбулат ага әле дә хәтерли: шундук, шешәне тотып, райүзәккә китте ул, «беренче»нең өйдә юклыгын чамалап, туп-туры шуларга барды. Баласы хакына дөньядагы мөмкин булган бар нәрсәне эшләргә әзер әни кеше, әлбәттә, суны шундук малаена кашыклап эчерергә керешә. Ике атна буена диярлек ире бу хакта бернәрсә белмәде. Көннәрдән бер көнне алар гаиләсенә могҗиза иңде: малай таң белән торып эшкә китәргә әзерләнгән әтисе янына килеп: «Әти, мин дә синең белән эшкә барыйм әле!» — дип аваз салды. Малаеның хәтере уянганын күргән Мостаев лып итеп идәнгә утырды, аннары, беркавым шулай тынсыз-өнсез торганнан соң: «Улым!» — дип кычкырып, аны кочагына алды. Ул таңда Мостаевлар яшәгән өй түбәсе кубып күккә ашты. Ачык түшәмле өй эченә иртәнге кояш нурлары кереп тулды, ата белән ана бу мизгелләрдә җирдә яшәмиләр дә кебек. Алар йөзәләр, алар кояш нурлары белән тулган күктә йөзәләр иде!

Ул тиз генә хатынына малайны киендерергә боерды. Барлык таләп-шартларга каршы килүгә карамастан, баланы үзе белән эшкә алып китте! Ул көнне алар

райком бюросында Казаннан килгән иптәшләр катнашында Баймурзинны партиядән чыгару хакында карар кабул итәргә тиешләр. Партиядән чыгару турыдан-туры эштән азат итүне дә аңлата иде.

Ул көнне бюроның «мунча ташы» каты кызды. Байбулат ага аны хәзер хәтерләми дә. Кем нәрсә әйткән, кем аны ни дип гаепләгән — исендә-хәтерендә булыр иде, ләкин ул җыелышта күңеле, уйлары белән катнашмады да диярлек, ниндидер сәер халәт биләп алган иде яшь председательнең эчен-тышын ул вакытта. Чөнки кабул итү бүлмәсендә ул «беренче» малаен танып, Апуш мөәзин әйткәннәрнең дөреслеккә чыгуын күргән иде һәм шул аптырау галәмәтләрдән һаман арына алмады. Җыелыш беткәч, атылып диярлек авылга кайтып китте, машинасын башка чакта ишегалдына — капка эченә кертеп куя иде, бу юлы урамда гына калдырып, бәрелә-сугыла өенә керде дә, шкафтан башланмаган «чикүшкә» алып, тустаган-мазарга салып тормыйча авызыннан гына эчеп тә бетерде. Аның монарчы аракы дигән нәрсәгә телен дә тидереп караганы юк иде, хәзер ул исерү халәтенең килгәнен көтте. Тик шыр аек килеш калды. Берзаман үтереп йокы басты, һәм ул чоландагы такта сәкегә ауды. Бөтен гаиләне генә түгел, колхозны шаккаттырып, Баймурзин ул көнне кичкә чаклы уянмыйча йоклады. Авылга: «Безнең персине эштән алганнар, мулла малаен кире Себеренә озаталар икән!» — дигән хәбәр үзеннән алда кайтып житсә дә, иртәгә ни буласын да, ничек тормыш итәчәге хакында да уйламады Баймурзин. Уянып киткәндә, үтереп башы авырта иде. Сәке янәшәсендәге артсыз урындыкка кемдер бер шешә су китереп куйган. Үрелеп кенә шул шешәне алды да бер сулышта эчеп тә бетерде. Гаҗәп һәм шаккатмалы хәл булды бу: баш авырту шундук юкка чыкты, әйтерсең, кемдер дымлы тастымал белән сөртеп алды баш авыртуны!!! Һәм, киләчәк язмышы хакында уйлана башлап, корт керергә тиешле күңеле тыныч, бик тыныч иде. Гүя бүген райком бюросы утырышы булмаган да, менә хәзер ул кичке нәрәт бирергә идарәгә барырга тиеш!..

Идарәгә барды ул кичне Баймурзин, ләкин үзе генә түгел, Мостаев шәхсән өенә килеп, үз машинасына утыртып алып барды. «Беренче» көне буе Казанда йөреп, күрәсе кешеләрен күреп, керәсе танышларына кереп, иртән бюро карары белән партиядән һәм эштән чыгарылып ташланган Баймурзинга булган «чин»нарын кире кайтаруны кайгырткан икән! Рәхмәт төшкере, үз максатына ирешкән иде Габдерәхим Мостаев дигән партия райкомының беренче секретаре!..

...Җиденче дистәне ваклаган Байбулат аганың фикер «алмасы» хатирәләр бакчасы буйлап әнә кайларга таба тәгәрәп китте! «Әллүки» күле кимегән чагында гына күренеп ала торган Әбелхәят чишмәсенең суы, чыннан да, зур сихәткә ия икән шул!!! Дөньяда су хәтереннән дә зуррак хәтер юк!.. Су хәтерендә дөнья яралганнан башлап бүгенге көнгә чаклы, хәтта киләчәктә ни буласы хакындагы мәгълүматлар да салынган. «Әллүки»дәге Әбелхәят чишмәсенең серен ил галимнәре генә түгел, дөнья галимнәре дә менә утыз елдан артык өйрәнәләр һәм әле һаман да очына чыгып житә алганнары юк. Һәр фәнни-тикшеренү нәтиҗәләрен галимнәр соңыннан ак кәгазьгә төшерәләр. Алма бакчасы гөрләп үсеп утыра, «Алма музее» да инде ишекләрен ачып, кызыксынучыларны кабул итә башлады. «Мина, мөгаен, мич башына менәргә дә вакыт житкәндер», — дип уйлады Байбулат карт шаулап чәчәктә утырган алмагачлар янындагы бер сәер алмагачның шәрә кәүсәсенә карап. Майның унбишләрендә йөздән артык төрле алмагачның һәрберсе шаулап чәчәк ата, ә бу агач исә июнь башында, Сабантуй алдыннан гына чәчәккә бөреләнә һәм аның әле бер дә алма биреп караганы юк. Алмагач, гадәттә, бер елны җимеш бирсә, киләсе елда ял итә. Ә бу алмагач һаман ялда. Ә чәчәккә нигә бөреләнә дә Сабантуй вакытында гына ни сәбәпле

чәчәк ата соң бу сәер алмагач кисәге?! Әллә бу да аның малае Байтимер кебек үз вакытында чәчәк атмаска «подписка» биргәнме!!! Улы бу хакта берничә елдан соң гына сөйләде. Юкса әтисенә теге чакта ук серне чишкән булса да яраган лабаса! Ата үз баласын сатсын димени инде?! Үзе теләп ФСБ капкынына илтеп тыксынмыни? Имеш, кул куйган, серне чишмәскә «подписка» биргән...

Йа, Әл-Варис, үзең сакла!..

## Яшь алмагач ботагы кебек нечкә ай...

— Әгәр бабаңның алтыннарын тапмаган булсаң, авылда калмый идең инде син, улым. Нишлисең җирдә, кесәң такыр килеш?

— Белмим, әти, белмим. Может, калган да булыр идем.

Байтимер шулай диде дә беравык тынсыз торды. Ул эченнән генә әтигә сөйләргә микән теге хәлне, юкмы дип уйлана һәм әле һаман ныклы гына бер фикергә килеп бетә алмый иде. Сөйләсәң дә ышанмас! Бәлки, ышаныр? Ни дисәң дә әти бит. Ул аның юк-бар сүз сөйләмәячәгенә, әлбәттә, ышаначак. Яшь вакытта ук хәтерли: Апуш мулла белән якын дуслар иде бит алар. Әнә, Борис абый малае Варисны Гарәбстанга ук җибәреп укытырга акчасын тапкан. Ә үзе Казанга китеп барган Мәхмүт хәзрәт урынына Байтамак мәхәлләсенә имам итеп Варисны түгел, Апуш мулланың оныгы Җәмилне билгеләттергән. Аңламассың бу картны!

— Җәмил хәзрәт бик акыллы, җайлы, гыйлемле кешегә охшаган. Сиңа күктә очраган галәмәт ни булды икәнлеген аннан сорап карыйммы әллә?

— Әти, әйттем бит инде, ике ел вакыт бар әле минем. Сиңа алданрак сөйләдем. Ачуланма, әти, алма бакчасына син алган яңа каравылчыны күрмәсәм, бәлкем, әлегә сөйләми дә торган булыр идем. Ни исемле дисең әле син аны?

Кинәт бирелгән бу сорау Байбулат аганы каушатып җибәрде, чөнки яңа каравылчының исемен хәтерләми ул. Әллә белеп онытты, әллә чынлап та белми.

— Тел очында гына тора инде менә.

— Әти, аңладым. Исемен дә белмисең син аның! Бер белмәгән кешене каравылчы итеп алгансың!

— Беләм! Ник белмәскә?! Мин ул кешене әллә кайчаннан ук беләм шикелле инде менә!

— Шикелле булгач, әйбәт инде ул...

— Ярый, тынычлан әле, белмәсәм, оныткаммындыр гына. Сорармын үзеннән, бүген үк.

Әтисенең борчыла башлаганын күреп, Байтимер аны тынычландырырга ашыкты:

— Ярар инде, әти, борчылма юк-барга. Менә бу Галин дигән кеше белән нишләргә диген син? Әллүки күле шуның аркасында гына юкка чыкты, диләр... Гаҗәп! Мона ышанасы да килми, әлбәттә. Ышанып була торган хәл түгел! Элек акчалылар әйбәт җирләрне, күлләрне сатып кына ала торганнар иде. Бу акча да чыгарып тормаган! Безнең Тәбәнәк тау урманына да кызыга икән. Приватизациялим, дип әйтә икән ди.

Карт ризасыз рәвештә Байтимергә күтәрелеп карады.

— Нишләп «ди» дип утырасың әле син! Күл хәтле күл җир астына убылып төшеп китте. Хәзер урман дип йөри, дисең. Нишләп аны үзең барып белешмисең?! Син бит ул тирәдә...

— Әйе, әти, авыл кешеләренә бүлеп биреп, фермер хуҗалыклары оештырам дигән идем! Шуннан ни?! Әле аэродром төзергә дә исәп юк түгел иде. Бәхти

әнә атлар фермасы ачарга да хыяллана. Тик Камышлыда эшләре бармый әле аның.

— Минемчә, Әллүки күле кире кайтыр, бәлкем. Камай да шулай дип сөйләп йөри икән. Бәлки, анда шифаханә кебек, үз кешеләребез өчен генә инде, берәр дәвалау пункты ачаргадыр?

— Әти, анда бүген бер нәрсә дә ачып булмый әле. Ул жиргә, әнә, хуҗа табылырга тора. Зур түрә. Ул кешенең теләсә кайда сүзе үтә. Аннан соң, әти, пожалысты, шул җүләр Камай сүзен сөйләп йөрмәгез инде, ә! Кеше көлдереп!

— Ышандырып сөйли бит ул, шайтан малай!

— Әйе! Ышанган ди берәү аңа! Әнә, киленең Нурбикә кебек хыялыйлар ышаналар! Хәзер икесе дә күлнең кире кайтканын көтеп йөриләр.

Байбулат ага дәшмәде.

— Син әйт әле миңа: Кабык күле буендагы урманны, мин әйтәм, әллә төпләп атасы инде? Урман димәсәң, хәтере калыр. Безнең бит Әбиләр сазлыгы буенда, әнә, нинди яшь яңа урман күтәрелеп килә. Тәбәнәк тау урманы да безнеке әле хәзергә.

— Әбиләр сазлыгының аргы ягында Камай күптән Сабантуй мәйданы ясап куйган икән инде. Шулай дип ишеттем.

Байтимер тагын бер тапкыр әтисе авызыннан Камай сүзен ишеткәч, бу юлы ачуланып тормады, бары көлемсерәп кенә куйды.

— Ул Камаегыз кичә минем янга да кереп утырды. Нәрсә ди, син дәүләт төзеп маташасың. Бар эшең дә уң бара. Тик дәүләтеңнең нигезе бар, стенасы бар, түбәсе генә тишек әлегә, ди. Нинди түбә турында сөйлисең, дим? Дәшми. Барыбер түбәгез, юк сезнең, ди. Һаман үзенекен тукуын белә. Рәсәегезнең дә түбәсе тишек, шуңа күрә ачык түбәдән кар-яңгыр кереп утыра, берзаман ул су фундаментыгызны чылатып, нигезегез дә ишеләчәк әле, ди. Нәрсә әйтәсең аңа, малайның үз түбәсе киткән вакыт булгандыр инде.

— Миңа да сөйләп китте ул боларны, алма бакчасына килеп. Теге яңа каравылчы белән бергә идек. Ул да тыңлады. Соңыннан, бу баланы ошаттым мин, диде. Кай җирен ошаткандыр? Матур итеп сөйли белүендерме?

Шулчак капкадан, атылып-бәрелеп, корсагы борынына житкән Нурбикә килеп керде. Ул, капкасын да ябарга онытып, ишегалдына узды һәм бусага төбендә Байтимер белән каенатасын бергә күреп, әүвәл шатлангандай итте, аннары, сулышына каба-каба, аларга яман хәбәр житкерде: «Борис абыйның үле гәүдәсен тапканнар! Зират буендагы кычытканлыкта!» Байтимер, хатынының болай атылып-бәрелеп йөрүен күргәч: «Нигә үзеңне сакламыйсың?» — дип ачуланырга теләде, ләкин ачкан авызы шул килеш калды.

Әлеге хәбәр икесен дә яшен суккандай итте. Байбулат ага, аптырап, малаена карады.

— Юк, әти, мин аны эшкә кире алган идем инде. Дөресрәге, айны да кил, гариза яз, кире элеккеге эшеңә урнашырсың, дидем. Хәтта элеккеге урынга да түгел... Тагын да зуррак эшкә. Теге олигархны кем диден әле син, фамилиясе, дим? Әйе, Галин. Аның янына барырга тиеш иде ул! Әллә, әллә, шул бандитлар... — Байтимернең сүзе капылт өзелеп калды, буенда бала йөрткән хатыны янында бу хакта сөйләшәсе килмәде бугай.

Шул кичне Байтимер Баймурзинны, Казанга алып китеп, вакытлы изоляторга ябып куйдылар... «Әллә Борисның үлемендә мине гаепliләр инде! Аңламассын», —дип уйлады Баймурзин. Баксаң, аны башка нәрсәдә гаепliләр икән, һәм сорау алуны да полиция оештырмады... Ләкин эшләр ул уйлаганча ук гади генә түгел икән. Төн уртасында Баймурзинны Түбән Новгородка ук

алып киттеләр. Аның соравына каршы бары бер генә сүз белән: «Коррупциягә каршы көрәш акциясе», — диде сары мыеклы капитан. «Кара боларны, эшләргә дә ирек бирмиләр бит!» — дип көрсенде Байтимер, аның җавабын ишеткәч.

Борис сүзен дәлил итеп, үзенә зур һәм нахак гаеп ягачакларын белми иде әле Баймурзин. Үз хәле хәл булса да, ул, бик борчылып Борис хакында уйлана һәм бу коточкыч хәлгә аның тамчы да ышанасы килми иде. Кемгә кирәк булды икән соң Айсинның үлеме? Бер гөнаһсыз кеше иде ләбаса ул! Әйе, Байтамак бистәсен оештырып йөргәндә, Байтимернең уң кулы буларак, күпләр белән ачуланышырга да туры килгәндер? Кайбер кешеләрне үпкәләткәндер дә? Тик... тик шул рәвешле, зират буенда сарык урынына суеп атарлык ни яманлык кылган соң ул?! Борисмы? Юк, Борис бернинди яманлык та кыла торган кеше түгел иде. Туры сүзле кеше, дөресен әйтә, каты әйтә торган иде. Ләкин аның туры сүзләре Байтимергә башкаларга караганда күбрәк эләгә иде. Алар пыр тузып бәхәсләшә, тик әлеге бәхәснең ахыры, кайсы якның җиңүе белән тәмамланса да, яхшы бетә, алар уртак фикергә киләләр, туганнар кебек кочаклашып, янә эшкә керешәләр иде.

Байтимер ирексездән авыз эченнән генә белгән догаларын укырга кереште. Һәм аннары: «Әлиф. Ләм. Мим», — дип куйды. Әлиф. Ләм. Мим. Теге чакта кемдер бу сүзләрне колагына пышылдады түгелме? Хәер, пышылдап әйтмәде бит: ошбу сүзләрдән барча галәм янгырап торды сыман... Әлеге сүзләрнең мәгънәсен Байтимергә Мәхмүт хәзрәт төшендереп бирде. Кара, безнең Җәмил мулла белә микән бу сүзләрнең ни аңлатканын? «Бәкара» сүрәсендәге беренче аять, әлеге сүзләрне моңарчы берәүнең дә төшендереп бирә алганы юк әле», — диде Мәхмүт хәзрәт. Шулчак кылт итеп Байтимернең фикеренә балачак хатирәсе килеп кунды: «Ләм-мим...» Мин дәшмәячәкмен... мин бер сүз дә әйтмәячәкмен... бу икебезнең арабызда сер булып калачак. Мин «ләм-мим». «Ләм-мим» мин, яме, борчылма!.. Бу бит алар авылындагы, әйе, әйе, авыл кешеләре сөйләшә торган гап-гади сүз, ләкин нинди дә булса зур серне саклый торган яки саклау сүзе: Ләм-мим. Бер сүз дә әйтмәячәкмен. Серне чишмәячәкмен... Баксаң, Ходай Тәгаләнең бердәнбер серле аяте икән ләбаса!»

Камерада пыскып янган ут бүлмәнең болай да шыксыз диварларын тагын да шөкәтсезләндергән. Байтимер күзен йомды. Әнә, иксез-чиксез галәм, биниһая күп һәм гаҗәп гүзәл утлар арасында Җир күренә. Нинди кечкенә ул, уенчык туп сыман гына! Ә шунда хәзерге минутларда нинди генә хәлләр булып ятмый торгандыр! Нәрсәгә, ни өчен, нәрсә хакына? Югыйсә галәм күзлегеннән караганда, кырмыска оясы кебек кенә бит! Хәзер анда, төрле почмакларында, хәтәр сугышлар бара торгандыр, кырмыскалар сугыша, кырмыскалар яши, яратышалар; Җир планетасының берәр ягын карангылык пәрдәсе каплауга, йөз меңнәрчә гашыйклар күккә күтәрелеп карап, үз йолдызларын эзләрләр, ул йолдызларга багып, вәгъдәләр бирешерләр. Нинди вәгъдәләр? Нинди хәят бу Җир шары өстендә?! Әйтерсең, гаҗәеп гравитация көче кырмыскаларны үз тәненә сыланган балга ябыштырып куйган, кырмыска-адәмнәр шул бал сазлыгы эчендә. Бал сазлыгы аларның инде күптән эчләрен пошыра, аларның нәҗес сазлыгына чумасылары килә... Юк, юк, болай гына уйлый бу хакта Байтимер, болай гына. Җир галәмнән көлке булып күренә. Әгәр мона алдан әзерләнмәгән булсаң, галәмгә чыккан һәр кеше җиргә карап кычкырып-кычкырып, шаркылдап-шаркылдап көләр иде!!! Үз-үзеннән көләр иде ул! Үзенең бик бәләкәй икәнлеген тоеп көләр иде. Һәм Җирдәге тормыш хакында шул мизгелдә үк аның карашы, фикере төбе-тамырыннан үзгәрер иде!.. Әнә, Кояш Җирне җылыта, карангылык пәрдәсе каплаган урыннарын ай шул ук кояштан алган нурлары белән яктыртып тора. Җир әйләнә, Җир галәмнең футбол

кырында оча, оча-оча яши, әйләнә-туглана, шул рәвешчә хәят итә!.. Жирдәге һәр адәм баласын да галәмгә алып чыгасы иде дә жиргә төртеп күрсәтәсе иде! Баштарак ышанмыйча торырлар! Мөселман өммәтеннән булса, шаклар катып, аптырап, гажәпләнеп һәм, әлбәттә, чарасызлыктан, үзенең көчсезлеген тойганнан соң: «Ләә иләһә илләллаһү!» — дияр иде, башка дин нурлары аша Аллаһына табынучы булса, бүтән сүзләрне кабатлар иде. Тик алар нинди генә сүзләр булса да, Ходайның бөеклегенә, аның илаһи көченә соклану булыр иде бу. Аннан соң Жирдә кылган яман гамәлләре исенә төшкән очракта, үзен кирәксез, мәгънәсез бөжәк белән чагыштырып карап, тагын бер мәртәбә: «Йа, Аллам!» — дияр иде.

Байтимер хәзер дә үзен монда алып килгән бәндәләрне: «Эш калдырып йөрисез!» — дип эченнән генә сүксә дә (хактыр ки, Галәмдә булганнан соң да, бигрәк тә соңгы арада Байтимер Баймурзин үзенең әлеге халәтенә шулчаклы вак нәрсә дип карый иде ки, аны монда алып килгән погонлы халыкның тынычлыгын бозуларына гына аптырый). Байтимер аптырашта иде бу көннәрдә. Алма бакчасындагы яна каравылчыны күргәннән бирле...

***

Каравылчы гаять озын буйлы, киң җилкәле бер адәм. Ул күп сөйләшми, хәтта сорау биреп сүз катмасаң, бөтенләй эндәшми. Байтимерне кулга алганнан соң, үзенә урын тапмаган Байбулат ага алма бакчасына килде. Монда ничектер тыныч ана. Юлда килгәндә исенә төште: әлеге адәмнең исеме Сәхабәме, Сәхабиме иде. Сәхаби... кызык исем... сәер исем... Бәлки, ана атасы «Сәхап» дип кушарга теләгәндер дә, авыл советындагы надан секретарь ялгыш «Сәхаби» дип язып куйгандыр? Борисның исеме кебек. Юкса ана атасы «Варис», ягъни дәвамчыны аңлаткан мәгънәле ат кушарга теләгән, ләкин авыл советы секретаре, әлифне таяктан көчкә аерган Бибиәсма апа, «В» белән «Б»ны буталтырганнан соң, теге гомерлеккә «Борис» булып йөрде. Йөрде... Байбулат аганың йөрәге дерт итеп куйды. Жаны кайный, эчендә әллә нинди мәчеләр тырнаша, күңеле дөрес дулкында түгел Байбулат аганың. Әйе, тынычлык эзләп килде ул алма бакчасына.

Алма бакчасын яңарту Байтимер фикере иде. Әле дә хәтерли Байбулат ага: бакчаны утыртыр алдыннан Байтимер ничек ялкынланып сөйләгән иде. «Жир өстенең 5 миллион гектар жирен алма бакчалары алып тора, — диде ул жыелган халыкка карап. — Хәтерлим: элек бар иде безнең колхозның алма бакчасы. Житмеш тугызынчы елгы салкыннар вакытында алар өшеп беттеләр. Без алманың нинди файдалы жимеш икәнлеген беләбез. Шуңа күрә кибеттән дә гел алма сатып алырга тырышабыз. Ләкин нинди алма сатып алганлыгыбызны гына белмибез. Һәм нигә аны хәләл акчага сатып алырга тиеш ди әле без! Үзебездә үсә торган жимеш ләбаса ул! Һәммәбезнең хәләл ризык ашыйсы килә. Хәләл ризык ул, беренче чиратта, бисмиллалы. Димәк, чиста ризык. Тик экологик яктан чисталыгын аның кем тикшергән?! Химия заманында яшибез. Беләбез бит: казылык-колбасаны гына түгел, хәзер ипине дә кәгазьдән әвәләргә өйрәнделәр! Ул жиләк-жимеш, карбыз-кавыннар тизрәк өлгерсен дип нинди генә химикатлар кушмый торганнардыр! Шулар исәбендә алма да бар. Без бит алманы гына түгел, хәзер карбызны, йөземне дә үзебез үстерә алабыз. Үзебез үстергән ризык чынлап та хәләл булачак! Хәләл булу, димәк, беренче чиратта, ризыкның экология ягыннан чиста булуы түгелме соң? Без аларны балаларыбызга бирәбез, ул жимешләрне имчәк балалары булган әниләр ашый. Газиз балаларыбызга хәләл ризык ашатырга теләүче кешеләр бармы арагызда? Бар! Беләм! Ә каршылар юкмы андый-мондый? Юк! Рәхмәт! Хәзер, авылдашлар, бисмиллаларыбызны әйтеп, эшкә тотыныйк. Хәерле сәгатьтә!»

Менә шулай елга буенда алма бакчасы, йөзем һәм карбыз үсә торган бакчалар булдырылды. Алма бакчасы аңлашылсын да, ди. Әмма йөзем һәм карбыз үсәсенә әүвәл көлеп кенә карадылар. Тик апрель аенда ук утыртылган карбызның уртача шалкан зурлыгында житешкәнен күргәч, бар да тел шартлатты! Ә йөзем уңышын кибеттә сатуга ук куйдылар!..

Баксаң, зур эшкә тотыныйм дисәң, күп тә кирәкми икән! Байбулат ага, шул турыда уйлый-уйлый, бакча ишеген ачты. Ул бу мизгелдә теләсә нинди хыял дингезенә чумарга әзер, тик күңелне шыксыз уйлар гына биләп алмасын; Байтимере кулга алынганнан соң, ата болай да ярты кеше иде. Байтимер киткәч, ата кеше «зур дөнья» белән элеккеге элемтәләрен инде югалта да башлаган иде югыйсә. Казанның үзендә генә дә аның күпме таныш-белеше, дуслары бар. Заманында ул да төшеп калган житәкче түгел иде, түрәләр белән аралашты, хәтта Мәскәүләргә барып йөрде. Янында Байтимер булгач, хәзер күп вакытын Байтамакта гына уздыра һәм таныш-белеш белән алай еш аралашмый карт. Ләкин ата кешенең улына ярдәм итү теләге шулчаклы зур иде ки, ул янә теге чактагы халәтенә кайтып, дилбегәне үз кулына алырга тырышты. Бу гамәленең исә максаты бер генә: ул да булса Байтимерне бәладән йолып калу. Каравыл өенә керде дә телефонны күтәрде, шалтыратты, сөйләште һәм танышларыннан үзенә кирәкле кешенең телефонын таптырды. Табып бирделәр. Элеккеге райком секретаре Габдерәхим Мостаевның малае хәзер Казанда зур түрә булып эшли иде. Байтимергә, бәлки, ул ярдәм итәр дигән өметле уй-фикер белән аның телефонын жыйды. Фәрит Мостаев теге вакытта Әллүки ярындагы Әбелхәят суы белән яңадан дөньяга туган малай иде. Бар ышанычы шунда иде Байбулат картның! Рәхмәт төшкере, кайлардан исенә килде соң әле авыр вакытта Мостаев малае?! Байбулат аганың күңеле аз гына урынына утырган кебек булды.

Ул, монда кергәндә, үз уй-мәшәкатьләре белән каравылчының юклыгын да абайламаган. «Кайда йөри бу, — дип уйлады Байбулат ага. — Бакчага чыгып киткәндер әле», — дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, тышка чыкты. Кичке күк болытсыз. Алмагачлар ай нурында коена. Ул бакча буйлап ары китте. Ләкин каравылчы Сәхаби монда да күренми. Байбулат ага, адымнарын тизләтеп, кызу-кызу бар бакчаны диярлек әйләнеп чыкты. Каравылчы беркайда юк. «Менә сиңа мә! Бер белмәгән кешене каравылчы итеп эшкә алалар димени!» — дип битәрли-битәрли янә каравыл өе янына килде. Сәхаби югалды, өй янында да күренми, ишекләре шыр ачык. Теләсәң, бөтен бакчасы белән күтәр дә кит!.. Байбулат ага, медер-медер сөйләшкән тавышлар ишетеп, бакча ишеге янына килде.

Сәхаби урам якта, бакча ишеге төбендә үк бер хатын-кыз белән сөйләшеп тора икән. Байбулат ага ишекне ачты да, ут яктысында хатынның йөзен күрергә теләп, алга сузылды. Тавышын таныган иде тануын. Бу аларның авылыннан Сания исемле тол хатын, ут яктысында тәгаен шул икәнлеген күрде. Сания, Байбулат аганы күреп, беркавым каушап калды, тик аның бу халәте озакка сузылмады, ул үзенең яңгыравыклы тавышы белән:

— Байбулат абый, безнең туганны эшкә алганың өчен рәхмәт сиңа! — диде.

— Синең туган? Сәхаби сиңа туган тиямени?

Сәхаби Саниядән узып:

— Мин бар адәм баласына да туган, — дип шаяртты. Тегесенең исә үз жавабы иде:

— Әйе, менә бик озаклап сөйләшеп утырдык. Озата килдем. Байбулат абый, рәхмәт сиңа!

Байбулат ага жавап кайтармады, бары башын гына какты һәм ишекне кире япты. Озак тормастан бакча эченә Сәхаби дә керде. Байбулат ага әүвәл бакчаны

калдырып йөргән өчен каравылчыны сүкмәкче иде, ләкин бу олпат гәүдәле, мөлаем йөзле кешенең бер гаепсез кыяфәт чыгарып, үзенең якты күзләре белән (караңгыда ул аның күзләрен ап-ачык күрде!) ана төбәлеп карап торуын күргәч, ошбу уеннан кире кайтты. Мәҗбүр булды! Әллә кайдан гына килеп чыккан бу адәмне сүгәргә, ана авыр сүз әйтергә теле әйләнмәде. Карале син: әнгер-мәнгер төшүгә карамастан, аның йөзе һаман яктылык чәчә сыман, гөнаһсыз карашы шундук әсир итеп тынычландыра, мәхәббәтле нурлы йөзен күрүгә исә, тел очындагы яман сүзләр үзләреннән үзләре эреп югала. Сәхабинең йөзен ишек өстенә куелган ут яктысы шулай яктырта кебек. Байбулат ага авыз эченнән генә «тәк... тәк... » диде дә ишеккә таба борылды. Алар өй эченә керделәр.

— Байтамакта туганнарың барлыгын әйтмәгән идең? И вообще, мин теге көнне сорамаган идем, сораштырырга вакыт булмаган иде, кайлардан килеп чыктың соң син? Кайсы як кешесе син?

— Мин алмагачлар үстерергә яратам. Хәзер алмагач бакчалары юк бит инде. Ә сездә бар, — дип җавап бирде Сәхаби. Аның сүзләрендә Байбулат агага шундый гүзәл алма бакчасы үстергән өчен рәхмәт сүзләре белән бергә бу алма бакчасына карата соклану да сизелеп тора. Моны тоймый һич мөмкин түгел иде.

— Безнең Рокфеллер алма сатып баеп китте.

Рокфеллерның кем икәнлеген ишетеп тә укып белгән Байбулат ага аның «безнең» дигән сүзенә игътибар итмәде, чөнки ул Рокфеллер фамилияле Америка миллиардерының исеме булырга тиеш иде. Әйтә белмәсән, янкиларның «Бжезинский» фамилиясе дә татарча «безелдәвек», «бөҗәк» кебек ишетелергә мөмкин.

— Җирдәге иң авыр алманың үлчәме бер кило ярымга тартканы бар.

Байбулат ага бу гадәти булмаган каравылчының сәер сүзләренә каршы бер кәлимә дә әйтмәде, бары аны игътибар белән тыңлаган булып кыланды.

— Кытайлар бер елны ярты килодан артыграк алманы ун мең ярым долларга сатып җибәрделәр. Долларга!

«Доллар» сүзен Сәхаби ничектер басым ясап әйтте. Әйтерсең, ул хәзер алма корты хакында сөйләүгә күчте. Байбулат ага яңа каравылчыны бүлдерергә ашыкмады. Тегесенә исә шул гына кирәк иде бугай, ул сүзен дәвам иттерде:

— Элек Яңа ел чыршысын төрле төстәге алмалар белән бизиләр иде. — Сәхаби Байбулат агага күтәрелеп карады. Тегесе дәшмәгәч, тагын сөйли башлады. — Алмагачтан алма төшеп, Ньютонның башын тишкәч кенә, ул гравитация законын ача. Җирнең тарту көчен... Гравитация генә түгел, Җирнең башка тарту көче гаять зур аның... Монысын аның... миннән башка берәү дә белми торгандыр...

Байбулат ага Сәхаби әйткән соңгы сүзләрнең мәгънәсен аңлап җиткермәде, шул хакта сорау бирмәкче иде, каравылчы ана сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп әйтеп куйды:

— Балаларның тарту көче. Син малаең өчен борчылма. Бернинди гаебе юк Байтимернең. Үтерүче ул түгел. Башка гаеп такмасалар инде».

Байбулат ага аның бу сүзләреннән сискәнеп китте:

— Нинди гаеп тагын?!

— Ришвәт бирү, аны алу, шуларны рисвай итү модада бит хәзер. Акча. Тәңкә. Тауар. Башта урлыйлар. Аннары фаш итәләр. Кемнәр кемнәрне фаш итә? Күп урлаган азрак урлаганны фаш итә. Аннан соң беркавым тынычланып торалар. Тагын урлый башлыйлар... Озак урлыйлар. Фаш итүче булмый. Аннары күп урлаучылар, үзләрен фаш итәрләр дип куркып, тагын теге... үзләреннән азрак урлаганнарны тотып ябарга керешәләр...

— Кит булмаганны! Нинди акча ди ул! Акчага исе киткән булса әгәр дә

мәгәр... — диде дә Байбулат ага телен тешләде, бу чаклысын әйтергә ярамый иде бит.

— Бер капчык алтын тәредән дә баш тартты ул, дисеңме?

Байбулат ага бу сәер каравылчының сәер сүзләренә баядан бирле аптырап, гаҗәпләнеп утыра иде, соңгы әйткәне исә аның башына чүкеч белән суккандай итте.

— Как так?! Байтимер үзе сөйләдеме?

— Мин Байтимерне күптән беләм...

Җаваптан Байбулат ага канәгать калды. Югыйсә болай да курку кереп оялаган җаны теләгән җавабын ишетмичә тынычланачак түгел иде. «Байтимерне белүен беләсеңдер... Аны белмәгән кеше юк. Тик шулай да син аны кайдан беләсең, аңлатыбрак сөйлә әле, иптәш каравылчы? «Әлеге уйлар Байбулат аганың үзендә генә калдылар. Башка чак булсамы? Юк! Дөресрәге, әңгәмәдәше бүтән кеше булса, әлбәттә, ул әлеге сораулары белән аның җанын алачак, барысын да энәсеннән җебенә чаклы сөйләтмичә туктамаячак иде. Әмма бу Сәхаби дигән адәм гади әңгәмәдәш түгел; әгәр дә мәгәр ул: «Синең уйларыңны укый алам мин», — дисә дә, Байбулат ага, аның сүзләренә исе китмичә: «Әйе шул, беләсең», дип башын гына кагар кебек иде. Моның шулай икәнлеген ул белмәде һәм белмәячәк тә! Сәхаби дигән бу зат исә белә...

— Паспортың бардыр бит синең? — диде кинәт Байбулат ага. Сәхаби куен кесәсенә тыгылып, аннан ниндидер катыргы чыгарды һәм Байбулат агага сузды. Тик тегесе әлеге катыргыны кулына да алып тормады, бары: «Бар икән». — дип кенә куйды.

Сәхаби, кесәсеннән алма алып, Байбулат агага бирде:

— Авыз ит әле моннан, — диде. Байбулат ага алманы кулына алды һәм ут яктысынарак китерде, бик озаклап әйләндерә-әйләндерә караганнан соң да аның нинди алма икәнлеген белә алмады, шуңа күрә күтәрелеп, янә Сәхабигә бакты:

— Нинди сорт соң бу?

— Анысын белмим. Син аны тешләп кара.

Байбулат ага Сәхабинең әйткәненә шундук буйсынды, алманың бер кырыеннан тешләп алды һәм беркавым тынсыз калды. Әче алма капсаң, үзеннән-үзе йөз сытыла, баллы алма эләксә, аны тешләүгә, авыздан сулар килә, ә бу алманың тәме әче дә, баллы да түгел, ошбу алманың тәмен тел белән әйтеп аңлатып булмый; кабылган кисәк шундук авызда эреп бетте дә аның тәэсире әүвәл авыз эчен рәхәт суытты, аннары җылытты, аннан соң шул алмадан тәненә, гәүдәсенә ниндидер рәхәт дулкын таралды. Күзләре ачылып китте, ул шул ачык күзләре белән үзенә елмаеп карап утырган Сәхабинең ике каш уртасында ниндидер гаҗәеп гүзәл яктылык күргәндәй булды. Аңнары ачылып китте, ирексездән алма тәме йогып калган тел очына «Ләиллаһы...» дигән сүзләр килде. Күңеле ачылды, ике як инбашында кинәт кенә көчле пар канат үсеп чыккандай булды. «Ләиллаһ иллалааһ...» дип кабатлады ул. Акылы бик якты иде. Шул сәбәпле Байбулат ага Сәхабидән: «Мондый алма безнең бакчада үсми бит!» — дип сорарлык көч тапты. «Үсми...» — диде Сәхаби тыныч кына. — Әйдә, аның орлыгын җиргә күмеп карыйк».

Орлыкларны бер буш урынга күмделәр.

Сәхаби, каяндыр алып, каршыдагы диварга дога индерелгән, кысасына алтын йөгертелгән догалык элеп куйды. Һәм үзе үк анда язылган сүзләрне укып күрсәтте: «Без Адәм балаларына ата-анага игелекле булырга васыять иттек. Анасы аны йөрәк астында йөртә. Авырлык белән дөньяга китерә. Баланың ана карынында йөрүе һәм сөт имә торган вакыты утыз айдыр.

Менә ул егетлек чорына житә. Кырык яше тулгач, әйтер: «Йа, Раббым, үземне һәм ата-анамны нигъмәтләндергәненә шөкремне кабул ит. Сине ризалатырлык хәерле гамәлләрдә булу өчен, мина куәт бир. Үземне вә нәселемне рәхмәтеңнән ташлый күрмә. Хактыр ки, мин Сина якынаю юлында. Шөбһәсез ки, мин мөселман булдым». Бу Коръән Кәримнән бер аять!» — диде Сәхаби.

Теге чакта ...мәэзин ихтыяры белән Әллүки буендагы Әбелхәят чишмәсенен сихри суы хикмәтеннән сон Ходай Тәгаләнен Коръәни Кәриме һәм Илаһка согыну хис-гамәле Байбулат аганын йөрәк түрендә яши. Улы Байтимер кайтып сөйләгән хәлләрдән сон гомер буе коммунист буларак динне читләтергә, туры килгәндә Ходай исеменә тибеп үтәргә дә мәжбүр ителгән бер Адәм баласы картаймыш көнендә Аллаһны тану юлында, инде яше дә алты дистәдән узу сәбәпле, сонга калмыйм дигәндәй, зур адымнар белән ашыга-ашыга һәм кызу-кызу бара иде...

— Ришвәт бирү, аны алу, шуларны рисвай итү модада бит хәзер. Акча. Тәнкә. Тауар. Башта урлыйлар. Аннары фаш итәләр. Кемнәр кемнәрне фаш итә? Күп урлаган азрак урлаганны фаш итә. Аннан сон беркавым тынычланып торалар. Тагын урлый башлыйлар... Озак урлыйлар. Фаш итүче булмый. Аннары күп урлаучылар, үзләрен фаш итәрләр дип куркып, тагын теге... үзләреннән азрак урлаганнарны тотып ябарга керешәләр... — дип баягы сүзләрен кабатлады Сәхаби һәм сораулы карашы белән Байбулат агага төбәлде:

— Ни анлата бу сүзләр? Берәү сөйләгәннән хәтеремдә уелып калды. Асыл мәгънәсенә төшенә алмыйча изаланам!

Байбулат ага көлемсерәп куйды.

— Күктән төштенме әллә син, Сәхаби туган! Монын ни икәнлеген хәзер мәктәп баласы да белә. Бу сүзләрне син үзен әйттен бит! Мин түгел! Егерме елдан артык ил байлыгын таладылар-таладылар да хәзер Мәскәү: «Нишләп бу илне алга жибәреп булмый икән? Нишләп халыкнын тамагын туйдырып булмый икән?» — дип уйлый. Юкса байлык та күпме бит инде! Жир асты байлыгы, урман-сулар, башка төрле байлыклар! Ә халыкнын яртысыннан күбрәге һаман ач, суган суы суырып утыра. Урамга күтәрелеп чыкканнарны «террористлар» дип казаматларга кертеп ябалар, сулый да алмый халык. Адәм балалары тәмам азды. Инде изге динебез белән дә сату итәргә керештеләр. Һәркем тизрәк урлап, баеп калырга тырыша. Бар кеше урларга, чәлдерергә тырыша хәзер. Теге урлый бит әле, нишләп мина да ярамасын дип урлыйлар. Кемдер миллиардлар урлый, кемдер әнә малына болгатырга бер уфалла салам урларга мөмкин. Күптән түгел шәһәргә барып кайттым, яна салынган асфальт тагын чәрдәкләнеп беткән. Менә күрерсен әле: кара көз житеп, көннәр пычракка киткәч, ул юлларны тагын ямый башлаячаклар. Корыда эшләргә ярамый, чөнки ул сыйфатлы була да озаграк тора. Ә болай берәр айдан тагын ремонтларга кирәк, анын өчен хөкүмәт тагын акча бүлеп бирәчәк. Күпләп урлаганнарга берзаман халык: «Нигә бу чаклы урлыйсыз!» — дип интернет, телевидение аша сораулар бирә башлагач, бар да, капылт кубып, каракны фаш итәргә тотыначак. Комиссияләр төзеләчәк каракларга каршы ул комиссияләрнен башында миллионнарны үзләштереп өлгергән агайларын утырачак.

Адәм баласы өчен егерме ел аз түгел бит ул! Бу вакыт эчендә нәкъ ике яна буын туып, тәрбияләнеп үскән дигән сүз! Алар бит хезмәтнен ни икәнлеген күрми, белми үстеләр. Алар урлауны тормыштагы бердәнбер яшәү рәвеше икән дип уйлыйлар, бу бит бала вакыттан каннарына сенгән! Ишеттенме әле, әнә анда шәһәр башлыгы балалар бакчасыннан коррупция эзли башлаган. Беләм, ишеткән бар: анда да кыек куллы мөдирләр бардыр, тик аларнын кесәләренә

салган тиеннәрен шәһәр түрәләренең чит ил банкларына, афшорларга җибәргән миллионнары белән чагыштырып буламы соң! Көлке? Адәм көлкесе!

— Алар бер-берсенең өенә кереп урлыйлармы соң?

— Син чынлап та күктән төшкәнсең ахрысы, агайне. Дәүләтнекен урлыйлар!

— Ә дәүләт кем ул?

— Кем булсын? Хөкүмәт инде!

— Дәүләт баеракмы, хөкүмәтнең алтыннары күбрәкме?

Байбулат ага бәйләнчек чебенне кугандай, кулын селтәде:

— Анысын кайдан белим. Шул икесе бер инде алар!

— Ә түрәләр кемнәр?

— Түрәләрме? Алар шул дәүләт, хөкүмәт кешеләре инде...

— Үзләренекен үзләре урлыйлармыни?

— Күрәсең, шулай булып чыга инде!.. — дип авыр сулады да, әлеге күңелсез сөйләшүдән котылырга теләп, урыннан кузгалды Байбулат ага.

— Ярый, кайтыйм. Байтимердән берәр төрле хәбәр юкмы икән? Булмаса, монда ятып булмас, шәһәргә китәм.

Әмма Сәхабинең сораулары бетмәгән иде әле, Байбулат аганың торып басканын күреп, беркавым тын торды, аннары барыбер түзә алмады:

— Бу мәхшәрне туктатырлык берәр кешегез юкмыни соң? — диде.

— Мин узган ел путёвка белән Дубайга бардым. Шунда бер гарәп белән танышып киттек. Нәкъ синең кебек сорау бирәм тегенә: «Нишләп сез бай, рәхәт яшисез? Сездә булган байлык, нефть, газ бездә дә бар, хәтта күбрәктер дә әле?» — дим. Ә безнең мантый алган юк, бездә йә ачлык, йә чуалыш», — дим». Беләсеңме, бу миңа нәрсә дип җавап бирде: «Бездә Ходай Тәгалә биргән... (җир астыннан чыккан нифте димәде!) Ходай Тәгалә биргән байлык, диде! Икенчесе: «Безгә Ходай Тәгалә һәрвакыт акыллы патшалар биреп тора», — ди!

Гарәпләр үзләре череп баеган халык. Ләкин ялкаулыкның ар ягына чыкканнар инде тәмам. Рухият турында уйламыйлар. Ә без алардагы мәктәпләрне иң гыйлемлегә санап, балаларны шунда укырга җибәреп ятабыз тагын! Әнә Борис малае Варисны, шәһәрдә азып-тузып йөри башлагач, тәмам бозык юлга кереп китмәсен дип, шунда укырга җибәргән идек, бу юлы башкача бозылып кайтты: мин — мондый, сез — тегенди, имеш! Дөрес эшләмисез, сез надан, намазны дөрес укымыйсыз, болай итмисез, тегеләй итмисез, имеш. Тора-тора халык аннан йөз чөерде. Хәзер әнә Байтимер йөзендә иман нуры булган Җәмил хәзрәткә тукталды.

— Йөзендә иман нуры бар, диденме?

— Бар.

— Ике каш арасында нур күрмәденме?

— Анысын белмим, — диде Байбулат ага.

— Алайса Гарасат микәнни инде?

— Гарасат? — дип, аңа күтәрелеп карады Байбулат ага. — Бездә бар ул Гарасат, Гарасат үзәне дигән җир. Житмеш бишенче елны анда, зилзилә кубып, бөтен урманны төбе-тамыры белән йолкып атты, урман үскән җирдә хәзер чөгендер басуы. Ә шуннан ерак түгел генә, тау ышыгы янындагы елга үзәнендәге көтүче шалашы бернәрсәсез исән-имин урынында утырып калды. Зилзилә тау ышыгына тимәде. Хәзер менә ул урыннарны халык «Гарасат үзәне» дип атый.

Сәхаби: «Ике каш араларында нур чагылган адәмнәр бармы сездә?» — дип тә сорамакчы иде, ләкин Байбулат ага: «Баягы сүземне әйтеп бетермәдем, менә шул: без житмеш ел буе Ходайны сүккәч, ул да безгә арты белән борылды,

ахры, аның фатихасы булмагач, нефть белән газның да кадере юк бездә, ил башына куярга акыллы патша да эзләшергә теләми торгандыр!» — диде дә ишектән чыгып китте.

Ишектән чыгып, урамга аяк басуга, Байтимер турындагы уйлар янә бөтереп алып, «жир»гә төшсә дә, Байбулат ага әле генә булган ошбу әңгәмәне «онытты», дөресрәге, бар сөйләшкән сүзләр ниндидер күзгә күренмәгән томан арасында эреп югалдылар кебек... Ярый, хуш... Әңгәмәнең кем белән булганлыгын онытсын да ди! Әмма һәр сөйләшкән сүз фотокәгазьгә сеңгән кебек башында сакланып калды бит! Ташкын буендагы халык телендә булган «Зилзилә яки «Гарасат үзәне дә... Ул чакта нинди давыл купканын үз күзләре белән күрде ләбаса! Аны ничек онытасын ди? Ләкин нинди вакыйга-хәлгә мөнәсәбәтле рәвештә сөйләштеләр — анысы мена чынлап та хәтереннән кул белән юып алынган кебек. Башка чак булса, ул Сәхабинен самими сораулар бирен утыруына гажәпләнеп шиккә калыр, аптырар һәм Сәхабине жүләрләр йортына озатыр иде. Бүген исә берни булмаган кебек. Күнелендә бары малае турындагы уйлар кайный. «Житмәсә киленнен дә корсагы борынына тигән! Бүген-иртәгә табарга тора!..» — дип көрсенде Байбулат ага, бәби алып кайтырга жыенып йөргән Нурбикәне исенә төшереп.

Ул туп-туры Байтимер белән Нурбикә яшәгән өйгә китте.

Бу Сәхаби — алма бакчасы каравылчысы йә берәр сихер-мазар белә торгандыр, йә булмаса гипнозчыдыр...

Сәхаби үзе дә баягы сөйләшү хакында онытkан иде инде, ул Байбулат ага артыннан бакчага чыкты һәм рәт-рәт тезелгән алмагачлар арасыннан койманың аргы ягына таба китте. Теге алмасыз агач янында туктады. Каравыл өе янәшәсендәге багана башына куелган прожектордан монда чаклы көчле яктылык көлтәсе сибелә, шунлыктан бар дөнья ялт иткән. Сәхаби алмагачның нечкә ботакларын бармаклары белән капшап чыкты да, башын күтәреп, әле яна гына туып килгән айга бакты. Туып килгән ай яшь алмагач ботагы кебек неп-нечкә иде. Аның каравы йолдызлар бик якты булып яна, күк каты гажәеп матур. Байбулат карт ана беркөнне: «Шәһәрдә йолдызлар юк анда, шуна күрә мин авылны яратам. Авылда күк йөзен болыт басмаган булса, ичмаса, йолдыз күреп була», — дигән иде. Анын бу адәме йолдызларга багып нәрсә эшли икән соң?

Йа, Әл-Бакый, ярлыкый күр барчасын да...

## Хөрмә мунчаласыннан ишелгән бау кирәк...

— Айсинның үлемендә синен гаебен юк. Анысын снимаем! — диде тикшерүче Баймурзин каршындагы өстәл янына килеп утыргач.

— Кем?! — диде ул, тикшерүченен күзенә туры карап. Бу сүздән бик аптырап калган иде ул.

— Анысы пока не важно! Син коррупциядә гаепләнәсен! Бик зур суммада ришвәт бирүдә!

— Мин?! Коррупция?! Ришвәт?! Кемгә???

— Әйе, нигә аптырадын? Алдан ук шуны әйтеп куям: чистосердечное признание өчен скосим! Мин сүземдә тора торган кеше. Ризамы?

— Риза, — диде Байтимер, аның бу сүзләреннән көләсе килеп.

— Ашыкма, туган, көләргә дә, еларга да вакытын күп булачак әле синен! Әйдә, лучше алдан ук килешеп куйыйк: дөресен сөйләп бирәсен дә и вәссалам. Мин әйткән вәгъдәмне үтәячәкмен! Сүз бирәм!

— Син түлке кемгә күпме биргәнемне әйт мина. Алайса мин кайдан белим ди аны!

— Галинга! Мәннәви Мансарович Галинга! Беләсеңме андый кешене? Ун миллион тәкъдим иткәнсең! Наличными! Кайдан килгәндер андый акча простой фермерга?! Беләсең бит Галинны?

— Галинны беләм белүен... Тик ул минем ришвәткә калган кеше түгел шул! Аннан соң моннан ярты еллап элек ул миңа үзе илле биш миллион тәкъдим иткән иде.

***

— Байтимер, әниеңнән сораганың юкмы? Башсыз тудыңмы әллә син бу дөньяга?! Тагын өтермәнгә килеп эләккәнсең!..

— Сорарага өлгермәдем шул, мине Себергә сөргән кайгыдан әни җан-тәслим кылган иде...

— Да. Да, да, да! Әйе, әйе, әйе.

— Соң син булып... син ышанасыңдыр бит инде миңа, Фәрит туган?!

— Мин ышанам ышануын да... Фактлар, фактлар бит. Шәп эләктергән сине Галин!

— Ул буржуйларга һаман җир җитми!

— Җир җитә, җир күп бездә. Түлке аларга теләсә нинди ташландык җир кирәк түгел шул! Күле, урманы, челтерәп аккан чишмәләре, шәһәргә якын булганы кирәк. Ә синең «Әллүки»ең нәкъ шундый урында.

— Мин анда туып үстем!

— Анысын беләм, беләм... Слушай, парин, карале, син космонавтлар отрядында булган кеше бит. Мәскәү белән, ФСБ белән бәйләнгән кеше бит син элеккеге хезмәтең буенча? Бабаң алтыннары өчен сине тиктомалдан Себергә сөрәләр?! Аның бит процентын түләп... Кыскасы, сине аннан соң ун кулың булып эшләгән Айсин дигән кешене үтерүдә гаеплиләр? Аннан соң инде монысы?! Имеш, олигарх Галинга Баймурзин дигән бер гади фермер ун миллион взятка тәкъдим иткән! Үзе тәкъдим итмәгән, уң кулы булып эшләгән Айсин аша эш йөрткән?! Ә шулчакта ни өчендер малае Айсин Варис дигән яшь мулла газиз атасын җәһәннәмгә олактыра?.. Үзе мулла... үзе үтерә? Әтисен, бертуган, кадерле әтисен?!! Логика күрмим мин монда, Байтимер... Карале, слушай, парин, син эшеннән нормально киттеңме, талашып китмәдеңме? Чиста булдымы барысы да?

— Бигүк чиста түгел... Дөресрәге, хәзер нәрсә дип әйтим, белмим инде, белмим, Фәрит, минем подписканың срогы чыгарга тагын ике ел бар әле. Мин сөйли алмыйм.

— Вәт монысы тагын да кызыграк...

— ...Подписканың нәрсә икәнен беләсең, Фәрит, аптыратма.

— Беләм, беләм. Молчу, молчу! Ләм-мим!

— Нәрсә, нәрсә дидең?

— Безнең авылда дәшмим дип әйтәсе урынга ләм-мим, диләр...

— Һе, кызык... ләм-мим, диләр икән алайса сезнең авылда... Безнең авылда да шулай дип әйтәләр шул...

Йа, Әл-Бәдигъ! Әлиф. Ләм. Мим...

*Дәвамы киләсе саннарда*



Хисам
Камал

# КӨН ЕЛМАЕП АТЛЫЙ КАРШЫГА

## Язның яшел күзе

Яз килде дә жылы нурга күмде.
Тау буенда жирдән пар чыга.
Һәр тере жан, һәрбер бөҗәк шунда
Яшәр өчен генә ашыга.
Көздән калган яфрак юрганын гел
Тишеп үткән яшел энәләр:
Яшь үләннәр тузган одеалны
Яшел җепләр белән тегәләр.
Киртә янда бәбәкләрен ачкан
Язның яшел күзе — кычыткан.
Шул күзләрне көтеп ала идек...
Хәзер әйбәт инде ул чуттан!
Балтырганның кече яфракларын
Ашка өзгән чаклар онытыллы.
Тик барыбер язның яшел күзе
Сөендерә торган ут булды.
...Кояш нуры муллыгыннан исереп,
Тургайлар да күккә менәләр.
Шатлыклары эчләренә сыймый,
Чырык-чырык итеп көләләр...
Яз килде дә жылы нурга күмде,
Көн елмаеп атлый каршыга...
Һәр тере жан тилпенеп һәм ярсып
Яшәргә, сөяргә ашыга!

***

Яшьлектә без юмарт: уңга, сулга
Өләшәбез күңел байлыгын.
Бетәр диеп уйламыйбыз, чөнки
Күрмәгәнбез әле кайгыны.

Хисам КАМАЛ (1926) — *Татарстанның халык язучысы, сугыш һәм хезмәт ветераны. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. 5 томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Өләшәбез, юк, бурычка түгел,
Яхшылыкка гына ышанып.
Яшерен исәп, шик-шөбһә юк бер дә,
Һәм юк бездә күнел кысанлык.
Ләкин бәла китереп кыса бер мәл, —
Тетри жаның, инри күнелең.
Кешеләр сиңа ярдәм итә алмый,
Бәла белән ялгыз берүзең.
Әрни-әрни эчтән син тоясың
Бик беркатлы ахмак булганың,
Сарыф итеп бар жан байлыгыңны,
Яклаучысыз, көчсез калганың...

## Парча

Сүзләр бетте.
Аңлаталмадым шул
Күкрәктәге чын хис — ут кына,
Үзем куркам,
Янымдагы матур
Хисләремне өерә упкынга.
Гүя барам упкын кырыеннан,
Упкын суыра — чак-чак атлыймын.
Анлатырга ихлас күнелемне
Бер чара да һаман тапмыймын.
Һәм кулларын алам кулларыма,
Пульсын тоям аның күнелдә.
Ә йөрәкләр, дөп-дөп тибеп, гүя
Сөйләшәләр Морзе телендә...

* * *

Гомерем минем — каралама,
Күп хаталар анда — аңлыйм.
Ә яшәгән гомеремне шул
Акка күчереп яза алмыйм.
Яшим фәкать каралама,
Акка яши алмыйм һаман.
Тормышымның бер битен дә —
Шатлыклысын,
Кайгылысын —
Төшермичә алга барам.

## Кырлар көрсенүе

Буразналар... Кантар-кантар балчык
Елык-елык ярмаланып тора.
Вак-вак дулкын булып тезелгәннәр...
Монсу зыңлый ызандагы кура.
Сөрелгән жир ерак жәелеп китә,
Ә офыкта ул шәмәхә төсле.
Буразнада пәрәвез жепләре,
Нечкә жилләр шуны иткән гөслә,
Һәм уйныйлар кырның монсу көен.
Ни генә юк икән ул көйләрдә? —

Бәхет, уңыш, диеп җилкенүләр
Сагыш булып хәтергә төйнәлә.
Әрнүле бу кырның мон-зарлары
Күнел кылын бәйли үзләренә.
Аерылып китсән дә син ерак,
Ачык килә алар күзләренә,
Һәм тарта ул сине, җибәрми гел
Тылсым сыман сергә өртелүе.
Йөрәгенне өзеп-өзеп ала,
Искә төшеп кырлар күренүе.

* * *

Нәзакәтле, итагатьле караш...
Һәм хәерхаһ сүзләр тезә ул.
Тик аларда бер хаклык юк, беләм.
Мин белгәнне әллә белә ул?
Тик әдәпкә төргән ялган белән
Изә мине, юкка чыгара.
Фаш итеп тә һәм каршы да килеп
Булмый моңа, ничек чыдарга?
Күренми һәм теркәп булмый торган
Шәхес «сугышы» мәллә үзара?
Анны гына адаштырыр өчен
Нәзакәтле ялган юл яра.

Каршы килеп булмавы бик авыр...

## Кырын эшең

Әллә кайчан кылган кырын эшең
Калкып чыгып, тагы гел яный.
Йолым сорый... Түләттен бит инде,
Диеп ана, куркып мин карыйм.
Ул чак алган хакың җитмәгәнме?
Тагы кирәк туймас убырга!
Начар эшләр үзенә кире кайтып,
Менә шулай җанны суыра...

* * *

Әй, сөйләгән сүзләребездәге
Гөнаһсызлык-сафлык тамчысы
Гына булса иде үзебездә! –
Бушка булмас иде пафосы.
Әй, сөйләгән сүзләребездәге
Акыллылык шулай һәр мәлдә
Булса иде кирәктә әз генә,
Тик сүз өчен түгел, гамәлдә.
Әй, сөйләгән сүзләребездәге
Батырлык һәм бер куркусызлык
Булса иде җанда бер тәкәнмәс...
Алга барган чакта юл сызып.
Без югалып калмас идек, бәла
Китереп суккан хәлдә почмактан...

Әй, сөйләгән сүзләребездәге
Гайрәт булса иде шул чакта!
Кем сөйли, шул хаклы чыга кайчак,
Сүзләр бары — тик хак төсләрдә...
Әй, сөйләгән сүзләребездәге
Хаклык булса иде эшләрдә!
Ул яхшылык кына теләп сөйли,
Гел яхшылык аның эчендә...
Сүзендәге шул яхшылыклары,
Әй, булсачы кылган эшендә!

## Тылсымлы кыр

Тук башаклар иелә бер-берсенә,
Пышылдашып нидер үзара.
Өмет белән елмаялар да күк,
Һәм гамь белән бераз моңсар да!
Авыраеп, тулып бик мөлаем,
Аксыл-сары башлар иелгән.
Һәрбер башта нечкә генә калфак,
Көмеш ука белән чигелгән.
Гүзәл бизәк, серле нәкышләргә
Таң каласың — бөек табигать!
Бернәрсә дә һич ясалма түгел,
Бар нәрсә чын, бары — асыл зат.
Бодай сабаклары —
Сорнай кылы,
Жил аларда уйный нинди көй?
Күнелле дә үзе һәм моңсу да...
Чыгарганмы яна «Әллүки»?
Моңын сибә күктән тургайлар да.
Барча кошлар сайрый, тилпенә.
Башак шавы кош җырына кушылып,
Моң көчәя кырлар иркендә.
Шул моң җанга майдай ята, рәхәт!
Сафланганын тоя барасың,
Һәм үзеңнең кайсыдыр бер кошка
Әйләнгәнең сизми каласың.

Әмирхан Еники

# КЕМ ҖЫРЛАДЫ?

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.

Көзге караңгы төндә кечкенә генә жимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп жылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә бер каралтысы да юк — бар да жимерелеп беткән. Тик юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән зур гына землянка ялгызы калкып тора... Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты жемелдәсен, — әйләнә-юнь моржа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы, — моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын жирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын торалар, әйтерсең, казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән бер көлгән, сөйләшкән тавыш та ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гажиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, анарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен жиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар, ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы инәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен жиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң, егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны, шул тонык яктылыкта басып торган ак

халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак янгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп алды. Кара яньп кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды, — эчәсе, бик эчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Я Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады.

Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Янадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер-берсенә капма-каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде.

Күзгә күренмичә, берничә адымда гына торып җырлаган кыз ялгызы гына булса кирәк, чөнки бүтән беркемнең дә тавышы ишетелми. Ихтимал, ул төнге дежурда торадыр, шунлыктан ахрысы, иптәшләренең татлы йокысын бозарга теләмәгәндәй, ничектер тыелып, әкренрәк җырларга тырыша кебек... Әмма аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.

Кыз, үзенең ниндидер яраткан көен эзлиме, бер җырны башлый да, бетермичә, икенчесенә күчә, бераз җырлагач, туктап тынып тора, аннан тагын акрын гына башлап китә. Үзен тирәнрәк тәэсирләндергән кайбер көйләрне озаграк та җырлап куя, әмма ул кем дә булса мине ишетәдер дигән уйны күңеленә дә китерми иде, әлбәттә.

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына — Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да, барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры... Аһ, моңардан да кадерле һәм ләззәтле нәрсә булырга мөмкинме?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән ингән ак канатлы фәрештәдәй, егетне, ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып китте. Аның хәтта тәне һавада йөзгәндәй җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары киң ялан,
Печәннәре җитәр бер заман шул,
Печәннәре җитәр бер заман...

Һәм егетнен күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп йомшак кына жил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак жил кибеп яткан покосларнын хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, анын күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таяк таянган, ак сакаллы бер бабай килә кебек.

Күпмедер вакыт узгач, кызнын тагын монлы жыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,
Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнен күз алдына үзләренен шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Энгер-менгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнен кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яна гына кайнап чыккан самовар тора икән. Әнисе анын институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

— Әнием, әнием! — ди егет, эченнән үксеп, һәм анын йомык күзләреннән, сыгылып, терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын анын манганена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Шул чакта кыз, тирән бер сагыш белән:

Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда... —

ди.

Һәм егет ике куллап Таһирәсенен башын күкрәгенә кыса, имеш, йөзен анын күперенке чәчләренә куя, имеш, иреннәрен анын җылы, йомшак муенына тидерә, имеш: «Бәгырем, бәгырем, күз нурым! Нигә алай дисен, нигә елыйсын? Без мәнге, мәнге бергә ич!»

Һәм кыз, башын анын күкрәгеннән алмыйча, назланып зарын әйтә кебек:

Сагынам үзем, юлда күзем,
Саргайды нурлы йөзем...
...............................

Юк, юк, бүтән аерылу юк. Инде без бергә, дустым, мәнге бергә!.. Менә алар җитәкләшеп, ашыга-ашыга Идел тавына менәләр, имеш. Тау бик биек икән, туктап-туктап тын алалар, кулларын җибәрмичә, сүзсез генә бер-берсенен күзләренә карап, бәхетле елмаялар, тагын кузгалып китәләр... Ниһаять, менеп җитәләр. Я Хода, нинди кинлек, нинди кинлек, нинди чиксез нур һәм ямь дөньясы бу туган жир! Шундый жинел, шундый рәхәт аларга! Менә алар, тотынышкан хәлдә кулларын кин җәеп, таудан күтәреләләр һәм пар аккоштай елгалар, кырлар, урманнар өстеннән шул чиксез нур дөньясына очалар, очалар...

Кыз жырлавыннан кайчан туктады, каршыдагы эшелон кайчан тавышсыз гына кузгалып китте, — егет моны сизмәде. Ул инде янадан анына

килә алмады. Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанер кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерга кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән еллары язылган иде. Күмүчеләр, башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр ачыклыктан, күмү мәрасименә соңга калгандай, ашыгып кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте, әйтерсең, егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә чыннан да бу егетнең сөйгәне Таһирә иде.

*1956 ел*

---

## *Кайтаваз*

### Аны үлемнән сугыш коткаргандыр

Журналда «Нинди җир ул Суслонгер?» (2013, № 12) дигән язма чыккач, әтиемнең дәү әти — Хәниф Гариф улы Гарипов турында сөйләгәннәре искә төште. Мари Республикасының Звенигово районындагы Суслонгер хәрби хезмәткә өйрәтү лагеренда дәү әти 1941 елның сентябрь — октябрь айларында була. Бирелә чыннан да татарлар күп хезмәт иткән, һәм тагын — чуашлар, башкортлар, марилар... Дәү әтием монда ач килеш урман кисә. Солдатларны ашатырга дигән он, ярманы, шуның өчен асралган дуңгызларны командирлар базарга чыгарып сатканнар. Анда хәтта ул торган барак та салам түбәле була.

Өч айдан аны сугышка алып китәләр. Монда, бәлкем, «бәхеткә каршы» дип әйтү дә дөрестер. Суслонгерда ачлыктан һәм төрле чирләрдән үлеп калган меннәрчә кешенең берсе дәү әтием дә була ала иде бит...

1941 елның 28 ноябрендә хәрби башлыклар таң алдыннан гади солдатларны Селигер күле бозына сузып салып, немецларга каршы ут ачарга кушалар. Дәү әти бик каты яраланып, боз өстендә ятып кала. Бу аның өчен чираттагы язмыш сынавы була. Тәүлеккә якын ятарга туры килә аңа. Шөкер, исән килеш госпитальгә эләгә.

Бик күп операцияләр кичереп, бер аягын җуеп, туган ягына — Актаныш районының Кәзкәй авылына кайта ул... Дәү әти бик көчле рухлы булган, язмыш нинди генә сынаулар китерсә дә, бирешмәгән, сынатмаган. Баштарак колхозда аркан ишү эшендә катнаша ул, соңрак агротехник булып эшли, шул чакта ОС-3 ашлык иләү машинасы өчен дә җаваплы була. Бу техника районның МТСына буйсына һәм андый агрегатлар азлыктан, дәү әтигә Сөн буеның күп кенә авылларына барып эшләргә туры килә. Аннары колхозда завхоз итәләр. 60нчы елларда исә ат җигеп районнан газета-журналлар ташый...

**Гөлшат ГАРИПОВА**

Михаил
Веллер

# БАЙРАК ТУРЫНДА БАЛЛАДА

*«Байрак — ул изге әләм... шул... шуңа...»*
А.Куприн, «Капма-каршылык»

Бөек Ватан сугышыннан исән-сау кайтып, хәрби хезмәтен дәвам иттерерлек офицерларны декабристларга тиң күреп, шау-шулы вакыйгалардан ерак тотарга теләп, илнең аулак урыннарына урнаштырдылар. Ауропаны күреп кайтканнар бит алар, Алла сакласын, ни килеп чыкмас. Шуларның күбесе сугыштагы хәлләрне искә алгалап, шул аулак почмакларда пенсия яшен житкерделәр. Шундыйларның кайберләре Ленинград хәрби округының бер мотоукчы полкына да урнаштырылды. Чынбарлыкта исә ул гап-гади пехота полкы иде.

Полк белән сугышны буеннан-буена узган, күп кенә орден-медальләр иясе, язмышым шушындадыр дип ризалашкан гаярь полковник идарә итә иде.

Сугыш беткәч, исән полковниклар чамасыз күбәя икән, аларны кая куеп бетерәсең? Штабта жылы урынга яисә вузның хәрби кафедрасына теләсә кем урнаша алмый. Ә бу туры юлдан гына йөри торган, хәйлә-мәйләләрне белми торган, ихлас күңелле полковник иде.

Полкта тормыш бер көйгә генә бара. Көндәлек гарнизон тормышы. Дан, батырлыкларга ирешүләр артта калды. Бүген яшь солдатларны өйрәтергә, унга-сулга хисаплар тапшырырга кирәк. Полкта эчү-салулар һәм вак-төякне чәйнәп утырулар да юк түгел.. Күршедә генә кечкенә авыл, тирә-якта урманнар һәм сазлыклар... Кая барырга? Күңел шөгыленә дә юньле ризык юк.

Авылда хәерчелек, сүрәнлек.

Шулай да полкта елга ике мәртәбә көтеп алынган вакыйга була. Хәрби парад. Аңа әзерләнгәндә, полковник хезмәттәшләрен жигеп, булачак тантананың бөтен вак-төяген барлап, вакытны онытып, көчен кызганмыйча эшли. Парадка ике атна кала тантаналы маршның ялыктыргыч күнегүләре башлана. Бер атна кала авыл советы бинасы каршына трибуна корыла, ул кызыл комач белән уратып алына... Транспарантлар ясала, коймаларга плакатлар эленә. Сержантлар солдатларны йөгертә, офицерлар орденнарын чистарта. Ул техниканы юу, аны буяу дисеңме, көпчәк дискларына хәтле ап-ак була, бар да ялт-йолт килеп тора.

Шулай итеп, 7 ноябрьның яки 1 майның куанычлы иртәләрендә авыл халкы алданрак жыелып, мәйдан тирәсенә туплана. Житәкчеләр һәм өлкән офицерлар – трибунада. Ак пирчәткәләр кигән, Симонов карабиннары тоткан комендант взводы мәйданның ян-якларына баса. Полк оркестрының быргылары кояшта ялтырый. Маршлар яңгырый. Өч батальонның тугыз ротасы да трибуна алдыннан үрә катып уза. Парадны, традиция буларак, разведрота ача, ә артдивизион белән танк ротасы тәмамлый. Иң соңгы сафларда – санчасть машиналары һәм роталарның кыр кухнялары.

Халык шат, малай-шалайлар акыра, офицерлар үрә каткан, ә үзәктә полкының фидакарьлегенә сокланып, орденнар белән тулган күкрәген киереп, горур полковник үзе генә басып тора. Гаскәри шөһрәт казануын, хәрби хезмәткә жаны-тәне белән тугрыклыгын шушы парадта раслый ул.

Әлеге иксез-чиксез тоелган колоннаның башында — байракчы! Дан орденнарының тулы кавалеры, мыеклы, ике метр буйлы көяз старшина бара. Мондагы халык аны ярата, хөрмәт итә. Дан орденнарының тулы кавалеры булгач, малайлар аны башка офицерлардан өстенрәк күрәләр, аның белән ихлас горурланалар иде.

Парадтан соң программаның кендеге — сыра! Моның мәгънәсен аңлар, бәяләр өчен ул вакыттагы хәерче, дөньядан аерылган авыл тормышын күз алдына китерергә кирәк. Елга ике мәртәбә фронтовик полковник, булмаганын булдырып, сәмәнен, чарасын һәм жаен табып, Ленинградка машина җибәреп, өч мичкә сыра алдырта иде. Жан башына берәр кружка исәбеннән. Бу мичкәләрне ел буена буш торган ларёкка тәгәрәтеп кертәләр дә парадтан чыгучыларга насыйп кружкаларын чират белән (анысы да алдан уйланылган) бирә торалар. Авыл халкы әле генә парадтан чыккан, төтене дә сүнмәгән кыр кухняларыннан салып биргән ботканы ашый. Халык саны солдаттан күпкә ким булганга, ботка барысына да житә. Бер читтә эленеп торган «Халык белән армия бердәм!» плакатының мәгънәсе бәйрәмнең рухына туры килеп тора.

Яхшы кеше булды полковник: солдатка да гадел һәм мәрхәмәтле, түрәләрдән дә сүз тидертмәде.

Ул көнне дә 1 май парады гөрләп бара. Оркестр дәртләнеп уйный. Гаскәриләр үрә каткан, штыклары сөнге сыман күккә терәлгән, аларга бәйләнгән әләмчекләр жилдә жилферди. Инбашы аркылы киң ал тасма таккан, авыл мәйданыннан шап-шоп атлап барган старшинаның кулында 327нче, Богдан Хмельницкий исемендәге орденлы Славгород мотоукчы гвардия полкының байрагы — чуклары, хәрефләре алтын, почмагында орден ялтырый. Аннан ярты адымга арттарак — ассистентлар, зифа буйлы яшь лейтенантлар, кулларындагы көмештәй кылычлары көн яктысында ялтыр-йолтыр килә.

Алар артыннан сызгыра-сызгыра жырлап разведрота үтә.

Йөрәкләр жилкенә! Жинелмәс армиядә фронт рухы яши бит!

Тиешле юлны узгач, байракчы старшина ларёкка килә. Кружкалар тутырылган, ак курткалар һәм калфаклар кигән кухня нәрәте сыра таратырга әзер — вакыт бик таләпчән, парадтагы мең ярым кешегә берәр кружка сыра минутлар эчендә таратылырга тиеш!

Старшина сыраны беренче булып, әле бер генә кружка түгел, икене ала. Беренчесен ул тын алмыйча эчеп бетерә, икенчесен тантанага алдан махсус хәзерләгән, кыйммәтле, командирлар гына тарта торган «Казбек» папиросын кабызып, төтен аралаш тәмләп, ләззәтләнеп суыра.

Ниһаять, көтеп алынган парад тәмам.

Хәзер инде гарнизон матур итеп бизәлгән ашханәгә, бәйрәм табынына ашыга. Төшке ашка полковник әмере белән ярдәмче хужалыктан дуңгыз, сарыклар суелган, авылдан тозлы кыяр сатып алынган, рота командирлары шау-шушысыз гына барлык составка «наркомски» йөз граммны да салып бирә.

Чыннан да, яхшы кеше иде полковник. Андыйлар, кызганычка каршы, юк шул хәзер. Полк аның хакына утка да, суга да керергә әзер иде. Житәкчеләр дә аның белән исәпләште, яхшыга мисал итеп һаман да аны күрсәттеләр, тик... үстермәделәр генә. Әллә кайдадыр артык сүз ычкындырган, әллә яше узып киткән, әллә инде йөз граммнар турында замполиты дивизиянең политотделына барып чаккан... Кыскасы, аның хәзер барлык тормышы шушы полкта иде, ә тормышының бар куанычы шушы парадлар иде.

Старшина исә тәмәке төпчеген ыргыта, бушаган кружкага моңсуланып карап тора һәм төрелеп янында гына ларёкка сөяп куйган байракны алырга дип кулын суза.

Сузса... Байрак урынында юк. Һай, Алла!.. Бутаган, ахры, байрак ларёкның икенче ягындадыр.

Анда да юк байрак...

Гаҗәп. Шунда гына сөяп куйды бит. Әллә артка сөяп куйганмы?..

Ларёкның артында да юк байрак!

Старшина ассистент-лейтенантлардан сорый:

— Егетләр, байрак кайсыгызда?

Тегеләр аптырашта.

— Кемдә булсын? Син аны кулыңнан төшермәдең ич.

— Менә бит, монда гына куйган идем...

Алар, җыелышып, ларёкның бар ягын да карап-тикшереп чыгалар — юк, байрактан җилләр искән.

Кем алырга мөмкин соң? Як-якларына күз атып эзләсәләр дә — юк, күренми. Әйләнә-тирәдә ашыга-ашыга сыра эчеп, взводлап, роталап кайтып баручы хезмәттәшләре генә.

— Кем бүген 1нче постта кизү? Каравылны постка куючы уйламыйча-нитмичә байракны парад бетүгә урынына илтергә кушкандыр да. Менә тинтәк. Аны сорамый эшләмиләр бит инде. Салагалар...

Старшина инде кылычларын кыннарына тыккан ассистентлары белән бергә полк штабына, андагы 1нче постта күкрәгенә автомат аскан сакчы басып торган атаклы витрина янына килә.

Витрина да буш.

— Байрак кайда соң? — дип сорый старшина сакчыдан.

Тегесе, мондый почётлы постта сөйләшү катгый тыелган булса да, аптыравыннан җавап бирә:

— Сез бит — байрак йөртүче...

— Ник, аны монда алып килмәделәрмени?

— Кем?

— Теге... тышкы каравыл...

— Юк. Алып килергә тиеш иделәрме?

Каравыл башлыгына баралар.

— Байракны син алдыңмы?

Тегесе, шаярту дип аңлап, көлеп җибәрә.

— Әйе, — ди. — Әз генә КПП өстендә дә җилфердәп торсын әле дип элдергән идем, белсеннәр, теләсә кая түгел, ә орденлы гвардия полкына кергәннәрен!

— Ну син ахмак!! Кайда ул?!

— Сез нәрсә?.. Егетләр... шаярып кына әйтүем... ни булды?

— Шаярттыңмы?! Ярар. Тыныңны чыгарма... Аңладыңмы?

Старшинаның йөзе агарганнан-агара, купшы мыегы югарганнан-югара бара. Ассистент-лейтенантларның да балтасы суга төшә. Алар дөнья бетереп актарына башлый: кайсы идиоты байракны алган һәм аны кайда тота икән, ну тапсалармы...

Ларёкка әйләнеп кайталар. Анда сыра хуҗалыгы инде җыештырылган.

— Юк, — ди ларёк кешесе, — сез нәрсә. Бернәрсә дә күрмәдем. Син бит аны кулыңнан да төшермәдең.

— Төшермәдем шул, — ди старшина зәгыйфь тавыш белән.

Бәлки полк командирының кабинетына керткәннәрдер йә штаб начальнигына?

Яңадан штабка кайталар. Штаб буш. Часовой да буш витрина янында басып тора, ишәк. Бөтен тәрәзә пәрдәләрен әйләндереп карыйлар.

Алар барлык роталарны кармалап чыга. Автопаркка хәтле баралар: бәлки,

ларёк кырыенда байрак авып төшкәндер дә, берәрсе ыгы-зыгыда күтәреп, әйтик, танкка салгандыр. Шулай итеп байрак автопаркка киткәндер.

Юк инде, юк, анасын сатыйм!

Парктагы дежурный да боларның тимер-томыр арасыннан байрак эзләп йөрүләренә гаҗәпләнде.

Ул арада полкта төшке бәйрәм ашы да тәмамланды. Солдатларның яртысы увольнениедә: көмешкәгә акча җыя, авылдагы дүрт кыз янында чуала һәм мәктәп яшеннән яңа чыккан шул балаларны гыйшык-мыйшык уенына кыстый. Офицерлар өйләрендә, табын янында бәйрәмне дәвам иттерә. Полк утарында тынлык. Ә байрак бер җирдә дә юк.

Сугыштан соң беренче ун елда Совет Армиясендә хезмәт итмәгән кеше — армия хезмәтен бөтенләй күрмәгән кеше бу коточкыч хәлне берничек тә бәяли алмый. Ул күп булса байрак астында берәр хатын-кыз белән яту кебек әкиятне ишеткәндер. Хәзер, автобуста лейтенант полковникка урын бирмәгән, солдат солдат түгел, офицер офицер түгел, ант ант түгел заманда, армия чәлпәрәмә килеп таралып ятканда, байрак түгел, крейсерларны, колонналары белән танкларны урлап, контрабанда итеп чит илләргә сатканда – сталинча тәрбияләнгән армия чал истәлек булып кына калды. Чөнки ул елларда колхоз малаена армияга бару бәхет иде: җылы, матур кием! Урын-җир, карават! Ун көнлек отпуск. Өч ел узгач — кулга паспорт. Син ирекле, бар теләгән җиреңә! Хәзерге замандагы һава десанты гаскәрләренә алынып, турникта бер тапкыр да тартыла алмаганнар түгел инде. Ә офицерлар аксөяк иде. Энәдән-җептән төшкән форма, паёк, юлы түләнгән отпуск, бару-кайту вагон-купеда, взвод командирының ике меңлек хезмәт хакы – офицерлар бай һәм хөрмәткә лаеклы кешеләр иде.

Частьта байрак булмау исә — әсирлектә булудан да яманрак. Бу — Ватанга хыянәт итүгә тиң. Бу — трибунал һәм мәңге юылмаслык хурлык. Бу... бу — күз алдына китергесез хәл, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел! Байрак өчен үләргә була, аны үз-үзеңне корбан итеп сакларга була, ут эченнән яраланган килеш тәнеңә бәйләп алып чыгарга була, тезләнеп үбәргә була, һәлак булган батырның өстенә капларга була. Ләкин аны югалтырга мөмкин түгел. Дөньясы шартласын – тик байрак сакланырга тиеш.

Ямьле язгы кояш ялт итеп балкый, берләшкән пролетарий бәйрәме дәвам итә, тик байрак кына юк. Вөҗдан кануннары мондый очракта җаваплыларга бердәнбер юлны тәкрарлый – атылырга!

Башта строй алдында синең погонарыңны өзеп атачаклар, аннары тормыш белән исәп-хисапны үзең ясыйсың. Инде соңгы исәп — син үз-үзеңне атарга ирекле.

Ләкин сугыш афәтеннән исән калган старшинаның бер дә атыласы килми. Шуның өстенә аның баласы, гаиләсе бар. Әлегә бит байракның табылу өмете дә өзелмәгән, ул бит каядыр монда гына, шушы тирәдә генә.

Байракны үзләренең кылычлары белән сакларга тиешле ассистент-лейтенантлар да атылырга теләми. Алар байракны кулларында тотмадылар, аны алардан тартып алмадылар, нишләп алар атылырга тиеш ди әле?!

Алар өчәүләп тагын полк хуҗалыгында казыналар – байрак беркайда да юк. Ленин бүлмәсендә дә юк ул, полк рәссамында да юк, оркестрның тромбоннары һәм геликоннары арасында да юк, дуңгыз абзарында да, ярдәмче хуҗалыкта да юк. Ни кухняда, ни полигонда, ни санчастьтә юк.

Байрак эзләүчеләр үзләре дә аңгырайды. Ни сөйләшмиләр, ни дәшмиләр. Хәер, кемгә дәшәсең, ни дип әйтәсең? Полкның иң мөкатдәс әйбере ялгыш кына югалды диясеңме?

Кичкә таба лейтенантларның берсе болай диде:

— Барып әйтик мәллә?

— Кемгә? — Старшинаның тавышы шулкадәр тоньк ки, мәрткә киткән дип уйларсың.

— Кемгә... Башта... полктагы дежурныйга.

— Сезнең звание дәрәҗәлерәк. Сез әйтегез.

— Менә сиңа шомыртым. Без дежурныйга доклад ясамыйбыз. Байрак байракчыга тапшырыла, менә үзең әйтерсең.

— Мин дежурныйга доклад ясамыйм. Устав буенча званиесе югарырак булган кеше ясарга тиеш.

— Устав буенча байрак югалткан өчен строй алдында сине атарга тиешләр!

— Дөрес, — дип килешә старшина, — мине уртага бастырырлар, сезне — ян-якка.

Ахыр чиктә алар өчәүләшеп кизү бүлмәсенә баралар һәм анда лейтенантлар старшинаны эткәләп-төрткәләгәп алга чыгарып бастыралар:

— Син — фронтта булган кеше, Дан орденнары кавалеры, офицер түгел, сине ... ничек тә кичерерләр... Ә безгә — вәссәлам: бетәбез, байрак табылган хәлдә дә ай-вайга карамыйча армиядан артыбызга тибәчәкләр.

Старшина докладны башлый:

— Иптәш гвардия капитаны... шулай һәм шулай... дөресен әйткәндә... хәлләр әйбәт түгел...

— Нәрсә тагын? — ди бәйрәм хөрмәтенә бер стаканны җибәреп өлгергән, шуна күңеле һушланган мыеклы гвардия капитаны. — Минемчә, начар түгел!

— ЧП...

— Ул нинди ЧП тагын? Нигә, старшина, чыраең сытык, сине полк байрагын югалткан дип уйларсың?

Старшина мондый күрәзәлектән агарынып китә һәм хәлсез генә мөгри:

— Нәкъ шулай...

— Нәрсә — нәкъ шулай?

— Ни... Сез әйткәнчә инде...

— Мин нәрсә әйттем? — дип аптырый капитан.

— Ни инде... Юк инде...

— Нәрсә юк инде?

— Югалды...

— Нәрсә югалды? Юньләбрәк аңлат!

— Байрак...

— Нинди байрак? — тинтәкләнеп кабат сорый дежурный.

— Безнең... полкныкы.

— Нәрсә?!

Капитанның мыегы тырпая, күзләре шакмаклана, башындагы фуражкасы калтырый башлый.

— Тьфү — дип куя ул. — Болай шаярту өчен күпме эчтегез? Ярар, алар яшьләр, син бит — фронтовик, карт солдат, шулай шаярталармыни?

— Мин шаяртмыйм, — ди старшина.

Байракның югалуын дежурный башына сыйдыра алмый. Шундый ЧП. Ул кизү торганда. Моннан да начаррак вакыйгага булырга мөмкин түгел. Кемнең башы иң беренче очачак — дежурныйныкы. Полктагы тәртип өчен ул җаваплы.

Ни эшләп була? Полк командирына хәбәр итәргә кирәк. Менә сиңа бәйрәм?! Ычкынмаса ярый инде.

Дежурный, ниһаять, карар кабул итә.

— Менә болай. Хәзер сәгать унҗиде дә кырык. Дежур егерме дә нуль-нульдә алышына. Шул вакытка кадәр байракны табыгыз. Эттән туганнар!!! Хәшәрәтләр!!!

Дежурный ярдәмчесе — «старлей» житәкчелегендә эзләү төркеме төзелә һәм полкның асты өскә китерелә. Эттән туганнар, хәшәрәтләр эзләвен эзлиләр, тик бернинди нәтиҗә юк.

Егерме дә нуль-нульдә капитан дежурлыкны икенче рота командирына тапшыра һәм һәлакәтле тавыш белән өзеп сала:

— Мин дежур торганда полкта гадәттән тыш хәл булды... Полкның байрагы югалды. Дежурлыкны тапшырам!

— Дежурлыкны кабул иттем! — дип җавап бирә яна кизү. — Хи-хи-хи! Күптән югалдымы? Авылга көмешкәгә китте мәллә?

Дежурлыкны тапшыручының йөзендә мәкерле елмаю балкый: «Әһә, кабул итте! Дежурлыкны кабул итте! Байрак югалганда, ул дежурлыкны кабул итәргә тиеш түгел! Тиеш түгел! Ул чаң сугарга тиеш, бөтенесен йөгертергә тиеш! Ә ул кабул итте! Минем җилкәдән арты тау төште!»

Дежурлыкны тапшыручы старшинага һәм лейтенантларга карап әйтеп куя:

— Менә шушылар... фашистлар!.. Парадтан соң байракны югалттылар.

Хәмерле бәйрәм ашыннан суынып бетмәгән яна кизү торучы боргаланып аваз бирә:

— Хи-хи-хи!

— Аңлат! — дип әмер бирә элекке капитан старшинага.

Тегесе үзенең җан әрнеткеч докладын яңадан кабатлап чыга.

Яңа дежурный күгәренә, махмырдан авызы кибә:

— С-е-зз нәрсә... — дип кычкырып җибәрә ул, — ычкындыгызмы?.. славяннар!.. Туганнар!.. Офицер иптәшләр! Мин дежурлыкны кабул итмим!

— Син инде аны кабул иттең. ЧП синдә!

— Миндә ЧП?! Синдә ул ЧП! Кыскасы, мин әлегә командирга әйтмим. Эзләргә!!! Барыгызга да!!! Бар җирдән!!! Иртәнге сигездә тезелергә! Сигезгә кадәр табыгыз!!!

Төне буе егермеләп кеше, фонарьлар тотып, акыллары җиңеләйгән хәзинә эзләүчеләр кебек, кая карама шунда казыналар: казармалардагы матрацларны әйләндерәләр, запчасть әрҗәләренә хәтле карап чыгалар — шымытыр да юк.

Иртән үзенең үрнәк хуҗалыгына бөркетнекедәй күз карашын салырга дип, чыраена бәйрәм төсе йөгергән командир пәйда була. Аңа чалшайган кыяфәтле капитан рапорт бирә:

— Иптәш полк командиры! Мин дежур торганда, гадәттән тыш хәлләр булмады!

— Вольно.

— Ләкин капитан Куманин торганда, андый хәл булды.

— Нинди хәл?

— Гадәттән тыш хәл! Полк байрагы югалды...

Полковник, шөбһәләнеп, як-ягына карый, чәнти бармагы белән колагын кашып ала һәм иснәнеп сорап куя:

— Ә син күпме эчтең, гвардия капитаны?

— Югалды полк байрагы.

Зур балыкны судан өстерәп чыгаргач, башта күсәк белән башына сугып аңгырайталар. Полковник та нәкъ шул балык хәлендә: баскан урынында чайкала башлый, күз аллары караңгылана, кашларына салкын тир җыела.

— Ничек?.. — дип, пышылдый ул.

Алга яңадан тәүлек буена ятып түгел, утырып та карамаган бәхетсез старшинаны бастырып куялар һәм ул инде унынчы тапкыр байракны ничек сөяп куйганын, ничек сыра эчкәнен, ничек төпчеген ташлаганын һәм ничек байракның урынында булмаганын бәян кыла.

Командирга урындык китереп куялар, су, аракы, тәмәке бирәләр, фуражкалар селкеп җилләтәләр. Байракны эзли-эзли җык булуларын әйтәләр.

Офицер иптәшләрнен алтын погоннарына Особый отделнын явыз болытлары сарыла башлый.

— Мин дивизияга хәбәр итмим, — ди командир. — Ни дип әйтим?! Мин бу байрак белән Одерга җиттем!!! Пулялар астында!!! Сез нәрсә?! Старшина, ...ай, старшина... ничек инде, син нәрсә... Эзләргә! Бөтен состав белән эзләргә. Төшке ашны ашатмаска!!! Увольнениеларга чыгармаска!!! Барлык офицерларны полкка җыярга!!! Тапмасагыз, үзем атачакмын! Плацта!

Кырмыска оясына кайнар су сипкән сымак, бөтен полк әрле-бирле байракны эзли. Тырма белән үлән тырмалыйлар. Җирне капшыйлар. Танкистлар мотор асларын карый, артиллеристлар пушка көпшәләрен актара.

Юк байрак.

Димәк, ошбу полк та бүтән юк.

Чөнки байрагы булмаса, хәрби часть тә була алмый. Юк бүтән андый номер, юк бүтән андый часть. Полк бар кебек — ә чынбарлыкта ул юк. Ул күләгә генә.

Командир өч көн өендә утыра һәм эчүдән туктамый. Эчкән саен көнен һәм төнен дежурныйга шалтырата.

Һәм, ниһаять, дивизияга шалтырата: шулай һәм шулай... Байрак югалды.

Анда ышанмыйлар. Көләләр. Аннан ярсып шашыналар. Комдив әйтә:

— Мин армияга хәбәр бирмим. Менә сиңа егерме дүрт сәгать! Табалмасаң — трибунал!

Эзлиләр. Командир эчә. Дежурныйлар да эчә. Эчсәләр дә эзлиләр. Ассистент-лейтенантлар да офицер погоннары, армия хезмәте белән хушлаша-хушлаша эчә. Старшина гына эчми. Ул сверхсрочник, аның эш хакы түбән, аның инде эчәргә сәманы да калмаган...

Комдив армияга хәбәр бирә, һаман да бер балык башы яңадан кабатлана. Тагын бер тәүлек эчәләр һәм эзлиләр. Бу халәткә акрынлап ияләнә дә башлыйлар. Бу сине бомба шартлатып тар-мар иткән кебек: башта — коточкыч. Аннары уйлыйсың: коточкыч булса да, яшәргә кирәк бит... Хезмәтең бетмәгән.

Армия округка хәбәр итә. Бу вакыйга «байрак югалды» дигән хәрби-спорт уенына охшый башлый. Барысы да бу табылмаслык байракка нәфрәтләнеп, киләчәк язмышларының ничек хәл ителәсен көтеп газаплана. 1нче посттагы часовой гына җүләрлеккә һәйкәл кебек басып тора.

Ниһаять, хәбәр Оборона министрлыгына барып ирешә. Инспекцияләр, комиссияләр, тикшерүләр: полкны таратырга тиешләр...

Шушы галәмәтнең Хрущёв тарафыннан армияне бер миллион ике йөз мең кешегә кыскарту вакытына туры килүен күр әле. Һәм шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, полкны тарату мәшәкате тавыш-тынсыз гына узып та китә.

Жуковны бәреп төшереп, отставкага озаталар, крейсерлар һәм бомбардировщикларны тураклап үтилгә җибәрәләр — бер полк кайгысымени?!

Артык шау-шу армияда беркайчан да кирәк түгел иде. Командирның элекке казанышларын исәпкә алып, тыныч кына пенсиягә җибәрделәр. Өлкәнрәк яшьтәге офицерларны да озаттылар. Яшьрәкләрне башка частьларга тараттылар. Капитаннарның берәр йолдызын алып, взвод командирлары итеп урнаштырдылар. Ассистент-лейтенантларның шулай ук берәр йолдызын киметтеләр һәм еракkарак олактырдылар. Техниканы алып киттеләр, каралтылар колхозга калды. Байракчы старшинаны шулай ук каһәрләмичә генә озаттылар. Үзе фронтовик, яше дә бар, Дан орденнарының тулы кавалеры, кызганыч инде ул... Яшәсен шунда!

Старшина авылда яши башлады. Барыр урыны юк иде. Монда исә барлыюклы малы, хатыны, бала-чагасы.

Аны колхозга бик куанып алдылар, ирләр җитми, ул сау-сәламәт, бөтенесе аны белә, хөрмәт итә. Хәрби кеше, хуҗалыкчан. Старшина шунда ук торак белән тәэмин ителде, бригадир итеп куелды, бакча җире алды, чучка асрый, тавык тота башлады. Колхоз тормышына тиз яраклашты ул.

Беркөнне пионерлар аны Җиңү бәйрәменә мәктәпкә чакырдылар.

Старшинага, билгеле инде, бәйрәм кәефе керде. Хатыны сандыктан аның парад киемнәрен алды, үтүкләде, ак якалар текте. Үзе орденнарын, медальләрен элде, бер стакан салып та куйды, мыекларын сыпырып җибәрде.

Дружина советы рәисе аңа тантаналы рапорт бирде. Аны дружинага шәрәфле пионер итеп кабул иттеләр, муенына кызыл галстук бәйләделәр. Аннары ул балаларга ничек сугышканын, ничек яраланганын сөйләде. Сугышчан дусларының шушы балалар бәхете өчен тормышларын корбан итүен әйтте.

Аңа озаклап кул чаптылар, аннары мәктәп күрсәтергә экскурсияга алып киттеләр. Кунак классларны, укытучылар бүлмәсен, карга һәм керпе яшәгән тере почмакны карады. Соңыннан үзен мәктәп музеена, Шәрәфле кунаклар китабына имза куярга алып керделәр.

Шушы балаларның мәхәббәтле күз карашларыннан, чирелдәүләреннән күңеле йомшарып киткән старшина сугышчан дан музеендагы күгәргән мылтык көпшәләре, саргайган гәҗитләр, фотографияләр, тузып беткән пионер быргылары һәм барабаннары белән тулган экспонатлар арасында үз полкының байрагын күреп алды!

Ул яхшырак күренсен өчен җәелгән һәм диварга вак кадаклар белән кадакланган.

Шунда ук төсле кәгазьдән киселгән зур хәрефләр белән язып куелган:

**327нче Богдан Хмельницкий орденлы**
**Славгород гвардия мотоукчы полкы байрагы.**
**Павлик Морозов исемендәге 27нче пионер дружинасына часть җитәкчелегенең бүләге.**

Бәй, моны бит пионерлар селтәгәннәр... Музейга. Укытучыларга «бүләк» дип әйткәннәр. Укытучыларны куандырганнар.

...Азрак аңына килгәч, старшинаның пионерларга ни әйткәнен, ни эшләгәнен тарих яшереп калдырган. Шулай ук аның ничек өенә кайтып җитүе дә билгесез. Тик юлда ул жизле бил каешын салып кулына ала, коточкыч сүгенеп, бөтен авыл ирләрен пыран-заран китерә. Бу салса булдыра икән... дип, мужиклар башларын гына чайкап кала.

Сәгате-минутында чучка сатыла, хатыны, күз яшьләрен йотып, көмешкәгә йөгерә. Тавыклар закускага кырыла. Бүтән бу авылга минем аягым басмаячак, ди старшина хатынына. Ул, гомумән, авылны яратмый, авыл хуҗалыгын яратмый, ә бу авылны бөтенләй дөньядан юк итәчәк. Иртәгә үк Ленинградка эш белешергә барачак. Ул үзе өчен башкача җавап тота алмый. Пионерларны дружинасы белән буып бетерәчәк, мәктәпне яндырачак, ә укытучыларны мәктәп ишегалдындагы агачларга асачак.

Шулай итеп, Ленинградтагы Нахимов училищесында ике метр буйлы, мыеклы һәм елгыр старшина пәйда булды. Ул әле егерме еллап Мәскәүдә кылычлы ике ассистент уртасында, иңбашына кызыл тасма бәйләп, кулына училищеның байрагын тотып, нахимовчыларның сафы алдында парадларда йөрде. Телевизор аша аны бөтен ил күреп белә һәм аңа карап соклана иде.

*Русчадан* **Рәис ШАКИРОВ** *тәрҗемәсе.*



Дамир
Гарифуллин

# РОБАГЫЙЛАР ӨЛӘШҮДӘН ЯЛЫКМЫЙМ

***

Шагыйрьне шагыйрь итә үз кавеме,
Болай гына төшерәм искә моны.
Кол Галидән башлап безнең көнгәчә
Һәрбер шагыйрь раслыйдыр безгә шуны.

***

Олыны да, кечене дә санла син,
Изге эшкә йөрәгеңне ялла син.
Узып яшә галиҗәнап Вакытны,
Ике килми кеше, шуны аңла син.

***

Туздырасың атаң малын көлеп син,
Ни эшләдең бу дөньяга килеп син?
Тузан кадәр эшең жирдә калмагач,
Жиһан өчен инде күптән үлек син.

***

Ни аяныч, дөньяда гомер чикле,
Юлларыбыз — кабер кырына тикле.
Пәйгамбәрләр өчен дә, уйлап баксак,
Мәңгелекнең ишеге булган бикле.

***

Дөнья тулы гайбәт, әләк, ялган ла,
Бер-берсенә алар оста ялганган.
Хакыйкатькә санап менә шуларны
Бу тормышта күпме адәм алданган.

Дамир ГАРИФУЛЛИН (1939) — *шагыйрь, археограф; «Чыгарсыңмы каршы алырга», «Сарман энциклопедиясе», «Җырларым, шигырьләрем...» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Сарманда яши.*

* * *

Яшə жирдə үз көченə табынып,
Торып йөгер, егылсаң да абынып.
Кыен димə, картлыгында кешелəр
Тəм табалар, шундый чакны сагынып.

* * *

Яшəүнең һəр мизгеле — шатлык миңа,
Меңьеллык оҗмахлардан артык миңа.
Тик нидəн бу Бəхет дигəн кыяга
Дөньяның хəсрəтлəрен тартып менəм?

* * *

Беркайчан да «вəгъдəң — иман» булмады,
Бер файдалы эш тə əле кылмадың.
Сине жиргə китереп мəңгелектəн,
Михнəт чиккəн ата-анаң уңмады.

* * *

Гаҗəп дөнья, мал-мөлкəткə муллыктыр:
Җылы сүзгə, якты йөзгə кытлыктыр.
Тук азгынлык йөри адəм башыннан,
Кем аларны симертүче утлыктыр?

***

Жиңеп чыга тормыш өчен көрəшкəн,
Шуңа тормыш гыйбарəттер көрəштəн.
Чын бəхетле булыйм дисəң дөньяда,
Бу чынлыкны юлдаш ит син бик яшьтəн.

* * *

Сəгать кебек булса Кеше гомере,
Бора-бора аның телен мин кире,
Яшьлегемə кайтыр идем янадан –
Синең янга барыр өчен йөгереп.

* * *

«Кояшым», — дип, дəшəмен сөйгəн ярга,
Ул булганда урын юк моңга-зарга.
Күрмисең, дилəр, йолдыздай кызларны,
Күренми шул йолдызлар Кояш барда.

* * *

Бу дөньяда яшəгəндə белеп тор:
Куштан сүзе ялган акча кебектер.
Гаебеңне якын итеп күрсəткəн
Туры сүзле дуслар өчен үлеп тор.

* * *

Күнелемнең сандыгыннан алып, мин
Робагыйлар өлəшүдəн ялыкмыйм.
Арасында энҗелəр дə бар микəн?
Ансын инде дус-дошманым аныклый.

* * *

Татардан күп асыл затлар җиһанда,
Горурланам тарих битен ачам да.
Дөрес икән: ничек кенә бутама —
Алтынлыгын алтын саклый кайчан да.

* * *

Гел төендә төен төйнәү эшебез,
Бер уйласаң, бик тә сәер кеше без.
Шул үзебез төйнәгәнне чишәргә
Житми һәрчак үзебезнең көчебез.

* * *

Һәркемдә бар табигатьнең биргәне,
Көлке синең «мин — галим», дип йөргәнең.
«Мин — юләр», дип сөйләгәнең юләрнең
Бармы синең берәр заман күргәнең?

* * *

«Яшәү ни ул?» — диеп кем баш ватмаган,
Тик берәү дә асыл җавап тапмаган.
Сораулардан хасил булган диңгезләр,
Кемнәр генә кереп анда батмаган.

* * *

Татарда да күп булды ул изгеләр,
Тик аларны таптый-таптый изделәр.
Гарипләнде шәҗәрәбез агачы,
Ай-һай, аның тамырларын күп өзделәр.

* * *

Әй син, язмыш, бирәсең лә кирәген,
Кара янып бетте инде йөрәгем.
Әләм итәм һаман да мин яшәүне,
Яшәү — минем җирдә иң зур терәгем.

* * *

Дөньяга мең йөрәк белән ташып мин,
Наз өләштем кешеләргә шашып мин.
Бу гамәлдән туктарга һич ашыкмыйм,
Чөнки якты дөньябызга гашыйк мин.

* * *

Килер бер көн, бу дөньядан күчәрбез,
Касәдәге соң йотымны эчәрбез.
Әгәр бер эз калдырмасак, ничек соң
Яшь буынның хәтеренә төшәрбез?

* * *

Дөбер-шатыр килә-килә һәр көнне,
Тормыш дигән арба йөртә һәркемне.
Беребез дә карамыйбыз уйлап та
Кайчан, кая аударасын беркөнне.

* * *

Алтыннанмы савыт, көмеш, таштанмы,
Кызыктырмый ансы ачтан шашканны.
Эчендәге ризык ана кадерле,
Ул бит көтә фәкать шуны ачканны.

* * *

Төкерәләр бакча тулы гөленә,
Козгын тулган сандугачлар иленә.
Чукый алар кан саркыган йөрәкне,
Тәгәрәтеп бабамнарның көленә.

* * *

Дәгъваламыйм ниндидер дан үземә,
Бер чалынсам җитә дөнья күзенә.
Минем өчен олы бәхет, әйткәнем
Дәвам булса бабаларым сүзенә.

* * *

Яшьләр яши алда көткән көн белән,
Картлар яши артка үткән көн белән.
Алары да, болары да бик кирәк
Үкенмәскә әрәм беткән көн белән.

* * *

Халык авызыннан чыкмас ялган сүз,
Ялган йокмас өчен яшә ялгансыз.
Халык күзе күпне күрә, онытма:
Бу гыйбарә — бабайлардан калган сүз.

* * *

Юкка исраф була шактый гомерләр,
Яши-яши менә шуны белерләр.
Бөкреләре чыккан картлык өчен дә
Кешеләр бит яшьлекләрен түлиләр.

* * *

Хуҗамнарның йөзе, керсәм, мөлаем,
Тик гозерне үтәтергә юк җаем:
Буш кул белән яннарыннан чыгамын,
Буш кул белән кергәнгәдер, мөгаен.

* * *

Урый-урый йөртә безне бер агыш,
Кая баксаң, шунда хәзер зар-сагыш.
И кардәшем, сине мәрттән уятып,
Шигырьләрем бирер әле бер тавыш.

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аны ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Нәбирә
Гыйматдинова

# НУРУЛЛА

БӘЯН

## 1

...Нибарысы төш кенә иде ул... Нибарысы төш кенә... Йөрәккә китереп бәрергә шул җитә калды микәнни?

— Авылда нихәлләр соң, бичәсе? Газраил берәрегезне чүпләмәдеме? — диде Нурулла, башын күтәрмичә генә. Бу уйлардан аның мие ташка әйләнгән сыман иде.

Сүзгә саран хатыны артык җәелмәде:

— Тыныч үзе, — диде.

— Өеңә караклар керсә дә, сиңа тып-тыныч! — Ир мондый җаваптан һич канәгать түгел иде. — Нишләп сөйләшергә иренәсең син, ә? Һәр сүзең алтын кыйпылчыгы мәллә? Әй, синнән ни көтәсең! Минем исемемне дә яртылаш кыскарткач теге.

— Ник битәрлисең, Нурла? Син минем белән сирәк яшәдең. Кунарга да кайтмый идең кайчак. Капкаңның кайда икәнен оныта идең.

— Менә, менә, телең ачылды, бичәсе! Анысы дөрес, колхоз рәисенең йорты хуҗалык аның. Төнлә кибән төпләрендә әз йокламадык без, арыта да, чүт кенә ятып аякларны язый дисең дә кояш белән бергә уянасың. Җә, үзгәрешфәләннәр дә юкмы Чурайбатырда?

— Өч айда ни үзгәрсен икән, Нурла?

— Өч ай озын ара, дөньясы уптым илаһи җимерелә ала.

— Аумады-егылмады, үз аягында басып тора авыл. Бер әрбир бар барын...

Хатыны ирен чите белән генә көлемсерәде.

— Җә, сүзеңне кое төбеннән багур белән тартып алгыры! — диде Нурулла, түземсезләнеп. — Нинди әйбер ул?!

— Сиңа әкәмәт кушамат тактылар, Нурла.

— Кушамат?! Мир кушканын кая куйдылар?

— Патша димиләр хәзер. Хастаханәгә кантур кызлары хәлеңне белергә баргач, син үзең: «Мин барыгызны да үтәли күрәм», — дигәнсең лә.

— Күрәм шул! Егерме ел колхоз тәхетендә утыр да кешеләрне үтәли күрмә, имеш! Кем ничек сулаганына кадәр тоям мин. Зерә генә патша димиләрдер. Җә, нинди яңа кушамат ул?

— Чү, кычкырма, Нурла.

— Нинди кушамат дим, чукрак?

— Сине әүлия, диләр, Нурла.

— Әүлия?! — Ир шаркылдап көлде. Мөгаен, Мирхан мулла тел кашыйдыр. Авыл башындагы ташландык кабергә Нурулланың күптән эче поша иде. Анда әүлия бабай күмелгән диләр иде. Кабер тирәсен тотып алган такталар череп, өстеннән терлек-туар таптап йөри башлагач, мәетнең сөякләре тузгып ятмасын дип, ул үз акчасына нарат тактадан аңа чардуган ясаткан иде. Аның бу эшен мулла бер дә килештермәде. Урамда очраган саен: «Син хаталандың, энем, син Аллаһ сөймәгән гамәл кылдың, син ул түмгәк өемен җир белән тигезләтәсе урынга, халык табынырдай кабер торгыздың», — дип нәгъләт укый иде. Тик мулла абзый ялгышты: беркем дә «әүлия» янына килеп маңгаен ормады. Адәм баласына фани дөньялыкта гел дөрес кенә яшәргә кирәк микән? Ялгышмыйча, читкә тайпылмыйча туры юлдан гына атласаң — табаныңа гөнаһ тузаны сыланмыйдыр һәм мин Аллаһ каршысына ак килеш, пакь килеш килеп басырмын дип өметләнәсеңдер. А, юк, туган, бер нәни генә хатаң мең изгелеккә тиңләшергә мөмкин.

— Ярар, таксыннар, — диде Нурулла. — Бытылдарлар, бытылдарлар да аннан туярлар. Син, дим, арурак күлмәк-чалбарларны караштырып бир әле.

— Кая җыендың, Нурла? Кичә генә хастаханәдән кайттың ласа! Хәлсез бит әле син!

— Эш сагындырды, Сажидә, эш!

— Колхоз дия-дия йөрәгең челтәрләнде бит, Нурла. Үлгәч кабат терелдең бит син!

— Кәчтүм-чалбарларны бир, дим!

...Нибарысы төш кенә иде шул. Һәм ул буталчык түгел, аңлаешлы иде. Ә чынбарлыктагы «төшләр» киресенчә, төен-төен бәйләнеп, чуалган, очын табарлык та түгел иде. Аның соңгысы куркынычрак булырга тиеш кебек иде. Әмма Нурулла өчен беренчесе шомлырак иде...

...Беркөнне дисә, кичә генә кебек күренер, моннан ничәдер ел элек, район хакимияте башлыгы кинәшмәдән соң аны кабинетына чакырды. Сүзне ерактан уратып башлады ул.

— Безнең бәхеткә, Азизов, өстән инвестор төшермәделәр. Министр Әхмәтовка рәхмәт, бу төбәктәге колхозларга тулаем тидертмәде. Үз җиребезгә үзебез хуҗа без. Ә җир тиздән алтын бәясе белән тигезләшәчәк, Азизов. Фермерлык, диләр, мактыйлар. Ә ул нәрсә? Ул — коллык, Азизов. Вәт син, мисалга, колхозникны ел саен бушлай ял иттерәсең, хезмәт хакын аен айга түлисең. Печәнен, бодаен, арышын өләшәсең, бакчасын сөрдертәсең. Аңа хезмәт стажы языла, киләчәктә әзме-күпме пенсия алачак агай-эне. Улын өйләндереп или кызын кияүгә биреп туй ясый икән колхозник, син аны эшеннән азат итәсең берничә көнгә. Ә фермерның кул-аягы богавыланган: ул үзе хуҗа булса да, кол дәрәҗәсендә. Син төшенәсеңме, Азизов, үзенә үзе батрак хуҗаның хәлен? Ашы — аш, ялы ял түгел мескеннең. Ял димәктән, син молодец, Азизов, сыер савучы апайларны Казанга концерт-театрларга ташыйсың ди. Яхшы гамәл, ну артык очындырма. Искусство боза кешене. Потом мечтательләргә әйләнерләр, тирескә карамаслар, һавадагы йолдызларга кызыгырлар. Җир мечтательләрне яратмый, Азизов.

Нурулланың бер шундый начар гадәте бар иде: әңгәмәдәшенең сафсатасы ошамаса, кырт кына кистереп әйтеп куя иде. Бу юлысы да, түрә абыныр димәде, аркылы «бүрәнә тәгәрәтте»:

— Фермерларны алай ук хурламас идем мин, Гата Кәримович. Танышымның

энекәше Чүпрәле кызына өйләнгәч, анда калды. Шәхси хуҗалыгын оештырды, кыскасы — фермер. Алар авылында эшсезлек, нужа борынынннан каптыргач нишләсен адәм баласы, ничарадан бичара берәр кәсепкә керешә.

Башлык ул тәгәрәткән бүрәнәгә аягы белән типте.

— Синдә дә эшсезлекме, Азизов?

— Әлегә юк.

— Вәт-вәт, пока юк! Колхозым алдынгы дип кәпрәймә син, Азизов! Һәркөнне берәр уч ком өстәмәсән, тау да әкрен генә кечерәя, Азизов! Мужыт чир эләгеп, синең бөтен терлек-туарын кырылыр, ә? Корылык булып, басуда икмәгең көяр, ә? Янадан ничек тергезәсең колхозны, ә, Азизов?

— Сәнгать тә халыкны бозмый, Гата Кәримович, бу мәсьәләдә сез ялгышасыз, — дип икенче юнәлеш алып, сүз көрәштерергә базган Нурулланы хәким бармак шартлатып бүлдерде.

— Мин сине дискуссиягә чакырмадым, Азизов! Хәзер минем әмеремне тыңла һәм үтә! Сарык-кәҗәләренне немедленно сатып, өч ферманы бушат. Ул мәкелдекләр белән акча ясый алмыйсың. Синең колхозыңа өч йөз баш ана, йөз баш ата дуңгыз тәгаенләдек. Самара өлкәсе губернаторы белән килештек, дуслык хакына җүн генә бәягә җибәртә. Бу хайван тиз үрчи, артымы зур, икеөч елда акчаны көрәк белән көрисең, Азизов.

— Кертмим! — диде тыны кысылган Нурулла.

— Нәрсә кертмисең, Азизов?

— Шул нәҗесегезне! Гомердә күрмәгәнне теге... Татар авылы бит без.

— Синнән кем сорый, Азизов, бар, кушканны үтә. Смотри, егет, бер генә дуңгыз югалсын, башың белән җавап бирәсең!

Хакимият бинасының баскычында өч тапкыр сөрлекте Нурулла. Тигез җир гүя түмгәккә әверелгән иде. Кертмим, диде ул һәм кертмәс тә! Киләхмәт батыр нәселе баласы, тез калтыратып, түрәләрдән өркер ди менә! Тиз генә халыкны кузгатырга кирәк! Тарихтагы хәлләр кабатланмый, диләр, ничек кенә кабатлана әле! «Гасыр арты гасыр үтсә дә, хәтердән җуелмас бер хикәят бар, оланнар, — дип, һаман-һаман әйләндереп сөйли иде бабасы Мотыйгулла. — Патша заманында Чурайбатырга бик каныгалар: мәчетен яндыралар, чукындырмак булып, авылга ябырылалар, — дия иде, мәрхүм. Әйтерсең, бу вакыйгада турыдан-туры үзе катнашкан, картның күзләре яшьләнә иде. — Безнең бабайлар юлбасарларга каршы көрәшер өчен, этрәт җыя. Сәнәк, көрәк, балта белән коралланa болар. Каты гына бәрелештә кяферләр җиңә безнекеләрне. Чукынырга теләмәгән кешеләрнең аркасына салам бәйләп яндыралар, таяк белән суктыралар. Вәләкин үз ирке белән беркем дә чукынмый, авылга нәсара дине керттерми бабайлар. Попларны куалар, тәреләрен сындыралар. Явыз Иван мәетне поп катнашында күмәргә дип фәрман бастырып калдыра. Бервакыт Чурайбатырда мөселман агае үлә. Мулла да, поп та килә. Мулла дога укып мәетне гүргә индерә. Шул чакта ерак Киләхмәт бабагыз: «Җәмәгать, патша фәрманында мәетне попсыз күмәргә ярамый диелгән», — дип, карагруһны чокырга мәтәлдерә. Ирләр тиз генә аны күмеп тә куя. Икенче көнне урәтник попны килеп эзли, оланнар. Арада шымчы сатлыкҗан була шул, оланнар. Ерак Киләхмәт бабагызны сөргенгә сөрәләр, ә яшь угланын — Нәҗибулланы базга яшереп кала халык, оланнар».

Бабасы риваять итеп ятлаган әлеге хикәятен вак кына хәрефләр белән шакмаклы дәфтәргә дә күчереп язган иде. Онытмасыннар дип кисәткәндер, мәрхүм. Оныттырмыйлар, бабай, гел искә төшереп торалар. Үткән белән бүгенге арасында уртаклык та бар: ирексезләү, көчләү, янау-куркыту. Шул ук чакта аермасы да бар: бүген милләт иманы белән үз агай-энең дә

«уйный». Тарих укытучысы иде Нурулла, ләкин мәктәптә озак тотмадылар, колхоз арбасына жиктеләр. Жир, туфрак, икмәк дисә дә, юк-юк та, тарих сагындырып куя иде. Алар укыган елларда әле нәсел-нәсәбендә казыну ят шөгыль иде. Бәлки, егет тә «чәйнәп каптырган тарих»ка ышанып институт тәмамлар иде, ничектер профессор Хәкимов түгәрәгенә эләкте. Укытучыга бабасынын риваятен сөйләгән иде, Хәкимов: «Чурайбатыр авылы миңа таныш, сездә гыйбрәтләр житәрлек, шуларны жый син, Азизов», — диде. Жыймады Нурулла, ә менә Хәкимов сендергән милли рух ялкынын сүндермәскә тырышты. Соңгы курста укыганда, урамда аңа ике башкисәр бәйләнде. «Дай закурить, татарская морда», — диде берсе. Күрәсең, Нурулланың төс-кыяфәте, килеш-килбәте: «Мин татар малае», — дип кычкырып тора иде. Печән чабып, утын кисеп, аннан да бигрәк итле бәрәңге ашап ныгыган йодрыгы белән сылап, берсен тәгәрәткән иде, икенчесе ялварып жиргә чүкте: «Не трогай, друг, извини».

Гәрчә, әүлия каберенә чардуган корганнан соң, мулла абзый аңа кырын караса да, олы кеше белән кинәшим дип, Нурулла туры аларга сугылды. Карт ишегалдында мунча себеркесе бәйли иде. Ботаклары нәзек, димәк, түбән урман каеннарын «чишендергән». Анда алар жирдән күтәрелеп кенә килә иде.

— Ни йомыш, Сафиулла углы? — диде мулла, кунакны өнәмичә генә.

— Үзәктән кайтыш, Мирхан абзый. Авылны дуңгыз тизәге белән быкырдатмакчылар.

Ул көткән иде, менә хәзер мулла утырган жиреннән сикереп торыр да, нәкъ анын кебек ярсып: «Кертмибез!» — дияр. Әмма абзый урынынннан кымшанмады.

— Өстенә бәла килә икән, Сафиулла углы. Әүлия каберләрен яңартып, ислам диненә кизәнүең хәерлегә булмады менәтерәк. Аллаһ жәзасын бирә менәтерәк үзеңә. Дуңгыз нәжесенә буяласың икән.

— Мин генәмени, авылыбыз белән буялабыз! Халыкка хәбәр итәсе иде, Мирхан абзый. Син бу хайванның безгә хәрәм икәнен аңлатсаң иде.

— Тавыш куптарырга дисәң — сезгә куш, каныгыз кайнар сезнең, Сафиулла малайлары. Әнәтерәк, игезәк сынарын күпер өчен буза куптарды. Аръякта елганын ине таррак, ди. Шунда төзик, ди.

«Анда тар шул», — дип олы кеше белән тартышу килешми дип, Нурулла бәхәсне куертмады. Вакыты да ул түгел иде.

— Безнең Чурайбатыр матур, төзек, яшьләр дә кубарылып шәһәргә чыгып китми, монда төпләнеп кала. Синдә йөрәк бардыр бит инде, йа, Мирхан абзый! Әйдә, авылны нәжескә батыртмыйк! Безне бетерер өчен тәреләр белән бер кергәннәр бит инде, бабайлар кан коеп, иманын саклаган ул чакта.

— Каберне изгеләштермәскә иде сина, Сафиулла углы, — диде мулла. — Монын белән син минем абруемны какшатмакчы иден, ахры.

Мирхан абзыйның үпкәсе бавырына ук төшеп, әчеттерә иде. Бу картка жир өстендә кемнеңдер сөякләре тузгып ятуы хәерлерәк иде микәнни соң?! Йа, дөньясы!

Каны кызса да, Нурулла түзде.

— Минем бакча артында кирәк ие ул күпер. Жомга намазына күрше Кызыл Тау мәчетенә йөрим, туры гына чыгарыем күпердән, мәйтәм. Безнең мәчет тузды, Сафиулла углы. Сезнең иман йортында гамегез юк, шайтан токымнары! Халыкны өндәргә дигәндә мина чабасыз!

Карт, каен ботакларын шап-шоп бәргәләп алды.

— Аның каравы синең йортың шәп! — диде ир. Монысында тыелып булмый иде инде. — Минем игезәк сыңары мәчет салдырам дип нараттан бура бураган

иде. Синең кодрәтле чагын, әйеме, Мирхан абзый, син парторг, ул бураны үзенә ташытып, өй тергезәсен, әйеме?

— Йә, хәсрәт капчыгы, авылга кем керттерә безгә ят хайванны? — Мирхан тиз генә сүз агымын борып жибәрде.

— Өстән, хакимияттән, мулла абзый.

— Бәрәкалла, минем дус Гата Кәримович үзе фәрман бирдемени? Алайса, энем, карышма. Башлыкларга буйсынырга куша китап, ие, шулай.

Нурулла йодрыгы белән мангаена төйде. Их, син ахмак! Кем белән кинәшәсен син? Кемнән ярдәм сорыйсын?! Бу бит чапанга төренгән парторг Нурихан Касыймов! Теге шомлы елларнын кара шәүләсе бит бу! Бер жылы оядан икенче жылы ояга оялаган карчыга бит бу!

Ул авылдашларын жыеп чаң сукмакчы иде, иртәгесен аны рәислектән алып ыргытты хаким. «Карчыга» сәгате-минуты белән барып «дусты»на каркылдаган иде.

Баш агроном Һавис: «Азизовка рәхәт, үзе баш, үзе түш», — дип мыжгылдап йөри иде, хужалыкнын барлык «рәхәте»н ана тапшырдылар.

Һависнын каны «салкын» иде, ул күндәм иде: атна-ун көн үтмәгәндер, фермадагы сарыклар каядыр озатылды, алар урынына «яна төр» хайваннар тутырдылар.

Хәзер Чурайбатырда тан бүтәнрәк рәвештә ата: әтәчләрнен «кикрикүк» дигән авазларына чинашкан-мыркылдашкан тавышлар кушыла да, гайрәтне чигерерлек «симфоник әсәр» янгырый иде!

Нурулла игезәк сыңары белән чуаш якларына шабашкага юл сапты. Озакка дип. Онытылырга дип. Ана өч көн күрмәсә тилерткән Туйбикәсе дә киртә кора алмады хәтта.

Өч елдан соң хакимият башлыгы аны үзе эзләп тапты.

— Тиздән мине Чистайга завод директоры урынбасары итеп күчерәләр, Азизов. Төгәлрәге, урынымнан аткаралар. Бер хатамны төзәтер идем, Азизов. Әйдә, эшенә кайт, туган. Авылыгыз таркалмагае. Ун гаилә башка районга тайган. Яңа рәистән унмадык без. Артта сөйрәлә колхозыгыз. Дунгызларга эчен поша иде синең, анысын үзең хәл ит, Азизов. Бу юлысы мин тыкшынмыйм. Ат асрыйсыңмы, сарык үрчетәсенме? — үз иркендә, — диде гаепле башын кашыган төрә.

«Уйларбыз әле, карарбыз әле», — дип сырланмады Нурулла. Ике дистә елда шушы хужалыкка жаны белән береккән иде ул. Басу-кырларның кара туфрагына анын күпме сәламәтлеге чәчелде, тик кире шытмады... Йөрәге чәнчегәндә күкрәген уып буразна кырыйларында әзме утырды рәис. Жәйләүләрдә, терлек тоягы астында никадәр исәнлек тапталды. Урманнан өере белән бүреләр ташланганда читәннән жирда суырып алып ерткычларга каршы атлаганда тез буыннары ничек хәлсезләнгән иде. Ә барыбер жинде. Күзләре күмерләнеп янган өер башлыгынын мангаена кусәк белән тондыргач, ач иярченнәре койрыкларын бот арасына кыстырып куак ешлыгына шылган иде...

Бар ачуы, бар ярсуы кусәккә күчте, ахрысы. Куе зәнгәрсу күк йөзендә ярым ай калыккан иде, гүя дулкыны бәрелеп анын бер чите нарат өстенә кителде. Урман калтыранып куйды. Төнге каравылда торган Хәмәтдин абзый күз яшьләре белән елады шунда.

— Син ничек төнлә киләсе иттең икән, олан? Нәсел таналарын ботарлап кына чыгалар иде, иблисләр. Бәла буласын сизенгәнсеңдер син, олан. Нишләрбез алга табан, олан?

— Мин сина мылтык бирермен, Хәмәтдин абзый, — диде Нурулла каравылчыны тынычландырып. — Гаеп миндә, яланкул чыгардым мин сине төнгелеккә.

Әйе, хуҗалыкны янадан сыртына салды Нурулла. Халык та аны сагынган иде. «Патша» кайтты дигән хәбәр Чурайбатырны бик тиз урап үтте. Инде хәзер авылдашлар аның янына агылачак һәм һәркем бер генә үтенеч белгертәчәк: «Зинһар, болардан котылыйк, Нурулла. Коткар, авыл нәжескә батты, Нурулла!»

Әмма, ни гаҗәп, ни яше, ни карты рәискә мондый гозер белән килмәде. Бер көн көтте Нурулла, ике көн көтте, өч көн көтте... Аннары ул үзе дә икеләнә башлады. Буяласы буялган инде... Әллә тимәскә микән? Хуҗалык өшәнгән, җирләр сөрелмәгән, сыерлар картаеп, сөтен киметкән иде. Бердәнбер карап торган нәрсә — шушы тукмак борыннар. Җитмәсә, ярты авыл халкы фермада ябырылып дуңгыз карый, аның да бердәнбер эше-ашы шул мыркылдыклар иде.

Тик, нинди генә акланулар тапса да, Нурулланың җаны тынычланмады. Авыл өстендә ят ис бар, һәм ни җилле көннәрдә дә ул таралмый, сулыш юлларын әрнетеп, тынны кыса иде.

Өч айда тәмам ябыкты Нурулла. Ә бер көнне... Хәер, таң сызылган иде инде. Ул уяу иде, күзен түшәмгә төбәп, чәбәләнгән уйларын бер җепкә тезмәкче иде, гәүдәсе кинәт кенә, авырлыгын җуеп, караваттан күтәрелгән сыман тоелды. Ир хатынына эндәшергә теләде, әмма теле көрмәкләнде. Төртеп уятмакчы иде, кулы селкенмәде... Кинәт аны торгызып, аягына бастырдылар. Ир, күзен уып, алдына карады. Ямь-яшел уҗым кырында — озын өстәл артына ап-ак киемле, ап-ак чәчле бабайлар тезелешеп утырган иде. Түрдәгесе Нуруллага эндәште:

— Йа, углан, син иманыңны каралттың, вәләкин без сине хөкем итмибез, без сине мотлак кисәтәбез: хәрәмны себереп түкмәсәң — авылың бетә, углан!

Ул:

— Бәй, син ерак Киләхмәт бабай түгелме соң? — димәкче иде, гәүдәсе, төртеп еккан төсле, ятагына ишелде.

— Нурла, нишлисең син?! Ник ыңгырашасың?! — диде хатыны.

— Төшемдә... төшемдә... кисәтәләр...

— Нурла! — Саҗиданең чәрелдек тавышы колак пәрдәсен зеңгелдәтте. — Аяклары бозланга-ан! Үлде, и Ходаем, үлде-е-е!!!

...Ул караңгы тыкрыктан каядыр очты. Алда гаҗәеп матур нур балкышы иде, ир шуңа орынам дигәндә генә катгый боерык ишетте:

— Борыл, кире борыл, Нурулла! Дөньялыкта бер бурычың үтәлмәгән, Нурулла-а-а!

Керфекләрен күтәргәч, ярымкараңгылыкта күрде: ак киемле берәү аның өстенә иелгән иде. Өлгергән карабодай төсендәге ике күз — Туйбикә күзләре иде... Нигә дәшми ул? Нигә аның иреннәре дерелди?

— Төш, төш кенә... — диде ир, сөйләшергә мәшәләнеп. Янәсе, үлмәгән Нурулла, янәсе төш кенә күргән.

— Тс-с, авызыңны яп! Хәл җый, син әле генә теге дөньядан кайттың. — Туйбикә бармаклары белән аның чәчен «тарады». — Ярый шоферың җәһәт китерде. Хәзер син үзәк хастаханәдә — реанимациядә, Азизов.

— Үлмәкче идем, димәк. Кара син, ә! Син коткардыңмыни?

— Кизү идем. Үлсәң, белмим, нишләр идем...

— Сиңа ни... Яшәдем ни, яшәмәдем ни...

— Ни шул, ни!

— Кайчан аякка бастырасың, Туйбикә?

— Ай ярымнан, Азизов. Йә, йокла!

Йодрык хәтле генә йөрәк әвен кебек ирне үз кубызында шактый гына биетте: Нуруллага өч ай буе дәваланырга туры килде.

...Төш бүтән кабатланмады.

...Таякка элгән сыман ябык гәүдәсендә җилфердәгән пиджагының соңгы төймәсен каптыргач, Нурулла:

— Хуш, мин әзер, — диде. — Безнең бүген җыелыш, бичәсе.

— Савыгыр иең әүвәле, Нурла.

— Мин тере, мин исән, бичәсе!

— Йөрәгең зәгыйфь әле...

— Шым бул, бичәсе! Адым саен чир белән авыз чайкама! Минем Чурайбатырларга тәҗел сүзем бар!

Клуб кәбестә басуы кебек яулыклы-бүрекле «башлар» белән чуарланган иде. Әһә, һәркем могҗиза белән күрешмәкче! «Нуруллага тегеннән бик күп нәрсәләр әйтеп җибәргәннәр ди. Үлеп терелгәч — әүлия өммәтеннән икән Нурулла... Баш түбәсендә нур балкый икән...» — бу чыш-пышлар көлке иде, билләһи. Җилдән яралган әлеге матур гайбәт өчен кайсысын тотып ярасың ди, йә?

Урман сыман шавылаган халык ул сәхнәгә менгәч басылды.

— Нишләп кул чапмыйсыз? — диде Нурулла, авылдашларының энә күк чәнчегән карашыннан өшеп. Аңлашулары җинел булмас ахрысы. Авыл өстендәге сасы ис клубка да тулган иде. Кешеләрнең өс-башларына ук сеңгән бугай. Менә хәзер һәркайсының киемен салдыр да утка як, чөнки ят ис юып кына бетмәячәк. Ә нәҗес агызып көйдергән-яндырган үле туфракта илле ел бөртек чәчмә!

Арткы рәтләрдән берничә ир күңел өчен генә дигәндәй учын учка шапылдатты.

— Ярый, алкышламагыз, мин артист түгел бит, — Нурулла терсәге белән трибунага таянды. Ышан бу хыянәтче йөрәккә! — Җәмәгать, фәрман нигезендә өч көннән дуңгыз фермаларын ябабыз!

Берәү таягы белән шак-шок идәнне кыйнады. Мирхан мулла!

— Кем фәрманы ул, кем, Сафиулла углы? Шәрехлә! Безне томана сарыкка санама, теге, кем, иптәш прсидәтел!

— Күкләрнеке! — Нурулла бармагын түшәмгә кадады һәм соңгы арала булып узган хәлләрдән соң суынып, тыныч кына тамырларында агарга тиеш кан, кисәк кайнарланып, аның башына йөгерде. — Син, Мирхан абзый, халыкка хәрәм белән хәләлне аерып күрсәтәсе дин әһеле, ни оятың белән кысылып сорау бирәсең монда?!

— Тукта, энем, тукта! — Карт урындыгыннан күтәрелде. — Бүгеннән мин муллалыкны ташладым. Ничу ягылмаган салкын мәчеттә аяк туңдырып, өч тиен сәдака көтеп утырырга! Сорау да бирәм, кысылам да, авызымны ябалмассың, нибуч! Фермаларны тузгытып син халыкны ризыктан өзәсең түлке, Сафиулла углы. Ысталин заманында сине баганага терәп атарлар иде, син — халык дошманы!

Зал төркемнәргә бүленеп бер-берсе белән ызгышырга тотынды. Ук төсле һавада сүзләр «сызгырышты». Әйтерсең, клубта мәхшәр купты. Йа, болар аның белән гомер юлыннан атлаган агай-энеләр, апа-абыйлармы соң? Ниһаять, бу Чурайбатыр авылымы? Моннан өч ел элек урамда койрык болгаган һәр эт Нуруллага таныш иде. Ул аларны өргәненнән үк аера иде. Авылдашларының олысы-кечесе аның җандашы кебек иде. Ә бүген ир бөтенләй башка мәмләкәткә эләкте шикелле. Егерме ел дәверендә ул аларны беләм диде, хәтта ки масаеп әйтте: «Сезне үтәли күрәм», — диде. Белми. Һәм үтәли дә күрми. Җитмеш җиде кабык белән чорналган болар... Белми... Ни кызганыч! Ә менә аны белергә тиеш авыл! Рәисләре мескен, көчсез, йомшак Нурулла түгел икәнлеген танырга тиеш, ахыр чиктә! «Сиңа кычкырырга ярамый, хәзер син — әүлия», — дип хатыны күзгә төтен өрә. Юк, ул әүвәлгечә патша. Каты

куллы, кырыс, усал һәм берникадәр микъдарда явыз патша! Шулай булмаса, авыл бәйдән ычкына.

Залда болытларны бер-берсе белән чәкәштереп, яшен чаткылары уйнатып, күк күкрәде. Нурулла үзе дә шаккатты. Элек аның тавышы болай ук зәһәр түгел иде.

Колаклары ярылдымыни, бермәлгә халык минкегән төсле, авызын ачып, тынып калды. Үзалдында мыгырданган Мирхан карт кына таягын идәнгә кадый-кадый ишеккә табан юнәлде.

— Җәмәгать! — Инде хәзер тавышны әз генә йомшартырга кирәк иде. — Сез акырышканда сүзләрегезне иләктән сөзеп тыңлап утырдым. Кемдер бала укытам, ди, кемдер йорт төзим, ди. Кайсыгыздыр машинага акча җыя. Операция ясатам диючеләр дә бар. Һәрберегез дә акча, ди. Мин ике сөйләшмим, әйттем икән, тимернең калын башыннан бөгәм! Элек яшәдек бит, хәрәмгә кул тыкмыйча да мал таптык. Киләчәктә дә яшәрбез! Миңа вакыт бирегез: ярты елда хуҗалыкны тергезәм мин, Алла кушса! Вәгъдә — иман!

Шунда урамда җырлап йөргән иләс-миләсрәк Фатыйма карчык:

— Ышаныйк без рәискә, җаныйлар. Әүлия кеше алдашмас, бәлдыгый, — диде.

**2**

Белми, хак. Алар аның өчен — авыл кешесе. Эш кешесе. Рәис аларның чиләк, сәнәк, көрәк күтәргән кулларын, елмайган яки хәсрәтләнгән күзләрен генә күрә, ә эчләрендә ни-нәрсә кайный? — анысы аңа караңгы. Анысын ул тоймыйсызми. Әгәренки, Аллаһы Тәгалә бер кодрәт белән унҗиденче гасырга кайтарса, һәм авылга тәреләр белән бәреп керсәләр, арада дошман белән якалашырлык гаярь Киләхмәт бар микән? Кем ул? Кайсы урамда, кайсы йортта яши? Белми Нурулла. Батыр янында куркак та йөри. Анысы кем тагы? Киләхмәтне Себергә озаттырган ялагай адәм кайсысы? Кичер, Ходай, ул авылдашларына бәнахакка гаеп ташламый, ул бары тик шахмат тактасындагы кебек «ак» һәм «каралар»ны тормыш тактасына күчереп урнаштырып кына карый. Бәлки, иң зур гаеп Нурулланың үзендәдер? «Халыкның тамагы тук булсын», — диде ул, икмәген, печәнен җәлләмәде, капка төпләренә китереп аудартты. Кесәсендә акчасы булсын, диде, тиененә кадәр айныкын айга хезмәт хакын түләттерде. Йорт тергезсен, авылда төпләнсен дип транспортын кызганмады. Автобусларга төяп (сирәк кенә билгеле) театрларга да йөртте. Баксаң, тамагы тук, өсте бөтен авылның иман баганасы бармак белән төртсәң — ава икән.

Хастаханәдә телефоннан шалтыратып хәлен сорашканда хакимият башлыгы (инде элеккеге башлык дияргәдер) атна ахырында Чистайга күчәм, дигән иде. Соңгы тапкыр күрешәбездер, бәлки, хуҗалык рәисләре дә киләдер, мин дә озатырга барыйм, дип Нурулла үзәккә китте. Ләкин берданбер озатучы кеше ул гына иде.

— Так-то, брат, — диде кичәге хакимият башлыгы, — тәхетеннән артыңа типсәләр, янындагы тугры вәзирләрең тараканнар кебек ярыкка шыла. Сиңа рәхмәт, Азизов. Мине сукмә, мин начарлык эшлим дип эшләмәдем, хуҗалыгың баер дип ялгыштым. Ярдәм итә алмыйм, кулымда власть юк бүген. Бу ситуациядән ничек чыгарга уйлыйсың? Все-таки син башлы егет.

— Яңа ферма төзеп, терлек белән тутырыр өчен биш миллион тирәсе акча юнәтәсе иде.

— Слушай, Азизов, выход бер генә: Минһаҗевтан сорап кара. Бүген Татарстанда иң бай кешеләрнең берсе. Саран мужик түгел.

Минһаҗев, Минһаҗев... Әзрәк якташ та бит әле ул. Мәктәптә, туган як тарихын өйрәнгәндә, шунысы ачыкланган иде: Минһаҗевлар нәселенең тамыры

— Чурайбатырда. Аларның борынгы бабасы Нуретдин хәзрәт авыл зиратының иске өлешендә күмелгән диләр. Ә хәзрәтнең балалары яшьтән үк, төрлесе төрле якка сибелгән, имеш.

«И Аллаһым, шушы бәндәң белән очраштырсаң иде», — дип, теләк теләргә генә кала иде. Беркөнне сәркәтип кыз, сулышына кабып, аның бүлмәсенә керде.

— Нур.. Нурул... Нурулла абый, кәнсәләр кырыендагы солдат сыны каршында теге дәү абзый... Соң теге телевизорда күрсәтәләр бит инде, гел-гел Президент янында чуалган дәрәҗәле абзыйны, шул тактадан фамилияләрне укып тора.

— Кем, кем? — диде Нурулла.

— Соң, табак битле, кин җилкәле теге абзый инде, Минһаҗев инде!

— Чакыр! Әй, тукта, хәзер үзем! Чакырып кертергә малай-шалай мәллә ул сиңа? — дип, иненә костюмын элеп, Нурулла тышка ашыкты. Ахырзаман могҗизасы, валлаһи. Кемне күрәсең килсә — шуны каршына китереп бастыра Ходай.

Ак күлмәгенең җиңен терсәгенә кадәр сызганган кунак Нуруллага җилкәсе белән тойгандай:

— Нихәл, энекәш? — диде. — Күп кеше үлгән икән авылыгыздан. Яшьяшьләр һәммәсе. Ай-яй, сугыш кырган ирләрне.

— Исәнмесез, Вәкил Минәхмәтович? — Нурулла ана кулын сузды. — Мин колхоз рәисе Азизов идем.

— Кем атлы?

— Нурулла.

— Тумышың белән Чурайбатырныкымы?

— Үзенеке, әйе.

— Рас син шушы авыл егете икән, үзең хуҗасы да икән, минем сиңа зур үтенечем бар, энем Нурулла.

Үтенеч?! Мондый кодрәтле затның җан тәслим кылган хуҗалык җитәкчесенә нинди йомышы төшәр икән, ә? Аның кулында тылсымлы таяк лабаса: бер селкесә йөз үтенечен үтәргә әзер йөз гыйфрит (тән һәм җан сакчылары) бәбәкләрен тәгәрәтеп: «Баш өсте, боер, хуҗам!» — диячәк.

— Олыгаябыз, Нурулла энем. Көнелләр нечкәрә. Нәсел-нәсәп турында уйланабыз. Кем без? Кайдан без? Бер галим: «Әйдәгез, шәҗәрәгезне төзим!» — ди. Без ваемсыз идек, ата-бабаларыбызны барламадык. Әткәй утызбиш яшендә үлде. Хәтерлим, без чыгышыбыз белән Чурайбатырдан, без Минһаҗ нәселенең бер тармагы, дия иде. Менә шул, Нурулла энем. Сәлимгәрәй бабай мин туганда ук вафат иде инде. Мәйтәм, Чурайбатырны урыйм булмаса. Бәлки, авылыгызның картлары Минһаҗ бабайдан хәбәрдардыр, мәйтәм. Балачакта әби-бабайларыннан нидер ишеткәннәрдер, мәйтәм. Кайбер нәселләр халык хәтерендә сакланып, буыннан-буынга күчә.

— Вәкил абый, ә нишләп сез Нуретдин хәзрәт турында сорашмыйсыз?

— Нинди Нуретдин хәзрәт ул?

— Берничә гасыр элек безнең Чурайбатырда Сергач якларыннан улын ияртеп яшь кенә тол мулла атлар сатып алырга килә. Кире китми, бер кыз белән никахланып, авылда төпләнә. Ул сезнең бабагызның атасы — Нуретдин хәзрәт. Нәселегез очы аңардан башлана.

— Чынлапмы? — диде кунак әсәренеп. — Менә сиңа иске яңалык! — Минһаҗев түш кесәсеннән куен дәфтәрен чыгарды. — Нуретдин дисеңме, энем? Вәт рәхмәт яугыры!

Күр, балалар кебек сөенә! Югалткан уенчыгын таптымыни! Кемгә нәстә — кәҗәгә кәбестә дигәндәй, Минһаҗевта — нәсел шәҗәрәсе, ә Нуруллада

акча хәсрәте. Сора, хәзер үк сора, жебегән! Кыюлыгың житмиме, Азизов? Уңайсыз, әйеме? Әрсезлек — ярты бәхет, диләр, ә сиңа ул тулысы белән кирәк. Чурайбатырны яшәтер өчен!

— Вәкил абый, Хәтимә әбигә барып карыйк без. Авылда иң олысы ул, аңа йөз яшь. Хәтере яхшы. Революция еллары турында әле дә сөйли ди оныкчаларына. Башта Чурайбатыр белән таныштырам үзегезне.

Нурулланың исәбе — Минһажевны ничек тә озаграк тоткарлау иде. Дәфтәргә исем теркәп кенә шәҗәрә ботакларында яфрак бөреләнми ул. Башта син бабаңнар салган сукмаклардан атлап йөр, алар сулаган һаваны сула, алар чәчкән-урган кыр-басуларны әйләнеп, кайчандыр шул туфракта үскән бодайның тегермәндә тарттырылган онынннан пешерелгән ипекәйнең исен иснәп кара. Еллар агышы белән бергә гасыр җилләре китерер бу татлы исне! Шуннан соң шәҗәрәңә дә җан өретелер, түрә абзый!

— Мин ашыкмыйм, — диде кунак.

Авыл тарихын сөйли-сөйли Нурулла аны кан кардәшләр иманын яклап көрәшкән тау сыртыннан уратты, салкын чишмәдән су эчерде, иске зиратны күрсәтте һәм, Минһажев, ни гаҗәп, түрә гадәте белән әледән-әле беләгендәге алтын сәгатен капшамады. Ул, чынлап та, вакыт белән исәпләшми иде. Төшке ашка Нуруллаларга керделәр. Чәйләгәч, кунак:

— Энем, — диде. — Мин сезнең авылга шәҗәрә өчен генә тукталмадым, — диде. — Анысы да кирәк, оныклар әнә: дәү әти, мәктәптә инша язабыз, җиде буын нәселеңне ачыкларга, диләр. Син бабайларның исемнәрен сана әле, дип аптыраталар. Оят, әти, Сәлимгәрәй бабай, аның әтисе Минһаждан гайре миндә мәгълүмат юк. Инде менә Нуретдин хәзрәт диденң син.

Нурулла җайсыз гына сүз кыстырды:

— Нуретдиннан ике углан туа. Ата — бер, ана — икенче. — Беренчесе — үзе белән Сергачтан иярткәне, икенчесе — Чурайбатырдагы яшь бикәдән. — Мин мәктәптә укыганда Хәтимә карчыктан балалар сөйләтеп яздырган иде. Ул угланнарның олысы — сезнең бабагыздыр, Вәкил абый. Кечесе — Гыйләҗетдин атлысы — соңгы никахыннан.

— Шушы Гыйлаҗетдин сызыгы табышмак та инде миңа, энем, — диде Минһажев. — Төп бер, тамыр бер, агач бер, ә яфраклары төрле-төрле, шайтан алгыры! Сүгенсәм, гафу ит — Вәкил, йодрыгын маңгаена терәп озак кына уйланып утыргач: — Да-а, энем, — диде. — Минһажныкылар барыбыз да җигелеп тормыш арбасы тартабыз. Кыскасы, тырыш без. Ерак бабай мәдрәсәдә укыган, Бохарада дин гыйлеме эстәгән, мәчетләр тергезешкән, шәкертләр укыткан, кызыл мал белән сәүдә иткән, диләр. Әткәй мәрхүм япь-яшь килеш завод директоры иде, ә аның атасының, ягъни минем бабайның Казанда өч кибете булган. Минем, шөкер, кесәмдә ике диплом. Мәскәүлеләр белән ярышырлык бизнес хуҗасы. Абзаң мактана димә, энем. Хәзер ни өчен уфырганнарымны анларсын... Менә сиңа ачыласы килә минем, энем Нурулла. Гыйлаҗетдин баба сызыгына карасаң — адәм хуры.

Минһаҗетдин бабайның газиз энесе Гыйлаҗетдин ни белән шөгыльләнде икән? — анысын теге галим архивта казынып чыгарса гына. Шәт, тапмас та. Рәтле шөгыле булды микән аның? Ник дигәндә, энем Нурулла, ул карт бурлыкта йөрмәде микән дип үземчә гөманлыйм. Чөнки аның улы мәчеттәге сәдакаларны урлаган, имеш. Галинур, ягъни яшьтәш туганым Фәритнең атасы, базарда теләнгән. Ә Фәрит... Мин аңа ничек кенә булышмадым, энем Нурулла! Туган, дидем, хур итмим дидем. Үзенә аерым эш ачтым — эчәгесе-ние белән сатып эчте. Машина бирдем — исереп бәрдертте. Бүген урамдагы сукбай сәрхушләр белән дуслашкан, фатирында эт оясы. Ник алай ул, йә? Бер кан юкса! Аптыраш!

Мине газаплаган сорау шушы иде, Нурулла энем. Чурайбатырда мона җавап табылмас микән дигән идем. Ничек табылсын, кайдан табылсын ди. Әткәйнең әллә шулардан җаны кыйналмаган дисезме!

— Ала биядән ак та туа, кара да туа, Вәкил абый.

— Шулай дип юат инде, энем Нурулла. Әйдә, нинди дер әби бар дигән идең.

Хәтимә карчык төштән соң йоклый икән, ишегалдында бераз уянганын көттеләр. «Кычкырып әйтегез, әбиебез колакка катырак», — диде киленнәре.

— Хәтимәттәй, син Чурайбатырның иң борынгы кешесе бит, — диде Нурулла, сандык өстендә тере курчак кебек утырган карчыкның иннәренә кагылып. — Хәтерең тутыкмадымы әле?

— Юк, олан, аяк кына сәләмә, баш әйбәт эшли минем. Син Сафиулланың игезәк сынары, төп колхоз хуҗасы да үзең. Ә бу кешене танымыйм, олан.

— Казаннан ул, Хәтимәттәй.

— Рибалүтсия турында сүләргә диме? Аттылар, олан, аклар тау башыннан, кызыллар елга ярыннан. Безне әбекәй базга яшерде, олан.

Нурулла карчыкка җәелергә ирек бирмәде:

— Син, Хәтимәттәй, шуны әйт безгә: балачагыңда олылар ни сөйли иде?

— Ир-атның телендә сугыш ие, кыз-катынның гайбәт ие инде.

— Нуретдин хәзрәтне телгә алалар идеме соң, Хәтимәттәй?

— Алалар ие, олан. Борынгы мулла ул Нуретдин атлы кеше. Без сабый чакта аның хакында риваять бар ие.

— Нинди риваять, Хәтимәттәй?

— Җандарлардан җик күргән хәзрәтемез, имештер, дия ие әбекәй. Мәсҗеден яндырганнар, мескенемнең. Үрәтмә дин сабагы диептер.

— Җандармнар эзәрлекләде микән? — диде Минһаҗев.

— Шуның белән тәмаммы риваятең, Хәтимәттәй? Азагы юкмы? — дип, карчыктан җеп очы тарта торгач, әбиең әйтеп куйды:

— Ансы гайбәт, олан. Сүләтмәгез, җаны бимазаланыр. Әрвахларга фанилыктагы һәрни мәгълүм, фәрештәләр начар язар Хәтимәттәгезнең ләүхелмәхфүз тактасына.

— Әбекәй, менә бу зур кунак — Нуретдин хәзрәтнең оныкчаларының оныкчасы.

— Җә, әлсә, гөнаһысы сезләргә — сорашкан бәндәгә. Әбекәй әйтер ие: хәзрәт ат яраткандыр, җәйләүләр аның бия-колыннары берлә тулгандыр, дияр ие. Гыйлеме диңгез күк тирәндер, дияр ие. Халыкның сөйкемле сөяге, дияр ие. Беттән — бет, эттән эт туа, оланнар. Әбекәй әйтер ие: хәзрәт яшь нәмәстәдән уңмаган, дияр ие. Гыйшык ни зиһенлене дә саташтыра, Нуретдин бабакаемыз, бичарамыз, үзенә тиңне ярәшмәгән икән лә шу-ул, гүзәл сыннарыннан биһуш булып, алак-шалакны куенына сыендырган икән лә. Нәсел-нәсәбен үрәнмәгән, чит-яр җир баласы шу-ул. Яшь катыны батрак җегет белән шаярып кара тутлы малай оланы бәбили. Хәзрәтемез, сабыр, изге, талак кычкырмаган катынына, дияр ие әбекәй. Авылга ис-тын чыгармаган, имештер, төпчекне үз угланы итеп мәсҗед кыйтабына теркәгән, имеш. Гайбәт, олан, хәшәрәт чебеннән яман, кай ярыктан да очып чыга. Төпчек ир углан исәйгәч, малайларны ияртеп авылдан чыгып киткән ди Нуретдин. Хурлыгыннандыр, олан. Катыны белән батрак җегет, ике ялкау, хөрәсән, аның мал-мөлкәтен туздыргач, койма-капкаларына тиклем сүтеп яккан дияр иде әбекәй. Янып үлгән алар соңра. Алла тоткан үзләрен.

Минһаҗев ухылдап куйды. Аның дулкынланудан йөзе кызарган, маңгаенда тир тамчылары җемелди иде.

Ул жилкәсен рәтләгәндәй хәрәкәт ясады. Күкрәк кыса бугай — матур хәбәр түгел.

— Минә кайда икән хикмә-әт!

Нурулла янадан карчыкның колагына иелде:

— Хәтиматтәй, хәзрәт шуннан соң Чурайбатырда бер дә күренмәде микәнни?

Карчык чепи күзләрен челт-мелт йомып:

— Тавыкларнын жиме бетте, олан, — диде. — Киленем әпәй турап сибә. Расхутланабыз зерә дә, олан.

— Миннән ике капчык бодай бүләк сиңа, Хәтиматтәй. Сәәлемне янадан кабатлыйммы?

— Күренмәгән кая ди хәзрәтемез. Аның, олан, гыйлем китаплары тау-тау дияр ие әбекәй. Ул аларны тимер сандыкка бикләп, янган мәсҗед нигезенә күмгән дияр ие.

— Шуннан ни, Хәтиматтәй?

— Әбекәй тагы да әйтер ие, хәзрәтемез изге китапларын юллап Чурайбатырга кайтыр да, урамда вафат булмыш, дияр ие.

— Әһе, кабере иске зиратта, димәк, — диде Нурулла. Ул инде хуҗалар белән саубуллашмакчы иде, карчык сискәндереп:

— Жук, кабере анда тегел, — диде. — Авыл халкы аның җәсәден жандармнардан качырып имән төбенә жирләгән, дияр ие әбекәй. Без бала вакытта шунын янында чуерташ чөеп уйныйдыр иек, олан. Иманен яшен ташы атып чәрдәкләгән ие. Мин әйтмәдем, олан, минем авыз сүзе тегел, олан. Блачлар белсә, мине өтермәндә черетер, хәзрәтемезнең каберен пыран-заран итәр. Аллам сакласын, олан!

— Каберләр туздырырлык власть юк инде бүген, Хәтиматтәй. — Нурулла беркатлы кортканың кулыннан сыйпады. — Борчылма, яме? Безнең әткәй курыкмаган әнә, иң кара елларда да аның черегән чардуганын янарткан. Картлар әүлия жирләнгән диләр иде, ә безгә ни, бер кабер шунда. Безне бит мәктәптә «үткәндәгеләр искелек калдыгы» дип өйрәттеләр.

Ике ир беркавым урам уртасында таптанып тордылар.

— Син миннән көләсеңдер, энем Нурулла. Казан бае вакланып нәселен тикшерә дисеңдер. — Минһаҗевнең йөзе комач кызыл иде. — Нуретдин бабайның рухы рәнҗемәс микән минем бу кыбырсуларыма?

— Вәкил абый, әнә теге тавылы урам ягына карагыз әле. Анда иске генә таш бина күрәсезме?

— Күрәм, энем.

— Чистай сәүдәгәре Фәтхулла абзыйның кибете була ул. Революциягә кадәр. Стенасы калын, кирпечен йомырка сарысы кушып сукканнар, ахры, каты, кувалда белән бәр, уалмый. Бер елны Фәтхулла абзыйның варислары җыйнавылашып кайтты. Кибет безнеке, диләр. Сәүдә оештырабыз, диләр. Оештырыгыз, дибез, жирле үзидарә рәисе белән. Карый болар, бина ташландык, түшәме мүкләнгән, идәннәре жир белән тигезләнгән. Тимер ишек кәкрәеп янтайган. Әгәр дә төзекләндерсәң, тагын өч йөз ел жимерелми. «Әй, бу чыгымлы икән, без аңардан ваз кичәбез, безгә компенсация генә түләгез», — диләр. Уйнап кына:

— Аның нигезендә алтын-көмеш тулы чүлмәк бар, казысагыз, яртысы сезгә, — дигән идем, күселәр төсле кибетнең нигезен актарып салганнар, сиңайтим! Менә ваклык кайда ул, Вәкил абый. Ә сезнең очракта, нишләтәсең, дөреслек төтен белән бер, күзне әчеттерә!

— Шикләнгән идем аны, энем Нурулла. Сизенү көчле икән миндә, их, тот

якасын! Сүгендермә, язмыш! Гыйләҗетдин бабай нәселе үзгә тармак икән. Атасы да, Фәрит тә төс-кыяфәте белән безнең якка охшамаган: алар кыска буйлы, кысык күзле, ә без — табак битле, киң җилкәле. Фәритне туганым дисәм, беркем дә ышанмый.

— Үги туганыгыз инде ул, Вәкил абый.

— Шулай, хакыйкатьнең төбенә төштем дип аны туганнар исемлегеннән сызып ыргытып булмас. Нуретдин хәзрәтнең рухы рәнҗер. Чит ояныкы димәгән, батрак малаен үзе белән алып киткән бабай. Йа, энем Нурулла, безнең сәяхәт тәмам. Синең хәлләрең ничек? Авылыгыз төзек, клубың, мәктәбең таштан, юлларың асфальт.

Аһ-зарларыңны түгәрлек бик җайлы вакыт иде бу. Бай түрә алдында гозереңне ярып сал!

— Хәлләр чыдарлык, — диде Нурулла. — Сезнең белән Казанда очрашырга мөмкинме, Вәкил абый?

— Ә син шушы моменттан файдалан, энем. Бәлки, иртәгә минем вертолетым шартлар. Сора!

— Сора дип... Уңайсыз да инде. Аръякта яңа фермалар төзеп, сыер-тана кайтармакчы идем, эш акчага терәлә...

— Күпме?

— Биш. Биш миллион кирәк. Бурычка бир, зинһар! Алдына тезләнимме, Вәкил абый?

— Тезләнмә! Мин хатын-кыз түгел. Болай итәбез: ун миллион күчерәм счетыңа: Нуретдин бабайның чардуганын саф тимердән эшләттер, таш куйдыр. Хәзрәт җирләнгәнен белсен халык, яшь буын белсен. Мәчет салдырып, аның исемен куш, ярдәмгә мохтаҗ карт-корыга сәдака өләш — шулар өчен биш миллион миннән бүләк, ә яртысын баегач түләрсең! Килештекме, энем Нурулла! Иске мәчет нигезен казыттырма, бабай сандыгын берәрсе тапсын дип яшермәгәндер.

...Атау болыныннан күтәрелгән вертолетның җиле сап-сары чәчәкләрне «аяктан екты». Нурулла тузгыган чәчен бармаклары белән аралап артка сыпырды. «Тезләнмә, мин хатын-кыз түгел...» Зур кунак очты. Хәер, кунакның зурысы яки кечесе була микән?

Кунак — кунак инде ул.

## 3

— Авылда минем турында ниләр сөйлиләр, бичәсе?

— Кәкре каен тузына язмаган нәрсәләр шунда.

Нурулла аш тәлинкәсен читкәрәк этәрде. Элек иртә китеп, төнлә кайтып, сизелмәгән генә икән: хатынының холкы таш төсле авыр, тиз генә кузгатам димә.

— Сәҗидә, нигә син мондый юаш-мескен соң, ә? Син бит колхоз рәисе хатыны, «мин кем!» дип күкрәк киереп йөр! Йә, нинди тузга язмаган нәрсәләр ул? Эчтәлеге нидән гыйбарәт?

— Фермаларга шаккаталар. Терлекнең күплегенә тагы. Ике айда житештерде, диләр. Мәчете дә яңа, диләр. Ни диим аларга?

— Аңа күктән алтын тәңкәләр яудырганнар, диярсең, бичәсе.

— Һи, тәңкә димиләр шул! Әүлия иренә рухлар булышамы, диешәләр.

Нурулланың йөрәге сыкрады. Хак, ырудашлары белми ул, белми! Әллә нишләде Чурайбатыр. Хәрәм малга буялганнан соң авыл күгендә иман нуры тоныкланды төсле. «Төсле» генәмени! Тоныкланды! Бүген таш мәчетнең манарасыннан азан тавышы ягырый, ә иман, куркып, бәнденең күңел ярыгына поскан. Их, сезне, авылдашлар!

— Сажидә, иске абзарлардан тукмакборыннарны җыештырганда, мөгаен, баш санын исәпләмәгәннәрдер. Имеш, безнекеләр чучка балаларын урлаганнар ди. Кемнәр икән алар? Ишетмәденме?

— Ишетмәдем, Нурла. Ник соң?

— Тик, — диде ир коры гына. Кайчакта хатынының аңгыралыгы аны пычаксыз суя иде. — Әзрәк эшем көйләнде, бүгеннән үк йорт саен йөрергә тотынам. Авыл белән өр-яңадан танышам.

— Кемнән башлыйсың, Нурла?

— Синнән, Сажидә! Егерме ел элек мин сине юлдан гына ияртКән идем. Атасыз үскән кыз идең. Ник син болай мыштым, ә? Җаныңда ниләр бар, әйдә, сөйлә!

— Быел безнең сыер кысыр, Нурла, — диде табын җыештырган Сажидә. Ул иренең төртмәле сүзләренә үртәлми иде. Боз кебек салкын һәм болытлы көн кебек төмсә хатын! Ә бит аңа алмаш бүтән иде. Туйбикә иде ул, Туйбикә... Үзенең туеннан качкан исәрбаш!

— Сөт эчәм дип балаларыбыз еламый әле, җиде-сигез айга түзәрбез, — диде Нурулла.

Ул беренче сәфәренең сукмагын уң кул күршесе Ибраһим карт йортыннан салырга булды. Бабай, тавышын акыртып ачып куеп, радиодан яңалыклар тыңлый иде.

— Бәракалла, синме соң бу, улым? — диде карт, радиосын тиз генә сүндереп. — Күземне җен бумыйдыр, шай?

— Мин, бабай, мин. Күршедә генә яшәсәк тә, керергә һич вакыт табылмый. Син ачуланма инде!

— Әй, улым, кем ачуланыр икән сиңа! Иртән дә калхузда син, кич тә калхузда. Йөрәгең түзсен генә.

— Сиңа да җитмеш биш тула икән, Ибраһим бабай.

— Җегетләр яшендә әле без, улым. Моның сере ни дисеңме? Хе-хе, мин дөнҗаны чиметеп кенә күтәрдем. Әнәгенәк, минем кордаш Мидхәт утыз ел элгәресе үлде. Чөнки дә дөнҗаны колачламактай кыланды. Пәтистинни агач йортын сүтеп, ташпулат тергезде. Турына фил тиклем машина бастырды. Каенатасы вафатының җидесенә нигезен сатты. Катынының апасын зар җылатып. Саймә җанвалид иде, аны психлар бүлнисенә яптырды. Кайтмаслык иттереп. Өч сарай, ике келәт, амбар тулы ашлык иде анарда. Нәпсесенә булашып җыйды байлыкны Мидхәт. Кем өчен, улым? Бер гуж тамак өченме? Мидхәткә Аллаһ бала-чагасын насыйп итмәде. Без аның белән бер юлдан бардык, ул дөнҗаны күтәрә-күтәрә бөкрәйде, ә мин учтагысына шөкрана кылдым. Ризыгым әзрәк кимесә — Аллаһы Тәгалә өстәде. Ә аннан, гүпчим, олавы белән аударды.

— Сиңа Финляндиядән доллар кучергәннәр ди, шул дөресме, Ибраһим бабай?

— Дөрес, улым. Әтинең энесенең малаеннан бүләк.

— Чит илдә туганнарым яши дип бер дә сөйләми идең.

— Ярамый иде, улым. Телне авызда бикләсәң дә таман гына замана иде кана. Мирсәлим абзый плингә төшкән безнең. Илгә сукмаклар ябык дип, ул фин мәмләкәтендә кала.

— Акчаларны ятим балалар йортына илткәнсең икән. Капка-коймаларың да иске иде.

— Мин тир түгеп тапкан малмыни, улым. Мужыт мине Аллаһы сынамак келәгәндер? Ибраһим колым мондый байлыкны күтәреп билен сындырмас микән дигәндер. Чү, улым, шайтан алдавычы акчаны куй әле син. Үзең соң, ничек, улым? Тегеннән кайтармыйлар диләр иде дә, кайткансың әле, шөкер.

— Әллә инде авылыгыз белән ычкынгансыз, Ибраһим бабай. Хастаханәдән гайре беркая да барганым юк минем.

— Сөйләмәскә кушсалар, сөйләмә, улым, — диде карт.

— Илгизләр өйдә микән? — Нурулла кырык ел тәрәзә белән тәрәзә күз кысышып яшәгән йортның капкасына байтактан бирле орынмаган иде.

— Илгизләр печәндә, улым. Зариф кордаш бакчасында бал суырта. Авыз иттерәм дигәние, Алла бирсә.

Зариф карт кордашы белән чагыштырганда үтә күренмәле пыяла: эче-тышы бер чама иде. Алай да хәлләрен белешергә кирәк.

Ир койма буена килеп картка сәлам бирде.

— Исәнме, Зариф бабай? Кортларын усал, ике тапкыр Сажидәне чаккан.

— Бал кортының угы файдалы, Нурулла. Сине үзем дә күрмәкче идем, ну койрыгың кыска, чаптың да чаптың, малайгынам. Атаң унган иде синең, син — аның дәвамы. Теге игезәк сынарың үшән берчәк. И-и, минем Мингалием белән яшьтәш идең син, Нурулла. Иртә хушлашты безнеке, и-и. — Зариф карт битлеген салып коймага сөялде. — Сорыймчы синнән, тегендә мәрхүм улымны күрмәденме?

— Кайда, Зариф бабай?

— Хи, тегендә, дим, әрвахлар илендә.

Нурулла кашын җыерды.

— Саташма инде, Зариф бабай.

— Туры бәреп соравым күнеленә ярамады, ахры, Нурулла.

— Шулай туры бәреп күп тапкыр маңгайны тиштең син, Зариф бабай! Хәтерендәме, мине рәис итеп сайлаганда кәнсәләр бинасы тузган иде. Колхоз акчасын әрәм итмим дип мин аны рәтләмәдем. Түзик, дидем. Ә син кердең дә, сәләмә бүлмәдә утырган председатель үзе дә сәләмә күренә, дидең. Хуш, гарьләндем дә, үз хисабымнан ясаттым кабинетны. Яңа җиһаз куйдырттым. Син тагын турыдан бәрдең:

— Аһ сине, оятсыз, колхоз акчасына бүлмәңне бизәндергәнсең-ясандыргансың, — дидең. Әйеме, Зариф бабай? Сиңа ничек тә ярап булмады.

— Кызма, Нурулла. Мин синнән ни печән, ни бодай сорамадым: Мингалине күрмәденме тегендә генә дидем. Начар кеше син, күрше малае. Әүлия исеме әрәм сиңа!

— Кызма, Нурулла, сабыр бул. Күрше хакы — тәңре хакы диләр.

Умарта оялары тирәсендә пыр-пыр әйләнгәч, карт кире коймага төртелде.

Балым быел тәмле, син дә тәмләп карарсың әле, Нурулла. Мингалиемне күрмәскә дә мөмкин шул син. Кайсысына эләкте икән, улым? Гөнаһлы да, гөнаһсыз да төсле иде Мингали, эһе. Үзеңне соң, Нурулла, әүвәл тәмугка яптылармы чистартырга? Туры җәннәткә озаттылармы?

— Тәмугка.

— Озак яндырдылармы?

— Юк, утыннары чи иде, — диде ир һәм китти генә: — Мәчетебез яңа, идәннәренә йомшак паласлар җәелгән, син, Аллаһ йортына якынай, бабай, — диде. — Шәт, мондый җүләр соравылардан телең тыелыр, — диде.

Өч йорт аша Фәнисләр тора иде. Яшерми Нурулла, колхоз рәисе булып эшли башлаганнан бирле бу гаилә белән аралашмады. Туйларында бәйрәм иткән иде, нибарысы шул. Тормышларын белә кебек. Хәзер кереп хәл-әхвәлләрен сорашып кына бернинди ачыш та ясамастыр, мөгаен.

Ир белән хатын печән өяләр иде. Юл кырыендагы клеверны чапканнар, ахрысы, икесенең дә өс-башы тузанлы иде. Быел хуҗалык өләшкән печәннәре

әз дисәң, колхозныкыннан һич ким түгел, вулкан тавы кебек олы гына кибән калыккан.

— Алла ярдәм бирсен, туганнар! Нихәлләрдә сез?

Хужа кибән башында иде, аның сәламен алган ишарә ясап, кул гына болгады. Илсөяр, сәнәгенә әләктергән печәнне иренә табан томырды да:

— Безнең хәлләр шундый, рәис иптәш, көн-төн нужа куабыз, — диде.

— Һаман житмимени?

— Олы улыбыз ипотекага чиратка басты. Ай саен егерме мең сум түлисе, ди. Ә аның хезмәт хакы ун мең тәңкә. Без булышмасак, хөкүмәткә кирәкмени безнекеләр!

— Сезнең Илдар мал табибы иде. Яшь белгечләргә йорт салырга ссуда каралган иде. Тынчу шәһәрдә аңа чүмече белән аш сосканнармы соң?

— Әй, Нурулла, саруымны кайнатмачы, йә! Үзебез төсле авылда интегеп яшәтәм ди балаларымны!

Нурулланың ирониясе Фәнискә әле генә барып житте бугай.

— Житми, яшьти. Биш үгез, дүрт сыер бер айда ярты кибәнеңне сыпырта.

— Эшләгез, соңрак тагын күрешербез, — диде Нурулла.

— Атасы, кибәннең уң ягы кабарган, ул төшен баскала, — диде хатын. — Тамагым кипте, су эчәм.

Илсөяр Нурулланы капка төбенә кадәр озата барды һәм аяк очларына караган килеш: — Ни, карале, син... — диде. — Оят та инде, Ходаем, сиңа бер соравым бар иде, Нурулла. Ир-ат кына жавап бирердәй сорау. Элек мин аны атып үтерәбез дисәләр дә синнән сорамас идем. Перси кешедән дигәндәй. Ә бүген бит син әүлия!

— Илсөяр, сез үз акылыгыздамы? — «Әүлия» сүзе баш миен кайната иде. Юри үртиләр мәллә соң аны, ә? — Мин бернинди...

— Чү әле, чү, Нурулла, чәпчемә! Син лутчы каршы якка бак әле. Бак, бак, сиңа, әүлия затына, кая караса да гөнаһысы юк.

— Гарифлар сезнең кебек үк печән өя, — диде ир.

— Безнең кебек түгел шул, агаем. Аерма зур. Гариф ялгызы гына мәтәштерә. Башта астан өскә ыргыта, аннан, кибәнгә терәтелгән баскычтан менеп тигезли. Ә хатыны Әнисә бакчада нишли? — жырлый-жырлый кура жиләге чүпли. Кышка витамин жыя, янәсе. Тик берне савытка, өчне авызына сала. Битенә нәстә сылаган — жиләк! Әгәр мин шулай кылансам — Фәнис үтерә. Мин гомер иргә куллаш идем. Мунча салабыз, диде Фәнис. Салдык. Бүрәнәнең бер башыннан ул, икенче башыннан мин тоттым. Гараж кирәк диде Фәнис — төзедек, мин кирпеч ташып, билемне имгәттем. Кое чистарттык, мин суынбалчыгын түктем. Ә каршы йортта гел икенче дөнья! Гариф Әнисәсеннән ярты чиләк су да ташыттырмый. Сыерларын үзе сава. Сандугачым дип кенә эндәшә ул хатынына, ә минеке «аңгыра», ди. Ник сез ирләр, шулай төрле-төрле итеп яратылгансыз икән, Нурулла?! Моның сере нидә, Нурулла?

Йөзе тузаннан каралган хатын кызганыч иде. Ул тырнак аслары керләнгән бармаклары белән юешләнеп чигәсенә сыланган чәч бөртекләрен яулык эченә төртә-төртә аңардан жавап көтте. Каян белсен моны Нурулла? Ирләр беркемнән бернәрсә дә яшерми, аларның күңеле — ачык дала. Ә менә хатын-кыз — карурман. Үз туеннан качкан Туйбикәнең жүләрлеген, йә, кем аңлата ала?

— Мин бу мәсьәләдә белгеч түгел, Илсөяр.

— Белгеч булмасаң ни! Аның каравы син әүлия!

— Тагын берегез әкият сөйли! Тамагым кипте дигән иден, Илсөяр.

— Кипмәде, Фәнис алдында юри әйттем.

— Яшәгәнсез бит инде, балалар үстергәнсез.

— Әй, сина сүз әрәм иткән мин — тиле! Ир кыяфәтендәге әүлия, билгеле, үз кавемен яклый, — диде хатын һәм шапылдатып капкасын япты.

Ул ике-өч адым атлаган гына иде, капка яңадан ачылды.

— Яшьти, ашыкмале! — диде Фәнис. — Хатын янында сүз алыштырырга кыен. Малайның коллыкка төшүенә эчем поша, яшьти. Банк миллион да алты йөз кредит биргән, ә малай аны ике ярым итеп кайтарырга тиеш. Монда авылда бер миллионга хан сарае төзи идек без. Син бит яшьти шәһәргә гел барасың, үгетлә Илдарны, кире кайт, диген. Китмәс тә иде, бәлкем, зараза белән фермаларны пычраттылар, ә аның катыборыннар белән дуслыгы юк иде, намазга керешкән иде. Әнә, хәзер яна фермада исәпсез-хисапсыз сыер, тана, сарык. Кинәнеп эшләргә мал духтырына.

— Илсөяр белән киңәш, Фәнис.

— Нәрсә дип? Син минем чәчбикәнең аждаһа токымыннан икәнен оныттыңмыни?

— Хатыныңны авыр эшләрдә кулдаш итеп имгәтмәгәең, Фәнис.

— Шилә имгәнер! Тимер ул Илсөяр. Аңа кем куша минем эшкә тыгылырга? Ярдәмгә туганнарымны да чакырттырмый, ашатасы, ди саран. Тыңлале, яшьти. — Фәнис тавышын әкренәйтте. — Нишләп минем чәчбикә тупас икән? — диде. — Гарифтан көнләшеп үләм, яшьти. Ну унды хатыннан, йомыкый! Әнисәсе әрәмә сандугачы төсле генә пыр-пыр оча да тирәсендә, иркә тавышы белән: «Гарифым, ярты жаным», — дип сайрапмы сайрый! Андый хатынны кочакласаң да саваптыр, яшьти. Вәт син шуны әйт миңа, нишләп хатын-кыз төрле-төрле икән? Адәм атабыз кабыргасыннан кисеп ясалгач, алар әммәсе дә бер үк төсле булырга тиеш түгелмени?

— Гаиләдәге тәрбиягә карый инде, Фәнис.

— Һы, тәрбия имеш. Әби белән бабай алтын минем, ә кызлары — аждаһа. Үлгәнче шуның авызыннан бөркелгән утта янармын микән инде. Син тагын шуны әйт, яшьти, тегендә һәммәбезгә дә хур кызлары беркетсәләр бу хатыннарны кая куярбыз икән?

— Фәнис, гафу ит, яме, син элек мондый түгел идең, — диде Нурулла. — Әйдә, ир башыбыз белән хатын-кыз чәйнәмик әле.

— Син дә элгәре бүтән идең, яшьти. Мактавылы перси генә идең, ә хәзер сине әүлия, диләр.

Бакча артыннан зәһәр тавыш ишетелде:

— Фәнис, эт бете! Кая олактың син?!

Күрше өйдә мөгаллимә Зәкия апа амәнәт итеп ана буыннан-буынга күчкән Коръән бүләк итте.

Тагын берничә өйгә сугылды рәис. Алжытты... Югыйсә кисми-турамый, өйми-ишми, авылдашларының жаны ни-нәрсә белән сугарылганны белмәк булып нибарысы капкадан керә-чыга гына иде. Тауга таш өстерәп менүен жинелрәк, ахрысы. Алжытты, валлаһи. Жеп өзәр хәл юк.

— Коръәнне күкрәгенә кысып кайт, балакаем, йөрәген савыгыр, — диде карчык. Мөгаллимә дә хәтәр ялгыша. Нурулла гөнаһсызмыни, йә? Бәлки аның бу китапка чәнти бармагы белән дә кагылырга хакы юктыр? Астан болыт та ак күренә, баксаң, аңарда да кара таплар бихисап: чөнки парга әйләндереп жирдәге пычрак суны «йота».

Ир мәчеткә табан атлады. Аның ишегенә амбар йозагы «асканнар» иде. Менә шулай, көннәрдән бер көнне адәмнең дә күңел капкасы бикләнәдер. Иман читтә генә сыкранып йөридер. Ә әрсез шайтан, йозак тишегеннән кереп, дөнья болгатадыр.

Жилкәдә, әйтерсең баш түгел, чуерташ тутырылган чуен чүлмәк иде.

Нуруллага аны бушатыр өчен нинди көч кирәк икән? Менә гомер икегә бүленде. Туйбикә: «Синең йөрәгең типми иде!» — диде, димәк, гомернең бер өлеше шуның белән тәгалләнгән. Үлеп терелгәннән соң аның икенче өлеше башланган. Ә йөрәк шул ук... Нурулла да шул ук... Хата-ялгышларына кадәр шул ук!

Кош оясы төсле түгәрәк чалма чәпәгән мулла килеп чыкты.

— Әссәламүгаләйкүм, рәис абый?

— Вәгаләйкүм-әссәлам, Руслан хәзрәт. Эшләр барамы?

— Бара, рәис абый. Йортны караштырдым, көзгә өлгертәләр, иншаллаһ. Бураң өчен Аллаһның рәхмәте яусын. Үзенә дип хәстәрләткәнсең диме?

— Рәхәтен күр, Руслан хәзрәт. Берьюлы ике йортта яшәмибез.

Нурулла монарчы хәзрәт белән йә урынбасарлары аркылы, йә ашыкканда юл өсте генә сүз алыша иде. Хәзер менә ичмасам иркенләп сөйләшергә җай чыкты. Мәчет боегып утырмасын, манарасыннан азан янгырасын дип рәис мулланы мөфтияттән чакырткан иде. Бүтән сәбәбе дә бар иде, билгеле. Чурайбатыр әзрәк иман сукмагыннан авышкан, аларны аклыкка-пакьлеккә өндәр өчен дин әһеле кирәк иде.

Тик халык Русланны тәкәббер ди икән. Менә хәзер шунысын да ачыкларга мөмкин.

— Без хәзрәтләрне парлы итеп күрергә күнеккән, — диде Нурулла,

— Мин дә Аллаһ ризалыгы белән никахланырмын, рәис абый. Күркәм холыклы, сабыр, итагатьле кәләш фарыз безгә.

— Чурайбатырда кызлар күп. Жаныңа якынын сайла, Руслан хәзрәт.

— Без — мөселман егетенә сезнең авыл кызлары хәрәм, рәис абый.

Нурулланың «чуерташ тулы чүлмәге»нә чүкеч белән суктылармыни, муены кәкрәйде.

— Ни-и-чек, энем?

— Авылыгызда чучка тоягы эзләре...

— Шуннан, энем?

— Чурайбатырда адәм баласы дененнән язган, шәригать кануннары буенча һәркайсына йөзәр камчы суктыру мәслихәт, рәис абый.

Нурулла әз генә хәзрәтнең баш түбәсендәге «кош оясы»н ишмәде. Ах, хәерсез, ничек кан кыза!

— Суктырсаң — кулың корыр, малай актыгы! Кирәксә, кешесенә карап мин үзем суктырырмын, моңа минем хакым бар. Шул «денсезләр» арасында тәгәрәп үстем мин! Ә син, йомыркадан борын төрткән чебеш, башта канатыңны жилпеп, кунакчага кунакла!

Ир йөрәгенең тибеше әкренәйгәнен тойды. Кызды, чамасыз кызды кан!

— Әйдә, Руслан хәзрәт, халыкка тимик, — диде ул. — Бөтен гаеп миндә. Аларның гөнаһын чиләге белән миңа аудар. Егерме ел тамаклары тук булсын дидем, иркен тормышта яшәсеннәр дидем.

— Аллаһ каршында синең гөнаһ миңа, минеке сиңа күчерелмәс, рәис абый. Котылу авылың белән дә, күршеләрең белән дә килмәс, һәркем аерым-аерым жавап тотар.

— Хуш, әлегә гөнаһларның эресен-вагын миңа өйик, Руслан хәзрәт. Чурайбатырны бетереп имансызга чыгарма син, яме? Хәрәм белән барыбызның да кулы пычранмады, ярты авыл дуңгыз фермасында эшләмәде.

— Бер риваять кылам, рәис абый. Фәлән шәһәрнең иң кырый йортында тәкъванең тәкъвасе яши. Бу намаз укый, аять-сурәләр ятлый, кояш баеганда, ай калыкканда сыктый-сыктый: «И Раббым, миңа җәннәтләреңне әйләсәнә», — дип ялвара икән. Аллаһу Субхәнәһу вә Тәгалә бервакыт искәртмәстән генә

таш-валчык яудырып каланы жир белән тигезләгәч, фәрештәләр: «Йа Раббыбыз, шәһәрдә бер диндар колың торадыр иде, ул да һәлак ителде», — диләр икән. «Ул да гөнаһлы иде, — дигән Кодрәт иясе. — Үзенә жәннәт ләззәте теләгәндә карендәшләрен онытты. Мина сәждәгә егылганда аларга да: «Әй ырудашларым, тәмуг газабыннан сакланыгыз, бозыклыктан арынып, калебегезне агартыгыз», — димәде».

— Әгәр син атлап-данлап безнең авылга кайткансың икән... — Нурулла шикләнгәндәй яшь хәзрәтнең күзенә карады: — Әллә сине Чурайбатырга ирексезләп кенә жибәрделәрме?

— Мәдрәсә тәмамлаган шәкертләрне авылларга тараталар, рәис абый.

— Ә-ә, син әле яна гына укудан өзелгән икән. Әле синең тагын икенчесендә — тормыш мәдрәсәсендә укыйсың бар, энем. Анысы гомерлек инде анын, гомерлек. Шунын яртысын узгач, син бүтәнчәрәк сөйләрсен: маңгайларыбызны таш белән ярмассың, камчы белән селтәнмәссең, киресенчә, һәркайсыбызны йомшак каз мамыгы белән сыпырырсын. «Дингә йомшаклык белән өндәгез», — дигәнме Мөхәммәд пәйгамбәр, ә, Руслан хәзрәт? Әгәренки мәчет ишегенә йозак салмасан, жомга намазларына яшен-картын үгетләсән — үземә йөкләнгән вазифамның тары бөртеге кадәрлесе үтәлде дип сөенерсең, шәт. Риваятендәге тәкъва кеше кебек үзенә генә иман ныклыгы сорама Ходайдан, Чурайбатырларга да котылу бир, диген, энем.

Яшь хәзрәт башын аска иеп дәшми-тынмый гына утырды. Нуруллага вәгазем үтемле булды дип сөенергә иртәрәк иде. Бәхәстә һәркем үзен хаклы саный, һәркем көндәшен жиңәргә тели. Бу егеткә бит инде үзенең генә сукмагы туры, ә башкаларныкы — кәкре дә бөкре. Ләкин, Нурулла, син дә сабыр бул. Бүген мин оттырдым дип килеш тә, чиген. Кайчакта мондый адым аклана да: арттагы кеше көтмәгәндә генә алга бәреп чыга...

— Руслан хәзрәт, мине тыңла әле. Безнең Чурайбатырда Зәкия исемле мөгаллимәбез хажи нәселеннән икән. Инсафлы, тәртипле карчык. Мәккәгә барасы иде, ди. Аны Хажның кагыйдәләре белән таныштырасы иде, — диде ул, күңелсез әңгәмәне йомгаклап. — Ничек, энем?

— Акчасы житәме? Аннан да битәр, хәләлме?

Бая гына сабыр төенен бәйләгән Нурулла тагын ычкынды:

— Бер елны аксакалларыбызны Мәккәгә жибәрергә жыендык. Моннан ун еллар элек район үзәгендә ни мәчете, ни дин әһеле юк иде. Киңәш-табышка Казанга киттек. Синең сыман яшь кенә хәзрәт пыр туздырды. Төкереген чәчә-чәчә:

— Бетәшкән картларыгызны кая озатасыз?! Аларга нинди Кәгъбәтулла?! Аллаһы һәркемнең йөрәгендә, аны шуннан эзләгез! Мәккәдәге таш мәжүсиләрдән калган! Пәйгамбәребез: «Бөтен жир Аллаһ тарафыннан намаз урыны итеп яратылган», — дип, дулап, өстебезгә акырган иде, Инсаф бабабыз мәчет бусагасында егылды да үлде. Син, энем, зинһар, мондый соравыларың белән Зәкия апаны тинтерәтмә. Мин өйләр төзешкән идем, акчам хәләл, мөгаллимәнең юл чыгымнарын үзем түлим.

Яшь хәзрәт чалмасын салып учында кыскалады.

— Син, рәис абый, мине дә дөрес аңла. Минем бу соравыларым табигый. Хаж кылуның беренче шарты: урланмаган, таланмаган, хәрәм белән табылмаган акча. Бүген дуңгыз сатып, иртәгә шуның тиярен учлап, хажга чапмыйлар. Ни белгәнемне аңлатырмын, иншаллаһ. Син үзең дә, рәис абый, акыл өйрәтергә оста.

— Остамыни? — Нурулла шаяртып киеренкелекне йомшартырга тиеш иде. Яшьләр белән телләшү жүнлегә илтмәс ул. — Әйдә, алайса, урыннарны алмаштырабыз, энем. Рәис эше жип-жиңел ул. Кыр-басуларда сөрәсең-чәчәсең,

урасын-суктырасын. Ә фермаларда сыер-тана үрчетеп, сөтен саудырасың, сарыкларның йонын кыркытасың, кыскасы, хөкүмәт планын үтисең һәм Аллаһ әппәр дип битенне сыпырасың. Ышана-ам, син минем урында эшләрсең, ә мин синекендә — юк. Синеке мең кәррә авыр, син бит адәм баласы карангыда адашмасын, калебе иман нуры белән нурлансын өчен маяк ролен башкарасың, энем.

Кибет тыкрыгында Нурулла Мирхан картны очратты. Арыдым бүген бу очрашулардан, туктап торыйм дип өенә юнәлгән ир аның белән исәнләшеп кенә узып китмәкче иде, карт таягын Нуруллага төрәде.

— Мина үчләшеп авылга мыек та үстермәгән япь-яшь сабый китерткәнсең икән. Урыс оланы диме?

— Руслан атлы ул, Мирхан абзый, — дип төзәтте Нурулла. — Хәзрәтнең исемен бозма инде син.

— Ай-яй, тәкәббер ди хәзрәтең. Андыйлар җәннәтнең исен дә сизмәс ди китап.

— Ә мин-минлек тәкәбберлекнең уң канаты ди, Мирхан абый. Мондый чирләрдән барыбыз да дәваланырбыз, иншаллаһ.

Кара, Нурулла хәзрәттән бер матур сүз дә отты түгелме соң? «Иншаллаһ!»

— Борын асты кипмәгән сабый безнең кебек тәҗрибәле олыларны ни-нәрсә белән куандырыр икән? Әкият-мәкиятләр беләнме? — Мирхан карт бәйләнчек чебенгә ошаган иде. — Гел кирегә сукалый ди урыс оланы.

— Кирегә дә сукалар, унга да сукалар, Мирхан абзый. Яшь чакта без дә шундый идек, — диде Нурулла. — Безгә хәтле беркем дә дөрес яшәмәгән, безгә хәтле беркем дә дөрес сөйләшмәгән, әйеме, Мирхан абзый? Хәтерлим әле, хуҗалыкның баш агрономы картайган иде. Мина рәис дилбегәсен кулыма тоттыргач, монардан шикләнәм генә бит. Авзал абзый басуларны дөрес бүлеп чәчтерми, ә менә мин анардан акыллырак та, белемлерәк тә, җирләрне үземчә «туракладым». Кукуруз — чөгендер кырына, чөгендер — бәрәңге басуына «күчте». Нәтиҗәсе шул: көзен берсеннән дә уңыш җыялмадык. Хәзер инде мин агач мылтыктан атабыз дисәләр дә алай эшләмәс идем.

— Син мине телең белән юмалама, рәис сынары! Күрә торып урыс оланын мәчеткә керттең, күрә торып! Мәхәлләдә тәртип сал дип мина ялынасы көннәрең алда синең. Ул талчыбыгы төсле килбәтсез ябык малайны җил манарадан очырачак!

— Ничава, Мирхан абзый, Чурайбатыр апалары пешергән бәлешләрне ашый-ашый тәненә ит кунар, иншаллаһ. (Әй, шушы җылы сүзне әйтәсе генә килә бит!) Әнә син парторг чагында арык кына гәүдәле идең, мулла булгач, мәҗлестән мәҗлескә йөреп сыйлана-сыйлана ничек симердең, ә!

Көлгән дә, елаган да бер авыз диләр.

Тик бүген авыз гына көлде, ә күңеле елады. Ир күңеле, югыйсә. Тупас тукымадан тегелгән, югыйсә...

...Нурулла Коръән китабын кочаклаган килеш уйга батты. Йә, бүләкне кайларга куйыйм дип аптырама, хуҗа. Син аны биек шкафның иң беренче бүлемтегенә куярсың, ә бу кыбырсык җанына урын кайда? Менә шунысы билгесез. Төшендә өстәл түрендәге ап-ак киемле бабайда син кемнедер төсмерләдең дә шикелле. Әллә ул ерак бабаң Киләхмәт идеме? Әнә, көзгегә кара, синдә аның чалымнары шәйләнә. Синдә Киләхмәт батыр каны ага! Ян-як урындыкларга тезелешкән картлар да таныш төсле иде. Аларның берсе Нуретдин хәзрәт түгел микән? Йөзе Вәкил Минһаҗевныкы кебек түгәрәк иде. Зәкия карчыкның хаҗи бабасы да бәлки шулар арасында утыргандыр, ә? Кырый урындыктагы картның күзләре, мөгаллимәнеке кебек нурлы иде...

— Нурла!

— Әү! — диде ир, сискәнеп.

— Ник үрә каттың, Нурла? — Хатыны анын касыгына төртте. — Даруыңны каптыңмы?

— Кайсысын? Агыңмы, сарысыңмы?

— Мин каян белим, Нурла?! Нинди төймә икәнен белер идем, мине бүлнискә якын җибәрмәделәр, Нурла!

— Кем җибәрмәде, Сажидә? Мин сине тыймадым.

— Кем, имеш! Туйбикә, Нурла!

— Шулай, шулай! Дула, тәртәләр ват, Сажидә. Рәис хатыны нинди гайрәтле икән дисеннәр. Алайса мыштымлыгын туйдырды, — дип көлде Нурулла.

**4**

Ул ишектә бармакларын биетеп алды. Кабинетта тынлык иде. Иртәнге обходта, димәк. Ашыкмады Нурулла, дивар буендагы йомшак кәнәфигә чумды. Туйбикә, Туйбикә... Үз туеннан качкан Туйбикә...

Авыруларның хәл-әхвәлен сорашып палаталарны йөреп чыккан бүлек мөдире озак көттермәде.

— О-о, бүлмәмдә тансык кунак икән! — диде ул гөлдерәп. — Син дөньядамыни, иптәш Азизов?!

— Дөньяда, әйе. Җәннәт сәкесендә аякны бөкләп җимеш ашарга җыенганда гына үзең кире сөйрәп кайтардың бит, Туйбикә.

— Һаман шаярасың, Азизов. Даруларыңны даими эчәсеңме? Әле синең йөрәк мускуллары зәгыйфь.

— Эчмим, бүтән рецептлар язма. Яшисе килә икән, үзе көрәшсен йөрәк.

— Авызыңда гел җүнсез сүз шуның! Ник килдең? Мине сагындыңмы әллә, Азизов?

— Сагынмадым. Нигә син реанимациягә Сажидәне кертмәдең?

Туйбикә эсселәнгәндәй халат сәдәфен чишеп, кулындагы кәгазь белән изүен җилләтте.

— Уф, бөркү!. Сине күрсәм, ялкынга чорналам, Азизов. Хатыныңа ни калган иде анда?

— Борчылган Сажидә...

— Юк, Азизов, хатының тыныч иде. Мин үлдем ул синең белән бергә, мин!!!

Нурулла бу ак канатлы фәрештәне кочагына кысып мең кат «рәхмәт» дип тәкърарларга тиеш иде. Һәм әйтергә тиеш иде: «Үтенне сытса да, дәвасы килешерлек бердәнбер дару ул син, Туйбикә!»

Ләкин ир кәнәфиеннән селкенмәде. Даруын дару ансы. Ә бит әүвәлесе чагып агулаган елан да шушы Туйбикә үзе иде!

Хатын тәрәзә кырыена басып борынын мышкылдатты. Газраил белән якалашып, Нуруллалны коткарган гайрәтле табибә димәссең, валлаһи. Каты балчык та уалыр икән!

Нурулла, ниһаять, урыныннан купты.

— Район киңәшмәсендә идем, сиңа да сугылыйм дидем, Туйбикә Зиннуровна.

— Сугылдың инде менә...

— Сиңа рәхмәтем чиксез, акыллым. Коры рәхмәт тамакны ерта ди, йә, боер, мин синең теләсә нинди капризыңны үтәргә әзер!

Туйбикәнең йөзе яктырды. Ул керфек очларында җемелдәшкән яшь тамчыларын озын тырнаклары белән каккалагач, елмаеп:

— Чынлапмы? — диде. — Син әкияттәге патша кебек ярты колхозымны бирәм димә. Мин мал колы түгел.

— Соң, чиреген генә бирермен.

— Шаяртма, Азизов. Минем каприз байлык белән бәйләнмәгән. Шалтыратырмын, көт.

Көт, әйе, көт, Нурулла. Җилбәзәк Туйбикә йөрәгеннән кан тамызырлык сюрпризлар ярата. Хәер, ана акыл тупларга вакыт инде. Табибә буларак аның кебек талантлы кеше юктыр, ә менә хатын-кыз буларак... Кайчакта иркә, назлы, мөлаем Туйбикәне танырлык түгел иде.

...Авыл читендәге бодае урылган камыллы басу турысында ул машинасыннан төште. Кыр җиле үзенә бер татлы, ул төрле тарафлардан җәйнең иң тәмле исе — икмәк исе белән буталып исә иде. Иртәгә арышка кушар, иншаллаһ. Әмма бөртек белән амбарлар тулмас. Нурулла өч ел ягада өйләр төзегәндә Чурайбатыр кырлары юньле-башлы сөрелеп чәчелмәде. Быел көздән үк җиңнәрне сызганырга кирәк. Орлык хәстәрен күреп чапмасаң — хәзерге кебек табанына камыл да кадалмас.

Ә яшәү барыбер рәхәт! Нәрсә ди Туйбикә? Синең белән бергә үлдем, диме, чибәр төлке! Бер китапта акыл иясе: «Гомер ике нәрсәдән: яратудан һәм сызланудан гыйбарәт», — дигән. Бу җөмләне укыгач көлгән иде Нурулла. Яшьлеге белән монын мәгънәсен аңламаган иде. Тән белән җан җыелмасы икән адәм баласы, аның бөтен яшәеше шушы ике ноктага буйсындырыла икән. Туйбикә әвендәй ир затын күпме сызландырды! Аңардан, билгеле, арынырга да була: моның өчен нибарысы Туйбикә белән өзелгән араларны гына ялгыйсы... Ләкин горурлык мең киртә кора! Әллә горурлык, әллә кичермәү... Соңгысы иргә хас та түгел. Юк андый ваклыклар Нурулладa, юк! Ә горурлык хәттин ашкан! Тау төсле ул, аны ни яңгыр, ни кар-буран йомшарта алмый.

...Нурулла өчен күрше авыл кызы чибәрләрнең чибәре иде. Дәрестән соң егет аны урман аша гына Шәрбәненә озата бара иде. Ике кулда ике сумка, ә янында алсу күбәләге — Туйбикә... Әй дөньясы түгәрәк тә соң! Урман авызында сукмак икегә тармаклана: берсе аланга табан сузыла... «Күбәләк», әлбәттә, үз «ишләре» белән күрешергә шунда «оча». Ни чагыштыр, ни чагыштырма, аллыгөлле «канатлылар» арасында да Туйбикә иң-иң гүзәле!

Чыгарылыш кичәсендә алар сыйныфташларыннан качып шушы аланга йөгерделәр. Аяк асты сап-сары май чәчәкләре белән «бизәлгән» иде. Туйбикә такыя үреп башына киде дә, чытыкланып:

— Мине яратасынмы, Азизов? — диде.

Авызына җилем ябыштыргандай дәшмәде егет. Йөрәк нарат ботагына кунган тукраннан да катырак итеп тукылдый иде. Яратмаган кая, җүләр күбәләк!

— Азизов, мәрткә киттең мәллә?! Яратмыйсың син!

Кыз ана такыясын томырды. Чәчәк бәйләме, күкрәккә бәрелеп, сүтелдетаралды...

...Туйбикә Чистай медицина училищесына имтиханнар тапшырганда зур укулар турында хыялланмаган Нурулла тракторга утырып җир сөрде. Игезәге исә агач эшенә оста иде, кечкенә генә пилорамда такта ярдырды.

...Өч елдан егет белән кыз кабат очрашты. Солдат шулпасы чөмергән Нурулла шәбәйгән, җилкәләре киңәеп, буйга үскән, ә Туйбикә һаман да учка бастырып биетерлек алсу күбәләк иде.

— Мин сине хәзер түш кесәмә салып өйгә апкайтам, — диде егет, батыраеп.

— Такыя үримме?

— Үрмә дә, теге сорауларың белән дә җөдәтмә!

— Жөдәтәм әле мена, жөдәтәм! — Туйбикә чәчәкләрне өзгәләп-өзгәләп атты. — Мине яратасыңмы, юкмы, Азизов дим?!

— Сон, йөрәкне тынла. Ишетерсен...

— Телен белән әйт!

— Әйтмим! Вакытым тар, хәзер безгә кайтабыз.

— Сезгә?! — Туйбикәнен күзе шарланды. — Ник?!

— Мин бүген сина өйләнәм, күбәләк.

Тып-тын алан жиде улактан аккан чишмә челтерәвенә күмелде. Өянәге кузгалгандай бөгелә-сыгыла Туйбикә көлә иде. Тик бу юньле көлү түгел иде шул.

— Берәү өйләнә ика-ә-ән... Үләм!

— Мин монын бер мәзәген дә күрмим, Туйбикә, — диде егет, житди генә. — Элгәре кызны ияртеп кайтканнар да, никах укытканнар.

Кыз тураеп, кулын бөеренә калаклады.

— Ә мин элгәреләр кебек жегетләргә иярмим! Эт мәллә мин?

— Сина ничек жайлы сон, күбәләк? Өч чакрым ни ул безгә, күтәрәм, әйдә.

— Күтәрмә!

— Алайса тракторымны кабызам.

— Тракторынны да кабызма! — Туйбикә иреннәрен уймак ясап нәрсәдер уйлады-исәпләде дә: — Өйдән килеп ал! — диде. — Ун машина белән! Авылыгыздан ук кычкыртып чыгыгыз! Тукта, селкенмә! — Кыз анын гимнастерка жинен чеметкәләде. — Фу, тукымасы калын. Моны никахка кия күрмә, яме? Ак күлмәк, кара костюм, ялтыравык туфли юнәт, бу әрмийский кирза итегенне сал. Үзәктә язылышабыз, мәжлесне кафеда уздырабыз, дусишләрне, туган-тумачаларны чакырабыз. Кимендә йөз кеше! Туй чыгымнары синнән, Нурулла!

Кыз нәрсә генә әйтсә дә, егет «юк» димәде. Әлеге минутларда аны Туйбикә отыры сихерләгән иде. Әгәр күбәләге: «Күктән аен-йолдызын чүпләп, каршыма өй!» — дисә, ул мөгаен, хисләрен тыялмыйча «хуп» дияр иде.

Ахырдан айныды Нурулла. Чамасын чамалап карады. Хәлләр хәл иде. Бабай мирасы — йорт сәләмә, абзар-кура сәләмә... Өч апасы кияүдә, сырхау анасы — аяксыз. Игезәк сынары белән икесенен өстендә солдат гимнастеркасы... һәм менә кесәсендә сукыр тиен дә чылтырамаган Нурулла кыз ярәшә, имеш!

Әни белән апалар кинәшкә ярамас дип ул «сынары»на сүз катты.

— Мин өйләнәм, Шәм.

Шәмсулла анын капма-каршысы: ташбака төсле үзе дә, сүзе дә әкрен иде. Ул мунча кыегында каркылдаган каргага карап торды-торды да:

— Нинди симез! Тавык хәтле, — диде. — Безнен ишегалдында бодай соса, гуж тәре!

— Аллаһ яраткан кош, соссын! Синнән-миннән сәдака.

— Һи-һа, бигрәк син, Нур, нәкъ мулла абзыйлар төсле пупылдыйсын.

— Онытма, Шәм, без Киләхмәт мулла оныклары!

— Һи-һа, — «Сынар» ат төсле мөһелдәп куйды. — Хәтерлисенме, тугызынчы сыйныфта Мифтах кылый безгә Чурайбатыр тарихын язарга кушты? Картқорыдан сораштырыгыз, балалар, диде. Без өчәү Бикморза бабайларга кердек. Габдел, син, мин, әйеме? Син бабайнын әкиятен и язасын, и язасын, ә без бу вакытта сиздермичә генә чыгып, бакчадан алма урладык.

— Хәтерлим, Шәм. Бабайнын эте чалбар төбенне умырган иде!

— Ә, син, нәстә диден әле? Өйләнәм, дисенме? Ни бетен белән, Нур?

Нурулла хыял атынын ялына чытырдап ябышкан иде.

— Көн-төн жир сөрәм, фермада тирес ташыйм, сина пилорамда булышам,

вәт шулай туйлык акча җыям, — диде ул. — Шәт, җизниләр әзрәк бурычка бирер. Йә, син ни диярсең, Шәм?

— Ни диярменме? Җир йөзендә кыз-катыннар кырылмыйдыр бит, Нур, ә?

— Сиңа дигәннәре кырыла ди. Ә минеке бирәү генә ул.

Ир туганы — туң күчән, аның «йөрәк эшләре»нә төкерә иде.

— Өйлән, ну түлке соңрак, Нур. Акча бездә бер букча дигән көнне сразы туй гөрләт!

— Без август азагына килештек, Шәм.

— Чистый ташыгыз кызган икән, туганкаем. Су сипсәң дә файдасыз, ахрысы. Туй итү чыгымнарын кимет, акчасын аз тот.

— Әз тотмыйм, күп тотам! Саран дигән ат күтәрмим, — дип ярсыды Нурулла.

— Мәйлең, Нур, — диде пошмас Шәмсулла. — Бу карга ярты чиләк бодай ашыйдыр, валлаһ! Очалмый җәфалана әнәгенәк.

Җәй төсен күрмәде ул. Тәүлек буе керфек тә какмыйча басу-кырлар сөрә-сөрә күзләре чепиләнде, тирес түгә-түгә ябыгып кабыргалары тырпайды. Бер кичне Нурулла күрше авылга, Туйбикә янына чапты. Акча хәсрәте, мөгаен, миен сыеклаткан иде, ни майка, ни күлмәк киелмәгән, шәрә тәнне байтактан бирле юылмаган гимнастерка гына каплый иде. Кыз, кулы белән тыгылып, егетнең күкрәген капшады:

— Абау, урманда караклар чишендерде мәллә?!

— Ашыктым, бүген сине күрмәсәм, үлә идем, — диде Нурулла, ул Туйбикәне биленнән кочакламакчы иде, ләкин хыянәтче ис — тир исе борынны яра иде. Егет үзеннән-үзе артка чигенде.

— Йә, әйт, мине шулай үләрлек итеп яратасыңмы, Нурулла? — Кыз һаман аңа сарылды.

Нигәдер егетнең бу сораудан җеннәре котыра иде. Йә инде, ир-ат «мин сине яратам» дип төчеләнәмени?! Аңа «синең өчен үләм» диюе җиңелрәк. Тел белән яратмыйлар, күңел белән яраталар, аның шунысы кыйммәт. Яратуы хак булмаса, өйләнәм дип шашар идеме Нурулла? Гаҗәп, аңардан җүнле җавап ишетмәгән Туйбикә турсаймады, төклетура сабагын өзеп, егетнең беләгенә төрткәч:

— Авыртамы? — диде. — Мин укол ясаганда ирләр йөзен җыера.. Гомумән, сезнең җенес бик кызык зат икән. Энәдән дә куркасыз...

— Ә син беләсеңме, фил өчен иң куркыныч дошман кем? — Нурулланың беләгендә төклетураның эзе калды. Ярар, йөрәккә генә кадамасыннар!

— Кем?

— Тычкан.

— Кеше көлдермә, Нурулла! Фил тиклем филне тычкан җиңәр ди сиңа!

— Колагына керсә, кытыклап үтерә, — диде егет. — Без, ирләр дә фил төсле, уколдан шүрлибез, ә башкасыннан... — ул җәлт кенә урман ешлыгына карап алды. Менә шуннан мич хәтле аю чыксын иде дә, борын төбенә берне ямыйсы иде! Күрсәтәсе иде бу «күбәләк»кә йодрык көчен! Аннан соң «ирләр» куркак дип мыскылламас иде! — ... ә башкасыннан өркегән юк. Туй көнен кайчан билгелибез, җаным?

— Ә син кыз сорарга килдеңме соң әле? — Туйбикәнең күзләреннән шаян очкыннар сирпелде. — Башта әти-әнидән сора-а! Йоласына туры китереп бал апкил, пар каз апкил, һәм дә мөһергә алтын йөзек. Балдак белән бутама тагы, анысын үзәк кибетеннән икәү сайларбыз. Менә йөзекнең үлчәме! — Кыз үлән белән бармагын уратты. — Артык калын булмасын, яме?

— Ярар, — диде Нурулла. Әйе, ул Туйбикәнең бөтен әмеренә «ярар» диде. Ниһаясез яратуы белән егет аяк астындагы каты җирне, баш очындагы күкне

теймады, ул əллə нинди сəер дөньяда яши, бу дөнья бары тик хислəрдəн генə тукылган төсле иде. Берни дə түгел, мəхəббəт дип, күзен-башын томалатып, мөгаен аны күрəчəк сикерткəндер.

Туйбикə исемлек төзеп тоттырган кучтəнəчлəрне төяп кыз сорарга баргач та булачак əби белəн бабай кияү дип əллə ни өзелмəде шикелле. «Үзегез карагыз, яшьлəр!» — белəн генə чиклəнде алар. Озак-озак карап торырга Нурулланың түземлеге төкəнгəн иде шул. Егет кистереп: «Август азагында туй, барлык расхутлар минем өстəн», — диде. Хəзер инде ничек тə сынатмаска иде исəп. Жиде кат тиресе туналса туналды, əмма Нурулла вəгъдəсен үтəде: танышбелешлəр ярдəме белəн ун машина табылды, ЗАГС белəн кафе сөйлəшенде, үзе дə, энəдəн-жептəн киенде һəм йөрəген учына кысып (бəхетен жил урламасын!) Туйбикə артыннан китте. Əле монарчы Чурайбатырда болай зурдан кубып беркемнен дə килен төшергəне юк иде.

Мəхəббəт дигəндə хатын-кыз да, ир-ат та үз гомерендə бер авыруга сабыша, лəкин бу чирдəн ирлəр озак, бик озак дəвалана, чөнки аларның хисе ясалмалык һəм хəйлə белəн сыекланмаган. Шөкер, Аллаһы Тəгалə адəм баласына ни-нəрсə кыланганнарын шунда ук күрсəтеп тормый, югыйсə Нурулла үзен читтəн күреп шаккатыр иде.

Шулай дус-иш, туган-тумача машиналарны улатып зəнгəр түбəле йорт каршысында туктады. Ə анда сəер тынлык иде. Бəйрəм көнне киереп ачып куясы капка нигəдер ябык. Ни жыр, ни гармун, ни яшьлəр тавышы ишетелми. Кияү балакай атылып ишегалдына керде. Монда да бəйрəм жиллəре исми иде. Баскычка яртылаш бөкрəйгəн Туйбикə əнкəсе чыгып басты. Аның чырае болыт сарган сыман карангы иде.

— И бəбкəм, ни əйтим инде сиңа? — диде ул ыңгырашып кына. — Күнеленə авыр алма, олан. Туйбикəбез кичəгенəк зур укуларга дип Казанга китте.

— Ничек китте?! Ничек?! — диде Нурулла, аның гəүдəсе тораташка əйлəнгəн, ул телен дə көчкə генə кыймылдата иде. — Бүг...ен без...нең ЗАГСта языл... язылышу көне! Таг... тагын бер сəгатьтəн!

— Ачуланма, бəбкəм. Ул кызны без генə тышавыларлыкмыни! Кешене хур итмə, белгертеп кит, дидек, тыңламады. Аңа жен шаукымы тигəн, бəбкəм. Мин аны абзыйның туенда тапкан идем, атасы исемен дə шуңа Туйбикə дип куштырды. Катыны, ире бии-жырлый, мин мич арасында бəбилим. Ходай жəзасы.

Егет тораташ гəүдəсен капкага табан сөйрəде. Хəзер инде аяк жирдə — чынбарлык аны хыял иленнəн аска табан тарткан иде. Күктəге болытлар да якын, бик якын, тик алар хəзер таш кебек укмашып баш түбəсенə ышкылалар иде.

Аның хəлен игезəк сыңары аңлады. Пар балалар бер-берсенен кичерешлəрен йөрəк белəн тоя, имеш.

— Бетеренмə, туган, дөнья катынга корымаган, ул сине барыбер санламас иде, — диде.

Ə туйны уздырдылар. Түрдə кəлəш тə, кияү дə утырды. Əй дөньясы!

## 4

Быел терлек азыгына кытлык дип, рəис бодай саламын яндырмады, кибəнгə өйдертте. Менə синə мə, кəтүк хəтле генə бала көчəнə-көчəнə салам йолкый иде. Ул үз эше белəн шулкадəр мавыккан иде ки, Нурулланың килгəнен сизмəде дə.

— Эһем, эһем, — диде ир əкрен генə. Чыбыркы шартлатырлык малыңны урламыйлар əле.

Малай аяк чалып еккандай арбасына ауды.

— Курыкма, сукмыйм, — диде рәис. — Син кемнең унган жегете, ә?

— Тәбрис хатыныныкы, абый.

— Сәйдәнекеме? Жиденчедә укучы Рәсим инде син. Әтиең нишли?

— Аракы эчә. Үги атаңнан ни он суы, ни тоз суы, ди әни.

— Салам белән нишлисез, Рәсим? Сез бит терлек асрамыйсыз.

— Син, абый, чуртым да белмисең! Бездә биш терлек, түлке без аны синнән качырабыз. Әни персигә күрсәтергә ярамый, ди. Бу салам кышка, асларына жәябез.

— Кара син, ә! Яшереп кенә абзарда аю тотасыз бугай, — дигән итенде Нурулла. Ә үзенең ияк яңаклары тартышты. Авыл халкын жыеп ялынды, ялварды, үтенде, ә нәтиҗәсе юк! Алар әнә борын төбендә ут көйрәтәләр. «Авылың бетә, углан!» Төшнең кайтавазы колак пәрдәсен чыңлата: «бетә-ә!»

Нурулла камылны изә-сыта машинасына табан атлады.

Сәйдә турларындагы коедан су ала иде. Ул аның сыйныфташы иде. Эшкә батыр бу хатынны Нурулла биш ел элек киендереп-ясандырып Казанга — авыл хужалыгы күргәзмәсенә жибәргән иде, аннан мактау кәгазьләре генә кыстырып кайтмады сыер савучы, ана бер ир бәндәсе дә тагылган иде.

— Танышыгыз, сабакташ, — диде бәхетеннән исергән Сәйдә. — Бу — Тәбрис. Улыма — әти, мина — ир. Йомшак хайванкаем ул минем, син ана да колхозда берәр эш бир инде, Нурулла.

Рәис «хайванкаем»ны төрле яктан сынап карады. Монын йолкысаң — йоны, саусаң — сөте юк иде. Шәһәрдә тырай тибеп яшәгән Тәбрисне, аптырагач, үз «тиннәре» янына кушты рәис: көтүче чыбыркысын тоттырды. Әмма хөрәсән көн уртасында болында йоклап, дисталәгән сыерны ужымда күбендерде. Куды аны Нурулла, һәм иң унган сыер савучысыннан да колак какты.

...Көтелмәгән кунак Сәйдәне каушатты.

— Сине өй борынча иснәнә дигәннәр иде, менә безгә дә чират житте, — диде ул, ризасыз тавыш белән. — Монда гына әрлә инде, жәме? Өйдә әтиебез исерек.

— Ник сәрхуш белән изаланасың, Сәйдә?

— Нишлим соң, синең кебек айныклары кыяклагач? Сажидә очрады бит сиңа юлда. Бәхетенне керпе тишкәләгәч, ни уфыр, ни пуфыр, мин дә ул көнне жәйләүдә идем. Сажидә башым авырта дип миннән алдарак теркелдәгән иде. Әнә, бүген балда-майда йөзә, мыштым. — Хатын сулы чиләген чайпалдырып жиргә куйды. — Мина да ир-ат назы кирәк иде. Казан урамында аунаган бомжны кунакханәдә юындырып, кибеттә киендереп, закунный мужик ясадым, вәйт! Син мина вәгазь укыма, жәме? Хет ун тапкыр әүлия бул, мина син указ түгел, Нурулла!

Тиктомалдан женләнгән Сәйдәне тынычландырмады рәис. Аның үзенең дә шулпасы кайнап, казаныннан ташый иде. Унганлыгы өстенә сабыр да, акыллы да иде сабакташы. Елгыррак сыер савучылар шешәләргә тутырып сөт урлаганда да ул, гөнаһ дип, колхоз әйберенә тими иде. Ә бүген, гажәп, аны чүпрәсе искергән әче камырдан әвәләгәннәрмени, Сәйдә бүтән, Сәйдә үзгәргән! Авылдашларыңны үтәли күрәм дип мактанган житәкче иптәш, йә, ни диярсең? Кайнап ташыйсың, бары шул гына, әйеме?

— Сәйдә, ирең белән яшисеңме, аерыласыңмы, синең ихтыярда, ә абзарга яшергән тукмакборыннар мәсьәләсендә болай: сина өч көн вакыт, әгәр дә өч көндә шакшыдан арынмасаң, өеңне сүтеп Ивановкага күчерәм. Суд белән янама мина, файдасыз ул.

Сәйдә, чиләгенә абына язып, ана ташланды:

— Мин ул дуңгызларны суеп ашамыйм, симертеп сатам! Улымны укытырга бит ул акча! Син бит әүлия, хәлемне анларга тиеш!

— Фермага кил, синең кебек алтын куллы хатынга егерме сыер да аз!

Ир кызу-кызу китеп барганда арттан Сәйдә кычкырды:

— Кабахәт син, Нурулла-а!

Ләкин баягы зәһәр тимер тавышы күз яшьләре белән җебеп изрәгән иде.

...Капка төбендә колхоз шоферы бүкәнгә куеп утын ваклый иде, Нурулла аның белән исәнләште дә:

— Еллар ничек, Шамил абый? — диде. — Мин сине Кара дингездә су коена мәллә дип уйлаган идем.

— И рәхмәт яугыры, иптәш прсидәтел, теге заманда ике тапкыр ял иттерден дингездә, әле дә авызда тоз тәме, — дип кеткелдәде абзый. — Берсекөнгә эшкә мина. Эш лутчы, иптәш прсидәтел.

— Ташла әле шул «иптәш»еңне, Шамил абзый. Партия җыелышы диярсең. Тәҗел йомышымны үтәсән иде. Сәйдәләр йортына каяндыр дуңгызлар адашып кергән икән, Ивановкадан, ахрысы. Шуларны кире үзләренә илт инде.

— Син Сәйдәгә ышандыңмы, иптәш... дим прсидәтел? Матри, көпә-көндез алдыйлар, имансызлар! Кемне диген? Иптәш... дим прсидәтелне! — Абзый балтасы белән чек-чек бүкән чокыды. — Иту ул мырык-мырыклар Арбалы Кәбирләргә дә, Закун Мансурларга да ялгышып кергән инде.

«Кәбирләр? Мансурлар?»

Нурулла иелеп ике пүлән алды да шак та шок бер-берсенә бәрде. Аларга ни җитми икән? Тагын кемнәр?

— Шамил абзый, синең өең дә, мунчаң да газ белән ягыла түгелмени?

— Арткы ызбадагы мичне сүтмәдем мин, иптәш... дим прсидәтел. Газ чыгымлы. Мичне ягам да, күмерен көрәгәч, кызу ташында бәрәңге тәгәрәтәм. Ялгызакның ашы-сые шул икән аның.

Абзыйның бөрешкән кара карлыганга охшаган күзләре моңсуланды. Нурулланың аңа болай төбәп караганы юк иде. Картая, Шамил шофер, картая... «Йөгенне төя, йөгенне илт, йөгенне бушат» дигән әмерләрдән гайре Нурулла бу бәндәгә берәр кәлимә әйтте микән? Машина төзек, хезмәт хакы түләнә, тагын ни кирәк? Ә күңел? Анда ниләр бар? Юк, монысы сине кызыксындырмады, рәис! Әнә, ялгызакның ашы-сые бәрәңге икән бит... Димәк, Шамил абзаның машинасы гына төзек, ә күңелендә — җимереклек...

— Өйләнмәдең, тәки, Шамил абзый.

— Өйләндем. Дүрт тапкыр, иптәш... дим персидәтел.

— Ничек дүрт тапкыр?!

— Һи, син яшь идең шул, минем тарихлар сиңа карангы. — Абзый кесәләрен актарды. — Чигарит... Кая соң бу чигарит? И, изелгән, хәерсез. — Сынык сигаретка ут эленмәгәч, абзый аны учында уып, җиргә сипте. — Сирәк кенә тартыштырам, исеннән җеннәр качсын өчен генә. Беренче катыннан әни аерттырды. Күп йоклый дип. Икенчесен телләшә диде, өченчесе сыерның сөтен сава да, чиләге белән күтәреп эчә, — диде. Дүртенче катын, Вәсимә, яшь иде, каенанага бирешмәде. Кушаматы да эт каешы иде аның. Ике бичә көн-төн блач бүлеште, кем хезмәтче дә кем хуҗа! Мин шунда бүрек белән киңәштем. «Шамил, — ди бүрек. — Бу катыныңны да кусаң — нәселсез каласың, ди. Катының ягына бас, — ди. Вәсимә тәки әнине җиңде. Мин эштә идем. Беркөнне ул сандыгы-ние белән каенананы урамга тибеп чыгарган. Хурланган әни, ахирәтенә күчте. Улым килеп алыр дип көткәндер, бичара. Мин бармадым, иптәш... дим прсидәтел. Катын корсаклы иде. Әни ахирәтендә үлде. Вәсимә, малай мәктәпне тәмамлагач, аны укытырга

урнаштырам дип Казанга киткән жиреннән суга чумды. Авыл тормышын бер дә өнәми иде, анда нәчәльник сымаграк ир тапкан ди. Аннан соң унбиш ел узды. Мин дә янадан өйләнергә уйладым. Фәнисә апаңны ошата идем, аңа сүз каттым. Син дә парсыз, мин дә парсыз, арканы аркага куеп булса да ятарбыз, дидем. Ризалаткан идем дә... Ул мулла белән кинәшкән, ә тегесе — чалмалы хәсрәт: «Шамил бишенче тапкыр никахлана алмый, шәригатьтә мөселман бәндәсенә дүрт кенә катын каралган, Аллаһ каршында гөнаһ кылмагыз», — дип, Фәнисәне орышкан. Киреләнде инде шуннан соң апаң, иптәш... дим прсидәтел. Мин сиңа хәрәм дә хәрәм ди. Әни каргагандыр мине, ялгызлыкта интек малай актыгы, дигәндер.

— Берәр бәрәңге тәгәрәткәч эндәш әле, Шамил абзый, гәпләшеп утырырбыз, — диде Нурулла. — Иркенләп чәй эчәрбез.

— Рәис белән чәй эчкән бар анысы. — Абзыйның йөзенә кояш кунды. — Ә мона әүлия белән юк. Шунысы кызык аның! Авылданиләр генә сөйләмиләр, шулар чынмы соң, иптәш...

— Утыныңны яр, Шамил абзый!

Кәефе кырылган Нурулла Кәбирләргә табан борылды. Монысының ипи шүрлегең жимерергә микән әллә?! Ферма мөдире — уң кулы бит, билдән бөртектә йөзә бит! Кичә генә хатын дүрт сыер сава, сөт файдалы кәсеп икән, дәүләткә тапшырабыз, дип мактанды, хәйләкәр төлке! Аның көненә өч тапкыр өен әйләнеп килүен дә, жәлт кенә арба төбенә йә печән, йә силос түшәгәнен дә күрмәмешкә салышты рәис. Хуп, аннан-моннан чәлдермәсәләр колхоз колхоз буламыни ул. Бу гадәт авыл халкының канына сеңгәндер, мөгаен. Бабасы урлаган, атасы урлаган, оныгы гына әдәп сакламас, билгеле.

Кәбир ишегалдындагы зур ләгәндә бәрәңге боламыгы изә иде. Бәрәңге парыннан аның күзе яшьләнеп, яңагына «тамчылар» тама иде. Хужа капкада рәисне күргәч чак кына борыны белән табагына кадалмады.

— Бәрәч, Нурулла туган, нинди жилләр ташлады?!

— Төньяк жилләре, сезгә табан исә иде дә, мине дә үзенә ияртте. Алла куәт бирсен!

— Минамы? Әһе, рәхмәт. Менә хатынга булышам, — диде Кәбир.

— Булыш, булыш! — Нурулла карашын юри читкә борды. — Әзрәк су салып болгат, бәрәңгең коры.

— Миңа бер-бер гозерең бар идеме, Нурулла туган?

— Юк. Ә соравым бар иде. Син кем?

— Ә?

— Син кем, диләр?

Тезләнгән Кәбир аякланды. Аның авызы ачылган, күзе шарайган иде.

— Минме?! — диде ул, күкрәгенә төртеп.

— Син, син!

— Үртәмә, Нурулла туган. Кәбир Ибәтов мин. Ферма мөдире. Үзең куйдың, туган, эшлә, диден.

— Ничек эшлә дидем?

— Инде... Эшлә дип, намус белән диден, Нурулла туган. Инде, күпсенмә, арба төбенә генә, арт шәрифләремә йомшак дип кенә салыштырам шунда. Угры дип сүгәсенмени инде, туган? Ярар, бүтән чиметем дә апкайтмам. Ике күзем чәчрәп аксын!

— Юк, син апкайт, Кәбир, чиметем генә тагын апкайт! Колхозның аның шул ягы күнелле дә. Мин сине урларга күрше авыл хужалыгына жибәрә алмыйм бит, әйеме? Намусның мәгънәсе тирәнрәк, Кәбир. Оятсызда юк та әле ул. Дүрт сыер дисеңме?

— Берәү, Нурулла туган, — диде Кәбир кызганыч тавыш белән. — Оят мина, оят. Хатын тиз үрчиләр, артымы шәп дип өч баласын абзарга җибәргән иде, туган. Син мине, зинһар, мөдирлектән чыгарма, иртәгә үк бу зәхмәтләрне чүплек базына ташлыйм!

— Их, мин сине тукмар идем, Кәбир, тик синен мескенлектән гәүдән кечерәйде, ә без кәрләләргә сукмыйбыз.

Нурулла йодрыгын йомарлап кара исемлектәге сонгы йортка табан китте. Ләкин монысынын капкасы бикле иде. Чурайбатырда халык ябылып яшәми иде, ни кылана болар дип тынланган иде, бер «ачыш» ясады: Закун Мансурлар капкасынын «үпкәсе» үскән, ахрысы, ул мыш-мыш сулый иде.

— Ач, качышлы уйнама! — диде Нурулла, тимер тотканы шылдыратып. — Юкса койма өстеннән сикерәм.

Хуҗа мытыр-мытыр килеп келәне шудырды:

— Перси безнен турдан үткәндә җиле бәрелеп капканы аудармасын дип кенә япкан идем, Алла бәндәсе.

Нурулла аны этәреп туп-туры абзарга юнәлде. Әмма сәнәк элəктергән Мансур анын юлын каплады:

— Син кая, перси? Сарайгамы? Нәмә тикшерәсен? Башта рөхсәт язуынны күрсәт! Эченне тишәм, перси! Йортыгызга бәреп керсәләр, үтерегез, дигән закун бастырды пыркарур!

— Атасы дим, атасы! — Баскычта куркынган хуҗабикә чыгып басты. — Ыргыт сәнәгенне! Нурулла бала сина перси генә мәллә, ул — әүлия хәзер, атасы!

— Исәнме, Гөлия апа?

— Исән, исән, бала. Син безнен атабызны ачуланма, бала. Күзе әйле-шәйле генә күрә, колакка да каты. Әрмиянеке ул, бала. Мансур бит анда камандир белән давылашкан. Иртән «Торыгыз!» дигән боерыкны үтәмәгән, Русия гражданинына сигез сәгать йокы тиеш, дигән. Шуннан камандиры монын шытырдатып колагын борган, закун чыгарма, Ишкуатов, дигән. Бу хәлләрдән сон Мансур: «Эти сәлам, әни сәлам, килеп алмасагыз — вәссәлам», — дип өйләренә хат язган. Закун кушаматы солдат бүләге ана. Син бездән нәрсә сорамак иден, Нурулла бала?

— Мансур абыйнын законына төзәтмәләр кертәсе иде, Гөлия апа. Сәнәге белән хәтәр кизәнә бит әле мена, — диде рәис, хуҗага ымлап. — Анын атасы — Кираметдин бабай бигрәк иманлы карт иде.

— Мөәзин иде, бала. Ипи валчыгына да: «Әгүзе әйтеп капсан — туярлык», — дияр иде. Каенатамнын урынын Аллаһ җәннәттән әйләсен берүк!

— Ай-һай, әйләр микән?

— Без анын нигезендә яшибез, Нурулла бала. Елына икешәр Коръән укытабыз, Аллаһ ризалыгы өчен. Абау, бала, шикләнәсенме әллә?

— Кираметдин бабайга оҗмахлар насыйп микән, Гөлия апа? Йортыгызда — хәрәм...

— Ай Аллам! Сезденмени, бала? Сизми ни, әүлия бул да, — дип, хуҗабикә аягындагы галушын салып шап-шоп кагарга тотынды. — Мансур, чукрак, акчага коенабыз дип асрый. Тот капчыгынны, коенырсын! Өстебезгә бер-бер артлы хәсрәте ишелә: башта малай мотоцикл белән бәрелде, анын артыннан кызнын малае хасталанды. Каенатам мина рәнҗиме? Килен Мансурны аздырды диме? Әйтче шуны, Нурулла бала?

— Озак сөйләшмәдек. Тиздән үзем кайтып колакларын борам, диде.

— Кем, бала?

Хәзер «теге дөнья хәлләре» Нурулланын үзенә дә мәзәк тоела иде.

— Каенатан инде, Гөлия апа.

— И, шаян кеше син, Нурулла бала. Ничә ел кызыл туфракта череп ят та аннан терел, янәсе.

— Мин терелдем бит менә.

— Әй, син свижи мәет лә, бала.

— Нишлибез, Гөлия апа? — Рәис шаяртудан туктады. Сәнәгенә таянган Мансур абзый мин җиндем дип кәефләнеп, кетер-кетер көлде.

— Минем хуҗалыкта — минем закун, баста!

— Ә Чурайбатырда — минеке, — диде Нурулла. — Мин сезне аксакаллар хөкеменә тапшырам. Гаиләгезне авылдан куаргамы, кумаскамы, әйдә, хәл итсеннәр.

— Чү, бала, ил-көннән кая сөрәсез?! — дип елап җибәрде хуҗабикә. — Чукрак абзанны үзем җайлыйм, аерылышабыз дисәм коты ботына төшә аның, хәзер абзарны тегеләрдән чистарта-а!

— Бүген үк аерылам диген, Галия апа, Иртәгә кадәр сузма. Ачуым яман, беләсез!

«Ачуым яман, беләсез...» Әйе, синең холкынны беләләр, Нурулла. Чөнки син урамнан үткәндә һәр капка ярыгыннан, һәр тәрәзәдән күзләр озаткан. Күзләр булмаса, этләре өреп калган. Яратканы — яраткан, нәфрәтләнгәне — нәфрәтләнгән. Син колхоз җитәкчесе, үзенә күрә хуҗа, мөгаен, барысына да ярап та бетмәгәнсендер. Кайберәүләр үзенең бәхетсезлегендә сине гаепләгәндер, ә икенче берәүләр рәхмәт кенә укыгандыр. Ә бүген син алар өчен әүлия икән... Сизәсеңме-тоясыңмы, халык чынбарлыктан арыган, ул могҗизага сусаган. Аның берара матур әкиятләргә ышанасы килә! Чынлыкта, авыл синең гап-гади кеше икәнеңне таный, ләкин егерме ел хуҗалык сөйрәгән рәис барысын да туйдырган, алар сине гайре табигый сыйфатлар белән чуарлап-бизәп әүлия исемле яңа зат тудырган. Сәбәбе дә булды: йөрәгең типмәде... Өсләрен бөтен, тамакларын тук итәм дия-дия артыгы белән җиргә беректек, Нурулла. Элгәре моржалардан бөркелгән төтен адәм баласының күк белән бәйләнешен искәртә, «бисмилла»сын кушып пешергән ипи исе галәм кинлекләренә таралып, дөньясын хушландыра иде. Нурулла Азизов иң беренче Чурайбатырга газ торбалары суздырып «төтенсезләр авылы» дигән кушамат тактырды. Баксаң, төтенсез авыл — күнелсез һәм шыксыз авыл икән. Юк икән күкләр белән тоташу! Быел тау итәге дә догасыз тилмерә. Шул якка караган саен кәеф кырыла. Һаман тамак кайгысы!

Урамнан озын ботларын чалыш-молыш китереп Зәкия карчыкның оныгы йөгерә иде. Галимнең аркасындагы йонлач биштәре дылк-дылк итә, әйтерсең, егеткә ябышып бер сары эт тә чаба иде.

— Нурулла Сафиуллович, спасите! Өч сәгатьтән Казанда ученый Капланның лекциясе икән. Интернеттан укыдым. Миңа аны тыңларга кирәк, срочно автовокзалга илтегез! Очень прошу! — Егет машинага утыргач та бал корты төсле безелдәде. — Боже, соңартма, боже!

— Ленинга аткан Каплан оныгы мәллә?

— Вы что, Нурулла Сафиуллович! Бусы башка Каплан! Бөек ученый. Сез аның ачышлары турында ишетмәдегезме?

— Юк, Алмаз.

— Да, авыл агайлары надан шул. Гафу, Нурулла абый. Капланның исемен история китапларына язачаклар.

— Күбрәк татарча сөйләш, малай актыгы! Профессор атаң белән без бер урамда сугышып үстек. Яртылаш авыл егете син. Капланыгызның бөеклеге нәрсәдә инде?

— О-о, абый Нурулла! Ул кешенең гомерен ничек озайтырга дип баш вата.

— Юк белән маташмагыз, энекәш. Аллаһы Тәгалә аны без карында чакта ук билгеләгән.

— Стоп, Нурулла Сафиуллович! Каплан — уникальный ученый. Ул сначала телоны ясарга ди, ягъни роботны. Күзе-колагы, авызы, кул-аяклары белән, ди. Соңынтын биологик баш миен шушы тәнгә пересадить, ди, вот! Клиент сайлый: үләргәме яки ясалма гәүдәдә яшәвен дәвам итәргәме. Әгәр без ученыйлар берләшеп шундый робот тудырсак, ул Айда да, Марста да яшәячәк, абый Нурулла! Халык күп, тиздән планета шартлый. Без роботсыманнарны бүтән күк җисемнәренә озатсак, Җирдә катастрофалар кими, точно! Планета кызганыч, абый Нурулла. Һәр туган бала аңа үлем белән яный. Урманнар таптала, сулар агулана, тереклек үлә. Җиде миллиард без бүген, коточкыч цифр, да? Капланның ачышы хуплауга лаек.

— Тимер сыныгызга каш-керфек, авыз-борын чәпәрсез, бу катлавылы түгел, Алмаз. Ә мәнә җан белән нишләрсез, ә? Галимнәр ихтыяры белән генә җан беркая да күчми! Уйдырмалар белән вакыт уздырмагыз, энекәш.

— Ужас, сез полный отстой икән, Нурулла Сафиуллович. Сез наукада ни-ни! Фән ул прогресс юлдашы, аңа вакыт та не жалко!

— Мондый фантазияләрдән безгә кирәк, энекәш. Син безне файдалы ачышларың белән куандыр. Ничә ел агулы бәрәңге ашыйбыз, шул каһәр суккыры коңгызга каршы робот-бөҗәк уйлап тап һич югы.

— Фу, мине кемгә саныйсыз, Нурулла Сафиуллович. Җук, таракан, кандала кебек хәшәрәтләр белән кайнашырга башыма тай типмәгән! Мин — ученый. Мин Каплан шәкерте! Без дә сезнең сымак авыл, җир, икмәк дип вак мәсьәләләр белән шөгыльләнсәк, кем глобаль проблемаларны чишәр?

Тукталыштагы автобус менә кузгалам, менә кузгалам дип тора иде, Нурулла биштәре-ние белән юлдашын ишектән кертеп җибәрде.

— Капланга сәлам! — диде ул, әмма бу тозсыз шаярту иде. Синең сәламең кемгә хаҗәт ди! Әнә алар дөньякүләм проблемалар белән мәшгуль, гәрчә уйтеләкләре фантазиягә корылып, акылга сыймаса да, бөек эшләр майтарабыз дип шапырыналар. Ә Нурулланың эше чынлап та вак: яз сөрә-чәчә, көз — урасуктыра. Хәсрәте дә чыпчык борыны хәтле генә: Чурайбатыр үлмәсен дип көнтөн чаба-йөгерә... Киләчәктә рәхмәт ишетерме? Ишетмәс. Капланнар кебек алтын хәрефләр белән тарих битләренә теркәлерме? Теркәлмәс. Һай, шайтан алгыры! Күңелдә нинди генә җүләр уйлар бөтерелми. Дан-шөһрәт казанып, сурәтен тимер такталарга уйдырыр өчен туганмыни Сафиулла малае?! Җир өчен дөньяга китергән аны Аллаһы Тәгалә. Кочагына йолдызы-ае, урман-кырлары, чишмә-елгалары белән Чурайбатыр исемле җыйнак кына, бәләкәй генә дәүләт салган. Йөрәгең белән янәшә кадерләп сакла, тузгытма-таратма, дигән. Әйдә, роботлары белән ят планеталарга Капланнар күченсен. Ә Нуруллага Җирдәге тормышның да үз җае, үз көе бар...

## 5

Менә шулай... Реанимациядән гомуми палатага чыгаргач, янәшә караваттагы абзый аңа:

— Ике тумыйбыз, ике үлмибез, иртән гел: «Бүген бәйрәм!» — дип уян, — диде.

Искерсә дә, асыл хакыйкать иде бу.

Менә шулай... Уяна Нурулла. Үз җае, үз көе булган тормыш иртәсе, гәрчә, йөз төрле мәшәкатьләре, аһ-зары, үкенеч-көенечләре белән бусага төбендә

үк сагаласа да, ул разый иде. Яшәү — бәйрәм! Йөрәге бер туктап алган кеше моны бөтен вөҗүде, бөтен күзәнәкләре белән тоя иде. Шуна күрә ир һәр иртәдә бәйрәмчә киенде: монарчы шкафта сөрсегән өр-яңа костюм-чалбарлар, күлмәк-галстуклар берәм-берәм кузгатыла башлагач хатыны шикләнеп:

— Ник алай көязләнәсең, Нурла? — диде. — Элек өстеңдә джинсы белән свитер гына иде.

— Бәйрәм бит, бичәсе.

— Саташма, гап-гади көн, Нурла! Синең шулдыр инде... — Сәҗидә мыш-мыш борын тартты, — даруга дип, хәйләләп китеп, аның белән серләшәсеңдер.

Нурулла бу очракта: «Син нәрсә лыгырдыйсың, ахмак бичәсе!» — дип ачуланырга тиеш иде, ләкин ул әлеге уен чалгы белән печән чапкан кебек кисеп ташлады. Тимә, көнләшсен! Сары алъяпкыч белән билен буган хатында җан юкмыни!

— Сөйлиләр инде... — Борын «ыш та ыш» һаман «такта ышкылады». — Хак икән, аңа булса чиста әйберләр киясең. Сиңа — әүлиягә, ят хатын-кыз мәхәббәте хәрәм, Нурла.

— Кем әйтте?

— Яшь хәзрәт никах тугрылыгы — җәннәтнең беренче баскычы, ди. Сиңа төбәп әйтмәде дә, Нурла. Алай да.... Без кызлар белән мәчеткә аның вәгазьләрен тыңларга кергән идек.

Мыштым хатынның көнләшүе дә кызык түгел, әйтерсең, коры чикләвек яшене: черт итә дә сүнә, черт итә дә сүнә... Зилзиләләр куптарып, тузан өемнәре уйнатып, күкләр күкрәтеп килсен иде дә, чартлатып яңакка суксын һәм күздән ут чәчрәтсен иде! Юк шул, хатын-кызларның барысы да Туйбикә түгел. Син соң үзең дә болай да күндәм, болай да басынкы кемсәне бастырасың:

— Халык арасында өтек-төтек йөрмәскә кирәк, бичәсе. Әллә миңа җүнлерәк кием дә хәрәмме?

Аңа «бәйләнеп» арыган хатыны аш бүлмәсендә кыштырдый иде инде. Нурулла озак кына көзге алдында галстук бәйләп азапланды. Муен элмәккә керергә теләми, башны әле уңга, әле сулга кыйшайта иде. Ир-атны йөгәнләр өчен уйлап чыгарылган чүпрәк кисәген шкаф тартмасына атып бәрде ул. Хуш, шушы килеш тә танырлар...

Авыл буйлап сәяхәт бүген дә дәвам итте. Юл уңае Нурулла такта яру цехына сугылды. Игезәк сыңары белән байтактан бирле күрешмәгән иде.

— Эшмәкәрнең хәлләре ничек? — диде ул, агач чүбенә буялган Шәмсулланың җилкәсеннән каккалап. Туган бит, якын.

— Икебез дә тартмыйбыз, ну барыбер тәнәфес ясыйк. — Игезәк өемнән киң генә такта суырып, баш-башларына бүкәннәр куйды. — Утыр, Нур! Син нигәдер бүген бәйрәмчә. Авылда туй-мазар мәллә?

— Туй, Шәм.

— Кемнәрдә?

— Миндә, Шәм. — Нурулла күнелле генә итеп сызгырды.

— Ышандылар ди сиңа! Сәҗидәнә кабат өйләнсәң генә. Тәки яшисез, ә?

— Мин нишләргә тиеш идем соң?

— Аерылмадың, рәхмәт яугыры. Исеңдәме...

— Кузгатма! — Нурулла дорфа гына игезәкнең авызын япты. — Үз бәхетеңне бел дә, дәшмә!

— Без Энже белән яратышып кавыштык, Нур.

— Мин сезнең өчен бик шат, эшкуар туган. Ярар, тәнәфес тәмам!

«Исеңдәме?» Исемдә, исемдә, сыңар. Тик син ул көнгә кагылма, яме?

— Безнең турдан үтәсеңдер, Нур. Энже студент малаены уятсын, мина

ярдәмче кирәк, — дип калган туганы Нурулланың ярты кисәге иде. Ул да өрсән шартлаган куык белән гомерен яндыра. «Без Энже белән яратышып кавыштык...» Шушы алдануың белән бәхетле син, Шәмсулла. Күрше авыл мәктәбе директоры Зөфәр үлгәч, аны Чурайбатыр зиратына җирләделәр. Энҗе соңыннан, халык таралышкач, аның каберенә ятып үкседе... Бу хакта сина бер ирештерерләр, Шәм. Ә син моны гайбәт дип сана. Сүз куган ир-аттан да кабахәт адәм юк!

Шәмсулланың олы малае капкадан чыгып килә иде, ләкин әнисе ана абыйсы белән иркенләп сөйләшергә ирек бирмәде, куарга тотынды.

— Әй сине, йокы капчыгы! Тизрәк элдер! Әтиен ачулана, Хафиз! Ни хәл, Нурулла?

— Яхшы. Хафиз буйга үскән!

— Үсмәскә ни! Кыш буе биш капчык бәрәнге, ярты үгез ашый. Алай да укуы уртача гына.

— Казанда тамыр җәяме?

— Юу-ук, ниткән Казан ди! Безнең бәхет — авыл. Әнә мәктәпләргә хатын-кыз сырышты. Бер-ике ел укытса, бәлкем, директор итеп билгеләрләр. Хафизның буй-сыны иллә шәп!

— Мәктәп директорларын яратасың бугай, Энҗе?

Нурулланың теленнән шайтан тартты, ахрысы, ул, чын мәгәр, хатын-кызның күңелендә казынып мондый түбәнлеккә төшмәскә тиеш иде.

Энҗе, кинәт тотылган карак сыман, калтыранды.

— Кайсы... кайсы укытучы бу урын турында хыялланмас икән. Безнең коллективта һәркем үзен директор итеп күрә.

— Китим әле, Энҗе, Габбас абзый чирләгән ди.

— Нурулла! — Хатын аның беләгеннән култыклады. — Әллә, җыр укытучысы дигәч тә, мин ангырамы? Кинаяләрең белән бәгырьне чеметмә инде син, Нурулла. Син безнең тормыштан бихәбәр, чөнки колхоз туганыңны да, дустыңны да алмаштырды. Синдә безнең кайгы түгел иде. Шәмсулла мине төнлә урлап кайтты! Юлдан! Без Зөфәр Газизов белән Яр Елгада укыта идек. Без бер-беребезгә балачактан ук гашыйк идек. Шәмсулла мине егетемнең куеныннан каерып алды! Минем ана тамчы да хисем юк иде. Мин балалар хакына түзеп яшим. Тик мин хыянәтче түгел! Күнел җылысын чит-ят ирләр кочагына ташымадым мин!

— Эрлисе эрләнгән, бәйлисе бәйләнгән, җиңги. — Ир әкрен генә Энҗенең кулын җиңеннән ычкындырды һәм ачынып: — Шәмсетдиннең бәхет кошы да канатсыз! — диде. Бу хатын да кызганыч иде. Яши. Язмышы белән тарткалашмый.

— Сабыр син, Энҗе, шуның өчен рәхмәт үзенә. Зөфәр Газизовны доганнан калдырма.

— Чү, ашыкмале. — Энҗенең ике бит алмасы кып-кызыл, гүя эчендәге ялкын йөзенә бәргән иде. — Син игезәгең өчен көенмә. Шәмсулланың тамагы тук, өсте бөтен. Өч бала атасы. Аларны өйләндерәсе минә. Туйларда парлашып утырырбыз, уртак оныклар сөярбез. Нурулла, карале, син тегендәге хәлләрне күреп-белеп кайткан диләр. Халык у-у итә. Миңа ачык кына әйт: хет анда җаным теләгән белән бер түшәккә баш куя аламмы? Сайлау мөмкинлеге бармы тегендә?

Йә, Нурулла, күкрәгендә кушаяклап тибенгән ярсу атыңны тышавылыйсыңмы, әллә ирекка җибәрәсенме? Укытучы башы белән әкияткә ышана, тьфү!

Юк, атыңны тышавыла, Нурулла. Игезәк сыңарың никадәр генә газиз булса да, бу хатынның өмет учагына нәзек кенә телеп чыра сал.

— Куярсың башыңны, җиңги, куярсың.

— Шулаймы, туганым. Ай, рәхмәт!

Бу матур ялганың өчен җилкәндәге фәрештә «гөнаһ» дип язар, Нурулла. Әнә, сул аягыңа аксадың, димәк, «дәфтәрең» авырайды.

Аның каравы учакта чыра кабынды!

Туксан яшьлек Габбас карт лупалы күзлеген борынына элеп Коръән укый, ә инвалид арбасындагы улы — аяксыз Хәйретдин кечкенә табакка бәрәңге әрчи иде. Хуҗалар кунакка шатланды.

— Уз, бирегә уз, улым, — диде карт, диваннан урын күрсәтеп.

— Мин үтешли генә, Габбас бабай. Ни хәлләрдә көн итәсез?

— Әлхәмделүлләһ, улым!

Карт артыннан улы да кабатлады:

— Әлхәмделүлләһ, энем. Безгә ни, пинсә — Хөкүмәттән, үлем — Ходайдан дип шөкерана кылабыз, әйеме, эти?

— Син, Нурулла улым, безнең хакта бер дә пошынма. Өебез җылы, син салдырдың кана. Тәмуг утын да син...

— Әй, эти, эти, — дип бүлдерде Хәйретдин абзый. — Ниткән тәмуг уты? Җир астыннан суыртылган табигый газ диләр аны, эти!

— Суыртса — тәмугтан суырталар, чутыр-матыр! Кысылма олылар гәпләшкәндә, — дип ачуланганнан соң, карт рәхмәтләрен тезде. — Суын да калункадан ялгаттырдың, мунчабыз да янәшәдә генә, тәмуг уты белән җылытыла, дәүләттән пинсәне дә күп бирдерттерәсең, Нурулла улым.

— Эти, син — сугыш ветераны, рәис яраларың турында белешмәләр юллатты, шуннан акчаң артты, — диде Хәйретдин абзый.

Шуңа игътибар итте Нурулла: картның чәче чем-кара, ә улыныкы тузганак төсле ап-ак, йөзендә дә буразна-буразна сызык иде.

— Сиңа алтмыш өч яшь бит, Хәйретдин абый?

— Алты да, өч тә, — дип җөпләде гарип. — Беркөнне чегән катыннары чүпрәк-чапрак сатып өй борынча йөри. Миңа «папаша», этигә «маладуй чалавик» диләр. Аңа джинсы чалбар, миңа җылы эчле ыштан төртәләр. Эти мут хайван, заманында өч катынга үләнгән. Мин гарипкә берсе дә тәтемәде, шуңа иртә картайдым мин, энем. Наз-тәрбиядән мәхрүм ир бәндәсе тиз муртая икән. Сиңа рәхмәт, энем, хет дөнҗа белән аралаштырасың. — Хәйретдин абзый арбасын өстәлгә табан эттерде. — Кампитыр бүләк итеп ялгызлыктан йолдың син. Сәйдә әбинең оныгы Алмаз «ә» дигәнче үрәтте, малайгынам. Башлы икән прафисыр балалары. Абый, ди, аягыңа интпланты куйдырабыз әле, ди, киләчәктә, ди. Җөртәбез әле сине, ди. Монда җөргәннән дә артык. Ентирнитка тоташтыргач, Җир шарының любуй җире белән чүкердәшәбез. Эти, әтәчнең кикриге канаган иде, үлмәгәнме-төгәнме, караштырып кер.

— Ә син, чурту-матыр, тагын тартмаңа кадаласыңмы? Әй, ахырзаман калдыклары! — дип карт сукрана-сукрана чыгып киткәч, «тузганак» авызын ерып:

— Энем, мин моннан апамны таптым! — диде. — Айт, туган, көлемсерәмә! Үз акылымда мин. Сиңа безнең бүгенге тормыш тәрәзәсе ачык, ә үткәннәрнеке — ябык, энем. Эти сугыштан марҗага өйләнеп кайта. Мария Сергей кызына. Аларның Маргарита исемле оланы туа. Ә бу чакта күршедә минем булачак әнкәм килен хезмәте үти икән. Ул үлгәндә син бишек баласы идең, Нурулла энем. Әнкәм гүрендә әйләнеп капланса капланыр, вчүтеки дөресе шул: мәрхүмә кәкре аяклы, кылый күзле иде, авызы чалыш иде. Чиләгенә таман капкачы — ире Гарәфетдин калхузда көтүче икән, ул иртән чыбыркысын асып киткәч, булачак әнкәм шомырт куагы төбенә посып җыру җырлый

икән. Әби хатирәсеннән болар, энем. Габбас солдат анын монлануыннан үксеп жылый икән.

«Әй, бакча карачкысы! Жыруы белән улымны сихерләде!» — дия иде әби. Габбас солдат маржасын кызы белән йорттан куа да, Гарәфетдин хатынын апчыга. Тугыз айдан мин — гарип туам. Әби: «Маржаның каргышы балага төште», — дип гел әнине талый иде. Маргарита апамның Ригада икәнен ачыклагач, хат яздым. Жавап бирде, ышанасыңмы, энем? Братишка, дигән, жәренгә сабантуйга приеду, дигән, ышанасыңмы? Әтигә пока белгертмим, сюрприз ясыйм, Аллаһы боерса. Тик, энем, мин аяксыз ничек Маргарита апамны каршылармын икән?

— Аэропорттанмы, поездданмы, апаңны үзем барып алырмын, Хәйретдин абый. Ике туган Сабантуй бәйрәмендә күңел ачарсыз.

— Өч туган без энем, өч! — Хәйретдиннең күзе сәер ялтырады. — Сенел дә исән минем. Әти аны белми һәм белмәве хәерлерәк. Безнең әни им-томчы иде. Бервакыт яңа гына туган сабыен биләүгә төргән апа аңа өшкертергә килде. Мин мич башында идем, әни, кеше-фәлән юкмы дип аралыкны карады, тик мине итекләр каплаган иде. Вәйт бу хатын жылый, Галимәттәй, кызым Габбас абыйдан, ди. Әни дә жылый. Үскәнем, нишләп син безнең тормышны ватасың, без бит гарип бала үстерәбез, ди. Ватмыйм, Галимәттәй, ант мәгәр, бу сер икебездә генә калыр, ди көндәш. Бездә ферма төзегән шабашниктан дип әйтәм мин, ди. Хатынлы ир белән чуалган дип авылда күземне ачырмаслар, ди. «Кызыңның дүрт саны да исәнме?» — ди әни. Шөкер, исән, ди тегесе. «Маржа каргышы синекенә тимәгән шул», — ди әни, көрсенеп. Азактан ул минем тыңлап ятканымны күрде. Ботымнан умырып: «Син, шымчы, мәгәр атаңа лыгырдасаң — Ходай ике кулыңны да өздертә», — диде. Әни үзе дә ир ерткан, фәрештә түгел, шуңа күрә көндәшен кыйнап чыгармагандыр дим. Аннан, сугыштан соң ирләр аз, безнең әти кебекләр пачутта. Синең безгә яхшылыкларың күп тиде, энем. Ашка — аш белән ат дисәләр дә, мин сиңа алай итмәдем шул, бер нәрсәне яшердем. Бүген буаны ерам, чөнки дә син әүлия өммәтеннән, энем.

— Гыйбрәтле язмышлар, — диде Нурулла, урындыгыннан күтәрелеп. Әүлия дисәләр аның шунда ук йөрәге кага иде. — Безнең күңел кин, сенеленне дә чакыр. Кайчандыр бер ул да абыйсы белән танышырга тиеш бит.

— Монысы бик четерекле мәсьәлә, энем.

— Алайса, үзеңә кара инде, Хәйретдин абый.

— Башта син карап кара! Син әүлияме? Әүлия! Килешерме бу эш? Ул кыз — кияүдәге хатын! Габбасны әтисе дип уйламый да.

— Йә инде, Хәйретдин абый, кырмавык төсле ябышма! — Нурулла аяк очы белән идән тактасын ышкыды. — Чери, сулап юасыз, ахры. Алыштырырбыз, иншаллаһ!

— Вәйт, ябышам әле! Синең хатыныңң Сажидә иде теге төргәктәге олан! Ул миңа сенел, ә син — кайнеш! Әһә, гарип туганыңнан оялясыңмыни?

Гөрс-гөрс... Жилкә чокырына гөрси белән кундырдыларммыни, ирнең колаклары шавылады.

...Ул хәтта Габбас белән дә саубуллашмады. Хәер, карт үзе дә илтифатсыз, эт сыман телен салындырып, сарай кырыенда чаш-чыш чалгы кайрый иде.

## 6

— Авылда тагы ниләр сөйлиләр?

Нурулланың бу соравы һәр иртә кабатлана, һәм һәр иртә Сажидәсе эчтәлеге белән бер-берсенә охшаган «исәп-хисап» тота иде.

— Сине мактыйлар, Нурла.

— Гелән-гелән мактагач начар инде ул, бичәсе.

— Яманлаучылар да хәйран, Нурла!

— Менә монысы шәп! — диде ир, хатынны шаккатырып. — Нәрсә быкылдыйсың, бичәсе? Кайчакта мактаучылар җиргә сылап кабырганны сындыра, ә хурлаучылар, канат үстереп, күккә чөя. Кеше ул гел киресен эшли!

— Нурла, яшь хәзрәт безне сабакка җыймакчы да, ирләрегездән, йә атагыздан рөхсәт сорагыз, ди.

— Рөхсәт, Сажидә, рөхсәт.

— Фельдшер Аниягә гашыйкмы соң Руслан хәзрәт, аңа караса — теле көрмәкләнә...

— Һе, гашыйк дисенме? Безнең Чурайбатыр кызлары чибәр алар, — дип, Нурулла үзалдына елмайды. Читтән ярәшә, имеш, бу авыл кызлары хәрәм, имеш. Йөрәгенә мәхәббәт шырпысы сызып ташласалар, дөрләп янасың, мулла энем!

Кинәт кенә ирнең күз кабаклары тартышты. Чаш-чош, чаш-чош... Габбас карт чалгы кайрый... Тау итәгендә печән чапканда да картның теле авызыннан бүселә иде...

— Ания акыллы нәселдән, безнең Рифатка да тиң иде дә... Ник син аны чит илгә җибәрдең инде, Нурла?!

— Өч айда улыңның укасы коелмас. Сентябрь урталарында кайтыр, иншаллаһ!

— Казан да Казан дияр микән? Хәзерге яшьләр авылда тирес түкмәс шул.

— Тиресен дә түгәр! Агроном бит ул. Син менә, бичәсе, аны бер начар гадәтеннән биздермәдең, ә?

— Нинди гадәт ул, Нурла?

— Берәр эш эшли башласа, теле авызына сыймый.

— Олыгая-олыгая җыйнакланыр әле, Нурла.

— Чир китә, гадәт китми, бичәсе! Әллә әтиең шундый идеме?

Нурулланың җилкә чокыры тагын бер гөрси тансыклый иде. Абыйсы кебек сеңлесе дә чатнатып: «Габбас карт минем әти!» — дисә? Тик Сажидәнең керфеге дә селкенмәде.

— Мин әтине хәтерләмим, Нурла, — диде.

— Эзликме соң?

— Әйем лә, кирәге юк. Син атамнан да якын, синең җилкәңә ышыкланып яшәдем, шуна бик канәгать инде мин. — Чәчәк сыман тажларын йомган хатын әкрен генә ачыла иде. — Тел дип... Мин генә гаеплемени, Нурла? Син малаеннын йоклаган чагын гына күрә идең. Сиңа колхоз баладан да кадерлерәк иде.

Хәйретдиннән ишеткән хәбәр атна буе бәгырьне тырнады. Шул хак микәнни? Гарип ир алдашмас анысы. Сажидәсе кызганыч, өч урам аша гына яшәгән атасына «әти» дия алмаган. Өч туганны сабантуйда һичшиксез күрештерергә кирәк. Әгәр Хәйретдин абый моннан егерме ел элек үк сер төенен чишсә, мөгаен, Нурулла кызының кулын сорарга туп-туры Габбас картларга керер иде.

— Алайса, мин мәчеткә барам, Нурла.

Баштан-аяк төренгән Сажидә нәкъ япон курчагы иде.

— Килендәшең Энжене дә үгетлә, — диде Нурулла. — Ул да догалар өйрәнсен.

— Ә син кая җыендың, Нурла?

— Үзәккә, бичәсе. Йомыш белән.

Анын «йомышы» бик катлаулы иде. Туйбикә чакыра... Йөрәк өчен ни-нәрсә белән бәхилләтер нечкәбил. Бу хатын, Казаннан күченеп кайтканнан бирле, тып-тын гына аккан гомер елгасында дулкыннар уйната иде. Нуруллаңы ике яктан ике көч йолыккалый: анын берсе — горурлык, икенчесе — ярату иде. Тик соңгысы көчлерәк иде. Йөрәкне кырык хәнҗәр белән чәнчегән Туйбикәгә ул һаман суынмады.

...Ун машина тузан болытына күмелеп олы юлдан җилдерде. Беренче очраган агачка асылыныр хәлдә иде егет. Туйбикә Казанга качкан! Туй көнендә! Йа, нинди хурлык!

Җәйләү сукмагыннан бер кыз йөгерә иде. Күзен хәсрәт элпәсе каплаган егет аны танымады.

— Кем ул? — диде.

— Мыштым Сажидә бит инде, — диде сынары. — Бездән өч сыйныф түбән укыды. Сыер сава.

— Йәле, Шәм, тормозга бас.

— Нишлисен, Нур?

— Шул кызга өйләнәм!

— Акылындамы син?! Мыштым дөмә ятимә. Без хәерче, ул бездән...

Нурулла игезәгенә кизәнде:

— Бас!!!

Күрәсен, анын ачуы бүртеп, тиресен кабарткан иде, кизәнгәндә костюм җиңе шытырдап ертылды. Ул кош кебек Сажидәгә табан очты. Кыз исә ярсып өстенә килгән Алыптан өркеп җиргә чүгәләгән иде, егет аны култыклап торгызды.

— Курыкма, сылукай, мин сиңа өйләнәм.

— Кайчан? — Сажидә аска караган килеш халатындагы сөт табын бармагы белән казыды.

— Хәзер үк!

— Ятимә дигәч тә, мыскыллама сана, Нурла!

Егет юлда туктаган машина кучена курсәтеп:

— Әнә, дуслар безне көтә, — диде. — Әйдә, җәлт кенә кулыңны сорыйбыз да...

— Кемнән, Нурла? Минем ни әти, ни әни юк.

— Кемнән, кемнән, янәсе. Капкагыз баганасыннан! Таяк белән шалт берне, шалт икене, шалт өчне! Дәшмәсә, риза, димәк.

— Шулай ярый диме китап?

— Ярый ди, сылукай. Йә, ялындырма! Тиздән ЗАГС бүлеге ябыла, кафеда ашлар суына.

Мәҗлестә Нурулла күнелсез иде. Гүя аны озак кына дөмбәсләгәннәр дә, аннары аркасыннан терәү белән терәтеп өстәл янына утыртканнар: сулаган саен тынга авырая, күз аллары караңгылана, ул әле тагы кунакларны сыйлаганда көләргә маташа, әмма бу көлү яралы арысланның ыңгырашуына тиң иде.

Туй узды. Кияүнең күнелендә төер-төер сагыш та, ямаулы кесәсендә түләнәсе бурычлар калды. Житмәсә, Шәмсулла урман бете сыман кадалып, канын агулый иде.

— Хатаң бә-әк зур, Нур. Язмышыңны җан сөймәгән белән бәйләдең. Эллертәсе иде безгә Казанга, башына капчык кигезеп апкайтасы иде Туйбикәне.

— Эчемне пошырма, Шәм!

— Ялгыштың, Нур, ялгыштың.

— Алай бик акыллы икәнсең, минем ялгышны кабатламассың, шәт, — диде Нурулла.

— Кабатламам, — дип әтәчләнде сыңары. — Кыз кереләнсә, мин аны урлыйм гына!

Нурулланың армиядә бергә хезмәт иткән дусты Идрис тә туйда иде. Ул институтның тарих бүлегенә имтиханнар тапшырган икән. Анда аның олы абыйсы декан икән.

— Син дә көндезге бүлектә укы, — диде хезмәттәше. — Абый барысын да җайлар, — диде.

Кияү егете ул кичтә томан эчендә йөзә иде. Шуңа күрә Казан кунагына «әйе» дә димәде, «юк» та димәде. Атна-ун көннән соң, зиһен күге аязгач, яшь ир игезәге белән уй-ниятен бүлеште.

Ни гаҗәп, «сыңары» аның шул сүзен генә көткәндәй:

— Миннән хәер-фатиха, хет син укы, иту безнең нәселдә гел кара халык — җир сөрәбез дә агачта чокынабыз, — диде.

Нурулла сызланып кына:

— Туй чыгымнарын нишләтим? — диде. — Җизни — туган, кәҗә — мал түгел, дигәннәр. Дөрес икән, әнә ападан әйттергән, кышка тиклем как ыштик акчаны китерсен энең, дигән.

— Ике бура бастырдым, шуларны сатып үзем түлим!

— Син аларны үзеңә атаган идең, Шәм. Үзбаш чыгам дисең.

— Һи, балта безнең кулда, бүтәнен салырмын. Ә син укы, бырат, син башлы.

Игезәкнең ярдәменнән дәртләнгән Нурулла тиз сүрелде:

— Онытканмын, каһәр суккыры! Мин бит өйләнгән!

Ләкин Шәмсулла аның юлындагы киртәләрне берәм-берәм ишеп бара иде.

— Өйләнсәң ни! Хатының койрык мәллә? Дүрт ел әни карчык белән яшәр. Ана бу бәхете дә житеп ашкан.

— Күпсенмә, Шәмсулла.

— Мина ни... Авыл кызлары тәтелдәшә. Шул буй-сыны, чибәрлеге белән баз бакасын яръште диләр.

— Сажидә дә адәм баласы, аны кимсетмәгез! Колагына киртләденме?

— Киртләмәгән кая! Син дә бугаз ерма. Нервыларың тузган, тизрәк Казаныңа сыптыр, эһе.

«Көндезге бүлеккә укырга чакыралар», — дигәч, Сажидә «синсез мин нишләрмен?» — дип елап муенына сарылмады. Ул бер генә күзәнәктән яралган хиссез хатын иде, ахрысы. Ә бит Казан Нурулланы дәваламады, киресенчә, йөрәк ярасын тагын да тирәнәйтте генә. Якында гына табиб студентларның тулай торагы иде. Урам аша чык та тәрәзә пыялаларын селкетеп сөрән сал:

— Туйбикә-ә-ә!

Йөзәрләгән тәрәзәнең берсеннән карабодай кырының буявына манчылган Туйбикә күзе багар...

— Нурулла-а-а! — дияр кыз, һәм, сөенеченнән аягына да кимичә, беренче катка атылыр. Тик нигәдер үз исеменең кайтавазын ишетми Нурулла. Ишетер иде дә, аңа Туйбикә кычкырмый шул...

Ял киче иде. Бүлмәдәш егетләрнең кайсы кая таралышты. Идрис аның караватына чалбар белән күлмәк ыргытты.

— Әйдә, киен! Күсе төсле үзеңне үзең кимермә, мәхәббәт колы! Туйбикәнне күреп кайтабыз!

Нурулла бу тәкъдимгә бишкуллап риза иде. Кыз белән кара-каршы утырып сөйләшсә, бәлки, бу газаплар кимер, ул тынычлап укыр. Ләкин акыл хистән көчлерәк иде. Ә горурлык баш имәс өчен тораташ катты. Гәрчә туеннан качкан

Туйбикәне кичерсә дә, ана үпкә-кинә сакламаса да, эчтә нидер бар, һәм шушы «нидер» кул-аягын тышаулаган иде.

Нурулла күлмәк-чалбарны бөгәрләп мендәр астына тыкты.

— Артык майлы ризык белән кыстама, Идрис, — диде ул, йөзтүбән караватына капланды. Шунда тулай торакның типсәң генә ачылган, типсәң генә ябылган катыргы ишеге шыгырдады.

— Өйдәләрме? — Тонык тавыш иясе — аның хатыны иде. Аркасына аллы-артлы төенчекләр аскан Сажидә бүлмә уртасында йөген «бушаткач», «уф» диде.

— Уф, алтынчы ятажда икән син, бик биектә икән, Нурла.

Идрис ир белән хатынны калдырып шыпан гына тайган иде.

Сажидә, шәлен чишә-чишә:

— Мин сиңа күчтәнәчкә бәрәңге белән ике каз түшкәсе апкилдем, Нурла, — диде. — Ач ятадыр, ди әни. Быел тананы тундыргач кына суярбыз, ди. Ана тиклем каз итеннән шулпа пешерсен, ди.

Башта Нурулла йоны сирәкләнгән иске шәл бәйләгән өтек кыяфәтле хатынына: «Нишләп кеше көлдереп йөрисен, көя күбәләге?! Мин төрмәдә мәллә?» — дип жикеренмәкче иде, тун төймәсен ычкындырган Сажидәнең нәни генә түгәрәк шар «йотканын» шәйләгәч, ачуы шиңде. Ул үзалдына мыгырданып:

— Казларны иртәрәк суйгансың, декабрьнең яртысы гына бит, — диде.

— Ызбада без хәзер дүрт тамак. — Сажидәсе капчыкларын бушатырга керешге. — Сиңа яңалыгым шул ие тагы, Нурла. Шәмсулла да иптәш хутлады.

Хатын идәнгә тункайган саен «шар» кысыла кебек иде. Ир аны кулы белән караватка табан кысрыклады.

— Утыр! Кая, әйберләрне үзем урнаштырам. Шәмсулла нәрсә хутлады дисең?

— Катын инде.

— Кайчан?

— Өченче көн никах укыттык.

— Кемгә өйләнде?

— Укытучы Энжегә. Туйлары Яңа ел бәйрәмендә. Син кайт инде, зинһарлап сорыйм, Нурла. Әни дә борчыла, дүртенче ай өнсез-тынсыз, ди сине.

— Кайтам, билгеле, — диде Нурулла. Ул үзен дә, Сажидәне дә түгел, ә кемнедер үртәгәндәй:

— Сафиулла малайларының туйлары, ни хикмәт... — Тел очындагы «кызганыч» сүзен акыл тиз генә башкасы белән алмаштырды: — ... кызык була.

Ир-атның хисе үрмәкүч кебек икән, пәрәвез жебе үреп тоткын итеп ала да, ычкындырмыйча, киптереп үтерә. Ярты елда Нурулла ябыгып саргайды. Туачак сабый да аны бу тоткынлыктан коткармады. Көндез — институт, кич — бүлмә, алда исә сөремле күк йөзендә тонык кына жемелдәгән йолдызлары белән ялыктырган шәһәр төне...

Идриснең туган көне иде. Егет табын әзерләде.

— Сез миннән башка гына күнел ачыгыз, — диде Нурулла. — Мин барыбер капмыйм, ә табындагы аек ир-аттан шымчы дип шикләнәләр.

Солдат дусты аның мондый галәтләренә күнеккән иде.

— Озак болганма, Казан жилендә суын да, безнең әртилгә кушыл, — диде.

Хыянәтче йөрәк аны биш катлы тулай торак бинасына табан әйдәкли иде. Ир, йодрыгы белән сул кулының учына төя-төя, үзен тыярга маташты.

Ахмак син, Нурулла! Туйбикә аргы ярда, син бирге ярда, ә уртада тирән дәрья...

— Гражданин ир! — Супермаркет ишеге төбендә озын тунына уралган бер хатын ана кул изәде. — Өч бүтилкәгә шабашка эшлисеңме?

— Мин эчмим, — диде Нурулла, юлын дәвам итеп. Ләкин хатын да эре иләктән иләнгән иде:

— Эчмәсәң, тагын да әйбәт! — диде. — Акча белән бәхилләтермен. Акайма, гражданин, постельгә кыстамыйм, кибет директоры Анна Ивановна мин. Ике йөкчем дә дупыл исерек, машинадан тауар бушатырга иде. Ризамы? Хәзер шоферымны да чакырам.

— Чакырмагыз! — Ир фургоннан капчыгы белән шикәр комын алып, бала кебек кенә җилкәсенә «атландырды»:

— О боже, әкиятләрдәге дию мәллә син, гражданин?

Директор капчыкларны чөеп «уйнаган» егеттән бихуш иде. Акыллы хуҗа мондый баһадирны йөз алтынга сатып ала!

— Гражданин, әйдә, миңа эшкә кер. Өчләтә түлим!

— Беренчедән, мин гражданин түгел, ә Нурулла. Икенчедән, мин — студент, ханым-апа.

— Нурулла икән, Нурулла! Кичкырын бушмы син?

— Буш!

— Давай, сәгать җидегә кил.

Йөкче һөнәре аңа бик килеште. Төннәрен студент Нурулла колагын аю чәйнәсә дә уянмас булып, изрәп йоклый башлады.

Ә беркөнне ул тотылды. Супермаркеттан көлешә-көлешә кызлар чыгып бара иде. Нигәдер ир каты гына тамак кырды. Бу инде кемгәдер «әй, син!» дигән ишарә кебек ишетелде, һәм менә берәү борылды. Ул Туйбикә иде. Кыз башта сәерсенде, аннан соң челтерәп «агып китте». Аның көлүе чишмә агышын хәтерләтә иде.

— Абау ла, абау! Азизов, синме бу?!

— Мин, Туйбикә. — Яшь ирнең өстендә онга буялган иске халат иде. Иртә уңмас — кич уңмас ди, нәкъ менә бүген кибеткә олавы белән он китергәннәр иде.

— Казанда нишлисең, Азизов?

«Сафиулла малаеның институтта белем ташы кимергәнен ишетмәгән бугай», — дип уйлады Нурулла.

— Нишләмим, тарих бүлегендә укыйм.

— Ой, тамаша! Кайчаннан бирле супермаркетта тарих өйрәтәләр инде, Азизов?!

— Биш былтыр! — диде ир, мәзәккә әйләндереп.

Ләкин аның шаяртуы Туйбикәне чыгырыннан чыгарды.

— Мине эзәрлеклисеңме, тинтәк! Мин кем дә син кем?! Мин — табибә, ә син — тракторчы. Кайт та, җиренне сукала!

Тамагына кадалса да, Нурулла бу каһкаһәне йотты. Хатын-кыз белән әрләшер өчен бүрегеңне салып ташларга кирәк. Димәк, син ир затыннан түгел.

Өч көннән ул склад тирәсендә тагын Туйбикәне очратты.

— Сәлам, егеткәй! — диде кыз. — Сине сагынып килдем әле.

Нурулланың җилкәсендәге капчыгы аркасыннан шуып, карга ауды. Һай сантый авыл малае! Хатын-кызның телендә дару да, агу да бер чама.

— Белештем мин, Азизов. Син чынлап та студент икән. Нигә соң хыялларың белән алданрак уртаклашмадың?

— Кинәт булды ул, Туйбикә.

— Кинәт дисең инде... — Кызның йөзеннән соры болытлар шуышты. — Ә бит син без ЗАГСта язылышасы вакытка сонармагансың, әйеме? Мина үч итеп өйләнден инде, әйеме? Яратуың ташка үлчим икән, егеткәй. Әйдәле, иртәгә сәгать икедә Бауман урамында күрешәбез. Миндә идеальный фикерләр туды.

Нурулла: «Барыйм микән, бармыйм микән?» — дип, ике сорау арасында чабулап йөрмәде: юынды, кырынды, киенде һәм очрашуга китте. Туйбикә түгәрәк сәгать астында таптана иде.

— Юеш кар ява, чыланасың, — диде ир. — Кафега керик.

Кафеда гына түгел, дөньясында алар икәүдән-икәү генә кебек иде. Туйбикәсе, яратып туялмаслык Туйбикәсе меню дәфтәреннән ризык сайлый... Борыны, иреннәре, тар мангае, каш-керфекләре Җиһаннын хуҗасы тарафыннан могҗизаи кылкаләм белән ясалган бугай, бигрәк матур, бигрәк камил! «Мина үч итеп өйләнден инде, әйеме?» Юк, Туйбикә, горурлык эше бу... Менә хәзер әкияттәге тылсымчы карт таягы белән бер селтәнер дә, үткәндәге барлык хата-ялгышларны төзәтер кебек...

— Төче коймак белән чәй эчәбез, — диде кыз. — Син, Азизов, башыңда нинди фикер туды дип төпчен, әйдә. Ярар, төпченмә! Бик гади нәрсә ул: без синең белән институтларны тәмамлагач, аспирантурада калабыз.

Тылсымчы карт таягы белән селтәнде, әмма могҗиза урынына башка таш яуды.

— Кыскасы, Туйбикә?

— Кыскасы-озыны шул, Азизов, син бүгеннән үк киләчәгең турында кайгыртырга тиеш!

— Минем киләчәгем — авыл, Туйбикә.

— Ә мин? — Кызның күзләре зурайды. — Мин борын-борын заманныкымы? Син мина тиңләшер өчен беренче адымны атладың инде. Икенче адым — кандидатлык диссертациясе, өченчесе — докторлык. Шуннан соң син мине профессор улыннан аертып аласың. Әйе, әйе, мин тиздән профессор килене булам. Биш-алты ел эчендә үзеңне тамырдан үзгәрт, Азизов.

Кайнар чәй яшь ирнең телен пешерде. Төннәр буе сагыштан өтелгән йөрәгенә шифасы тиярдәй көчле дару биреләр, егет. Кап! Юк, капма, ахырдан ул барыбер агуга әйләнер...

— Мин үзгәрмәм шул, Туйбикә, чөнки эчемдә һаман тракторчы малай утыра, — диде ир.

## 7

Тик трактор тимердән, ә җан — хистән гыйбарәт иде. Тормыш мәшәкатьләренә никадәр генә күмелсә дә, Нурулла ярату савытының төбен корытмады. Хәер, корытырлык көче дә юк иде.

Дөньясын сыртына күтәрерлек дәрт-дәрманга ия иргә мәхәббәт дигәнең генә буйсынмады. Югыйсә йөрәккә сыеп беткәч, ул бәләкәйдер, бик бәләкәйдер инде, ә үзе нинди кодрәтле иде! Әмма Туйбикә ягына авышмады Нурулла. Кызның хыялы — офыктагы рәшә иде. Ахыр чиктә Туйбикә — Казанны, ә Нурулла Чурайбатырны сайлады.

Менә икегә аерылган сукмак кабат тоташты... Тик ни үзгәрер икән? Әлегә хәтле ничек яшәлгән, шулай яшисе дә яшисе... Туйбикә барыбер аныкы. Аның ярасы, аның сызланулары, аның бәгырь кисәге. Бер генә адәм баласы да арбасына шатлык-куанычлар гына төяп келтер-келтер гомер күпереннән узмыйдыр.

Үзәккә барышлый ул аръяктагы Кәҗә Фатыймасына керде. Тирә-якта оста шәл бәйләүче дигән даны таралган аксак хатын йон эрли иде.

— Шәлләрең бармы, Фатыйма апа?

— Миндәме? Дистәләгән алар, рәис балам, дистәләгән. Синең Сажидәңә, мөгаен, сорысы төстер.

Нурулла хәйләләп маташмады:

— Хатынга түгел, — диде.

— Бәрәч, кемгә?

— Бүләккә, Фатыйма апа.

— Һе, шулай ук мыни. — Шәлче диванга кадакланган үрнәкләргә күрсәтте:

— Эрерәк бизәклесе кыз-кыркынга, ваграклары — кыз-катынга, тыгызрак бәйләнгәне — әби-чәбигә. Бүләк итәсе кешең яшьме, картмы, рәис балам?

— Яшь, бик яшь, унҗидедә, — диде ир. — Син миңа кар кебек ап-агын бир.

— Кесәңә генә сыешлы итеп төримме, рәис балам?

— Төр, Фатыйма апа. Бүген бөтен авыл белер инде бу шәл турында.

— Авыл ук димә әле, син! Аксак аяк әллә ни кинәндермәс. Ярты Чурайбатыр тучны белер, монысына гарантиә, рәис балам.

... Туйбикә аны үзәктәге беренче тукталышта каршы алды. Ул машинасының гына тәрәзәсен шудырып:

— Әйдә, Азизов, — диде.

Анда ук сизенгән иде Нурулла, хатын урман юлына борылды. Димәк, аланга ашыга.

Хыялларның туры килүен кара син! Ул да ничәмә ничә тапкыр шушы табигать оҗмахына талпынды, әмма нигәдер күңел тартмый, мөгаен, алан аларны парлап көтә иде.

Алан һаман шул алан иде...

Туйбикә кулындагы сумкасын чирәмгә ыргытты.

— Исәнмесе-е-ез!

— ... с-е-ез, — диде кайтаваз, гаҗәпләнеп. — Сез?! Ничә елдан соң монда нәрсә югалттыгыз?! Әллә кешеләрдән качып-посып очрашасызмы се-е-ез!!

— Азизов! Мәрткә китмә! Нинди шомлы тынлык бу? Нишләп кошлар сайрамый, нишләп күбәләкләр очмый?

— Август бит, Туйбикә.

— Ә кайда соң ул май айлары?! Кайда, Азизов?! — дип еламсырады хатын. — Мин сары чәчәкләрдән такыя үрер идем!

— Такыя ни ул, менә моны ябын әле син, Туйбикә. — Нурулла түш кесәсендәге шәлне туздырды. — Сиңа килешәдер.

— Фатыйма апа әле дә бәйлимени? Шәленә кушып гайбәтен дә сата инде, бахырым. Әй, иртәгә чәйнәрләр сине авылда, әй чәйнәрләр, Нурулла фәлән, Нурулла төгән...

— Гайбәтсез авыл — җансыз авыл ул, Туйбикә. Рәхәтләнеп чәйнәсеннәр! Мин катырак инде, тешләрен сындырмасалар ярый.

— Рәхмәт, искиткеч матур, — диде Туйбикә һәм шәлне йомарлап сумкасына сонды. — Без бу аланга бүләкләр бирешергә килмәдек, яме, Азизов?

— Йә, — диде ир, ул Туйбикәнең менә шулай якында гына, бик якында гына ярым үпкәләп, ярым үртәлеп торуына ышанмый, аның бу нәзберек күбәләккә кулын тидерәсе, аның дөньяда барлыгына тагын бер кат инанасы килә иде. Ирләр хисләнсә гаҗәп икән бит! Горурлыгыңны кис тә ат инде, Нурулла. Туеннан качкан җилбәзәк кыз белән акыл утырткан хатынны бер җепкә бәйләп уртаклык эзләмә! Үткәннәр тузанын туздырып ни файда? Алай дисәң? Менә үзең дә буталасың инде, Нурулла. Шул үткәннәрдән бирле Туйбикә бер тотам

калмыйча синең янәшәңнән атлый түгелме соң? Иртән, кырына башласаң, битеннән тиресе киселә: чөнки көзгедән Туйбикә карый... Шунда йөрәкнең дә читенә пәке элгә...

— Алан картайган. — Хатын жинелчә генә аны аркасыннан этте.. — Әйдә, урманнан әйләнәбез, Азизов. Әнә тегендәге зу-ур гына кырмыска түмгәге кайда икән?

— Кырмыскалар синең арттан ук каядыр күченгән, Туйбикә.

— Хәтерлисеңме, без бәхәсләшкән идек. Әгәр чыгарылыш имтиханнарында син «бишле» алсаң — кырмыска оясына биш минутка мин битемне куям, әгәр алмасаң — син.

— Хәтерлим, мин оттырган идем.

— Абау, ә ник теге имәннең яфраклары каралган, Азизов?

— Сине сагынуга түзмәгәндер, Туйбикә!

— Хәтерлисеңме, син минем букчамны иң югары ботакка чөйгән идең.

— Кайтам да кайтам дип ачуны чыгардың бит, Туйбикә.

— Әй, жыен бала-чага сүзе сөйлибез инде! — Хатын кисәк кенә туктады. — Азизов, бу районда мин өч ел да биш ай яшим! Син нишләп монарчы, Туйбикә, хәлләрең ничек, дип ишегемне какмадың, ә?

— Йөрәгем белән кактым бит, Туйбикә.

— Йөрәгем белән, имеш! Син миңа мәет килеш кирәк түгел, Азизов!

Нурулла «күбәләк»нең кулыннан тотты.

— Хәлләрең ничек, Туйбикә?

— Миннән көлмә, яме, Азизов, — диде хатын. — Теге Туйбикә юк инде ул. Дөнья мине уңлы-суллы янаклады, Азизов. Син минем хакта ни беләсең инде, йә? Казанда укыганда киреләнмәсәң — бергә каласы идек без, ә син — боз сын, әз генә дә эремәдең. Профессор малаеннан мин ун елдан соң, улыбыз исәйгәч аерылдым. Вак иде, эт бете иде. Ир затларыннан унмадым мин, Азизов. Жир синдәйләрне бүтән тудырмаган иде. Бүлектә без ике хирург-кардиолог идек. Коллегам операция ясаса — авыру үлә, ә минекеләр өр-яңадан яши! Коллегам шуңа кара коела иде. Көнләшү начар нәрсә икән, Азизов: ул бәндә юк гаебемне табып минем өстемнән министрлыкка шикаятьләр язды, клиниканы гайбәт белән сасытты. Мөдир, билгеле, аны яклады, чөнки кодасы иде. Шуннан соң мин клиникасына да, Казанына да «әллүр» дидем дә үзебезгә кайттым. Әләкче коллегамны хәзер операциягә кертмиләр, бармаклары кәкрәйгән икән. Ә син, Азизов, үзең белән таныштырма, яме. Ничә тавык-чебеш асравына хәтле хәбәрдар мин. Чурайбатырларга бәхет капкасын ачкан кеше инде син.

Туйбикәнең кулы каз мамыгы сыман йомшак иде, ир аның жылысын йөрәгенә сеңдереп өлгермәде, хатын кисәк кенә читкә тартылды һәм күзендә пәриләр биетеп:

— Йә, мин һаман чибәрме, Азизов? — диде.

Нурулла каушамаска тиеш иде, Нурулла жир йөзендә нинди назлы сүзләр уйлап табылган, шуларның һәммәсен дә жыеп бу күбәләкнең колагына пышылдарга тиеш иде. Ләкин авыз эчендәге агач тел нәрсәдер әваләде дә әваләде, әллә жөмләләр, әллә авазлар...

Туйбикә тагын һөжүмгә күчте:

— Ә син мине әле дә яратасыңмы, Азизов? Нигә баш кына селкисең? Кычкырып әйт, шау тимер! Мин синнән шушы сүзне күпме ишетергә тилмердем!

— Болай да аңлашыла бит, Туйбикә.

— Нәрсә аңлашыла, Азизов?

— Гомер сине уйлап үтеп бара, Туйбикә. Иртә дә син, кич тә син... Инде нәрсә диим?

Әйе, Нурулла тыштан шау тимер, ә күкрәгендә ялкын, өтә-көйдерә иде. Ниһаять, тышауларыңны чиш, ир-ат! Алдында хыялында кабат терелгән мәхәббәтең түгелмени!

— Каприз, дигән идең, Туйбикә. Ни-нәрсә ул? Аны балга манып ашыйлармы, суда жебетепме?

— Уенга борма, Азизов! — Хатын усалланды. Бер кавым туфли очы белән чирәмне изә-сыта җәфалангач:

— Өйлән, миңа, Азизов, минем капризым шул, — диде.

Алан бер кинәйде, бер тарайды. Агач-куаклар бер озынайды, бер кыскарды. Чәчәген койган төклетуралларны җил аска бөгеп каядыр очырта төсле иде.

Нурулла дәшмәде. Болыт әсәре түшәлмәгән чип-чиста күк йөзенең нәни генә уемы каралып яшь койды.

Бу — Туйбикә күзләре иде...

Моңарчы яшәлгән гомер корыган агач ботагы түгел, балта белән чабып ыргытып булмый. Шулай да яраткан кешеңне сагынып узган елларны да гамәлдән сызып булмый.

Булмый! Берни эшләп булмый!

...Туйбикә, машинасын кабызгач, күз яшьләре аша елмаеп:

— Хуш, — диде. — Үзеңне сакла, — диде. — Синдә чын ир солтанының йөрәге, Нурулла, — диде.

Әйтә алмады ир, син бу юлысы да йөрәгемне телем-телем кисеп китәсең, тик монысы авыррак, монысы хәтәррәк, дия алмады.

Машина җиленнән төклетуралар сынын турайтты...

...Тау сыртында ап-ак киемнән ике кеше чалгы белән печән чаба иде. Кем кушкан, йә? Көннәр көзгә авышкан, үләннәр, гәрчә яшел төсен җуймаса да, хәлсезләнеп, саргаерга маташа иде.

Нурулла әлеге аймакка беркайчан да тимер ургыч керттермәде. Бабайлар каны тамган уентыкны ул ел саен ике-өч карт белән чистартыр һәм азактан шәһитләр рухына дога кылдыртыр иде. Ә быел вакыт тимәде. Их!

Юк, кешеләр аның күзенә генә күренә иде. Китеп барышы, ахрысы... Теге чакта, йөрәк чыгымлаганда, ул бит кыр уртасындагы өстәл тирәсенә тезелешеп утырган аксакаллар белән очрашкан иде. Китеп барышы, әйе... Хәзер аяклары җирдән аерыла да... Ни үкенеч, фанилыкта күпме эшләре өелеп кала... Чү, икәүнең берсе Габбас бабасы түгелме соң? Ә аның кырыенда теге яшь хәзрәт! Тәгаен үзе!

Нурулла дык-дык җиргә басып карады. Хәтта үкчәсе чатнады. Шөкер, аяк асты каты иде...

*2013-2014 еллар.*



Таһир
Шәмсуаров

## ХАЛКЫМА БАГЫШЛАНА

### Бергә булыйк, бердәм булыйк

Тарихлардан килгән сабак,
Йөрәк тибә сулык-сулык.
Меңенче кат кабатлыймын:
Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Татар хакын барлыймын да
Күнел китә кайчак тулып...
Безнең язмыш бездән тора:
Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Бергә булыйк. Ник таркау без?!
Кайта-кайта моны уйлыйк.
Дәүләт тоткан кавемнән без,
Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Бергә булыйк, бердәмсезлек
Башка төшә гөрзи булып.
Акыл теше чыгар вакыт
Бергә булыйк, бердәм булыйк!

### Китеп кара

Туган җирнең матурлыгын
Тау башына менеп кара.
Аңлар өчен якынлыгын,
Ераккарак китеп кара.

Таһир ШӘМСУАРОВ (1954) — *шагыйрь; җирле нәшриятларда чыккан берничә китап авторы. Лениногорск районы Мөэмин-Каратай авылында яши. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

Яз кайтмаса, көз кайтыр дип,
Сабыр гына көтеп кара.
Яратасын яратмыйча,
Сөюләрдән китеп кара...

Сандугачлы авылыңны
Нәни илең итеп кара.
Кендек каны тамган җирне
Йөрәгеңнән китеп кара...

Җан тартмаса, кан тартмаса,
Беркем тотмый — китеп кара.
Минем чабу туган җирдә,
Йолкып алып китеп кара...

## Кырык берләр

Әтиләрен яшьли кырган үлем,
Бездән ерак диеп торганда,
Эзләп таба сезне палатада,
Якалардан ала урамда.

Балачагын сугыш йоткан буын
Кырыс язмыш сезне сөймәде,
Күпләрегез әтиләре биргән
Солдат пилоткасын киmәде...

Җиңү бәйрәмендә һәйкәлләргә
Кызыл кәнәферләр салалар,
Исән калганнардан сора менә —
Яртылашы ятим балалар!

Сезгә чират ерак иде бугай,
Бәсләр иртә сарган агайлар.
Әтиләрен эзләп китеп бара,
Җитмеш яше тулган малайлар...

## Илһамга

Син мине бәхетсез итмә,
Бер мизгел дә ташлама.
Минем бит һәр язган җырым
Халкыма багышлана.

Көтмәгәндә кил син миңа,
Биләп ал мине, яндыр.
Мин бит бары син барында
Яши алучы җандыр.

Син килсәң, кайчак елыйм да,
Кояштай балкып көләм.
Сине көтеп мин кесәмдә
Йөртәмен кәгазь, каләм.

«Шигырь ничек туа?» — дигән
Сорау килә күпләрдән.
Ә мин исә инә, димен,
Мәңгелектән — күкләрдән!

Әрсез диеп гаепләмә,
Сиңа гозерем бардыр.
Яшьлектән җибәрмә мине —
Сөю илендә калдыр.

Бәхет ачкычын алма син —
Бер мизгел дә ташлама.
Минем бит һәр язган җырым
Халкыма багышлана!

## Авылдашка

Күргәннәргә миннән сәлам диген,
Үзгәрмәгән диеп тамчы да.
Аның өчен җирдә ят юк диген,
Патша да иш аңа, ямчы да.

Шомырт чәче корым көнләшерлек,
Май күгедәй диген күзләре.

Әйткәннәре жанны сыйпап үтә,
Өтеп ала диген сүзләре.

Төп шөгыле шигырь язу диген,
Шулдыр диген сөйгән эше дә.
Ел әйләнә шигъри бакчасыннан
Гөлләр бүләк итә кешегә.

Сикәлтәле текә тормыш юлын
Авылдашлар горур үтсеннәр.
Картларга әйт: быел кайта диген,
Сабантуйга мине көтсеннәр.

Ул дөньяда ин бай кеше диген,
Патша да иш диген, ямчы да.
Күзләреннән яше тамар чагы,
Үзгәрмәгән диген тамчы да...

## Татар чәе

Нихәл, туган, ниләр майтарасың,
Ике куллап, әйдә, күрешик.
Ишек ачып кергән икән кунак —
Рәхәтләнеп бергә чәй эчик.

Маңгайлардан тирләр бәреп чыксын,
Пар бөркесен кабат самовар.
Татардагы ихлас кунакчыллык
Башка жирдә, әйтче, кайда бар?!

Тарих үзе шаһит минем сүзгә,
Без беркайчан чәйсез тормадык.
Хәмер түгел, татар чәе эчеп,
Сабан туйларында жырладык!

Тик ул гына баса сусауларны
Эссе көндә тамак кипкәндә.
Бисмиллалы чәйләр эчеп чыктык,
Бусагага дошман килгәндә.

Башка кавем «чәй безнеке» дию,
Алдакчыга гына баталыр.
Мәй хужасын күптән ачыкладык,
Чәй хужасы — бары татардыр!

Ишекләр дә, күнелләр дә ачык,
Ничек итеп түргә үтмисең?!
Уз син, әйдә, шундый йола бездә
Чәй эчмичә чыгып китмисең...

*Күптән түгел каләмдәшебез үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Аны әлеге бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рүзәл
Мөхәммәтшин

# АК БҮРЕ

ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНӘ
НИГЕЗЛӘНЕП ЯЗЫЛГАН ЛИБРЕТТО

**Катнашалар:**
**Ак Бүре**
**Хан**
**Ханбикә**
**Тәгин**
**Өлкән углан**
**Уртанчы углан**
**Юха**
**Өч башлы Дию** — Юханың агасы
**Хор** — Изге ияләр, Яман ияләр һ.б.

**Башлам**

*Дала. Кала чите. Дивар капкалары киерелеп ачылган. Арткы планда гаҗәеп матур шәһәр — Алтын Кала күренеше. Таң вакыты. Сәхнәнең нәкъ уртасында — кеше буе ак таш сын тора. Пәрдә ачылганда, Изге ияләр аның тирәли биеп йөриләр. Кинәт, көтмәгәндә, таш сын Ак Бүрегә әверелә. Борынгы көй агыла. Ак Бүре мәгърур төстә басып тора, бераз торганнан соң, сүз башлый.*

**Ак Бүре** *(салмак кына, залга мөрәҗәгать итеп).*
Сезне артык ялкытмыйча гына,
Арындырып ялгыш-ялганнан,
Мин сөйлисе хикәятнең очы
Бик еракка барып ялганган.

**Изге ияләр хоры.**
Дөнья — тоташ диңгез иде әле,
Һәм юк иде кояш югары.
Су төбеннән томшыгында үрдәк
Бер чеметем туфрак чыгарып
Төкерде дә кыйтга-кыйтга җирләр
Хасил булды, текә башларын

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1989) — *шагыйрь, прозаик, «Каралама» исемле китап авторы. Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Өскә суздыг...
Менәр елга житәр
Тарих әнә шулай башланды.

**Ак Бүре.**
Күк астында яна ыру тугач,
Тәнре үзе шулай хак күреп,
Тавыш бирде:
Саклаучысы бул, дип,
Яклаучысы бул, дип, Ак Бүре!

Күпме төнне көн алышты инде,
Күпме сулар акты, жил исте.
Күпме язга, көзгә, кышка кереп
Алыштырды төсен жир өсте.
Күпме гомер узды! Бурычымны
Үтим әмма һаман — качмадым:
Ыру — исән!
Менәр елга житәр
Үлемсезлек шулай башланды.

**Изге иятәр хоры** *(күтәренке).*
Ыру — исән!
Менәр елга житәр
Үлемсезлек шулай башланды.

**Ак Бүре** *(тынычланып, уйчанланып, исенә төшерергә теләгәндәй).*
Күптән булды бу хәл...

**Изге иятәр хоры** *(ерактагы кайтаваз сыман).*
Күптән булды...

**Ак Бүре.**
Күптән булды бу хәл:
Киң далада
Гомер сөргән шушы ыруның
Юлбашчысы — олуг хан бар иде...
Һәм бар иде аның өч улы...
Һәм бар иде аның ханбикәсе —
Тәнре, берүк, берүк күз тимәсен! —
Дөньяда бер чибәр иде ул...

*Ут сүнә.*

## БЕРЕНЧЕ АКТ

### Беренче күренеш

*Хан сарае. Уртада — тәхет, тәхеттә — Хан, аның янында Ханбикә. Ике углан ата-анасының янына баскан. Аяк очларында кечкенә Тәгин уйнап утыра.*

**Хан** *(масаймыйча, әмма горурланып, торып баса).*
Мин түгелме кояш чыгышыннан
Кояш батышына кадәрле
Кыргый ыруларны халкым иттем,
Халкым иттем кыргый адәмне?

**Ханбикә** *(аның янына килә).*
Син, олуг хан...

**Хан.**
Мин түгелме төннәр тарафыннан
Көннәр тарафына житәрлек
Япан далаларны илем иттем,
Илем иттем япан жирләрне?

**Ханбикә.**
Син, олуг хан...

**Сарай хадимнәре хоры.**
Кендек каны тамгач туган иман —
Һич таптыйсы түгел аны без:
Күктә Тәнре хаким булса,
Күктә Тәнре хаким булса,
Жирдә хаким безнен ханыбыз!

**Ханбикә** *(ханны коча).*
Илең — чәчәк тулы баг икән,
Син ил таянычы — хан икән,
Син ил даны, диләр — хак икән...

**Хан** *(кинәт йомшарып).*
Ә син — жаны аның, ханбикә...

*Ханбикә канәгать елмая. Аннары ханга башын ия дә чыгып китә. Аның артыннан кәнизәкләре ияра.*

**Хан** *(тагын рухланып).*
Мин түгелме дүрт кыйбланы бергә
Тоташтырган шәрә үзәнне
Пайтәхетем — Алтын Кала иттем?
Алтын Кала — дөнья үзәге!

**Өлкән углан.**
Тик варислар булса гына —
чын варислар!

**Уртанчы углан.**
Курку белмәс арысланнар,
юлбарыслар!

**Ике углан бергә.**
Илнең нигезе нык булыр,
тарих — дәлил!

**Хан** *(беренче улына килә).*
Өлкән улым...

*(икенче улына килә)*
Уртанчысы...

*(өченче улына килә, аны сөя)*
Улым Тәгин!..

*(барысына да ишарәләп)*
Сез булганда, безнең якка
төртмәс кылыч!
Сез булганда, мин борчусыз,
жаным тыныч.

Ташламасын Тәнре генә,
яхшы барсы,
Һәм Ак Бүре — ыру рухы —
ташламасын!

*(үз биләмәләрен колачлап күрсәткәндәй, кулларын җәя)*
Шушы кала, шушы жирләр һәм
күк бераз...

**Өлкән углан.**
Оланнардан — оланнарга...

**Уртанчы углан.**
Оланнардан — оланнарга...

**Ике углан бергә.**
Оланнардан оланнарга күчәр мирас!

**Хан** *(нәтиҗә ясаган сыманрак).*
Тормыш тукталмасын,
Ил-йорт таркалмасын!

**Икенче күренеш**

*Кинәт сәхнә карангылана. Аннары яшен яшьни, күк күкри. Шом. Еракта-еракта нindидер усал, ямьсез көлү ишетелә.*

**Дию** *(тавышы гына).*
А-һа-һа-һа!..

*Хан, угланнар куркуга кала. Кабат яшен яшьнәгәндә, арткы планда Диюнең шәүләсе чалына (аны сәхнәдәгеләрнең берсе дә күрми).*

А-һа-һа-һа!..

**Сарай хадимнәре хоры** *(куркып).*
Әйтерсең лә жир астыннан
Сихер калыкты.
Яшен генә кисеп үтә
Карангылыкны.

*Яшен яшьнәп алганда, яктылыкта, сәхнәнең эчкерәк ягында кабат Дию күренеп китә.*

**Дию.**
А-һа-һа-һа!..

*Сәхнәгә күзе-башы тонган, елап беткән кәнизәк кыз атылып чыга.*

**Кәнизәк.**
Дию-ү-ү!
*(елый)*

*Хан, угланнар аңа ташлана.*

**Угланнар** *(кабаланып).*
Ни, ни булды?

**Хан** *(шомлы, куркып).*
Ни булды?

**Кәнизәк** *(елый).*
Дию-ү!
Өч башлы Дию
Ханбикәне урлап алып китте!

**Хан.**
Аh!..

*Хан йөрәген тота. Анын янына хезмәтчеләр йөгереп килә. Гаскәриләр кереп житә. Тәшвиш. Ут сүнә.*

### Өченче күренеш

*Почмакка гына ут төшә. Кара-караңгы бүлмә. Бүлмә уртасында зур казан. Аның тирәсендә Кам ана йөренә. Ул әледән-әле казанга төрле-төрле үләннәр, яфраклар ыргыта, аннары таягы белән болгатып ала. Үзе сөйләнә.*

**Кам ана** *(таягын күтәреп).*
Күрәм, күрәм...
Караңгы зиндан күрәм...
Караңгы зинданда боек чәчкә
күрәм...
*(болгатып ала)*
Аh, гомернен йомры йомгак кебек
Тәгәрәвен, тәгәрәвен күрәм!
*(болгатып ала)*
Таш бәгырьләр күрәм...
Ул таш кинәт бәгырьләрдән ташып,
Гәүдәләре буйлап таралыр!
*(болгатып ала)*
Күрәм, күрәм... Ак рух күрәм...
Ак баһадир күрәм...

*Ут сүнә. Кам ана киләсе күренешләрдә дә шушы почмакта утырачак. Вакыт-вакыт анын турысында ут янып алачак.*

### Дүртенче күренеш

*Хан сарае янәшәсендәге мәйданчык. Тирә-юнь мохиттән сагыш, моңсулык аңкый. Тәгин пәйда була. Аны нидер борчый — хор жырлаганда, ул уйга батып сәхнә буйлап әрле-бирле йөренә.*

**Сарай хадимнәре хоры.**
Вакыт туктый белми ул,
Иркен мәйдан даулап,
Чалкан сала көнне һәм
Гомер артта кала.

Аннан гажәпләнәсен,
Кай арада икән:
Кечәге ир — бүген карт,
Сабый — үсеп житкән.

Вакыт туктый белми ул,
Иркен мәйдан даулап,
Чалкан сала көнне һәм
Гомер артта кала.

*Хан керә. Ул, чыннан да, карт инде.*

**Хан** *(керә-керешкә, Тәгингә).*
Нинди борчу басты сине, улым?

**Тәгин** *(Ханны күреп ала, янына йөгереп килә).*
Атам, син бит мине алдамассын?

*Хан, аптырап, кулын жәя, тораташ булып ката.*

**Тәгин.**
Әйтче, зинһар...

Иртән мин ук атып сынашканда,
Кам ана бик усал карады,
Янады да, күзен томан басты
Һәм сукранды: имеш...

**Кам ана** *(үз почмагында, кабатлаган кебек, Тәгинне дәвам итә).*
...күр аны,
Туганнары белән ханбикәне —
Үз анасын эзләр урында
Ул жил куып йөри!..

**Тәгин** *(өзелгән урыннан дәвам итеп).*
Әйт, олуг хан,
Сөйлә миңа шулар турында:
Бу ни хикмәт?
Бу ни хәлләр, атам?

**Хан** *(бер мәлгә өнсез кала, аннары мөмкин кадәр битараф күренергә тырыша, сүз һич мөһим булмаган нәрсә турында барганлыгын күрсәтергә теләп).*
Сиңа аны белү кирәк түгел...

**Тәгин** *(сүзеннән чигенми).*
Минем туганнарым да бармыни?

**Хан** *(тагын тынып кала, каушый башлый, аннары, басым ясап).*
Сиңа аны белү мөһим түгел!..

**Тәгин** *(чигенми).*
Бармыни?..

**Хан** *(ниһаять, күнә, көрсенеп).*
Бар шул, улым...

**Кам ана** *(кабатлаган кебек).*
Бар, бар!..

**Тәгин.**
Мин анамны хәтерләмим...
Булдымы ул?

**Хан.**
Булды, булды...

**Кам ана** *(кабатлаган кебек).*
Булды!..

**Тәгин.**
Кайда алар, атам?

**Хан** *(тыныч кына).*
Их...
*(бераз пауза)*
Анагызны Дию алды,
— Табабыз, — дип, көзен
Ике агаң чыгып китте,
Һәм югалды эзе...

Сиңа белгертмәдек — саклап
Зилзиләдән, жилдән...
Илем сулса, каным калсын,
Калсын, дидем жирдә!

**Тәгин** *(гажәпләнә, аннан, анык фикергә килеп).*
И мескен карт! Чәченә чал кунар
Вакытларда терәк тиешле
Улың булалмадым...
Итәгенә
Яшерену миңа килешми!..

**Хан** *(куркып).*
Исәбең ни синең, күз алмам?

**Тәгин.**
Мин хәзер үк юлга кузгалам!..

**Хан** *(куркып кала, карышырга тели).*
Юк! Юк!

**Тәгин** *(атасын кочып ала).*
Фатихаң бир, атам...

**Хан.**
Юк! Юк!

**Тәгин.**
Фатихаң бир...

**Хан** *(чын баһадир үстергәненә инанып, горурланып, сүзсез генә улына карап тора, аның битен-маңгаен сыйпый).*
Тәңре юлдаш булсын!
Фатиха!

**Сарай хадимнәре хоры** *(күтәренке).*
Өмет туды!..
Имин сәфәр, Тәгин!
Күнлең тагын бер кат төшенер:
Тәңре ташламый ул үз Тәңресен
Күңелендә йөрткән кешене.

*Тәгин чыгып китә. Хан идәнгә утырып, йөзен каплый. Ут сүнә.*

## ИКЕНЧЕ АКТ

### Беренче күренеш

*Гаҗәп гүзәл урман эчендәге аланлык. Тирә-юнь ямь-яшел. Агачлар, куаклар. Ара-тирә эре-эре ташлар сибелгән. Шуларның берсенә утырган килеш Ак Бүре үз биләмәләре белән хозурлана.*

**Ак Бүре** *(залга).*
Урманга изге сүз әйтми кермә,
Күнелен саф икән — ач аны,
Күнелен таш икән — әфсенләрмен,
Бар гәүдән таш белән капланыр!
Урманга изге сүз әйтми кермә,
Ямьсезләнмә,
Урман ул — тылсым...
Кем дә кем ак җанлы, кунагым бул,
Бу моннар синарга сый булсын!

*Табигатькә дәшкәндәй ишарә ясый. Шуны гына көткәндәй, урман җанланыбрак китә гүя — кошлар сайрый башлый, күбәләкләр оча, талгын җилдә чәчәкләр бии.*

**Изге иялар хоры.**
Юкә чәчәк ата анкып,
шаулап кына,
Кошлар сайрый, күбәләкләр
килеп куна...

Яран канәферләр белән бии җилдә,
Өстә — кояш, тирә-юньгә
нурын сибә.

Аяк асты — яшел келәм —
зөбәрҗәттән,
Үләндәге чыкка кадәр энҗе хәтта.

Яшел сихер! Ямьле сихер —
урман, урман!..
Тәнре күзен алмый күктән
багып тора...

### Икенче күренеш

*Кинәт ачы сызгырып очкан бер ук агачка килеп кадала. Күбәләкләр, кошлар куркып очып китә, чәчәкләр каплана. Тәгин пәйда була.*

**Тәгин** *(чыгышлый, үртәлеп).*
Их, т-тимәде...

*Бераздан үзе күренә.*

**Ак Бүре** *(сикереп тора, ачулы).*
Кем син?
Кем рөхсәте белән
Тынычлыкны боздың,
Минем киекләрне аулыйсың?

**Тәгин** *(җәясен төшерә, аны таный).*
И Ак Бүре, ыруыбыз рухы!
Исән-саумы син?
*(баш иеп исәнләшә)*

Кичер, зинһар, рөхсәт сорамыйча
Кизәнгәнем өчен кошына.
Арыдым бик. Тамагым да ачты.
Тик: «Кит!» — дисәң, китәм —
Куш кына!

**Ак Бүре** *(дикъкать белән Тәгинне карап чыга, күзенә карап тора).*
Кем син?

*Кошлар тагын сайрап ала. Чәчәкләр башын күтәрә. Бер-ике күбәләк очып килә. Алар да игътибар белән Тәгинне күзәтә.*

**Тәгин** *(сөйләгән вакытында чәчәкләрне сөеп ала, күбәләкләрне сыйпый).*
Мин — бер тәгин.
Бик күп еллар элек
Дию урлап киткән анамны,
Ике туганымны эзләп чыктым.

Тәңре ярдәм бирсә —
Табармын!

**Ак Бүре** *(сынап).*
Туганнарың һаман исән диеп
Уйлыйсыңдыр, бәлки?..

**Тәгин.**
Һичшиксез!

**Ак Бүре** *(бераз тын тора, аннары кискен итеп ташларга төртеп күрсәтә).*
Менә алар!
Бусы — уртанчысы,
*(бер ташка күрсәтә)*

Бусы — өлкән агаң!
*(икенче ташка күрсәтә)*

**Тәгин** *(башы иелә, тәне йомшара).*
Син алдыйсың!..

**Ак Бүре.**
Алар үзен артык әрсез тотты —
Өсләренә төште шуна каһәр уты.

Кисәткәчтен, гафу үтенделәр
Диеп уйлыйсыңмы? —
Ялгышма!

*Ак Бүре кулын җәя, урман тынып кала, ерактан, сәхнә артыннан, теге чордан кайтаваз сыман, Өлкән углан белән Уртанчы углан, аларның гаскәриләренең мыскыллы тавышлары ишетелә.*

**Беренче тавыш** *(элгәре вакытта угланнар әйткәннең кайтавазы кебек).*
Эт өстерик!

**Икенче тавыш.**
Атыйк!

**Өченче тавыш.**
Аучы-бүре...

**Дүртенче тавыш** *(җөмләне әйтеп бетерә).*
Әверелде киек-табышка!

**Барысы да** *(усал итеп көләләр).*
А-һа-һа-һа!

**Өлкән углан** *(ташлардан салкын, тонык тавышы — үкенеч авазы чыга).*
Шундый идек ник кенә без?..

**Уртанчы углан** *(ташлардан салкын, тонык тавышы чыга).*
Үкенәбез!

**Икесе бергә.**
Үкенәбез!

**Тәгин** *(ташларга кагыла, сыйпый, аннары Ак Бүрегә тезләнеп ялвара).*
Ыруыбыз рухы! Күрәсең ич:
Саташканнар алар —
Кичер! Кичер!

**Изге иәләр хоры.**
Кичер һәм терелт!

**Ак Бүре** *(уйга кала).*
Йөзең нурлы, карашыңда —
сафлык кына,
Күңелеңдә — аклык кына,
Йөрәгең нык!
Йөрәгеңдә — хаклык кына...

Син дигәнчә булсын, ярар,
Гозереңне үтим...

*Сихри-дәртле музыка. Ак Бүре учына әфсен укый.*

Әфсен-төфсен, ташка җан инсен!

*Ак Бүре учын ачып җибәрә, әфсенне ташка таба «өреп очыра» — беренче таш Өлкән угланга әверелә. Тагын укый.*

Әфсен-төфсен, ташка җан инсен!

*Ак Бүре учын ачып җибәрә, әфсенне ташка таба «өреп очыра» — бу таш Уртанчы угланга әверелә.*

Яшәгез!

**Угланнар** *(терелә).*
Без янадан тере!
*(шатланалар)*

Ак Бүре!
*(рәхмәт йөзеннән, Ак Бүрегә баш иятәр)*

Тәгин!
*(әниләренә баш иятәр, кочаклап алалар)*

*Күрешү мизгеле. Күбәләкләр янә бии башлый, чәчәкләр дә куана, кошлар да сайрый!*

**Тәгин** *(агаларына).*
Анда әткәй сагнып көтә сезне,
Өзгәләнә җаны.
Сез кайтыгыз инде, кочып алып
Юатыгыз аны.

**Угланнар** *(саубуллаша).*
Хушыгыз!

*Угланнар чыгып китә.*

**Ак Бүре** *(ария).*
Ыру, юкка табынмагансыңдыр,
Нәсел башы диеп, Бүрегә:
Аның күзенә ак — тик ак булып,
Кара — кара булып күренә.
Аяз күк астында яткан киңлек —
Газиз җире, җыры тумыштан.
Шуны яклап ул җиңүгә кадәр
Йә үлемгә кадәр сугыша.

Артык катгый әйтәм икән әгәр,
Гаеп итмә, Тәңре, ярлыка! —
Курку да юк һәм җиңелү дә юк
Бүрткән тамырларда шыгрым тулы
Бүре каны аккан халыкка!

Бүре — горур, шакалларга җыен
Үрнәк булыр сыйфат аңа хас:
Көчлерәккә ташланырга мөмкин,
Үләксәгә борылып карамас.
Аның рухы корыч, иманы нык,
Иманы бер аның: «Хөр яшә!»
Шуны даулап ул җиңүгә кадәр,
Йә үлемгә кадәр көрәшә.

Артык катгый әйтәм икән әгәр,
Гаеп итмә, Тәңре, ярлыка! —
Курку да юк һәм җиңелү дә юк
Бүрткән тамырларда шыгрым тулы
Бүре каны аккан халыкка!

**Тәгин** *(Ак Бүрегә).*
И Ак Бүре, рәхмәт, әнкәемне
Ничек табыйм?
Белсәң, әйт иден...

**Ак Бүре** *(пауза).*
Беләм...
*(пауза)*

Әмма үтәр юлың — һай авыр...
Син әзерме моңа?

**Тәгин** *(кискен).*
Әзер!

**Ак Бүре.**
Уяу бул, егетем!..
Тәкъдиреңдә —
Гади дә, куркыныч та барсы...

**Изге иятәр хоры.**
Уяу булсаң — табарсың анаңны,
Ә юк икән — үлем табарсың!

**Тәгин.**
Мин моңа да әзер!

**Ак Бүре.**
Йом күзеңне!

*Тәгин күзен йома да басып тора.*

Әфсен-төфсен, әфсен-төфсен!..

*Сәхнәдә тәшвиш башлана, Яман иятәр, Изге иятәр куыша-узышырга керешә, сәхнәнең бер ягыннан икенчесенә Хан, Өлкән углан, Уртанчы углан, Ханбикә — кыскасы, барлык катнашучылар йөгереп узып китә. Ак Бүре югала. Тиз-тиз генә декорацияләр алышына. Бу вакытта сәхнә уртасында Тәгин күзен йомып тора бирә. Хор Ак Бүренең әфсенен кабатлый. Кам ана, үз почмагында, әфсенне куәтләргә теләп, дөңгер кага.*

**Изге иләр хоры.**
Әфсен-төфсен, әфсен-төфсен!..
Әфсен-төфсен, әфсен-төфсен!..

**Ак Бүре.** *(тәшвиш арасыннан аермачык булып тавышы гына ишетелә).*
Ач күзеңне!

*Бөтен дөнья тына. Сәхнәдә Тәгин берүзе. Күзен ачып җибәрсә ул Дию патшалыгына килеп эләккән.*

## ӨЧЕНЧЕ АКТ

### Беренче күренеш

*Дию патшалыгы. Караңгылык. Бөтен җирдә баш сөякләре аунап ята. Бернинди тереклекнең әсәре дә юк. Хәвефле, шикле музыка.*

**Тәгин.**
Нинди шомлы урын...

*Тәгинне Елан-кызлар уратып ала. Биеләр.*

**Елан-кызлар хоры** *(Тәгиннең аңын томаларга тырышалар).*
Ерактан килдеңме, арыдыңмы?
Ятып ял ит бераз...

*(сихерләргә, йоклатырга тырышалар, ысылдап)*

Кара җир — түшәгең ул,
Сөякләр — ястыгың.
Ятып ял ит бераз,
Куйныбыз — наз тулы.
Ятып ял ит бераз,
Куйныбыз — наз тулы.

**Тәгин** *(авызын ача — сихерләнә башлаган).*
Хак әйтәсез: ташлап бар борчуны,
Черем итү комачауламас...

*Кам ана үз почмагында дөңгер кага.*

**Кам ана.**
Юк, ярамый, йомсаң күзләреңне,
Мәңгелеккә, Тәгин, йомарсың!..

**Елан-кызлар хоры** *(сихерлиләр).*
Йокыга тал, егет, хәлеңне җый,
Көчең җитмәс юкса Диюгә!

*Вальс. Оркестр. Тәгин авызын ача, киерелә.*

**Кам ана.**
Юк, ярамый, йомсаң күзләреңне,
Мәңгелеккә, Тәгин, йомарсың!..

**Тәгин** *(үзен кулга ала, катгыян).*
Изрәп торыр чак түгел!
*(катгыян)*

Юк әле!
Алдымда —
Бик озак юл әле...

### Икенче күренеш

*Тәгин тагын кузгалам гына дигәндә, кинәт манма яшькә чыланып, әллә кайдан бер гүзәлләрнең-гүзәле, күз явын алырлык кыз бала атылып чыга. Бу — Юха елан. Тәгин аны юатырга ашыга. Елан-кызлар кереп китә.*

**Тәгин.**
Нәрсә булды сиңа, таң йолдызы?
Ник елыйсың?

**Юха.**
Сиңамы соң минем хәлгә
керү...

**Тәгин.**
Нәрсә булды?
Сөйлә хәсрәтеңне...

**Юха** *(ариозо).*
Мин бер ханның төпчек кызы идем,
Һич кайгысыз үстем, житлектем.
Тик беркөнне — нәкъ төш
турысында! —
Әллә ничек... кинәт житте төн,
Күк каралды — дегет сеңгән сыман! —
Тирә-юньне хәвеф чорнады:
Илебезгә басып керде Дию,
Һәм ил белән матәм жырладык...

**Кам ана** *(уз почмагында дөнгер кага).*
Ышанма, ышанма, ышанма!

**Тәгин.**
Аh, никадәр таныш вакыйга бу!

**Юха.**
Кылыч аша үтте ир-атлар,
Хатыннарны колы итте Дию...
Һәм китерде монда —
Еракка...

**Кам ана.**
Ышанма, ышанма, ышанма!

**Тәгин.**
Әнкәем дә шунда иде мәллә?

**Юха.**
Шунда иде...
*(елый)*

Нык бул!
Килешмичә,
Сиңа һичбер нинди чара юк...
*(пауза)*

Сагынуны басалмады алар —
Һәм һәммәсе үлде саргаеп.

**Кам ана.**
Ышанма, ышанма, ышанма!

**Егет** *(Юханы биләгеннән тота).*
Мөмкин түгел!

**Юха** *(аннан ычкынып).*
Ә мин качтым — күзем күргән якка
Мен егылып чаптым, абынып!
Инде менә, сине таптым, егет,
Һәм жанымда... өмет кабынды...
Икәү бергә матур тормыш корыйк!
Яшик ләззәт кичеп, шатланып!
Булган — беткән, калсын!
Ханбикәсез —
Сүнгән учак синең ватаның...

**Кам ана.**
Ышанма, ышанма, ышанма!

*Юха яшьле күзен Тәгингә теки. Аларның карашы очраша. Егет «Аh!» дип тартылып куя — аның үзәгендә нидер өзелде гүя, шулай дигәндә, сәхнәдә ут уйнап ала — сихер галәмәте.*

**Тәгин.**
Аh!

**Юха** *(залга, аннары Тәгингә хәйләкәр-астыртын елмаю ташлый).*
Инде син дә мине ташлама!

*Тәгинне иненнән тота, аның куллары уз биленә куя. Бии-бии дуэт жырлыйлар.*

**Юха.**
Мең ялындым!
Бир яктылык, дидем!..
Күрәсең ки, күкләр ишетте...

*Тәгин ана кушыла.*

**Икесе бергә.**
Бәхетсезлек көрештерде безне,
Бәхетсезлек безне иш итте...

**Тәгин.**
Күпме юллар үттем синең өчен,
Узган көннәр — гомер тиңентен...

**Икесе бергә.**
Бәхетсезлек табыштырды безне,
Бәхетсезлек безне тиң итте...

**Юха.**
Мин бар идем синнән башка да бит,
Син дә миннән башка бар идең...

**Икесе бергә.**
Бәхетсезлек кавыштырды безне,
Бәхетсезлек безне пар итте...

*Биләр. Көй әувәл бик матур булып ишетелә, акрын-акрын гына аны катырак, көчлерәк, усалрак музыка алыштыра башлый. Биләр, биләр!.. Тәгиннең хәле начарая, ул ритмнан калыша башлый, тез буыннары йомшара, азактан, гомумән, сыгылып төшә. Юха үзе генә бии.*

**Юха** *(биеп туктагач, Тәгиннең гәүдәсенә аягын куеп, залга яный).*
Авызы — кан булыр, кара кан!
Яшь түгәр: «Яратам! Яратам!»
Таң атсын — шаккатып күрерсез!
Мин — Дию сеңлесе!
Һәм Тәгин миңгерәп уяныр:
Онытыр нәселен, иманын!
Онытыр нәселен, иманын!..

**Кам ана** *(куркып).*
Онытыр нәселен, иманын...

*Тәгин, хәрәкәт итә алмыйча, идәндә азаплана. Торырга, шуышырга тырыша — хәленнән килми. Юха аның тирәсендә бии. Усал көлә-көлә кереп китә. Тәгин шунда кала. Ут сүнә.*

**Өченче күренеш**

*Мәгарә. Юханың куышы. Караңгы. Сәхнәдә Тәгин аунап ята. Көч-хәл белән тора. Ул бөкрәйгән, кибешкән, тузган. Кырыйдан караганда, кимендә 50-60 яшьлек картны хәтерләтә. Сәхнәнең икенче ягында — Кам ана «почмагына» капма-каршы — Ак Бүре пәйда була.*

**Хор.**
Вакыт туктый белми ул,
Иркен мәйдан даулап,
Чалкан сала көнне һәм
Гомер артта кала.

Ни галәмәт булыр бу,
Әллә сихер микән?
Кичәге ир-егет тә
Тузган, кибеп беткән.

Вакыт туктый белми ул,
Иркен мәйдан даулап,
Чалкан сала көнне һәм
Гомер артта кала.

**Ак Бүре.**
Ни эшләткән сине Юха елан?
Корыткан ич, мескен егетем...

**Тәгин** *(көч-хәл генә).*
Мин бәхетле...

**Ак Бүре.**
Максатына ирештеңме?

**Тәгин.**
Мин бәхетле...

**Ак Бүре.**
Синең максат — әнкәеңне табып
Алып кайту түгел идеме?

**Тәгин.**
Мин бәхетле...

**Ак Бүре.**
Ай-һай хәлләр яман икән...

**Кам ана** *(үз почмагында дөңгер кага).*
Коткар, коткар аны, Ак Бүре!

**Тәгин** *(көч-хәл генә).*
Мин бәхетле...

**Ак Бүре.**
Йә, тырышып карыйк...
Әфсен-төфсен!

*Ак Бүре учына әфсен укып, сәхнә-*

*нен бер почмагына өрә. Шул төштә хатирә рәвешендә Тәгиннең ике агасы барлыкка килә.*

**Өлкән углан.**
Төпчегебез, күзеңне ач, уян!

**Уртанчы углан.**
Чык сихердән, кагын, җилпен дә бер!

**Икесе бергә.**
Туганнарың, агаларың ич без —
Исендәдер?

**Тәгин** *(бераз уйлангannan соң).*
Юк, исемдә түгел, хәтерләмим...

**Ак Бүре.**
Әфсен-төфсен,
Әфсен-төфсен!

*Ак Бүре учына әфсен укып, сәхнәнең икенче почмагына өрә. Шул төштә хатирә рәвешендә Тәгиннең әтисе — Хан барлыкка килә.*

**Хан.**
Уян, балам! Сихереңнең
Умырткасын сындыр!
Атаң ич мин, чал атаңны
Онытмагансыңдыр?

**Тәгин** *(уйланып алганнан соң).*
Кем син, картлач?
Тәүге кат күрүем...

**Ак Бүре.**
Һай бозымы көчле! Соңгы өмет —
Инде берүк шифасы тисен:
Әфсен-төфсен,
Әфсен-төфсен,
Әфсен-төфсен!

*Ак Бүре учына әфсен укып, сәхнәнең бер почмагына өрә. Шул төштә хатирә рәвешендә Тәгиннең әнисе — Ханбикә барлыкка килә. Ул яшь, чибәр. Кулына сабый бала тоткан. Аны тирбәтә. Тәгин аны күрми, ишетә генә.*

**Ханбикә** *(баласын йоклата).*
Әлли-бәлли ит, гөлем,
Пакь җаным, саф күңелем,
Алып батыр шикелле
Үс син данга күмелеп!

Йөзләрең нурлы булсын,
Сүзләрең туры булсын.
Тәңре биргән бәхетнең
Иң зуры, зурыдыр син...

Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү...

*Бишек җыры дәвам иткәндә, Тәгин тынгысызлана башлый — акрын гына битен, күкрәген капшый, аның аз-азлап хәтере ачыла бара. Җыр бетүгә, ул сихердән тәмам котылган була инде.*

**Тәгин.**
Хәтерлим... Хә-тер-лим...
Мин ич бу!
Әнкәй мина бишек җыры җырлый!..
Әнкә-әй!..
*(һушына килеп)*

Аһ, бу Юха, башны томалаган...

**Дүртенче күренеш**

*Сәхнәгә җинелчә сикергәләп Юха чыга.*

**Юха** *(керә-керешкә борын төбеннән көйли).*
Чибәрлек — куркыныч корал ул,
Һөҗүме зур аның һәр яклап:
Күңелне дә каплый,
Күзләрне дә каплый,
Иң юан беләкле батырны да ега
аяктан —
Һөҗүме зур аның һәр яклап!

*(Тәгинне күреп ала, кочакларга тели)*

Бер килешме хәлең, кадерлем?

**Тәгин.**
Гажәпләнерсеңме, кечкенә сер ачам:
Хәлем — яхшы...
*(кылычын чыгара, Юханың баш өстенә күтәрә, нәфрәт белән)*

Ә синеке — начар!
*(чабып үтерә, Юха елан ысылдап-ысылдап үлә)*

*Тәгиннең «күзе ачыла». Баксаң, тирә-юне — Дию патшалыгы, караңгылык икән ич! Бөтен жирдә баш сөякләре аунап ята.*

**Тәгин.**
Нинди шомлы урын...

*Хәвефле, шомлы музыка.*

Сиңа киләм, әнкәй!

*Чыгып китә.*

## ДҮРТЕНЧЕ АКТ

### Беренче күренеш

*Сәхнә кап-кара, караңгы төсләрдә бизәлгән. Дию сарае. Уртада — тәхет. Тәхет янында, идәндә, Ханбикә моңланып утыра. Аның янында берничә кәнизәк бар. Алар тирәли Яманияләр йомшак кына бии.*

**Ханбикә** *(сагышлы).*
Ятьмә төште ирегемә минем,
Кидерделәр богау кулыма.
Мин кайчандыр ил анасы идем,
Бүген — бер кәнизәк, кол гына...

Йортым — зиндан,
бу таш диварларны
Кем дә булса килеп ватармы?
Син кай чорда калдың, исәнме син,
Ни хәлләрең синең, газиз ватаным?

**Кәнизәкләр хоры.**
И ханбикәбез, чү! Елама бары —
Язмыш бәхетле, хөр чагын
кайтарыр!..

**Ханбикә.**
Син кай чорда калдың, исәнме син,
Ни хәлләрең синең, газиз ватаным?

**Кәнизәкләр хоры.**
И ханбикәбез, чү! Елама, зинһар,
Сөрт күз яшеңне син —
әле өмет бар...

**Ханбикә.**
Син кай чорда калдың, исәнме син,
Ни хәлләрең синең, газиз ватаным?

*Дию килеп керә. Ул өч башлы: Беренчесе — Усал баш, икенчесе, уртанчысы — Ахмак баш, өченчесе — Хәйләкәр баш.*

**Усал баш** *(Ханбикәгә кушылып китә, мыскыллырак).*
Син кай чорда калдың, исәнме син,
Ни хәлләрең синең, газиз ватаным?

*(усал көлә)*

А-һа-һа-һа!

**Хәйләкәр баш** *(Усал башка кушылып көлә).*
А-һа-һа-һа!

**Ахмак баш** *(ике башка кушыла).*
...Һи-һи-һи-һи!

*Тегеләре көлеп туктагач та Ахмак баш бераз көлеп тора әле. Ханбикә урыныннан күтәрелә, яшьле күзләрен Диюнең һәр башына төбәп тора да усал гына карап китә.*

**Усал баш** *(усал).*
Һаман шул жыр, туйдырды!..

**Ахмак баш** *(юаш кына).*
Тавышы моңлы да инде...

**Хәйләкәр баш** *(астыртын).*
Моңлы кеше бәхетсез була, диләр...

*Тагын өчесе бергә көлеп ала.*

**Өч баш бергә.**
А-һа-һа-һа! Һи-һи!

**Усал баш.**
Кемнәр килеп ватсын бу диварны...

**Хәйләкәр баш** *(Усал башка карап).*
Артык каза нигә ул ана?

**Усал баш.** *(Хәйләкәр башка карап).*
Монда килеп исән калырлык зат...

**Хәйләкәр баш.**
Жир йөзенә әле тумаган!..

**Ахмак баш.**
Тумаган!

*Өчесе бергә тагын бер кат көлеп ала.*

**Өч баш бергә.**
А-һа-һа-һа!

*(Залга мөрәҗәгать итә, терцет жырлый).*
Ялган кыйммәтләргә бер төрт кенә –
Нигезенә кадәр ишелә...
Ни ул намус... вөждан...
рәхим-шәфкать?.. –
Оныттыгыз! –
Рәхмәт, кешеләр!

Рәхмәт сезгә!
Мен-мен шөкер итәм!
Алдамыйм ич, хактин-хак ласа:
Өч башлысы нәрсә эшләр иде,
Сезнең йөрәкләрдә егермешәр
Башлы Дию яшәп ятмаса?

Рәхмәт сезгә!
Явызлыкка — ак юл!
Явызлыкка чикләр юк ана...
Мин бит сезнен ин-ин чуар, түбән
Хисләрегез белән тукланам!

Үтерегез,
Зина кылыгыз сез,
Урлашыгыз!
Сыкмый балавыз,
Бугазлагыз йомшак булганнарны,
Көчлеләрнең артын ялагыз!

Хур калмагыз ләкин!
Оят ич ул –
Чит берәүнең гомрен бизәшү...
Аһ, ни ләззәт — кеше хәсрәтләре,
Аһ, ни татлы тәгам — күз яше!

Рәхмәт сезгә!
Явызлыкка — ак юл!
Явызлыкка чикләр юк ана...
Мин бит сезнең ин-ин чуар, түбән
Хисләрегез белән тукланам!

*Яманияләр тантанасы. Кап-кара күләгәләр сәхнә буйлап котырынып йөри. Куркыныч, көчле музыка.*

**Яманияләр хоры.**
Күңелләргә кул суз — салкын өрә,
Йөрәкләргә кагыл — боз анда...
Имансызлык — фарыз, иманына
Дию оялаган заманда.

**Икенче күренеш**

*Тәгин пәйда була. Күләгәләр аны уратып, тирәли бии. Тәгин, як-ягына борыла-борыла, кылычы белән селтәнә. Кинәт усал музыка бетә, күләгәләр төрле якка таралыша. Урталда — Тәгин һәм терцеттан соң тәхетенә менеп утырган Дию генә кала.*

**Усал баш** *(Дию сикереп тора, гаҗәпләнеп, усал).*
Кем син? Ничек үттең монда?

**Хәйләкәр баш** *(хәйләләп).*
Кәнизәкләр!
Кайда ашлар, кайда чәегез?

**Ахмак баш** *(куана).*
Кунак килгән — табын җәегез!

**Тәгин.**
Юк, кирәкми! Каның белән,
Җаның белән авыз итәрмен!..

**Усал баш** *(гарьләнә).*
Кавырсының ныгымаган әле...

**Хәйләкәр баш.**
Гәүдәң үсеп, гаклың калышкан...

**Ахмак баш** *(куркыбрак).*
Алыштан, дисеңме?

**Тәгин** *(ачуын теш арасыннан гына сытып чыгара).*
Алыштан!

*Тәгин кылычын тотып ата. Алышырга тотыналар.*

**Яман иярләр хоры.**
Шулай алыша торгач,
Алыша торгач һаман,
Тигез җирләр — түмгәккә,
Түмгәк җир карашакка
Әверелде берзаман.

*Тагын алышалар.*

**Дию** *(Тәгингә суга).*
Бездә алай бәрмиләр,
Бездә болай бәрәләр!

**Тәгин** *(Диюгә суга).*
Бездә алай бәрмиләр,
Бездә болай бәрәләр!

**Яман иярләр хоры.**
Шулай алыша торгач,
Алыша торгач һаман,
Карашак җир — түмгәккә,
Түмгәк җир тигез җиргә
Әверелде берзаман.

*Бераздан Тәгин дә, Дию дә хәлдән таеп егыла.*

**Хәйләкәр баш** *(көчкә сулыш ала).*
Тукта! Ял итик әле...

**Усал баш.**
Һич егәрем калмады...
*(бер-ике тирән сулаганнан соң, Дию торып баса)*

**Ахмак баш** *(китмәкче була).*
Киттек куәт тупларга!
*(әмма калган ике башка бәйле буларак, урыныннан кузгала алмый)*

**Усал баш белән Хәйләкәр баш бергә** *(Тәгингә).*
Аннан булыр дәвамы...

*Дию китә башлый.*

**Тәгин.**
Кара әле — бу башның
Юньсез берсеннән-берсе,
Мин дә ардым, югыйсә,
Мине дә алып кер син!

**Хәйләкәр баш** *(калган ике башка карап күз кыса, аннан, Тәгинне алдан уздырырга ниятләп).*
Рәхим ит...

*Тәгин берни абайламый сәхнә эченә таба барганда, Дию ул ыргыткан кылычка үрелә, аны кулына ала. Тәгиннең баш турысына күтәрә. Бәрдем дигәндә генә Тәгин борылып калырга өлгерә, шул уңайга Диюнең яңагына берне кундыра. Дию сәхнә буйлап тәгәри. Кылычы төшеп китә.*

**Тәгин** *(ачуы чыга, акрын гына кылычны ала).*
Аһ, әле син шулаймы?!
*(Диюнең Усал башын өзә)*

**Ахмак баш** *(ялвара, китмәкче була, әмма китә алмый).*
Харап итмә, харап итмә, егет!

*Ахмак баш кылычтан капланырга, качарга тырыша, әмма Тәгин аны барыбер чабып төшерә.*

**Хәйләкәр баш** *(тыныч).*
Шулай жинел жиндем дисен әллә,
Кеше-туганым?
Явызлыкның башлангычы бар да,
Азагы юк аның!..

А-ha-ha-ha!..

*Тәгин бу башны да өзеп төшергәч кенә көлү туктала.*

**Тәгин.**
Көлүе дә көлү төсле түгел...

*Шул арада сәхнә яктыра башлый. Бераздан Яман иярләр үзләре белән ияртеп Ханбикәне алып чыга. Сәхнә уртасына — Тәгин янына кадәр озаталар да юк булалар.*

**Тәгин** *(әнисе янына йөгереп килә, тезләнеп кочаклый).*
Әнкәй!

**Ханбикә** *(кочаклаган килеш Тәгиннен башын сыйпый).*
Улым минем...

*Очрашу-куаныч-шатлык — музыка! Ут сүнә.*

**Бетем**

*Башламдагы кебек, кала чите. Дивар капкалары ачык. Пәрдә ачылганда, акрын гына, кып-кызыл кояш күтәрелә. Сәхнәдә — Ак Бүре, төп каһарманнар, Алтын Кала халкы. Борынгы көй агыла.*

**Ак Бүре** *(залга).*
Теш-тырнагы белән ябышса да,
Кара ният чынга ашмады:
Ыру — исән!
Меңәр елга житәр
Тарих әнә шулай башланды.

Үткән — беткән диеп тынычланма,
Дию, димә, жанны саумый — соң:
Ыру исән!
Йөрәгендә әмма,
Ыру рухы һаман саумы соң?

Кем син? Кайдан?
Кай тарафка барыш?
Уйлап кара — нигә тугансың?
Кыйссалардан үткәннәрен чыгып
Якаларлык кына булмасын!

Бабаларың синнән жавап көтә:
Саумы, дәвам?
Кычкыр: үлмәдем!..
Һәм хикәят бетмәс бу урында,
Юк, хикәят бетми шул әле...

**Кам ана** *(кояштан хозурланып).*
Яңа сабый сыман таң туа...
*(пауза, кояшка карап тора, аннары — акрын гына, үзалдына)*
И Тәнре!
Якты көн, жылы кояш бир!
Дөньялар тыныч, имин булсын!

**Хан** *(ана кушыла).*
И Тәнре!
Ач итмә, ялангач итмә, мохтаж итмә!
Хөр яшәргә боер!

**Ханбикә.**
И Тәнре!
Мал-туарлар, иген-тарылар
Күп булсын, уң булсын,
И Тәнре!

**Өлкән углан.**
И Тәнре!
Ыру-халыкның йорт-жире өчен!

**Уртанчы углан.**
И Тәнре!
Бала-каза килмәсен өчен!

**Тәгин.**
И Тәнре!
Тулылык түгелмәсен өчен!

**Төп каһарманнар бергә.**
И Тәнре!

Тулылык түгелмәсен өчен!

**Алтын Кала халкы хоры.**
Сүзләребез ишетелсен җиде күктә –
Ялварабыз!
Ялварабыз!
Ялварабыз!

**Төп каһарманнар.**
Куркуга салган иде,
Өметләр янган иде...
Килде төн, көнне этеп –
Хәерле белән үтте!

**Алтын Кала халкы хоры** *(төп каһарманнарга кушыла).*
Ватан исән! Ватан тере!
Сәлам шатлык юраучыга –
Күзне рәхәт яшьләндереп,
Кояш чыга! Кояш чыга!

**Бергә.**
Сәлам, кояш!
Тигез карап,
Нурларыңны
Тарат, тарат!

Сәлам, кояш!
Бәйрәм бүген!
Куанычтан
Җырлый күңел!

Сәлам, кояш!


**Кам ана** *(тантаналы).*
Ырудашлар!
Көн туды!
Яңа көн туды!

*Барысы да куана, яңа туган көнгә, кояшка сәлам бирә. Пәрдә.*

*Казан, 2012 елның октябре – 2013 елның апреле*

**Он-лайн язылу: тиз, уңайлы, һәрчак кул астыңда!**

1. Зайдите на сайт tatmedia.ru.
2. Кликните раздел "Подписка".
3. Пройдите несложную регистрацию.
4. Выберите районные, городские или республиканские газеты и журналы.
5. Оформите подписку.
6. Оплатите квитанцию через интернет или вызовите почтальона на дом, в удобное для вас время.




16+

татмедиа

tatmedia.ru

Реклама

# ТУРЫ ТУЛПАР КАЯ ЧАБА?

## I

КамАЗ автомобиленең келәймәсе, ягъни бүгенге тел белән әйткәндә, «бренды» (күркәм сүз булмаса да, кулланырга мәҗбүрмен!), тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, символы — ат. Акбүзат. Кашка Туры тулпар. Өркетелеп, акылыннан шашып чапкан ат. Әйе, символ, йөрәкләргә төшеп ярсыткан символ бу. Менә утыз биш елдан артык Җир шарының тигез һәм сикәлтәле юллары, хәтта Африка саванналары һәм Көньяк Америка (шарты килсен дип әйтсәк) прерияләре, бөтенләй дә юлсыз комлыклары буйлап шулай акылдан язган халәттә чаба ул. Чын атмы ул, әллә «аттан калган хат» кына — шәүләме? Аны кем, нигә өркеткән? Ни сәбәпле болай шашкан? Саф су урынына бензин эчеп тилермәгәнме? Нигә шулай күзләрен алартып, алдын-артын күрмичә, кайларга таба чаба бу җан-символ? Татар җирендә туган, татар һавасын сулаган, икмәген ашаган, татар суын эчкән, шактый күләмдә татар тырышлыгы, татар кулы белән җыелган заман «дженерал моторс»ы куйган бу сорауларга татар әдәбияты, анығрак әйткәндә, аның әдипләре инде әллә кайчан җавап бирергә тиешләр иде.

Бирә алдыкмы соң сорауларга җавапларны? Бу мәкаләдә сүз шул турыда барачак. Ул сүз әллә кайчан кузгатылырга, уртага салып иләнергә-сөйләнергә, бер фикергә киленергә һәм тиешле нәтиҗә ясалып яши башланырга тиеш иде. Быел Ат турында сүз кузгату — савап. Аллаһның үзеннән төшкән һиммәт. Быел, халыкара җанварлар календаре буенча, Ат Елы.

Ат! Нинди сөйкемле, акыллы, ышанычлы, көчле, планетар энергияле җан иясе ул ат! Аның азиатча матур кылый күзләрендә ике җир шары бер юлы чагыла бит!.. Кешелек тарихы — ат тоягы белән язылган, әмма еш кына атның ролен читтә калдырып язылган тарих ул. Бу күзлектән караганда, атка караш икегә аерыла: бары тик үзе турында гына уйлаган адәм ат ярдәмендә теләгәненә ирешкәч, атны оныта. Барысын хәтеренә бикли, әмма атны гына «исеннән чыгара». Аттан төшкәч, аның авызлыгын салдырып, үләнгә җибәрергә дә онытып, үзенә һәйкәл куя, әмма атны хәтереннән җуя. Милләт, халык, дәүләт турында уйлап җан аткан шәхес атны беркайчан да онытмый. Борынгы җырларыбызның берсендә «Кайда гыналай барма, дус-иш кирәк йөгереп чыгып атлар бәйләргә» дип җырлана. Борынгы заманда һәр йорт каршында ат бәйли торган багана булган. Ат баганасы — татарның иминлек символы. Зыялы шәхес, зыялы милләтләр атны алга чыгарган. Шуңа да милли мөстәкыйльлек тойгысы нык тамырланган илләрдә атка һәйкәлләр күп. Мәсәлән, Америкада. Минем шундый сыгымта да ясаганым бар: ил үзаллы фикергә никадәр ия булган саен, анда атка куелган һәйкәлләр шулкадәр күп булучан. Татарстанда, мәсәлән, бер генә дә атлы һәйкәл юк. Чөнки дәүләтчелек тойгысы юк дәрәҗәдә зәгыйфь. Хәтта цивилизация — китап тарихы да ат көче нәтиҗәсендә бар ителгән могҗиза бит. Дөнья тарихында урын алган дәүләтләр — ат күзенең алмасыннан өзелеп төшкән ялкын ул. Әдәбият тарихында сурәтләнгән мәхәббәт — ияр өстендә язылган дастаннар бит. Ат булмаса, бөек җиңү-җиңелүләр, яулап алулар нәтиҗәсендәге социаль тетрәнүләр, дәүләти оешу-таркалулар булмаган; төркиләр халыкларның бөек көченешләрен җитәкли алмаган, Бөек Кытай стенасы төзелмәгән, «Илиада», «Котадгу белек»ләр, «Диване лөгатет-төрк» язылмаган, Бастилияләр җимерелмәгән, Берлин алынмаган, кешелек Айга күтәрелмәгән, колхозлар түгел, КамАЗлар да төзелә алмаган булыр иде. Әле моннан утыз ел элек «Атка мактау» дигән шигыремдә, бу хакта уйланып, болай язганмын: *Бу елларда — ирек кошы каны. / Тарих үре — тояк эзләре. / Ат кешнәтеп, таңга бәреп кергән / Тәрәккыят Робеспьерлары... / Бу елларны космик җил көйдергән. / Ат бит безне Айга күтәрде. / Аттан канат алган ракетада / Без галәмгә чөйдек күпләрне.*

Олы юлларның утыз еллык тузаннары аша бу фикергә кире әйләнеп кайтырмын дип кем уйлаган?!.

Җир йөзендә төп образы-символы ат булган гомерлек әдәбиятлар бар. Мәсәлән, Төньяк һәм Латин Америкасы әдәбиятлары. Саванна һәм прерияләр безнең төрки телебездә һәм әдәбиятыбызда табигый рәвештә тугай-сахралар булып сурәтләнсә дә, атның образ буларак сурәтләнеше бу ике әдәбиятта битабигый рәвештә тигез түгел: атта-арбада дөньяны яулап алган, Европага ат белән арбаны (ябык кибет-кибитка) күрсәткән, ир белән ат (ир-ат) бер булып берекккән төркиләрнең әдәбиятларында ат образы, минем карашка, Американың борынгы һинди кабиләләре һәм аларны аяусыз яулап алган ак тәнлеләр әдәбиятлары белән чагыштырганда азрак, күпкә нәкысрак, саранрак сурәтләнеш тапкан. Бер караганда, татар әдәбияты, авыл әдәбияты буларак, дөньяда иң «атлы» әдәбият булырга тиеш иде кебек: анда «формаль» булса да авыл капкасы һәм ат телгә алынмаган әсәр дә табуы кыен кебек.

Безнең татар көнкүрешендә Ат зур хәреф белән язылырга хаклы. Татар Атының тарихи язмышы, минем карашка, өч тарихи чордан тора: «иркен болын-колхозга кадәр» һәм «колхоздан соң»; ирекле тормыш — өтөрмә — өтермәдән соң; яшәү — үлем — үлемнән соң. Боларның һәркайсына аңлатма бирер китәргә кирәк. Без, гадәттә, татарның акыл һәм хиссияти өскорма — цивилизациясен мең ел белән чикләргә өйрәнгәнбез. Әйдә, бу юлы да шулай калсын. Башыбыз үзебез белән булса, безгә мең ел да житеп тора. Әйе, татар цивилизациясе башыннан 1917 елга, дөресрәге, оешуы утызынчы еллар башына тәмамланган колхоз чорына кадәр чор татар атының болын чоры, яшел печән, ак солы чоры дип аталырга хаклы. Әгәр шулай билгеләргә яраса, атның бәйге-сабантуйлар, хезмәттә төп тартучы көч — генератор булу чоры. Татар атының романтизм чоры. 1930 елдан СССР таркалган, колхозлар таралганчы, ягъни 1991 елга кадәр алтмыш ел гомер татар атының иркен-ирекләп колхозларның ирексез ат двоты-өтөрмәсенә куып кертелү, саламга һәм кара солы-әвчүккә утыртылу, трактор типкенендә атсыз калу — татар атының тере жан иясе буларак хуҗасын ташлап китү чоры. Атның «убшый ат дворында» — иҗтимагый «өтөрмәдә», авыр хезмәттән коры саламда колын салу, үлеме чоры. Хәзер исә өченче чорда без үзебез, аттан башка гына, жан тәслим кылып ятабыз. Ягъни без, татар гавамы, атыбыз үлгәннән соң, коллык «убшижитие»ләрендә атсыз, исемсез, жисемсез гомер кичерәбез. Йә, җәмәгать, ничегрәк? Әгәр моннан алдагы мең елда төрки кабилә «татар» аталып, аннан сталинизм тарафыннан дисталәгән «үзбәк, казакъ, төрекмән, каракалпак, башкорт һ.б.» аерылып чыгарылып, үзебезнең кемнәрдән кемгә калганлыгыбызны аешмас дәрәҗәдә ушсызлансак, катып калсак һәм чит кавемнәр язып биргән жидешәр томлык тарих китапларыбызда үзебезне нинидер «кытай-манчжур татарлары» итеп сурәтләп, чынлап та исемсез — милли ансыз калсак, бүгенге чорыбызда без инде атсыз да, жисемсез дә калдык. Кайчандыр «татар аты» дип кенә аталган атыбыздан шул ук «үзбәк, казакъ, төрекмән, каракалпак, башкорт атлары» аерылып чыгып, без «татар аты» дигән атыбыздан баш кактык. Халыкта — атыбыз, йөрәктә — дәртебез, музейларыбызда йөгәнебез дә калмады түгелме? Аннан татар «татар балы» дигән балсыз, «татар кымызы» дигән кымызсыз, хәтта «татар катыгы» дигән милли катыксыз да калмадымы? Мин бу фикерләрне курка-курка, тыела-тыела гына әйтәм, чөнки кайбер килде-китте тәнкыйтьчеләребез минем кебек дөреслекне ярып, гарьләндерергә теләүне «зарлану, мескенләнү» дип бәяли. Әйткәнең гаделгә тартсын: миңа калса, татарның бүген күргән-кичергән барлык җәфа-газаплары менә шушы исемсез-жисемсез, ирнең — атсыз, атның — ирсез, татарның ир-атсыз калу, ягъни хәләлне — хәрәм, хәрәмны хәләл итү гөнаһларыннан киләдер.

Әйе, ничек кенә булмасын, татар ире белән татар аты (ир-аты) нинди генә чорлар кичермәсен, әдәбиятыбызда күпмедер дәрәҗәдә урын алган. Күпмедер дәрәҗәдә генә шул. Тиешле, житәрлек дәрәҗәдә, татарның затын һәм атын сакларлык күләмдә түгел. Евразия халыкларынын милли дастаннарында ат үзәк образ булып тора. Шушы Евразиянең Азиясен Европа белән бәйләп торган, ихластан да дисталәгән империяләр, каганатлар, дәүләтләр төзегән татар халкының бөек дастаны «Идегәй»дә шулай: ат — татар дәүләтчелегенең чуклы әләме, татар цивилизациясен, татар әхлагын-канунын тудыручы жан иясе. Татар атсыз яши алмаган, атлы булу аны бөек империяләрне киләчәккә «үтеп барышлый» гына бар итәргә этәргән. Атны иярләгән милләтләр шактый булып, татар кебек аттан төшмәгән, атта хат язган, атта кыз урлаган, атта туй туйлаган кавемнәр генә сирәк, ә анын кебек «ир-атлы» (ирнең — атка, атның иргә әверелүе, башы — ир, гәүдәсе ат булган сфинкска әйләнүе) кавем бер генә.

Ул — татар. Ат — татар бәрәкәте. Аны сакларга кирәк. Даулашып-талашып, атсыз калсаң, бәрәкәтсез каласың. «Идегәй» бу мәсьәләдә катгый: *Таяк тайга җиткерер, / Тай дүнәнгә җиткерер, / Дүнән атка җиткерер, / Ат морадка җиткерер...*

Ат морадка житкерер! Нинди дәһи юллар! Әмма бүгенге татар укыймы бу бөек әсәрне?! Бетүгә барган татар мәктәбе аны тәмам хәтереннән чыгарган инде. Без инде үз атыбыз-исемебездән мондагы тирәнлекне аңлый алмас дәрәҗәдә ераклашканбыз. Төрки-татар дала камгагы кебек бөтерелеп чапканда да, ерактагы якын туганын онытмаска тиеш. Аның аты да, авызы бәйле булса, колагы белән пошкыра, борыны бәйле булса, күзе белән сулыш ала. Шуңа күрә һәр төрки-татар «Идегәй»нең үзе кебек: *Аты юкка — ат булды, / Чүлләгәндә — су булды, / Адашканга — юл булды, / Ялгызга — ясак, / Җаяүгә — таяк ул булды...*

«Идегәй» дастаны башыннан азагына кадәр ир-ат бердәмлеген сакларга һәм якларга боера. Әгәр бу бердәмлек бозылган, җимерелгән халдә, табылган мал, төзелгән ил-империяләр генә түгел, төрки кавем үзе дә таркалыр, морадын исраф итәр, дип кисәтә. «Идегәй» — иртәсен-кичен укылырга тиешле әсәр. Кич укыганда, анда кояш баеса, иртән укыганда, анда кояш чыга. Ярый, бүгенге татарның бу хакта онытмыйча искә төшереп торучы әдибәсе бар. Ул Әлмәттән электрончы-инженер Зәрия Хәбипова. Һич арттырмыйча әйткән халдә, бездә «Идегәй» буенча даими эзләнүче белгеч. Үзе бер институт. «Казан утлары» журналының ноябрь (2013 ел) санында аның «Атка мәдхия яки «Идегәй» дастаны ат турында ни сөйли?» дигән бик кызыклы хезмәте басылган. Ул атлы татарның атсыз калуга барган юлындагы беренче каршылык-түмгәләкләрне тикшерә һәм бик кызыклы күзәтүләр ясый. Әмма киләчәк хакына без ана кайбер житди методологик теләкләр дә әйтергә бурычлыбыз. Зәрия ханым, алынган проблеманы тарайтып, үзен көткән ачышлардан үзе теләп читләшә кебек. Мондый читләшү «татар тыйнаклыгы», «татар тарлыгы» дип атала. Ул нишләптер «бер «Идегәй»не генә «күреп капланып», төрки-татар прогрессын бары тик төркичелек, тәңречелек белән чикли, мөселман цивилизациясенең исен дә якын китерми. Шуның нәтиҗәсендә «Идегәй»дәге тарихи кисәтүләрнең бүгенге татар язмышында, аның әдәбиятында чагылачак һәм инде чагылган фаҗигаи чынбарлыкка күпер салмый, гомумиләштерми, киресенчә, күрми үтә. Уйлап карасаң, бүгенге татар әдәбияты, аның күп кенә күренекле әсәрләре «Идегәй» белән меңләгән җепләрдә бәйләнгән бит! Аларны ничек күрмәскә мөмкин? Нәтиҗәдә, әдәбиятыбызның мирас катламнары бик тә ярлылана. Шушы житешсезлекне кулымнан килгәнчә йомшарту өчен, мин бу мәкаләмдә «Татар әдәбиятында ат язмышы» дигән теманы яктыртмакчы булдым. Татар чәчмә әдәбиятында сюжет җебен «Идегәй»дәге кебек, ат образы тартып барган, метафорик рәвештә милләт образын сынландырган, ат язмышы милләт язмышын хәл итүче символ бурычын үтәгән дүрт әсәр билгеле. Әгәр мин, әдәбиятчы да, әдәби тәнкыйтьче дә булмаган гади каләм иясе, ат образын сурәтләгән нинди дә башка бер лаеклы әсәрне хәтеремнән чыгарып җибәргәнмен икән, укучыларым өстәрләр, мин аларга моның өчен рәхмәтле генә булырмын. Дүрт әсәрнең беренчесе — Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе (1922). Әсәрләрнең язылу елларына игътибар итегез. Бу бик мөһим. Икенчесе — Айдар Халимнең «Өч аяклы ат» повесте (1989). Өченчесе — Вахит Имамовның «Могикан» повесте (2000). Дүртенчесе — шул ук А.Хәлимнең «Хунвейбин» роман-эпопеясыннан «Казыкка кадалган атлар» повесте (2007). «Ат караклары» темасына язылган төрле «мажаралы язмалар», минем фикеремчә, бу төр әсәрләр рәтендә карала алмый, чөнки югарыда күздә тотылган әсәрләрдә социаль аспект беренче урынга куела.

## II

Ат турында кайгырту — милләт турында кайгырту ул. Г.Ибраһимовның Лев Толстойның атаклы «Холстомер»ы кебек, тулаем атка, аның фаҗигале язмышына багышланган әлеге әсәре 1922 елда язылган. Бу — гражданнар сугышы тәмамланып, инде большевиклар кулы астына кергән илнең тарихта күрелмәгән 1921 ел ачлыгыннан чыккан чоры. Әмма әлегә Галимҗан абзыйның шул ачлыкка багышланган һәм Җир йөзендә булып узган ачлыкларның берсендә дә язылa алмаган һәм татар тарафыннан гына язылырга мөмкин, куркынычлардан куркыныч, дәһшәтлеләрдән дәһшәтле «Адәмләр» (аны хәзер безнекеләр «Адәмнәр» дип төзәтеп чыгаралар, шулай атап йөртәләр, хакыйкатьтә исә Ибраһимов кулы астыннан кәгазьгә ул «Адәмләр» буларак төшкән) әлегә язылып өлгермәгән аралык. Әмма тема һәм образлар язучының кальбендә колмак балы шикелле әчеп, мичкәсендә

бөкесен атып чыгарырдай басым туплап яталар. «Адәмләр» ачлыктан бераз һуш алгач, 1923 елда язылачак. Илдә инде Ленин һәм партиянең X съезды тарафыннан игълан ителгән Яңа Икътисади Сәясәт (НЭП) хосусый милеккә вакытлыча булса да юл ачып, тормышны җанландыра башлаган чор... Бер унайдан, форсаттан файдаланып, темадан читкә чыгуым өчен гафу үтенеп, шунысын да әйтеп китим әле. Ачлык — кешелекнең даими халәте. Берләшкән Милләтләр Оешмасы китергән мәгълүматлар алты миллиард кеше яшәгән Җир шарында ел саен сиксән миллионлап кешенең туйганчы ашамавын раслый. Әмма шунысы кызык: дөнья халыклары әдәбиятларында ачлыкны Г.Ибраһимов кебек адәмзатлылык яссылыгы аша болай глобаль сурәтләгән язучы юк. Аллаһы Тәгалә «Адәмләр» кебек сирәк әсәр тудыру батырлыгын Идел-Уралдагы татар милләте вәкиленә биргән. Бу бит юкка түгел! Моның кадерен белергә кирәк. Минем бүгенге әдәбиятыбызда исе дә булмаган ниндидер «постмодернистик әсәрләр» уйлап чыгарып, мәкаләләр язган тәнкыйтьчеләребезне төртеп уятасым килә: юк белән маташмагыз, ачыгыз Г.Ибраһимовның «Адәмләр»ендәге тирән реалистик һәм каннибалистик катламнарны, күрсәтегез аларны кешелеккә! Менә кайда ул «постмодернизм»! Аны язганда, Галимҗан абзыйның йөрәге бәйгедәге Алмачуарыныкы кебек ничек шартламый калды икән? Дөнья яратылганнан алып Ленин-Сталинның коммунистлар хакимиятенә кадәр күрелмәгән, бу хакта язу түгел, телгә алырга да куркыныч мондый вәхшилекне сурәтләгәндә, ничек кенәләр түзде икән ул?! Күпмилләтле совет әдәбиятында Ленин-Сталин диктатурасын Г.Ибраһимовның «Адәмләр»е кебек тирән һәм натуралистик фашлаган башка әсәр юк. Ул Короленконың Ленинга язган хатларыннан, Максим Горькийның «Новая жизнь» газетасында басылган мәкаләләреннән күпкә көчлерәк. Без йомыклыгыбыз, мескенлегебез аркасында гына аны бәяли белмибез. Шунысы кызык: «Адәмләр» матбугатта басылып чykканнан соң, бүгенгә кадәр татар гуманитар югары уку йортларында ана багышлап күпме фәнни эш язылды икән? Без булдырабыз. Һичшиксез, татар әдәбиятында талантлар, даһилар бихисап булмаса да, бар.

Бая әйткәнемчә, «Алмачуар» кебек тулаем ат язмышына багышланган гүзәл, нечкә лиризм белән сугарылган бу әсәрнең сәер рәвештә «Бер мәхәббәтнең тарихы» дип «адәмиләштерелеп» билгеләнүе бүгенге укучыны сискәндерергә мөмкин. Атка нинди мәхәббәт булуы мөмкин, имеш? Монда бернинди дә гыйшык-мыйшык һәм мәхәббәт божрасы юк, бары тик авыл малае Закирның башкорт бүләк иткән бурлы биядән туган колын — булачак толпар, бәйгеләр тотачак чабыш атына, ягъни ир баланың, бу очракта мал баласына — колынга, аннан кырыкмыш тайга, аннан чабыш атына булган «мал ярату» тойгысы гына бар. Их, ничекләр генә онытылып, сагынып сурәтләми язучы үзенең Алмачуарын һәм ул чемәтә торган сусыл үләннәрне! Андагы суларның сафлыгы, һаваның чисталыгы, табигатьнең матурлыгы! Ялгышмасам, булачак чабыш атының аркабилен кызлар биле белән дә чагыштыра, тояк тавышларын көмеш кыңгырау зеңгелләре белән дә тәңгәлләштерә, чабып барганда борын тишекләренең фырылдап киңәюен, күзләренең кабарып зураюын татар атына дөньяви иркенлек җитмәү идеясенә китереп тоташтыра кебек. Әнә бит ничек: «...Асыл сөяк булган Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык җефәкләнеп, дулкынланып тора. Эч каеш белән тарттырган кебек нечкәреп, тип-тигез булып эчкә керде. Буе тагын да озыная төшкән кебек күренә. Аяк атлаулары шундый җинел инде, әйтерсен, ул җиргә басмый, бәлки күзгә күренми торган канатлары белән очып кына бара...» Әйе, безгә билгеле татар цивилизациясенең ун гасырлык генераторын тәшкил иткән татар атының ирекле — 1917 елга кадәр булган романтик чорын — болын чорын, яшел печән, ак солы чорын шулай мөкиббән китеп сурәтләгән биредә язучы. Ул үзенең бөек художник-сурәтчелек көчен-талантын «адәмләр»дән генә түгел, аларның малыннан да сыйнфый дошман эзләп әзәрләкләгән кара көчләрдән яшереп, аны әле кичә генә «кеше ашаучылар» оештырган 1921 ел ачлыгыннан исән-аман чыккан һәм бүген НЭП биргән өмет-янарыштан килгән куанычын кая куярга белмичә, Агыйдел буе тугайларында чабулаган Алмачуарына бүләк итә. Кыйммәткә төшә бу бүләк. Язучы нечкә сизем белән сизә — большевиклар Алмачуарларга «колхоз буразнасын» алып килә. Ул бу хакта ачыктан-ачык әйтергә курка, чөнки аны, «җир-су социалистын», шушы ук буразнага төшерделәр һәм кесәсеннән эсэрлар партбилетын суырып чыгарып, большевиклар партбилетын тыктылар. Әйе, илдә сыйнфый дошман эзләү көчәйгәннән-көчәя, язучының үз гәүдәсе дә Архангель зиратындагы чокырга ташланыр сәгатен озак көтәсе калмаган. Әмма әлегә... бөдрә

таллы тугайларда, НЭП алып килгән романтик чорда, башына яшел яулык бәйләнгән романтик Закирны алып киләчәккә томырылган татар аты — Алмачуар белән нишләргә?! Сирәк психолог-язучы аптырашта. НЭП «җепшеге» озакка бармас. Бу ике адымлык тын алыш кына. Алда — хосусый шәхеслектән күмәкчел шәхессезлеккә кучү фаҗигасе. Артта — аерым хуҗалык, алда — колхоз. Артта — яшел печән, алда — сарык силегендә җепшегән салам. Артта — алтындай сары солы, алда — тилебәрән орлыгы. Урталык һәм урталык юк. Булмаячак та. Әмма кая чаба бу тулпар? Нинди упкынга? Һәм якын киләчәктә йорттан йортка, келәттән келәткә, абзардан абзарга йөреп, мал талап колхоз төзиячәк коммуннар кулына тапшырырга теләмәгән язучы үзенең кадерле мирасын — Атын-Алмачуарын — чираттагы бәйгедә «яндырып үтертә». Бу сталинизм тарафыннан татар атына, аның аша татар әдәбиятына бирелгән сигнал иде.

### III

Һәм татар аты, һәм әдәбияты бу һәлакәт сигналын ишетте. Әмма диктатура шартларында алар бернәрсә дә эшли алмый, бары тик булганны һәм булачакны теркиячәк хронометрлар булып кына хезмәт итә алалар иде. Бу күзлектән караганда, татарның чәчмә әдәби поэтикасында икенче игътибарга лаек әсәр 1989 елда язылып, 1992 елда «Казан утлары»нда басылып чыккан «Өч аяклы ат» повестедыр, мөгаен. Язучы үзенең остазы туктаган, Алмачуарның йөрәге шартлап ауган төштән торып үткән гасырның утызынчы елларына һәм аннан илленче елларга сикерә һәм татар аты, татар авылы кичергән иң зур фаҗигане — атсыз, киң масштабта гомумиләштереп әйткәндә, атсыз-җисемсез генә түгел, атсыз-исемсез (игътибар итегез: атың-исемең кем?) калу чорын сурәтли. Әгәр Галимҗан Ибраһимов заманнарында, югарыда әйткәнемчә, бары тик кешеләр генә сыйнфый дошман дип игълан ителсә, атылса һәм катыр китсә, инде А.Хәлим сурәтләгән чорларда мондый «дошман»нарның маллары да «сыйнфый дошман» итеп игълан ителә һәм репрессиягә эләгә. Әсәр үзе тулаем авыл тормышының көндәлек романтизмы белән сугарылса да, биредәге сурәтләнеш чаралары бик кырыс. «Алмачуар»дагы романтик буяулар «Өч аяклы ат»та күренми. Ул — колхоз буразнасыннан чыкмаган арык мәхлук. «Кулак нәселе» булганы өчен тукмактан калмаган Бамбукның арба араталары кебек шәрә кабыргаларын гына санамый язучы. Әмма Бамбукның табигатьтән сылу бия булуын аның Бамбук дигән романтик исеме, кайчандыр бамбук камышын хәтерләткән нәзек сыйраклары раслый.

«Өч аяклы ат»тагы бүре тешенә эләккән буаз Бамбукның язмышы — үз чорының «тере пашпорты» ул. Менә кайда «Идегәй»дәге тарихи кисәтүләр, берсе икенчесенә яу чапкан ир-атлар, ике төрки-туган Аксак Тимер белән Туктамыш алышлары, дала тулып кыйралып яткан атлар күз алдына килә!.. Биредәге әсәрнең эчтәлеге авылның үзе кебек бик гади. Авыл гүзәле Саниянең әти-әниләрен «кулакка үткәргәндә», совет куштаны, сәнәктән көрәк булган сукбай Гыйльметдиннең шушы гүзәлгә күзе төшә. Әмма Сания үзенең сөюен хакимият вәкиле белән алыш-бирешкә алыштырмый һәм Гыйльметдингә кияүгә чыгудан баш тарта. Саниянең сөйгәне, инде аның кияве Хәлим, сугышта ятып кала. Сугыштан соңгы чорга таланган һәм ач-ялангач калган авылда бригадир булып үрмәләп өлгергән Гыйльметдиннән ат алып, улы Кәбир белән Сания кайчандыр утызынчы елларда авылдан качып киткән һәм ерактагы совхозда яшәп яткан тутасы белән җизнәсенә кунакка бара. Тик биредә аларны фаҗига көтә: төнлә абзарга бүре төшә һәм Бамбукны яралап, аягын имгәтә. Бала белән ана илле чакрым юл үтеп, авылга җәяү кайталар. Биредә аларны тагын да аянычрак фаҗига көтә: Саниядән шәхси үчен кайтарып, алдына тезләндерергә хыялланган Гыйльметдин тарафыннан ул колхозны атсыз калдыруда гаепләнеп, эше прокуратурага тапшырыла. Атның исәнлеген расларга һәм әнисен коткарырга теләгән ун яшьлек Кәбир җиде сынау, житмеш бәла аша Бамбукны авылга алып кайтуга ирешә. Үз хәйләсенең фаш ителүен теләмәгән Гыйльметдин, Саниянең район эчке эшләр КПЗсында утыруыннан файдаланып, «ач колхозчылар»ның «тамагын туйдыру» ниятендә буаз Бамбукны суйдырта. Татар колхоз крестьяны белән аннан тартып алынган мал-туар — Ат арасындагы тере җеп, ниһаять, шартлап өзелә, татар авылының социаль җирлеге — үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге менә шушында упкынга убыла...

Моннан ун ел чамасы элек IV Халыкара мөселман кинофестивалендә җинүче урыннарның берсен яулаган «Өч аяклы ат» фильмының авторлары белән булган

матбугат конференциясендә кинорежиссёр Нурания Жамалинын, Казан артындагы Биектау районында фильмны төшергәндә, Бамбук ролен башкарыр өчен бөтен районда бер ат таба алмаганнарын сөйләгәне хәтердә. Табылды ул ат эзли торгач, арык булырга тиешле Бамбуктан аермалы рәвештә эре сөякле һәм чамадан тыш симез булса да. Анын исерек хужасынын сәгать саен аракы сорап килеп йөдәтүе дә хәтердә калган. Болар барысы да татар күптән арынырга, үзенең нинди һәлакәт алдында торганын аңлап, айнырга тиешле галәмәтләр дә бит, югыйсә...

Атсыз татар авылынын ямьсез калуы, анын «перспектив рәвештә» бетүгә баруы — бүгенге чынбарлыгыбыз. Югарыда сурәтләнгән картиналардан соң илле еллап вакыт үткән. Әгәр Татарстан хөкүмәте, беренче чиратта, анын югары уңышлар яулаган авыл хуҗалыгы министрлыгы «Татар атын аякка бастыру» дигәнрәк программа булдырып, эшкә башласа, безнен авыллар бу кадәр бөлгенлеккә төшмәгән булыр иде. Әмма, әмма... Татар атлары белән бүгенге хәлләребез ничегрәк тора соң? Гарәбстаннан миллион долларлар исәбенә Татарстанга китертелеп, жылы түшәкле ипподром араннарында кара уылдык һәм сортавай печенье ашап, «гылавалар» һәм башка кин жилкәләрнен алтын-көмешкә чумган хатыннарынын яхшы кәефләре хакына гына түгел, дөньякүләм Спорт узышулары өчен дә әһәмиятледер, әмма ул узышкан медальле тулпарлар безгә мәртәбә дә китерми, авылыбызны атлы-колынлы да итми, ягъни бездән «колхоз пычагы» алып киткән татар атларын кире кайтармый. Бу хәл шул ук Айдар Хәлимнен моннан өч-дүрт ел элек «Казан утлары»нда чыккан «Хунвейбин» роман-эпопеясынын «Казыкка кадалган атлар» китабында сурәтләнә. Әгәр Ибраһимовнын XX гасыр Алмачуары печәндә һәм солыда, Айдар Хәлимнен XX гасыр уртасындагы Бамбугы соры саламда тотылса һәм иткә чалынса, «Хунвейбин»дагы Кизләү авылы житәкчелеге үз атлары алдына, кая ди балык уылдыгы, черек салам да салып маташмый: кайчандыр кешеләре качкан, инде хәзер ачлыкка түзә алмыйча авылдан качкан атларын, эзләп табып, абзарга биклиләр һәм аларнын барлыгы да онытылып, айлар буе азыксыз, сусыз тотылган малкай-мескенкәйләр, абзардагы матча-өрлек ишарәтен ашап, тешләре белән өзелгәнче кимереп, акылдан язалар һәм казыкларга кадалып жан бирәләр.

## IV

КамАЗ автогигантынын келәймәсенә әверелгән Кашка Туры Тулпар күзләрен алартып кая чаба? Шулай алдын-артын белми чаба-чаба, жил-юргага әверелгән бу жан иясе, Лермонтов әйтмешли, үзенә бәла эзлиме? Вахит Имамовнын Могиканы ул. Шул исемдәге әсәрнен төп герое Вәлит кечкенә акылы белән халкынын язмышын туган Идел-Чулман буе татарларына тиндәш күреп, Шонкар дигән биядән туган булачак чабыш атынын исемен Көньяк Американын һинди кабиләсе — Могиканнар исеме белән атаган. Замандаш язучыбыз үзенең сирәк лирик әсәрләреннән исәпләнергә хаклы «Могикан»ындагы тулпарын Галимжан Ибраһимовнын Алмачуар чалымнарын күреп тасвирлый: «Мангаенда ап-ак йолдызы бар. Сыйраклары озын. Карындыктан арынып, ярты сәгать үтүгә үк, әнисенең жиленена барып ябышты. Ай-һай тере!.. Әнисе сымак тулпар булмагае!..»

Әмма татар чабышкысынын тыны кысылган. Аны кичә генә сабан арасыннан чыгарып, бер-ике көн жикми тордылар, кеше кыйлана дип кыйланган булып, авызын шакарып, ак тешле тамагына бер-ике йомырка тамыздылар да бүген бәйгегә ярышка чыгардылар. Автор татар атынын һәм татар авылы язмышын бертигездән куя. Ат юк — авыл юк, авыл юк — ат юк. Биредә кинрәк алырга кирәк иде: ир-ат юк — авыл юк, авыл юк — ир-ат юк: «Әле кичә, өченче көн генә тәртә арасында йөргән бичара малкайлар, ярты чакрым ара үтүгә, ак күбеккә баткан. Чабатадай жәелгән тояклары тузанлы, йомшак юл өстендә лап-лап килә. Хужаларынын аяусыз камчылавына, яман типкәләп, һау-һаулап куалавына түзмичә, бәбәкләрен акайтып, гыжлап-пошкырып чапкан була алар. Боларнын бер өлеше аксап-туксап ярты юлда туктап калачак... Юк булгач, юк инде ул, гомер буе читлектә, коллыкта интеккән, ирекнен, чын дала һәм чиксез күк йөзенең ни икәнен дә белмәгән, өркетелгән, тоткын кошлардан башкаларны чүкеп ала йә булмаса әйдәп бара торган бөркет, лачын, шонкар чыгамыни?!»

Яхшы бит, жәмәгать! Матур бит! Татар атынын, димәк, авылынын юкка чыгуына багышланган реквием-поэманын кереше бит бу!

Могиканга өркерлек кенә түгел, бәеннән алагаемга ычкынып, упкыннарга ташланыр

сәбәбе бар: аның туган авылы Гәрдәләгә, җир актарып, бульдозерлар кереп килә. «КамАЗ сезнең артта калган төбәгегезне алга җибәрәчәк», имеш. Авыл халкын күп катлы баракларга куып кертеп, урынында чуен кою заводы төзеләчәк. Әйе, татарның бары тик илле-алтмыш еллык гомерендә нинди үзгәрешләр: әгәр Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар»ындагы Закир тулпарының бәйгедә янып үлүе белән егетләрчә «килешсә», атының үлеп тә, аның һәм үз (ир-ат) нәселенең мәңге исән булачагына инанып, авылының «үлемен» күз алдына да китерә алмаса, Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат»ында Кәбир, Бамбугының суелып ашалуы белән килешә алмыйча, исән авылын ташлап, «шәһәргә чыгып качарга» хәл итсә, Вахит Имамовның Вәлите һәм Могиканы исә бөтенләй авылсыз калалар. Болар барысы да «бәхетле киләчәк-коммунизм» һәм аны югарыда утырып тормышка ашыручылар («Сыка белән совет хөкүмәте») хакына. Ничек түзмәк кирәк? Завод төзү өчен нигә кара туфраклы җирдә иген үстергән, мал асраган авылны күчерергә? Аһ, татар авылы булган өчен. Туфракның культуралы кара катламын культурасыз кызыл катлам, зыялы татарны башка кавем белән буташтырып, катнаштырып өчен. Бу каләр гаделсезлек һәм мәгънәсезлектән җаны әрнегән язучы әсәренә ашыга-ашыга публицистик гыйбарәләр белән яна диспозицияләр ача: «Ялан-кырларда, инеш-ерганаклар кузгалып, калкулыкларда тәүге «түбәтәйләр» пәйда булгач, шул ук далага һәркайсы авыл йортларыннан да биегрәк грейдерлар, бульдозер, экскаваторлар, «КрАЗ», «БелАЗ» машиналары килеп тулды. Шул гыйфритләр калкулыкларны унга-сулга йолкып җимерә, көздән генә орлык чәчелгән иген басуларын катлам-катлам итеп кисә башладылар. Тау-тау булып өелгән чем-кара туфракны экскаваторлар «БелАЗ», «МАЗ»га төйи, ә тегеләре икмәк өстенә ягып ашардай шул байлыкны әле теге, әле бу яктагы ерымнар, чокырлар эченә, күлләр, чишмәләр өстенә илтеп аудара торды.»

Нәрсә, кара туфраклы басулар, татар халкының үзе белән шулай булмадымы? Иң яхшы, затлы никах ул катнаш никах икән. Никадәр күбрәк булса, шулкадәр һәйбәт. Бигрәк тә «олы туган» вәкиле-вәкиләсе белән. Иң теләктәшсез, начар никах — үз милләтең белән. Менә төрки-татарның башка бер генә милләттә дә булмаган тарихи «ир-ат» төшенчәсе кайларга барып ялганды һәм акланды! «Сау кеше аракы эчәргә тиеш. Кырлы стаканлап». Килмешәкләр авылның түтәйләренә көн дә иртән «йөкләмә» биреп китә: «Кечкә җан башына ким дигәндә берәр шешә «первач» әзерләргә». Караңгы төшүгә ярты авыл исерек. «Өйдәш»ләргә ияреп, хуҗалар үзләре дә эчә. Һәркөн саен ихаталар эчендә талаш-сугыш. Ата — улны, ана кызны белми. Иваново маржалары ямалныкыларга ияләшкән. Псков ирләре Рязань хатыннары янында, йә лапас сәндерәсендә, йә мунчада кунып йөри».

Вахит Имамов заманында туган авылыннан да ваз кичерәләчәк татар аты үзе көннән-көн камалышта кала бара: ул черки-кигәвеннәрдән кача, салкын күләгәсендә шартлатып үлән өзә, ял итә торган урманнар киселә, кырыла; ул суын эчә торган чишмәләр-күлләр күмелә; печәнле болыннар бетон астындагы завод нигезләнәчәк «геодезик объект» булып кына кала. Гәрдәләләр бәйге-Сабан туй үткәрү хокукыннан мәхрүм ителә. Хәзер аның сараенда да килмешәкләр яшәгән һәм почмаксыз калган Могикан икенче елны Чаллы сабантуена бөтенләй кертелми. Атның хуҗасы Вәлитнең сөйгән кызын килмешәкләр көчли, дөресрәге, ул үзе бирелә, чөнки «Мәрьямнең имчәкләренә мыек төртеп күңел ачкан, аның белән күптән әшнәләшкән бәндә янына килеп йөргән иң «галаунайларның» берсе икән». Бирелә бер уңайдан шунысын да әйтми булмый: Вәлитнең Мәрьям, «мыеклы түрә» һәм Сабантуй ярышында башкорт җайдаклары арасындагы конфликты үтә дә ясалма һәм примитив килеп чыккан кебек. Монда сурәтләүне сөйләү, сурәтче-художникны очеркчы-публицист җиңгән. Иң мөһиме: автор мир белән төзелгән КамАЗның, объект буларак, субъектның ирек сөйгән холкын үзгәртүен күрсәтүгә ирешкән: Мәрьямен яклап, аны көчләүчеләргә каршы ташланасы урында Вәлит каядыр кача; шулай итеп, «герой» өстән төшкән күрсәтмәләргә буйсынып кына яши башларга тиеш була. Могикан үзе дә бәйгеләрдә ярыша алу-ярышмау хокукыннан мәхрүм ителә. Тора-бара камалыш авыл тупсаларына килеп җитеп тарая. Йорт-җирне чит-ят халык баса. Хатын-кызларны сакларга хет милиция куй. «Сентябрь башында Гәрдәләне юкка чыгардылар... — дип кырыс сабырлык белән нәтиҗә ясый автор. — Халык зар елады. Кар базлары, иске бурадан салган мал йортлары, келәт, чиннек — бөтенесе дә ун сумга янды. Әмма гомерендә беренче мәртәбә мондый «зур акча» тоткан күпчелекнең күзе сукырайды... Уяураклар үзенең мунчасын-йортын сүтеп, бер-ике төн эчендә якын-тирә

авыллардагы туган-тумачасына илтеп куйды. Ачыгавызларга анысы да тәтемәде, аларның ихатасына «кызыл әтәч» кунды. Октябрь аенда инде авыл урынында тигез мәйдан гына җәйрәп ята, анысы да гыйфрит-бульдозерлар белән ерылып, чокылып, асты-өскә килеп беткән иде. Шуны күргәч кенә халык айныгандай булды.

— Ә зират кайда? Әби-бабайларыбыз яткан газиз зиратыбыз кая киткән?!

Юк, анысы да юк, ул «газиз»не дә гыйфрит төрәне тетеп үткән иде...»

«Халык айныгандай булды» дип язучы ашыгыбрак әйткән, минемчә. Мин Вахит Имамовны аңлыйм. Аның татарны айнытасы килә. Әмма, ни гаҗәп, безнең халык әле бүген дә айнымаган. Без моның чынлап та шулай икәненә язмабыз дәвамында ышанырбыз.

КамАЗ — татар халкының, бигрәк тә Татарстан татарының, аеруча Кама аръягы татарының йөрәк ярасы. Бу ярадан кара кан булып безнең бәхетсезлекләребезнең башы булган җир мае — нефть саркый. Без аны хәзер, гадәттәгечә, татарча «нәфт» дигән атамасын ташлап, урысча «нефть» дип кенә атап йөртәбез. Юк, Нефть үзе, җир асты байлыгы буларак, һич кенә дә бәхетсезлек чыганагы түгел. Киресенчә, бәхет чыганагы. Нефть исәбенә яшәп яткан гарәпләрне искә төшерегез. Ул — безгә Аллаһтан бирелгән газиз байлык. Куллана белеп кулану һәм бәрәкәт табып баю өчен. Без аны куллана белмәдек, хуҗа була алмадык һәм бүгенге мескенлеккә төштек. Шуның өчен Аллаһ җәзасына лаек булдык. КамАЗны безгә үзебезнеке булган нефть, җир, су, һава, эшчеләр, ипекәй, сөт, май, ит «чакырып» китерде. Барысы да үзебезнеке, барысы да бушка, тик КамАЗ үзе генә безнеке түгел — «ский»ләрнеке. КамАЗ безне кайгылы итсә итте, бәхетле генә итә алмады. Инде талауның чигеннән чыккач, янгын чыгарып, тагын бер тапкыр таладылар. Ичмасам, бер генә пожарный да җәза алмады. Ә менә шушы КамАЗ алып килгән социаль-әхлакый, милли-мәдәни, рухи-матди һ.б.ш. проблемаларны ачып салган публицистик, әдәби-чәчмә, шигъри әсәрләребез бармы? Алар тарихта калганмы? КамАЗ сафка басканнан соң үткән кырыклап ел эчендә Татарстан Язучылар берлегенә килеп исәпкә баскан йөзләгән язучыларыбыз «КамАЗ һәм татар милләте» дигән глобаль проблеманы яктыртуда нинди эшләр майтарган? Милләтне, Вахит Имамов әйткәнчә, айныткан, мәсьәләләрне җан ачысы белән ачкан, тетрәткән, безнең нинди хәлгә төшкәнлегебезне Чыңгыз Айтматов, Виктор Астафьев, Валентин Распутин кебек осталык белән сурәтләгән язучыларыбыз, очеркларыбыз, хикәяләребез, романнарыбыз бармы? Юк. Ә нәрсәбез бар? Тикшеренүләрем шуны күрсәтте: КамАЗ төзелә башлаганнан бирле, аны шаштырып мактауга — кирпеч кебек калын, әмма буш, социалистик ярыш алдынгыларын чамасыз шыттыруга багышланган меңләгән «Огонёк» глянецлары, төче вә баллы очерк җыентыклары, елтыр, ярпач альбомнар, календарьлар чыгаруга барлыгы 137 вагон фин кәгазе киткән, әмма алар арасында дистә меңләгән хезмәтчәннәрнең тозлы вә ачы яшь тамчысын күрсәтеп язылган бер генә тетрәткеч язма — очерк та, хикәя дә юк. Әмма, гафу, татар әдәбиятында бер хикәя бар икән. Ул да, кичерәсез, А.Хәлимнең 1993 елда язылган «Энгер» хикәясе. Укучы аның белән янәшә куярлык башка берәр хикәя тапса, хәбәр итәр — бу язмабызга өстәрбез. Әмма Татарстан Милли китапханәсенең библиография бүлеге һәм халыкара интернет әлегә безгә бүтән мәгълүматларны бирми. Ул 1972 елда минем күз алдымда булган вакыйганы сурәтли.

«Энгер» язылган һәм басылып чыкканнан соң шактый гомер узгач, КамАЗ исеме астында татар өстенә төшкән проблемаларны шундый кискенлек белән күтәрү һәм ача алу вәхие Аллаһы Тәгалә тарафыннан күренекле язучыбыз һәм публицист-нәширебез Вахит Имамов өлешенә туры килгән булып чыкты. Моның өчен намус, сәләт-талант кына түгел, шактый дәрәҗәдә батыр булу да кирәк иде. Рәхмәт анарга. Ә бит Татарстан Язучылар берлегендәге дүрт йөзләп язучының һәркайсы тәрҗемәи хәле, туганлык җепләре, матди хәләте һ.б. ягыннан чыгып караганда, ниндидер күләмдә КамАЗ белән бәйләнгән иде һәм бүген дә бәйләнгән хәлдә кала. Ә нигә күтәрмибез без КамАЗ темасы аша татар, гомумән, татар халкы, Татарстан, аның табигый байлыклары булган нефь, газ, су, һава, кара туфрак, җир, урман һәм башка төр мирасыбызның Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан җирле милләт мәнфәгатьләрендә яклланган күләмдә файдаланылуы һәм сакланылуы мәсьәләсен?! Бу язучыларыбыз, журналистларыбыз, сәнгать эшлеклеләребезнең бурычы түгел мени? Әнә, намусы булган һәм гражданлык бурычын тойган язучыбызны сискәндергән бит! Һәм ул бу темага романнар, «Кәнәфи»,

«Күке», «Могикан» кебек курку-өркү белмәгән повестьлар, «Сәет батыр», «Татарларның яшерелгән тарихы» дигән тарихи-публицистик эзләнүләр, дистәләгән үткен мәкаләләр язган һәм, Аллага шөкер, бүген дә язуын, үзе баш мөхәррир булган «Мәйдан» журналында чыгаруын дәвам итә. Әмма һаман үз бәясен генә ала алмый!.. Тәнкыйтьнең бурычы — язучы язганны ачу! Уңы һәм сулы белән! Бары һәм югы белән! Көнләшмичә, тибешмичә, сүгешмичә. Бер генә язучының иҗаты да бары тик җәүһәрләрдән генә тормый. «Могикан»да байтак тел һәм сурәтләнеш табышлары очрый. Американың колонизаторлар тарафыннан кырылып беткән һинди кабиләләренең тел-атама, мәдәни-мәгърифәти структурасын «үзебезнең әйбәт колонизаторлар» тарафыннан кырылып диярлек беткән татарның тел-атама структурасы белән бербөтен булып сурәтләнүе, татар балаларының һинди мифлары, ат-мустанглары белән саташуы, минемчә, язучының кызыклы җәүһәре буларак танылырга хаклы. Менә бит иртәгә җир белән тигезләнәчәк Гәрдәле малайлары ничегрәк кенә сөйләшә: «Кичә мустангларны прериягә алып чыккан идек. Бивакка туктагач, муссон купты, томогавклар белән ботак-санак кисеп, бик зур вигвам кордык... Мустангларны лассо ыргытып кына тотарга туры килде...»

Милләтнең иҗтимагый хокукы турында сүз кузгалганда, язучы тарихның курку-өркүдән үткән мирасы белән чын «Сәет-батырларча» эш итә. Кайвакыт биредә, югарыда әйтә биреп куйганымча, язучылыкны публицистлык басып киткәндәй тоела: «Мөшһид Иван илле икенче елны Казанны яуласа да, безнең кавем халкын тезләндерә алмаган. Аннан соң падишаһ булып килгән Алексей, Пётр, Анна, Екатериналар да буыннан-буынга әманәт тапшырган: «Татарларга янә берләшергә ирек бирмәс өчен, Казан җиренә урыс авылларын күчереп утыртырга. Юлбасар, катил, караклар табыла икән, аларны үлем җәзасыннан азат итәргә дә шулай ук татар авыллары арасына мәҗбүриләп китереп утыртырга. Мәчетләрен җимереп бетерергә, мәдрәсәләрдәге шәкертләрен куып таратырга, халкын чукындырырга, каршыларын җирсез калдырырга. Андагы җирләр тимер-бакырга бай. Шуна күрә ул җирләрдә заводлар төзергә дә татар крестьяннарын шунда беркетергә, теленнән аерырга. Менә шундый сәясәт нәтиҗәсендә безнең җирдә Алабуга, Чистай, Зәй, Питрәч, Тәтеш сыман урыс утраулары үсеп чыккан. Патшалар кулыннан килмәгәнне хәзер Совет власте эшли...»

Кыскасы, Вахит Имамов үзенең «кечкенә дә төш кенә» кебек «Могикан»ында татар әдәбиятында беренче тапкыр Магниткалар, Чиләбе ЧТЗлары, КамАЗлар басып киткән татар авылларыннан берсе булган фаҗигаи Гәрдәле авылының елый-елый җир йөзеннән китеп баруы турында поэма тудырган. Үзенең алтмыш яшен каршылаган әдипне мондый уңышы белән котларга кирәк. Әлбәттә, камиллекнең чиге юк. Бу урында язучыга берничә теләк тә әйтәсе килә. Әгәр дә шушы теләкләр «язучы язган чакта» ниндидер могҗиза белән аның зиһенендә утырган һәм гамәлгә ашырылган хәлдә әсәр күпкә уңышлырак, камилрәк туган булыр иде. Әсәр бик ашыгып язылган. Язылганнан соң аек зиһен, ачык күз белән яңадан карап чыгылмаган. Әсәрнең «ат башы» итеп казыкка элеп куярлык символы табылмаган. Әдәбиятта чын ачыш символлар аша гына бара бит. Тел тигез түгел. Ясалма рәвештә китереп чыгарылган конфликтлар, тел төгәлсезлекләре, урынсыз кулланылган гыйбарәләр шактый. Бер генә мисал. Татарда ара-ераклыкны борынгы заманнарда «дилбегә буе» белән чагыштыру булган. Әмма, халыкчан булам дип, егерменче гасыр уртасында, космик кораблар Айга менгән заманда, «Григорий дәдәй аның кыяфәтен инде ике-өч дилбегә буе озынлыктан ук чамалап өлгергән иде» дигәнне бүгенге укучы ничегрәк күз алдына китерергә тиеш икән? Житмәсә, «кыяфәтен», житмәсә, «чамалап». Йөзен, сынын түгелме? Гади генә «күреп» түгелме? «Первыйлар» күрсәтмәсенә «протест» рәвешендә бәйгедә «мотоциклдан һәм өч меннән «баш тарткан Могиканның ничегрәк тормыштан китүе — «җиңеп җиңелүе» аңлашылып җитми.

Чынлап та, язмамның башына чыгарылганча, КамАЗ келәймәсендәге Могикан — «Туры Тулпар кая чаба?» Язучының бер раславында, Могикан җилеп барышлый, читкә каерылып, «өч йолдызлы полковник»ны фуражкасы-ние белән «чәчрәтеп очырса», шуннан ике бит аша гына аны «Арлувка янындагы чокырда суеп үтерделәр» дип расланыла. Монысын, әдәбият кануннары ачылганны кабатлау тенденциясеннән чыгып караганда, бөтенләй дә аңлап булмый кебек. Моннан егерме елга якын элек «Өч аяклы ат»ны — Бамбукны татар колхозы бер тапкыр суеп ашаган иде бит инде.

Болар әдәбият тормышында була торган хәлләр. Әсәрнең киләсе басмаларында язучы алардан җиңел котылып, «Могикан»ны әдәбиятыбызның асыл әсәре итә ала. Ничек кенә булмасын, Вахит Имамов Гәрдәле авылын йоткан, димәк, татарны, Кама аръягы татарын авылсыз калдырган КамАЗ темасына тотынып, язучылыкның зур социаль-әхлакый бурычын үтәгән. Аннан язучының йөрәктән тетрәнеп чыккан авазы, Чаллының Сидируфка пачулкасында төзелгән биек йортның уналтынчы катындагы Вәлитнең сыкрануы, юк ителгән татар авылларының тере авазы булып яңгырый: «И туган җир! Син юк инде! Урынында хәзер күк йөзенә кара баганалар сузып гыйфрит завод утыра. Мичләрендә руда, күмер түгел, ә шул завод астында калган ил зираты, хәтер, тарих яна... Аларга ил-йортының күптән кирәге юк. Айрат, Мәрьям, Делавар, Могиканнарның һәммәсен дә шулар кәнәфи һәм акча хакына сатты. Мондый илнең миңа кирәге юк. Телсез бөҗәк булып яши алмыйм, син мине ярлыка. Хуш туган җир! Саумы газиз, гаярь Могикан!»

## V

Менә юнәлешен югалтып чапкан Туры Тулпарыбыз кая килеп чыкты. Саумы, газиз, гаярь Могикан! Бу бит тарихи аваз! Тарихи чакыру!.. Таң калырлык! Соңгы йөз ел эчендә әүвәлдә татар ире-егете тарафыннан мең ел янәшәдә булган татар атын юк иттерү, расхутка чыгарттыру, аннан татар ир-егетен үзен юкка чыгару хакына язылган өч әсәрне — «Алмачуар», «Өч аяклы ат — Бамбук», «Могикан»ны — гүя бер даһи режиссёр кушуы буенча бер даһи сценарий остасы язган һәм төрле заманнардагы төрле тиран-падишаһлар түгел, ә бер замандагы бер падишаһ тормышка ашырган диярсең! Әмма Вахит Имамовның «Хуш, туган җир!» дип төшенкелек аңкытып куйган гыйбарәсенең иң азакта, күңелләрне җилкендереп: «Саумы, газиз, гаярь Могикан!» — дип әсәрен тәмамлавы бездә, татар баласында, реквиемнан соң патетик ораторий тыңлау хиссиятен уята.

Ат елы 2014 елны була, дидек. Иншалла. Татар баласы, татар ир-егете, үзенең бай тарихы, тоташ бер цивилизациясе белән юкка чыгарга теләми, ә киресенчә, атыисеме, Алмачуар-Әлифбалары белән мәңге яшисе, кешелек харитәсендә югалмыйча, үз юлы белән барасы, шиксез таланты белән дөньяны сыгындырасы килә икән, ул, ничек кенә, кайда гына, нинди генә материкларда, хәзерге тел белән әйткәндә, регионнарда — Алтайдамы, әллә Мөслимдәме — яшәвенә карамастан, үткәне һәм бүгенгесе, Европаны таң калдырган арбасыннан алып, безне харап иткән колхоз нигезләренә, алардан үрчегән кооператив ЖҖЖларга (колхозга кадәр — колхоздан соңгы чор), үзен татар санаган һәр адәм затына кадәр җегәрләнеп һәм илһамланып, тарихтан китеп югалган татар атын аякка бастыра башларга тиеш. Татар йорты, татар капкасы каршында татарның иминлек символы — ат бәйли торган баганасы булырга тиеш. Татар ир-аты аякка басмый, гамәлгә килми торып, татар мөстәкыйль була алмый гына түгел, хәтта аның турында уйлый алу батырлыгына да ия була алмаячак. Бүген бу идея һәр татар авылы тупсасыннан шәһәрләрнең иң биек йортларында яшәгән татар җаны аша Казан Кремле, Татарстан җитәкчелегендәге «ат җанлы» ирләр (ир-ат) йөрәгенә кадәр үтеп, Татар атын гамәлгә кую программасын булдырырга һәм шуны тормышка ашырырга керешергә тиеш. «Идегәй»дәге Идегәйнең ир-ат бердәмлеген сакларга кушкан васыятен үтәү булыр иде ул. Татар аты үзбәк, төрекмән, башкорт һ.б.ш. атларга бүленеп юкка чыкканнан соң, без татар аты буларак кире кайтырга тиеш. Татарстанның Авыл хуҗалыгы министрлыгы әлеге программаның штабы ролен үтәргә бурычлы. Бу — прожект түгел, яшәтә һәм яшәртә торган проект. Аллаһ безгә шундый тантаналы бурыч-җәза әзерләде: исән каласыбыз килсә, татар атын яңадан тудырырга һәм аның иярсез сыртына атланырга тиешбез. Бу уен эш түгел. Кыен эш. Бәрәкәтле, иманлы, гуманлы эш. Бу — яһүди кардәшләребезнең, Синай комлыкларыннан куылганнан соң өч мең елдан үткәч, үз дәүләтләрен торгызырга тотынуларына һәм шуңа ирешүләренә тиң бәракәт. Шулай була күрсен иде. Шулай булмаса, 2014 елның АТ ЕЛЫ дип игълан ителүеннән татарга ни файда?

**Айдар ХӘЛИМ**

# ЮМОРНЫҢ СОҢГЫ ТӨНЕ

## ЯЗУЧЫ ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ФАҖИГАЛЕ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР, ВЕРСИЯЛӘР, ФАКТЛАР



*Язучы Фаил Шәфигуллин (1939-1982) — күп кырлы талант иясе. Кыска гына гомере эчендә танылып, балалар әдәбиятында, шигърияттә һәм җыр сәнгатендә, бигрәк тә юмор өлкәсендә, бүгенгәчә актуальлеген югалтмаган, кабатланмас әсәрләр калдырган автор. Аның шаян хикәяләре чын мәгънәсендә классик әсәрләр рәтендә. Ни кызганыч, язучының иҗаты мәртәбәле галимнәр тарафыннан тиешенчә өйрәнелмәгән әле. Язылырга тиешле олы фикерләр, тулаем кәгазьгә төшмичә, телдән әйтелгән килеш кенә яши.*

*СССР Язучылар союзы әгъзасы Фаил Шәфигуллин ерткычлар кулыннан шәһит китте. Бу мәкаләбез моннан унбиш ел элек «Татарстан» журналында басылып чыккан материалларга таянып язылды. Иң аянычы шул: каләмдәш дустыбызның җанын кыйган җинаятьчеләрнең шушы көнгәчә һаман да тотылганы юк...*

*Алда тора салкын көннәр –*
*Кышны ничек чыгарбыз?*
*Хәтер сунсә – чыдамабыз,*
*Ялгызлыкка чыдарбыз!..*

Эльмира Шәрифуллина
(«Бер кычкырды көккүк» поэмасыннан).

***1982 ел, 5 октябрь.***

Күп еллар үткәч, җинаять үзеннән-үзе фаш ителә...

Фаилне үтереп ташладылар!..

Бөтенесе дә бәйрәмчә башланып киткән иде югыйсә.

Бу көнне көндезге сәгать икедә идарә утырышы берьюлы алты кешене: Газиз Кашапов, Фәрит Гыйльми, Ямаш Игәнәй, Мөнир Мазунов, Нурмөхәммәт Хисамовны һәм мине СССР Язучылар берлеге әгъзасы итеп раслады. Матур йола буларак, алтыбыз берләшеп, әлеге вакыйганы билгеләп үтәр өчен, чәй, купшырак итеп әйтсәк, банкет әзерләп йөрибез. Идарә бүлмәсеннән чыгып, озын коридор буенча егерме метр атласаң, җыйнак кына буфетыбыз бар иде. (Соңрак аны Китап палатасы архивы иттеләр.) Әллә кайлардагы аулак рестораннарга барасы булмагач, Сибгат Хәким белән Атилла Расих, Әмирхан Еники белән Фатих Хөсни, Аяз Гыйләҗев белән Мәхмүт Хәсәнов һәм гомергә чәйле-мәйле табыннан читтә йөри торган Адлер Тимергалин, Хәкимҗан Халиков кебек сабый җанлы кунакларыбыз да бар иде.

Аксакаллар идарә утырышы беркетмәсеннән яшереп алып калган кайбер

кинаяләрен житкерә, кара сакаллар аларны хуплап тост әйтә... Ә без — сакалсызлар, бөтенесенә дә рәхмәт укып утырабыз. Алтыбызга өчәр язучы рекомендация язган — алар барысы да табын артында, түрдә — Фаил Шәфигуллин.

Кичке жиделәр тирәсе.

Буфетчы Мария Соломоновнаның кулкасы коры: «Всё, ребята, всё!» — дип бер генә әйтте, өйдәге кухаркаларга баш иеп күнеккән горур язучылар, әртилләре белән бердәм күтәрелеп, өйләренә таба юл эзли башладылар.

Егерме метрлы коридорда әрле-бирле йөреп, өлкән язучыларның таралышканын түземсезлек белән көткән «банкет санитарлары» бәйрәмне йомгаклап чыккач, буфет эче ятим калды.

Нәкъ кичке жиде...

Язучылар берлегенең тарихи йортында (Бауман урамы, 19) булган кешеләр еш тукталып, сөйләшеп тора торган баскыч мәйданы бар иде, Фаил шунда берүзе калган. Өч сәгать буе идарә утырышында, аннан ике сәгать буе буфетта утырып та чалбарының «стрелка»сы сынмаган, галстук астындагы ак күлмәге әле яңа гына үтүкләп киелгән кебек, кулында ак кыршаулы кара дипломаты...

Икәүдән-икәү калган форсаттан файдаланып, мин аңа тагын рәхмәт әйттем, эшен калдырып килгәне өчен, Фәрит Гыйльми белән икебезгә дә рекомендация язарга ризалашканы өчен...

«Интеллигент бишегеннән төшкән булсагыз, кәгазь әрәм итми идем мин сезгә! Килер бер көн, син дә яшьләрне Союзга тәкъдим итә башларсың әле»... — диде Фаил, ә үзе минем рәхмәтләремнән оялыпмы, кирәкмәгән жиреннән дипломатын ачып, нидер эзләгән булды, анда — чиста кәгазь битләре өстендә — тышлыгы таушалган калын китаптан гайре берни дә юк иде.

Фаил үзе белән гел китап йөртте, мәжлесләр ул теләгәнчә бармаса, партжыелышларда бәхәс купмаса, докладчыларның чыгышы сыегайса — ул ачу китереп китап укый башлый иде.

Остазымның исән чагы белән иң соңгы тапкыр сөйләшүем булган икән: «Мин хәзер буфетчыны такси белән кайтарып куям. Әйдә, Фаил, юл уңае синең өй аркылы китәрбез. Кайтасыңмы?»

Ул сәгатенә карап куйды.

«Өйгәме?! Бу вакытта кайтып керергә әллә син мине...»

«Бәлки, саубуллашу йөзеннән берәр рюмка?..»

«Юк. Иртәдән бирле бүген баш сызлый. Өстәл артында да грамм капмадым. Ну, кыен димәсәң, берәр сухойны алып чык».

Мин исән калган хәзинәдән бер шешә ак шәраб алып чыккач, ул аны тиз генә кәгазьләре белән каплап, дипломатын япты һәм, бу Шәле малае мине артык үгетләп, өйгә кайтарып куймасын тагы дигәндәй, ашыгып кына араны өзде дә бильярд шарлары чәкәләшкән якка кереп китте.

«Пока!» дигәне «берничә космик елга» булган икән...

Кеше үкенечле үлемгә дучар булса, аның соңгы сүзләреннән фәлсәфи мәгънә эзли башлыйсың. Күңеле сизенгән, тәкъдирен алдан күргән, дисең.

Идарә утырышына ашыгып чыгып киткәндә (ул гомумән әкрен йөри белми иде), Фаил «Чаян» журналындагы хезмәттәше-бүлмәдәше В.Луценконың эш өстәленә болай дип язып калдырган: «Вадим Иванович! Меня не ждите, я ушёл на несколько космических лет!»

Хәзерге акылым булсамы?!

Кичке сәгать жидедән соң Фаил кебек дусларны, аяк-кулларын бәйләп, хатыны янына илтеп куяр идем... Өенә кайтырга ашыкмаган күпме ир әрәм булды инде бу доньяда!..

***1982 ел, 6 октябрь.***

Мин ул вакытта Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында «уполномоченный» идем. Язучылар аппаратында эшләүчеләргә эш сәгатен уникедән башларга рөхсәт булса да, бу ташлама безгә кагылмады, чөнки әдәбиятны халыкка житкерү авыл житәкчеләре белән килешү нигезендә эшләнә, ә авыл кешеләрен, район житәкчеләрен кабинетларында туры китерү өчен, телефонга иртәнге жидедән ябышырга кирәк иде.

Килдек. Кичәге идарә утырышын искә алдык, СССР билетына тәкъдим ителгән алты яшь язучыга дусларча бәя биреп, буфетта үткән мәҗлесне сагынып утырабыз...

Бактын исә, нәкъ шушы вакытта язучыбыз үлем ачысы кичереп яткан икән...

Фаилнен фатирына Бауман районы айныткычыннан сары чәчле, озын буйлы, шәрә погонлы бер егет килеп керә. Эльмира ханым коелып төшә.

«Бер дә борчылмагыз, сезнен ирегез бездә...» — ди ул, русчалатып һәм чынында ниләр булганын сиздермәскә тырышып.

Фаилнен кулы алтын, зиһене уяу, фикере асыл. Ул туктаусыз эштә, көне-төне яза, хикәяләре матбугатта өзлексез басыла килә, конкурсларда гел җинүче. Гонорар шәп керә. Акчага интекмәгәч, дус-ишләре бихисап. Дусларыннан бигрәк «ишләре» күбрәк. Шуңа күрә дә иренең өйгә кайтмый калуы Эльмира ханым өчен инде яналык түгел иде.

Ләкин...

Язучы хатыны дигән мәртәбәле, әмма аеруча җаваплы, үтә сизгер һәм тынгысыз профессия бар. Язучы хатыны ирне мәктәп баласын карагандай көйли, пөхтәли, дәвалый, унышлары өчен сөенә, тәнкыйтьләүләре өчен көенә. Кыскасы, анын иҗатында яши. Ул язучынын иҗат рухы итеп балаларын үстерә.

Эльмира ханым нәкъ менә 5 октябрь кичендә сөекле ире Фаилне ниндидер фаҗига көткәнен сизеп бәргәләнә, ике бәләкәй кызынын йокысын саклап, төне буе ут йотып чыга, «дерт» иткән тавышка да ишеккә йөгерә. Билгесезлек вакыты үтсен, тизрәк тан атсын дип шигырь яза. Шагыйрь белән яшәп, шагыйрә булмам димә...

*Безнең күңел нигә моңлы икән,*
*Безнең күңел ничә кыллы икән?*
*Онытыласы иде тын калып.*
*Гарасатка кереп югалмыйча,*
*Гөнаһларга гына уралмыйча,*
*Бәхет йөрсә икән юл ярып.*

Эльмира Шәрифуллина («Безнең күңел»).

Гомердә булмаганны, коммунист башы белән, сәрхушләр кунакханәсенә эләккән! Кайтып күренергә оялып йөри торгандыр...

Ләкин күнел сызлана, бәргәләнә һаман.

Кичке сигезләр тирәсендә, авырулар янына кертү сәгатьләре тәмамлангач кына, Фаил фатирына тагын борчулы хәбәр өстәлә: «Ирегезне 15нче хастаханәгә алып киттеләр. Хәле уртачадан әйбәт!..»

Язучылар оешмасында атнанын соңгы эш көне тыныч кына үтеп китә. Фаил Шәфигуллин фаҗигасе турында беркем, бернәрсә белми кала. Ыгы-зыгы, күз яшьләре, төрле имеш-мимешләр икенче көнне генә башлана.

Үләр алдыннан Фаил берничә исем атаган. Әллә чынлап, әллә махсус, палатадагылар ул исемнәрне искә төшерә алмый: «Татар исемнәре иде, отып булмады, ләкин Резидә, Раушания, Эльмира да, Зөлфәт тә түгел», — дигәннәр. Айныткычта ул вәхшәтле төнне кизү торган шәфкать туташы да: «Минем нәни кызчыгымны исән-имин үстерәсем бар, тизрәк өемнән чыгып китегез», — дип елый-елый ялвара. Күрәсен, айныткыч хезмәткәрләре шаһитларны алдан ук «эшкәртеп» өлгергән инде... Сонрак Эльмира ханымнын үзенә дә ачыктан-ачык янаулар житкерелә: «Туктат эзләнүенне, юкса арестуем!» — диләр.

***1982 ел, 11 октябрь.***

Гөнаһ шомлыгына күрәдер, 7 октябрь көнне мин иртән иртүк Әгерҗе аша үтүче беренче поезд белән хатынымнын туган авылына киткән идем. Язучы исеме алуым белән горурланып кайтам, имеш. Килсәм — Матбугат йорты ишегендә Фаилнен кара кысалы фоторәсеме элeнеп тора. Ну, минәйтәм, шушы егетнен шуткылары!.. Якынрак килеп укысам «...фаҗигале төстә вафат булды...» диелгән. Ул елларда «һәлак булды» дип язарга ярамый иде.

Ары сугылдым, бире сугылдым, бу явыз хәбәргә ышанасы килми генә бит. Ләкин язмыш ялган сөйли белми — кемнән генә сорасаң да, «кыйнап үтергәннәр», диләр.

***Мирсәй Әмир:***
*Ничә еллар инде менә, әдәби эшчәнлегебезгә йомгак ясауга багышланган чыгышларда булсын, мәкаләләрдә булсын, без һаман, юмор-сатира жанры артта калып килә, дияргә мәҗбүр идек. Күрәбез, бу катлаулы, әһәмиятле жанрны торгынлыктан чыгару юлында Фаил Шәфигуллин бик зур эш башкара. Чын мәгънәсендә юморист язучы!*

*1979 ел.*

***Фәнис Яруллин:***
*Бүген Фаилне күмәләр. Нурсөя шунда китте. Фаилнең үлгәненә гел ышанасы килми... Фаилне җәлләүдән Нурсөя дә ике-өч көн инде аңгыраеп йөри. «Бер кешенең дә болай җәл булганы юк иде», — ди. Әйе, шәп егет иде. Көн саен диярлек телефоннан сөйләшеп тора идек. «Чаян»ны Фаилдән башка күз алдына да китереп булмый. «Юморист №1» дип йөртә идем мин аны. Җибәргән әйберләрне икенче көнне үк укып чыгып, фикерен әйтә иде. Ул «Чаян»да эшли башлагач, мин дә ныклап юморга тотындым...*

*1982 ел.*

***Рабит Батулла:***
*...Фаил Шәфигуллин кебек саф әхлак иясе, пакь күңелле язучыбыз үз үлеме белән үлмәде. Кинәт китте Фаил. Үзе елмаймыйча гына кешеләргә шатлык тарата белүче, назик итеп шаярта белүче, күңеле юмарт, иҗаты юмарт, сүгенә дә белми торган изге бер шәхеснең җанын кыйдылар. Ни гаҗәп: әҗәл гаугасыз, тыйнак, саф күңеллеләргә аеруча игътибарлы түгелме?*

*1999 ел.*

Инде кичә үк, якшәмбе көнне күмгәннәр булып чыкты. Мин аның гүренә бер уч туфрак та сибә алмадым. Аның «берничә космик елы» — Яңа Бистәдә. Тукайдан соң киткән олы шәхесләребезнен Даими йорты менә шушы зиратта — бу урын татар зыялыларының фаҗигале антологиясе кебек. Татар эстрада юморының Тукае — Яшел Үзән районы, Карашәм авылы егете Фаил Шәфигуллин — шул антологиянең бер сәхифәсе. Язучы кешенең гамен язмаучы кеше аңламас... Хөкүмәт карары белән генә урын алып була торган әлеге каберстанда Тукайлар-Фаилләрнең нигезе кара-кызыл гранитлы, ак мәрмәр һәйкәлле «яңа байлар» күләгәсендә хәзер. Базар реформаларының алыпсатар тукайлары күбрәк икән...

Шау чәчәкле май аенда туган Фаил 43 яшендә шыксыз, салкын, юеш октябрь куенына инде.

Үлгәннәрнең арбасы исәннәр кулына кала. Аның ике кечкенә кызы — 13 яшьлек Раушания белән 4 яшьлек Резидә; жиде ячыйны куып җибәрерлек багалмадай хатыны һәм без — әдәбиятта Фаилнең дингезче шинеленә сыенып үскән кәрлә пәһлеваннар, ятим калдык.

Өзлексез сорау алулар башланды.

Фаилне гомер буе белгән, аны соңгы көннең соңгы сәгатенәчә күргән язучылар үз версияләрен алга сөрде. Эчке эшләр министрлыгы үз версиясен, тикшерүчеләрен һәм үз егетләрен яклады. Дөреслек ике арада юкка чыкты. Ә дөреслек югалган җирдә халык яңа төрле дөреслекне үзе уйлап чыгара башлый.

Россия империясе Пушкинны Дантес кулы белән үтерде дигән табу балалар язучысы, шагыйрь һәм юморист Фаил Шәфигуллинга кагылмый. Фаил хөкүмәт белән тату яшәде. «Чаян» журналында эшләсә дә, фельетоннар язмады, гел хикәяләр генә бастырды, башкалар белән әчелешле булмады. Ул анда татар әдәбияты һәм тәрҗемә бүлеген житәкләде. Эстрада өчен язган әсәрләре көнкүреш юморына кагыла, сарказм алымнарын ир белән хатын, гаилә-мәхәббәт орбитасында гына куллана иде. Югары урыннарда утырганнарга эзоп теле белән кинаяләп, бармак төртеп күрсәтмәде. Кыскасы, фаҗиганең бу өлкәдә версияләре юк.

***1982 ел, 16 ноябрь.***

*Мәскәү.*

*«Литературная газета» редакциясенә.*

*(Хат оригинал телендә бирелә).*

*Уважаемая редакция!*

*6 октября 1982 года при неизвестных обстоятельствах был убит член Союза писателей СССР, заведующий отделом республиканского сатирического журнала «Чаян», член КПСС с 1969 года, писатель-сатирик Шафигуллин Фаил Хафизович, 1939 года рождения.*

*Излагаем некоторые подробности, касающиеся убийства Шафигуллина Ф.Х.*

*5 октября 1982 года, где-то в 20-21 часов вечера на возвращавшегося домой вероятно напали неизвестные лица, избили его, захватили «дипломат» и исчезли. На месте происшествия потерпевший лежал до утра 6 октября. Около 5 часов утра по звонку неизвестной женщины подъехала спецмедслужба и Шафигуллина увезли в медвытрезвитель (?!) Бауманского РОВД г.Казани. Избитый до смерти, раненный в голову, со сломанными рёбрами Шафигуллин находился в медвытрезвителе до 15 часов дня и ему никакой медицинской помощи оказано не было. Затем его отвезли в городскую больницу №15, где он вскоре скончался.*

*Материалы для расследования были переданы в Бауманский РОВД г.Казани, в чьём распоряжении находится и вышеуказанный медвытрезвитель. Далее материалы переданы в прокуратуру данного района, следователю Фатыхову Р.Р.*

*Прошло уже более 40 дней после гибели нашего товарища, а виновные до сих пор остаются безнаказанными.*

*Я, молодой прозаик Каримов Камиль Адгамович, по праву ученика потерпевшего, обращаюсь к вам с убедительной просьбой направить в г.Казань специального корреспондента для изучения фактов трагической смерти писателя Шафигуллина Ф.Х.*

*Возникает ряд вопросов: почему т.Шафигуллин, избитый с вечера, лежал на мостовой до утра и никем это не замечено? Почему его, раненного, увезли в медвытрезвитель, а не в больницу, где своевременная помощь, возможно, спасла бы ему жизнь? Почему так упорно затягивается расследование? Почему притихла общественность? Ответить на эти вопросы сможете только вы — уважаемая редакция!»*

***Нурихан Фәттах:***
*Безнең өчен ул зур эшләр эшләп калдырды. Үлгәннәр гадәттә тиз онытыла. Ләкин Фаил Шәфигуллин онытылмаска тиеш. Аны онытмау өчен, беренче чиратта, әлбәттә, ул язган әсәрләрнең тулы җыентыгын чыгарырга кирәк. Вакытсыз арабыздан киткән каләмдәшебез иҗаты игътибар һәм кадер-хөрмәткә тулысынча лаек.*
*1984 ел.*

***Зөлфәт:***
*Беркем күрми, беркем ишетми торган рухи сукырлык, рухи саңгыраулык елларына туры килде Фаилнең иҗаты. /.../*
*Аның иҗаты хакында уйланганда, ирексездән, В.Шукшин, Ф.Искәндәр кебек талантларның исемнәре хәтергә килә. Фаил язган каурый да шул ук каз канатыннан лабаса. Фаил Шәфигуллин да — үзгәртеп кору чорын әзерләшкән, якынайтышкан язучыларның берсе.*
*1989 ел.*

***Равил Кукушкин (Рахмани):***
*Җыеп әйткәндә, бу күптөрле, күпкырлы юмористик һәм сатирик образлар Ф.Шәфигуллинның күңел өлкәсендәге бик сирәк очрый торган табигый таланты, зур художниклык көче турында сөйли. Г.Тукай һәм Ф.Әмирханнан соң татар әдәбиятында мондый көлдерү куәтенә ия икенче бер юморист язучы булганын без хәтерләмибез.*
*1985 ел.*

* * *

Мәхәббәт турында күпләп язган авторлар хакында төрле эротик легендалар йөри, дөресрәге, ул легендаларны шагыйранә затлар үзләре уйлап чыгара.

Исән калган егетләр аркылы Фаилнең гаиләдән тыш элемтәләрен эзләү башланды. Язучы халкы талантлырак булган саен, күбрәк типтерә дигән төшенчәне алга сөрү иде бу. Типтерә — димәк, сөяркәләре бар, ә сөяркәләр булган җирдә җәнҗал чыгара торган ирләр йөри. Бәлки, алар Фаилне сагалап йөргәннәрдер дә... Ләкин бу версия өч кенә көн яшәде... Чөнки Фаил өзелеп яратырдай кызлар дөньяда икәү генә: олысы — Раушания һәм кечесе — Резидә. Кыз үстергән әти кеше читкә китә алмый. Кыз бала әти кешене әнисеннән дә артыграк ярата. Мин моны бүген үзем дә беләм инде. Әтиләрнең жаны — кыз балада! Кыз бала — гаилә ныклыгы. Аерылышучылар арасында ир бала үстерүчеләр күбрәк. Ә Фаилнең берьюлы ике кызы үсә — ике катлы тышау.

1976 еллар иде. Сүз ара сүз чыгып, ул миннән берзаман сораштырып алды.

«Өеңдә иминлекме?»

«Аерылышырга туры килер, ахрысы...» — дидем мин, аның төпле киңәшен ишетергә теләгәндәй.

«Дуракланма! Язучы гел ирек турында хыялланып яшәсә дә, өен ташлап китә алмый ул. Кодрәтеннән килсә, бөтен шагыйрьләр, драматурглар, галимнәр, артистлар — барысы да аерылышып бетәр иде. Йөрәге җитми иҗат кешесенең...»

«Минем йөрәк таза!»

«Белмим инде. Син башка материалдан ясалган булсаң гына».

«Бер кузгалгач, азакка сузмыйча араны өзәргә инде ул...»

«Ә бәлки, ир бала үстергән кешегә җиңелрәктер дә?!»

Әлеге сөйләшүдән соң мин шуны гына аңладым: акыллы кеше бәхетле була алмый икән ул...

Төрле гайбәтләрне дә версия итеп була, ләкин ул сүзләрне «дело»га теркәп булмый. Ирләрнең «бер-ике генә сәгатькә буйдак булып карыйсы иде», дип хыялланырга хакы бар. Ләкин ул сагышлы кичләрдә, фаҗига китерердәй төннәрдә гаилә ышыгында булырга омтыла. Ирләрдә генә түгел, «азатлык» турындагы хыял хатыннарда көчлерәк тә була әле ул... Табыгыз сез мина бәхетле дигән берәр парлы шагыйрәне?!

Иң кыска һәм иң туры юлдан өенә кайтып барганда, Фаилнең язмышына кем аркылы төшкән соң? Бауман районы айныткычының гаебен аклар өчен, куштан сәрхушләр өр-яңа версия уйлап чыгара.

Шундук 1972 елгы бер вакыйганы да искә төшерәләр, Казанның Красное Знамя урамында яшәгән чакта кемнәрдер Фаилне тукталышта посып көтеп торган һәм йодрыкка төрелгән кастет белән сугып, аның башын ярып качканнар. Төнге сәгать унберләрдә Фаил аңына килә — сәгате исән, акчасы исән, портфеле таланмаган... Өч көннән соң ул эшкә чыга. Милициягә бу турыда хәбәр итми, кыйнаучыны эзләтми. Фаилнең әле «Идел» альманахында җаваплы мөхәррир булып утырган чагы. Дүрт катлы Матбугат йортының һәр коридорында очраткан кеше: «Нишләдең, Фаил, нәрсә булды?» — дип тенкәсенә тия башлагач, ул үзенчә юмор белән җавап бирә:

«Төнге унберләрдә автобус ишеген фатир ишеге белән бутаганмын...»

Пәһлевандай ир – матрос Фаил мине малай-шалайлар дөмбәсләп китте дип зарланып тора аламы?!.

Мин Фаилнең гаилә коллизияләрен өйрәнүне максат итеп куймадым. Берәүнең дә гамь казаны буш түгелдер... Ун ел буе аралашып, мин — яшь язучы, остазымның гаилә хәлләрен сорашып утырырга җөрьәт итә алмадым. Остаз үз шәкертенең бөтен тормышын яттан беләдер, яшь язучы өчен остазның шәхси тормышы — тыелган зона кебегрәк, аны белмәсәң дә ярый.

«Гаилә драмасы» дигән версия бик тиз коелып төште.

***1982 ел, 5 октябрь.***

Ак кыршаулы кара дипломатка салынган болгарский шәрабны Язучылар берлегенең бильярд өстәленә китереп куя Фаил, тамагы кипкән ирләрне сугара...

Бильярд шарлары тәгәрәшеп арыгач, кичке тугызлар тирәсендә язучылар гөр килеп таралыша. Фаил идарә утырышына дип килгән Чаллы, Әлмәт, Лениногорск язучылары-

на ияре, дөресрәге, алар тукталган «Совет» кунакханәсе анын кайту юлында... Кичке унбердән соң Фаилне күргән кеше юк. Иртәнге бишләрдә урам себерүче апа «аунап» яткан ир кешене күреп, милициягә шалтырата. Башы ярылганчы, кабыргалары сынганчы кыйналган дустыбызны айныткычка алып китәләр. Тикшерүләр эшенә күләгә салырдай төп факт шушы. Кыйналган, яралы, авыру кешеләр җирдә ятса да, милиция хезмәткәрләренең аларны айныткычка илтеп ябарга закон алдында хокуклары юк, кичекмәстән медицина ярдәме күрсәтелергә тиеш ләбаса! Ә Фаилне алып киткәннәр, һәм безнең күңелдә шик калды: «Димәк, ул айныткычка эләккәндә сау-таза булган. Димәк, аны милиция хезмәткәрләре «тәрбияләгән»... Ни өченме? Барыбызга да мәгълүм, погонлы агай-энеләр үз адресларына төрттереп шаяртканны өнәп бетермиләр. Янына «луноход» килеп туктагач һәм фуражкалы егетләр таныклык сорап юморист язучыга бәйләнә башлагач... — Фаил, тумышыннан «Чаян» рухлы Шәфигуллин, дәшми калгандыр дисезме?!. Менә шушы соңгы юморы хәл иткәндер анын язмышын. Ә инде кулындагы дипломатны һәм кесәсендәге «Чаян» журналы таныклыгын юри күрше ишегалдына ыргыталар да, үзе белән берние дә юк иде, диләр, кем икәнен белмәдек, шуна күрә артыграк дөмбәсләп ташлаганбыз дип аңлатма да язып куярлар...

Фаилнең шаяртуларын кабул итәр өчен, аны бик якыннан белергә кирәк. Кул биреп күрешкәч, син аннан: «Нишләп кулың бик салкын?» — дип сорасаң, ул сиңа: «Әле генә кабердән чыктым!» — дип котыңны алыр. Махмырдан интеккән дустын очратса: «Бөтенләй беткәнсең ич син, бар, тизрәк өенә кайтып үл!» — дияр. Яшел Үзән поездыннан төшкән чакта туры китерсәң, туган авылыннан күчтәнәчләр күтәреп кайтып килгән Фаил тотлыгып та тормас: «Менә, айныткычтан чыгып киләм әле», — дип сорау бирүчене сөендерер иде...

***1975 ел, 25 май.***

Фаилнең шаянлыгы димәктән, халыкара «Волга» лагеренда иҗат яшьләренең бер атналык семинарында «ял итәбез». Бер бунгалода без алты кеше: Фаил, Хәлим Җәләлов, Зөлфәт, Ризван Хәмид, Фасил Әхмәтов һәм мин. Безне бер түбә астына Фаил үзе җыйды... Шулай иртәнге алтыда Идел буендагы тансык йокыны бүлеп, Фаил минем аяк очыма килеп утырды:

«Син кайсы авылдан әле?» — ди бу тыныч кына.

Берәр этлек уйлап чыгарганын сизенәм, шуңа күрә дә: «Шәледән!» — дип рас кына җавап бирергә ашыкмыйм.

«Үзең дә беләсең ич!» — минәйтәм.

«Юк, чынлап та, әйт әле, кайсы авылдан соң син?»

«Кыланма инде, Фаил, Шәледән икәнемне миннән дә шәбрәк беләсең бит!»

«Ә, Шәледән?!! Чынлап мәллә, Шәленең үзеннәнме?» — ди бу, беренче тапкыр ишеткәндәй шаккатып һәм бунгалодан сикереп төште дә:

«Җәмәгать! Шәле кешесе бар! Коткарыгыз, Шәле кешесе бар! Шәле кешесе!» — дип, бөтен лагерь буйлап йөгерә башлады. Үзе кроссовкасын, трико чалбарын, футболкасын кигән.

Мин куркуымнан ап-ак булып торып утырдым. Бунгалодагы абзыйлар дәррәү күтәрелеп, көлешә-көлешә җиргә коелгач кына, иртәнге зарядка вакыты җиткәнен абайлап алдым.

«Волга» лагере дип аталган истәлекләр ярында без Фаилнең бер атна элек кенә үтеп киткән туган көнен дә билгеләп өлгердек. Ана 36 яшь тулган иде. Прозаиклар өчен бөтенләй үсмер чак инде бу. Иҗат кешесенең гомере башка үлчәмнәр белән үлчәнә, ул хәтта үлгәннән соң да үсә...

«Волга» лагере дүрт ел рәттән иҗат яшьләренең оазисына әверелеп алды. Исемсез бармакларның алтын богавын онытып, гаилә нужаларыннан качып, эш арбаларыннан бер атнага булса да туарылып торасың, шагыйрь ирләрен тикшерергә дип эзләп килгән хатыннарны кораллы сакчылар капкадан ук кертми.

Көне буе лекция тыңлыйбыз. Кичен яна әсәрләр турниры оештырыла. Ә төнлә учак ягып, таң атканын көтәбез. Ашау-эчү комсомолның өлкә комитеты хисабына... Без ул чакта егерме биш яшькә яшьрәк. Безнең бәхеткә сөенеп, Илдар Юзеев гармун уйный; Гәргәри (Гәрәй Рәхим) җырлый; Аяз Гыйләҗев радио һәм телевидение

хәбәрчеләренә туктаусыз интервью бирә; Батулла юан наратның симез ботагына кунып, сандугач булып сайрый; Рөстәм Мингалимов, күрше бунгалода эт яши дип зарлана-зарлана, дәһшәтле учак эченнән кичәге бәрәңгесен эзли; Равил Фәйзуллин, тарихка кереп калыр өчен, картечкәгә төшерүчеләрне аулап йөри; Туфан Миңнуллин учакны сүндерерлек акустик тавышы белән Гөргөри кияүләреннән көлә; Роберт Миңнуллин каеннар арасыннан үзенең тәүге китабына исем эзли; Разил Вәлиев кичке аштан калган алмасын бишкә бүлә; Марсель Галиев, Чаллыдан килгән шагыйрьләрне мактый-мактый, «кучтәнәчле» сумкаларын бушаттыра; Мансур Вәлиев Иделнең сай ярыннан котылыр өчен, ятим бүрәнәне интектерә...

Мөхәммәт Мәһдиев белән Фаил Шафигуллин ярыша-ярыша көлкеле хикәя укыйлар. Иң әүвәл Мәһдиев сөйли, аннан соң гына — Фаил. Фаил бик күп очракларда ярышларга беренче булып ыргылмады... Мәһдиев «тишек ләгәнле» роман өзеге укыганда, халык башын артка ташлап көлә... Бу вакытта Фаил, сулыш алырга да онытып, хикәя сайлый. Ул сәхнәләрдәге җинелүне авыр кичерә. Аңа Мәһдиевтән дә катырак итеп кул чабарга тиешләр, һәм шулай була да...

Кайсы гына газета-журналларда конкурс игълан итсәләр дә, Фаилнең кыска хикәяләре җинеп чыга иде!..

Эстрада кануннарын бөтен нечкәлекләре белән тоя торган комарлы юморист иде ул. Сәхнәләрдә, язучыларның Тукай исемендәге клубында гына түгел. Хәтта җиде метрлы «Тынгысыз каләм» дивар газетасын да ул чын сәхнә әсәре итеп чыгара белә иде.

Комарлы дигәннән, Язучылар берлегенең пропаганда бүлеге аша Актаныш районы игенчеләре белән очрашулар ясап йөргәндә, Фаил «хохма» уйлап чыгара. Төркемдә трибун шагыйрь Зөлфәт тә бар, тамашачылар аның шигырьләренә хәйран мавыгып кул чаба торган була. Ләкин китапханәләр өчен язылган иҗат белән сәхнә әсәрләре арасындагы аерманы бик яхшы сизгән Фаилнең алкышларны Зөлфәт белән бүлешәсе килми... Бер кибеткә кергәч, Фаил өч шешә «тройной» хушбуе ала. Нәрсәгә ул шулхәтле одеколон, дип аптырый Зөлфәт. Чынлап та, эчәсең килсә, әнә — аракының иркен чагы...

«Син, энем, бернәрсә белмисең икән, «тройной» одеколон тавышны ныгыта ул, чыгыш ясаганда җинелрәк булачак!» — ди Фаил.

Торналы кое янына килеп, тешенне сындырырлык су кушкач, ул мөлдерәмә тулы стаканны Зөлфәткә суза: «Мә, энем, эчеп куй!»

Зөлфәт бер стаканны каплап куйгач, Фаил калган ике «тройной»ны портфеленә салып, кое яныннан китеп бара.

«Ә син нишләп эчмисең, Фаил?» — дип аптырый Зөлфәт.

«Мин дурак түгел ич. Одеколон тавышны яндыра ул!» — ди Фаил җиңүчеләр тантанасы белән.

Чынлап та, кичен клубта халык алдына чыгып баскач, Зөлфәт гыжылдап кала. Бөтен алкышлар Фаилгә эләгә.

Дуслары аның шаяртуын аңлый, куана һәм күтәреп ала иде. Димәк, 1982 елның 5 октябрь төнендә Фаил янында дуслары булмаган...

Шунысы сәер: Фаилне яхшы белгән, аның белән күбрәк аралашкан дусларын, танышларын допросларга чакырырга бик атлыгып тормадылар. Мәгъсум Хуҗин белән мин, әйтик, тикшерүче янына үзебез ялынып кердек. Ни өченме? Чөнки безнең версия башкалар теленнән барып җиткән иде инде аларга: «Фаилнең үлеменә милиция хезмәткәрләре үзләре гаепле!» — дип тукыдык без. «Өч көн эчендә айныткыч хезмәткәрләрен алыштырып куюлары һәм Фаил җан салган 15нче хастаханәнең алтынчы палатасындагы күрше авыруларның, кинәт телсез калып: «Белмәдек, күрмәдек, ишетмәдек», — дип утырулары безнең шикләрне көчәйтте генә.

***1982 ел, 3 ноябрь.***

*Прокурору ТАССР*
*тов. Узбекову В.С.*
*копия: прокурору РСФСР*
*тов. Кварцову Б.И.*

*Несмотря на то, что прошёл уже целый месяц, преступники не обнаружены. Как стало известно, материалы по факту убийства без конца передаются из рук*

*в руки. Даже дело дошло до такого абсурда, что этот материал вёлся Бауманским райотделом милиции г.Казани, хотя отдельные работники спецмедвытрезвителя данного РОВД были замешаны в деле непосредственно.*

*В настоящее время расследование материала поручено молодому, неопытному следователю прокуратуры Бауманского района и ведётся очень пассивно.*

*Мы, писатели ТАССР, убедительно просим, чтобы материалы по убийству писателя Шафигуллина Ф.Х. были переданы в прокуратуру ТАССР для высококвалифицированного расследования одним из старших следователей.*

*Ответ просим адресовать жене потерпевшего.*

*Подписи: Члены Союза писателей СССР —*

*1. (К.А.Каримов), 2. (З.Г.Маликов), 3. (М.С.Шабаев).*

Күнелдә тагын бер үкенеч калды. Ул вакытта да язучыларыбыз арасында дәүләт эшлеклеләре бар иде. Әлеге гариза астына депутат имзасы да куелса, җинаятьчеләрне эзләү житдирәк төс аласы иде. «Жалобага сез генә кул куегыз, югары органнар сораса, мин үз фикеремне әйтермен», — дип юатты безне Гариф Ахунов. Мин аларны аңлыйм. Коммунист Фаилнең фажигасен ачып салыр өчен, ул көннәрдә милиция, прокуратура һәм КПСС өлкә комитеты адресына ямьсез сүзләр әйтергә һәм билгеле бер дәрәҗәдә үз язмышыңны куркыныч астына куярга кирәк иде. Менә шуна күрә дә кырыс жалобаларга кул куярга кирәк булганда, Фаилнең йөзләгән дуслары арасыннан без өч кенә кеше торып калдык.

Ә теге — «Литературная газета»га җибәрелгән хат СССР прокуратурасына киткән. СССР прокуратурасы аны РСФСР органнарына, ә инде РСФСР, үз чиратында, ТАССР прокуратурасына тапшырды. Шулай итеп, бөтен көчәнүләребез иске эзгә кайтып төште. Өч баскыч — өч инстанциядән килгән җавап өч игезәк кебек иде: «Товарищ Каримов К.А.! Ваше письмо поставлено на особый контроль...»

Шикаятьләрне яңартып торуның нәтиҗәсе шул булды: мәрхүмнең гәүдәсен гүреннән чыгарып, кабат экспертиза ясадылар һәм баш сөягенең ватылуы — икенче каттан баш белән асфальтка төшүгә тиң дигән карарга килделәр. Шуннан соң инде менә утыз ел узды, әле һаман бу фажига «контрольдә тора».

Без бүген В.Листьев, Д.Холодов, Г.Старовойтоваларга корал күтәргән киллерларның тотылмаячагын базар хаосына, Мәскәү чиновникларының җинаятьчел структуралар белән үрелгәненә сылтыйбыз. Ә Фаил язмышы — татар әдәбиятының фажигасе. Ачылмаган җинаятьләр ил намусында кала.

Югалган көмеш алтынга әверелә...

Фаил Шәфигуллин исән чагында да алтын иде!..

***1999 ел, 27 апрель.***

Фаил Шәфигуллинның туган көненә багышланган әлеге язмада мин бик күп тапкыр аның исемен телгә алдым. Әтисенең үлүе турындагы хәбәрне ишетеп, берара теленнән язган һәм үскәч, һичшиксез, юрист булам, үтерүчене үзем табам, дигән кызы Раушаниянең «Идел» журналында бастырган аналитик язмасы, гаилә альбомыннан алынган фотолары белән таныштым, М.Хужин белән Зөлфәтне тыңлап, истәлекләрне кабат яңарттым, документлар өйрәндем. Инде 1999 елның 27 апреле, кич, алты тулырга ун минут булыр, Фаил турында җөмләләремне түгәрәкләп маташам. Кинәт, «Чаян»ның мин утырган бүлмәсенә Фаил Шәфигуллин үзе килеп керде! Ай буе гел аның турында гына уйлап йөргәч, күземә күренә бугай инде дип бисмиллаларымны укыштыра башладым. Йа Хода, шулкадәр дә охшаш кешеләр булыр икән! Дингезчегә хас киң җилкәле, уртача буйлы, кылыч борын, тирән күзле, маңгай чәче сул якка авыштырып таралган. Тавышы, күз карашлары, хәтта йөреше дә Фаилнең үзеннән дә фаилрәк...

«Мин Чакмагыш районыннан, Алмаз исемле булам. Казанда укыйм, өченче курста. «Шәһри Казан»да практика үтәм. Шигырьләр, хикәяләр язам», — диде әлеге егерме яшьләрдәге егет.

Һәм шулвакыт Фаилнең: «Мин берничә космик елдан соң әйләнеп кайтырмын!» — дигән соңгы җөмләсе исемә төште.

**Камил КӘРИМОВ**

## Фаил Шәфигуллин

### Сафура, Бәкер һәм трактор

Фронтка китүчеләр урман борылышында күздән югалдылар. Алар киткән якта тузан болыты гына бөтерелеп калды. Озатучы карчык-корчык, хатын-кыз, яулык читләре белән күзләрен сөртә-сөртә, моңаеп калган урамнарга, тыкрыкларга сибелде. Шул чагында авыл читендәге зәңгәр капкалы өйдән яшь кенә бер ир белән яшь кенә бер хатын гөрләшеп чыкты.

— Бәкер дим, соңга каласың, чукынчык, йөгер тизрәк...

— Ашыктырма. Сафура... Уйнарга китмим, фронтка китәм. Ишетсен колагың, карап кына йөрт тракторны.

— Ишеттем ләбаса. Йөгер тизрәк, поездга сонга каласың, Бәкер!..

— Калмыйм. Алай-болай ватыла-нитә калса, карбюратор белән магнетога тыгылма. Аларына синең баш җитмәс. Бригадирга күрсәтерсең.

— Бар инде, бар... Берәр җиргә китә башласаң, «карбюратор», «магнето» дип тенкәмә тиясең чистый...

— Теленә салынма, җен хатыны. Алай-болай булса, кайткач кара аны...

— Курыктым ди бик! Котым очты...

Бәкер, кулындагы капчыгын култыгына кыстырып, авыл башына кадәр йөгерде дә, артына борылып, хатынына йодрык күрсәтте:

— Подшипникларны эретмә!..

Китүчеләр китеп атна-ун көн узды микән, юк микән — авыл белән фронт арасында өчпочмаклы хатлар йөри башлады. Авыл кешеләре фронттан килгән хатлар аша Гайфи Исхагының медаль алуын, тимерче Маратның кулы яралануын, Вәлиулланың командир булуын, Шәмси Мохтарының хәбәрсез югалуын белделәр. Көннәрдән бер көнне тракторчы Бәкердән дә хат килеп төште.

«Уйлап-уйлап тордым да әле туп янында, Сафура, — дип сәламсез-нисез илаһи уптым башланган һәм шулай ук илаһи уптым тәмамланган иде бу хат, — узган ел мин Хөрмәтша биргән свечаларне Кодрәт басуында калдырганмын, ахры. Әле иртән генә туры наводка белән немецларның унбер танкысын яндырдык. Соңгы танкка ут капкач, кылт итеп исемә төште. Хәтереңдәме, син миңа ашарга китергән идең. Елга буенда учак ягып чәй кайнаттың. Ә мин свечаларне чистартып утырдым. Шунда син сихерче кебек муеныма килеп асылындың. Зәңгәр бәбәкләрең белән күзләремне бораууладың. Свечаларнең кулдан ничек төшеп киткәнен үзем дә сизми калганмын... Бу хатны алгач ук барып эзлә. Ишетсен колагың. Эш вакытында сырпалана торган гадәтеңнән биздерәм әле мин сине, кайткач. Шабаш... Немец тагын кузгала...»

Сафура жиделе лампа яктысында, шәмәхә карандаш кисәген иренендә чылата-чылата, Бәкеренә җавап хатын язып ташлады:

«Кодрәт басуын сөреп бетердек. Свечаларенне таптым, тутыкканнар, бензинга салып куйдым. Әйберне кая очрады, шунда ташлыйсын да аннары кешене гаеплисең. Окопта мылтыгыңны онытып калдыр тагын!.. Ул танкларны яндырмыйча гына плен алып булмый идеме соң?.. Машиналар җитешми... Оекбашлар җибәрәм, катырып бетермә. Аягыңны юып йөр...»

Бәкердән ике елга якын хат килмичә торды. Сафура бу вакыт эчендә ни уйлагандыр, үзе сөйләмәгәч, әйтүе читен. Әмма һич көтмәгәндә, язгы матур көннәрнең берсендә, ана (бу юлы дүрт почмаклы) хат китереп бирделәр. Хатны шактый озын сырлаган иде Бәкер.

«Сагынганга чыдый алмыйча яза икән дип уйлама, җен хатыны, әле берникадәр вакыт чолганышта калып, немецлар белән кети-кети уйнап йөрдек. Үзебезнен якка чыкканда, бер аягым снаряд кыйпылчыгына бәрелде. Госпитальдә ятып чыктым. Соңгы көннәрдә борчу басты. Трактор ни хәлдә? Кичә төшемдә бригадир Хөрмәтшаны күрдем. «Трактор хәтле тракторны хатын-кызга ышанып тапшыралармы соң?! Чәч озын, акыл кыска бит аларның», — ди. Ну, кара аны, Сафура, тракторны алай-болай эшләтсән, кайткач, рәхим-шәфкать көтмә миннән! Рәтле генә йөрт. Ремонтлаганда, карбюратор белән магнетосына бригадирдан башка орынма. Немец Сталинград яныннан шыр җибәреп качты. Оекбашыңны ертылганчы киеп булмады — тегеннән бер немец майорын урлап чыккан идек. Кырда катып үлә башлады да... Киерттек инде шуна, бигайбә. Колшәриф басуы ташлы. Плугарыңны кисәтеп куй, үзең дә авыз әчеп йөрмә...»

Сафура көне-сәгате белән Бәкергә җавап язып җибәрде.

«Сугышуыңны бел! Юк акылың белән кешегә акыл өйрәтеп маташма. «Трактор начар тарта, трактор керосинны күп бетерә», — дип зарлануларың исеңдәме? Карбюратор белән магнетоны көйли белмәгәнсең икән шул, җанкисәгем. Трактор сәгать кебек эшли хәзер. Берьюлы ике сабан тагып йөрим!..»

Бәкер тагын озак кына дәшми торды. Инде аның турында «хәбәрсез югалган икән» дип тә сөйләштергәләделәр. Мондый хәбәрне ишеткәч Сафура: «Югалыр, югалтырсың аны... — дип кулын гына селкеде. — Исегездәме, Чәчкап канюшние яңа башлагач, ут эченнән биш колынны алып чыкканые, ә үзенен бер генә чәч бөртеге дә көймәгәние, чегән арбасыннан төшеп калган нәрсә бит ул, югалтырсың аны!..»

Чыннан да, югалмаган икән Бәкер. Аның соңгы хаты Берлиннан килде.

«Сафура, тракторның тузаннарын сөрткәли тор. Җинелүе турында Гитлердан белешмә яздырып алам да кайтырга чыгам», — дип, өч-дүрт кенә авыз сүз язган иде ул.

Сугыш бетеп, кырык-илле көн узган иде. Сафура, тракторы белән дөбер-шатыр авылны чыгып барганда, чак кына бер солдатны бәреп екмый калды. Селкенми дә, хәерсез. Аякларын аерып юл уртасына баскан да тик авызын ерып тора. Түшендә орден-медальләр ялтырый.

Сафура, тракторын туктатып, кулларын йодрыклап җиргә сикереп төште.

— Нәрсә трактор астына керәсен? Монда кайтып үләргәме?! Әнекәчем!.. Бәкер, син ич, чукынчык!..

— Сафура, җен хатыны!..

— Әбәү, мыек үстереп кайткан булган берәү... Җибәр, чукынчык, билемне өзәсең. Кара, кара, үпкән була, оялмый да.

— Кемнән оялыйм, Сафурам, — дип, як-ягына карап алды Бәкер. Тирә-юньдә берәү дә юк, тик биш-алты адым читтәрәк, ир белән хатынның кавышуына шатлангандай, тигез тавыш белән трактор гына тыкылдап тора иде.

## Бер мәхәббәт тарихы

Элек мин кызлар белән таныша алмыйча иза чигә идем. Аракыны ташлагач, хәл үзгәрде.

Әле беркөннәрдә Фәнзилләр туенда бик озаклап Нәзирәне күзәтеп утырдым. Чәчләрен дә әллә ниләр кыландырып, кырыкка бөтереп бетермәгән, сыра күбеге сыман күпертеп маңгаена гына төшереп куйган. Күзләрен дә башка хатын-кызлар шикелле алан-йолан уйнатмый. Акчасы җитеп бетмәгәнлектән, өч борынга керергә базмаган кыюсыз кеше сыман уңайсызланып кына утыра. Үзе ара-тирә дус кызларына сүз каткалап ала. Башлап җырламый. Әмма җыруга

бик теләп кушыла. Тавышы зур тизлек белән ераклашып барган олаудагы буш шешәләр чылтыравын хәтерләтә.

Туйдан чыкканда, Нәзирәне күздән җуймаска тырыштым. Егете-фәләне, озатучысы, көтеп торучысы юк икән. Багана башларындагы лампалар мөлдерәмә тулы әче бал графиннарына охшаган. Тротуар буендагы чәчәкләрдән тройной одеколон, ликёр һәм дә тагын әллә нинди мин авыз итеп карамаган татлы шәраб исе килә.

Ниһаять, Нәзирәне куып җиттем. Оялып кына сүз башладым:

— Ай-һай, Нәзирә! Син шешә җыючы Гыймраннан да тибешрәк йөрисең! Дәшми. Биек үкчәләре белән асфальтны шакылдатып баруын беләә.

— Гастроном чатына кадәр генә озатыйм әле, Нәзирә?

Шунда Нәзирә авызыннан, шешәдән бөке атылып чыккандай, хәтәр-хәтәр сүзләр барысы берьюлы шартлап чыкты:

— Күрәсем дә килми эчкән кешене, җенем сөйми.

— Гафу ит, Нәзирә, аракыны ташлаганыма ай була бит инде. Әле бүген туй хөрмәтенә генә...

— Сөйләшәсем дә килми, айныгач килерсең.

Нәзирәнең мондый бик үк өметсез булмаган сүзләреннән бөтен җаннарым рәхәтләнеп китте. Махмыр белән бик озак газапланганнан соң, бер стакан саф көмешкә эчеп җибәргәндәй булдым.

Атна буе авызыма бер тамчы хәмер капмый чыдадым да шимбә көнне, киенеп-ясанып, клубка таба юл тоттым. Клуб тирәсе, сыра залы шикелле, халык белән шыгрым тулы. Колмак тәлгәшләренә охшаган муенса таккан Нәзирәне ерактан ук танып алдым.

Елмаеп сәлам бирдем. Алды сәламемне.

Ләкин минем йөзгә күтәрелеп карагач ук, Нәзирәнең яп-якты күзләре ничектер болганчыкланып, Идел суы кушылган вермутка охшап калды.

— Эчкәнсең, — диде ул, яна гына ачылган шампанский кебек чыжылдап.

— Юк, юк, Нәзирә, нәрсә син, атна буе авызыма да алганым юк.

— Борының нигә кызыл?

Мин борынымны учларым белән томаладым һәм аяк очларыма карап:

— Әллә кайчан эчкәннеке бетми, — дип мыгырдандым.

Шулай да Нәзирә акыллы кыз икән — сүзне урманнарга, басуларга, болыннарга борып алып кереп китте. Мин дә сиздерми генә үрелеп, аның кулын кыстым.

Без карт өрәңге төбендәге эскәмиягә килеп утырдык. Кич җиләс, һавада җинелчә генә борыч аракысы исе аңкый.

— Сөйлә инде син дә нәрсә дә булса, югыйсә һаман мин генә сөйлим, — диде Нәзирә, бераз тынып утыргач.

— Бервакытны шулай Ризван, Дамир, мин, бер яртыны алып, кибет артына борылуыбыз булды...

— Башка нәрсә турында сөйлә. Әтү һаман аракы турында сөйлисең...

— Нәрсә сөйлим?

— Эшең турында, уйларың, үзең турында.

— Аппаратчы булып эшләгәнемне үзең дә беләсең бит. Болай кызыклы эш. Аппарат чистартырга атна саен өч йөз грамм спирт бирәләр...

— Әй, сөйләмәсәнә шул спиртың турында. Әнә күрдеңме, Зөһрә йолдыз янына тагын бер нәни йолдыз калыкты.

— Кызык, ике генә йолдызлы коньяк була микән?..

Мин шулай уйлаганмын гына кебек иде. Тик, кызганычка каршы, кычкырып әйткәнемне үзем дә сизмичә калганмын икән.

Нәзирәнең керфекләрендә яшь бөртекләре ялтырап китте.

— Мин синең белән чынлап сөйләшәм, Һәнүс абый, ә син миннән көлеп утырасың, — диде ул һәм инбашларын калтыратып елап җибәрде.

Ми күзәнәкләрен киереп, мин аны юатыр сүзләр эзләдем. Ләкин кирәкле сүзләр табылмады.

Озак кына сөйләшмичә утырдык. Инде Нәзирә дә елаудан туктады. Әкрен генә ниндидер миңа таныш булмаган озын, моңлы көйгә җыр башлады:

Сандугачлар гына кайда сайрый,

Сарман буйларында тирәктә, шул...

Мин тагын, буш шешәләр төяп, ераклашып барган олауны күз алдыма китердем. Өрәнге ботаклары арасыннан сары калай бәке сыман ялтырап торган айга карый-карый байтак кына җырлаганнан соң, ниһаять, Нәзирә башын минем якка борды.

— Ярар, Һәнүс абый, юк өчен үпкәләшмик. Әйдә, хәзер син җырлап кара инде, мин үлеп җыр яратам, — диде.

— Җырлый белмим мин.

— Җырның ертыгы юк, белгәненне җырла. - Нәзирәне кабат үпкәләтәсем килмәде. Аны-моны уйлап тормыйча, үзем яраткан «Алмагачлары» көенә җыру суздым:

Айкап җибәр, чайкап җибәр
Казакларның камчысын шул.
Ал күтәреп, эчеп җибәр,
Калдырмыйча тамчысын.
Ал күтәреп...

Нәзирә капылт кына урыныннан сикереп торды да алагаемга кизәнеп яңак төбенә утыртты. Әйтерсең лә дистәләп шешә берьюлы асфальтка төшеп чәлпәрәмә килде.

Мин, күземне ачарга куркып, оеп утыра бирдем. Таныш аяк тавышлары бөтенләйгә, инде мәңге-мәңге минем янга әйләнеп кайтмаска ераклаша иде.

## Аерылышу

Аерылыштык. Хатын китте. Йокы бүлмәсендә яши. Мин асылынырга бау әзерләп куйдым. Менә әйберләрне бүлешеп бетерәбез дә тәвәккәллим. Суд бүлешкән өчен акча ала, ди. Судсыз гына бүләбез әйберләрне. Хатынга — диван, миңа — карават, хатынга — телевизор, миңа — радиола. Калак-чүкеч — миңа, инә-җеп — хатынга. Чәйнек мәсьәләсендә бәхәс купты. Ни өчен дигәндә, икебезнең дә чәй эчәсе килә. Ә чәйнек бер генә. Кулымнан эш килә минем: анысын да бүлдем. Аркылыга ярып, ямап, бер ягына борын, икенче ягына сап куйдым. Пычакны икегә ярдым. Чүмечне дә. Коридорны бүлдем, кухняны бүлдем. Ванна гына җайсызрак килеп чыкты, бүлгәч, кайнар су краны хатын ягында калды. Суны ваннага плитәдә җылытып китереп салам. Хатын, киресенчә, кухнядан салкын су ташый. Бүлешүнең әле тагын бер четерекле ягын әйтмәгәнмен икән. Хатын минем һәр мероприятиегә аяк чалып килә. Пычакның үткен өлешен үзенә алды. Газ плитәсенең дә ана ике комфоркасы эләкте. Чәйнекнең дә борын ягы хатында. Хәер, чәйнегенә сапны бик хөрт куеп бирдем — озакка чыдамас.

Ниһаять, бүлешеп бетәбез бугай. Түшәмгә алка кагып, бауны хатын күз алдынарак бәйләп куйдым. Кызганмас микән дим, ит турагычны, бәлкем, бөтенләе белән үземә бирерие дим. Юк, бауны күрмәгәнгә салыша. Югыйсә элмәген дә ясап куйдым бит инде. Бүл, ди. Ит турагычны да, борыч тегермәнен дә бүл, ди. Тфү, бөтенләй миһербансызланган. Уйлап-уйлап тордым да туалетны бүләргә керештем. Хатынның җен ачулары чыкты. Нервысына чыдаша алмыйча,

ике чәшкене идәнгә бәреп ватты. Дәшмәдем. Хатын-кыз белән булышканчы, кухня өстәлен бүлим лутчы дип, пычкы кайрарга утырдым.

Шулай игәү елатып маташканда, ишек шыгырдады. Борылып карасам, бусагада шахтадагы малаем Әсфәндияр, анын янында кулына яшь бала күтәргән сары чәчле, борау күзле бер хатын-кыз кәмәше басып тора. Пычкыны ташлап, яннарына бардым. Күрештек. Хатын инде әллә кайчан болар кочагында. Балавыз сыга.

Оныгыбыз туган, имеш. Бик шатландык. Үзләре дә шатландылар.

— И-и, әти, син бигрәк инде, — дигән була малай, — каян ишеттегез безнең монда торырга кайтасын, кухняларны, коридорларны бүлеп куйгансың, — ди. Ванна белән туалетны күргәч, эчен тотып көлде.

— Боларын сүтеп ташларбыз инде, әти, болары уртак булыр, безгә бер бүлмә, ярты кухня житкән, — ди.

Әнфисә килен, түшәмдәге бауга төртеп күрсәтеп, шатланып кычкырып жибәрде:

— Әсфәндиярчик, карале, әнә әткәй Фердинанд бишеген эләргә бау да әзерләп куйган.

Ашап-эчеп, малайлар мунчага киткәч, хатын:

— Савыт-саба ватылса, сөенеч булла, диләр, тәки дөрес икән, — дип, идәннән чәшке ватыкларын жыеп алды.

Мин уйлап-уйлап тордым да кухня өстәленә тимәскә булдым. Йокы бүлмәсенә кереп, хатын диванына сузылып яттым. Озакламый хатын да минем янга кереп утырды. Учын маңгаема куеп:

— Авырмыйсыңдыр ич, атасы? — дип сорады.

Кулы кайнар иде хатынның. Моннан егерме биш ел элек тә шулай кайнар иде аның куллары.

— Менә әби белән бабай да булдык инде, — диде хатын һәм кайнар учы белән йомшак кына итеп пеләшемнән сыйпады.

## Әти тәти

Күптән кызыгып йөри идем инде мин шушы ике яшьлек сөйкемле кызчыгыбызны үземчә тәрбияләргә. Олы кызны күбрәк әнисе тәрбияләде. Тик әнисенең тәрбия нәтижәләре ошап житми миңа. Күнелгә ятмый торган сүзләр ычкындыргалый кайчагында олы кыз. Кемгә дисез әле? Миңа, әтисенә. «Нигә кычкырасың?» дип допрос ала. «Кычкырмыйча гына аңлатып булмыймы әллә?» дип акыл өйрәтә. Әйтеп тә торасы түгел — әнисе мәктәбе.

Кичәгенәк эштән кайтып керсәм, әнисе, әлеге дә баягы, шул ике яшьлек кызыбыз Резидәне орышып маташа.

— Тилесендер син, бу кадәрле иркә, назлы сүзләр әйткәч, изрәп кенә йоклап китәр иден, тибенеп ятмас иден, — ди.

— Сон, жүләр! «Тилесендер» назлы сүз буламыни? — дип элеп алдым мин әнисен. — Балага шундый сүзләр сөйләргә ярыймыни? Шундый сүзләр белән тәрбияләп буламыни баланы?

— Алай бик оста булгач, мә, үзең тәрбиялә, үзең йоклат! — дип, тиктомалдан гына кызып китте хатын.

— Тукмак чаклы баланы тәрбияләмәскә тегеі Тәрбиялим! Рәхәтләнеп тәрбиялим! — дип гайрәт чәчтем мин, жиннәремне сызгана-сызгана. — Сары май кебек эри ул назлы гөл минем куенымда.

Мин, шулай гөрли-гөрли, Резидәне кулыма алдым. Әнисе, ирен читләре белән мыскыллы елмаеп, икенче бүлмәгә юнәлде.

— Жүләр әниен, ие бит, — дип тирбәтә-тирбәтә, өстенә жылы юрган яптым мин Резидәнен.

— Әни жүлә, — дип кабатлады Резидә, ялагай тавыш белән.

— Әти тәти, — дидем мин күнелем булып, һаваланып.

— Әти тәти, — дип кабатлады Резидә.

— Тәти әтисе ә-ә-ә иттерә хәзер тәти Резидәне.

— Ризә тәти, Ризә тәти...

— Ризә ә-ә итә. Йоклый хәзер Резидә. Тәти әтисе ә-ә-ә иттерә тәти Резидәне...

Резидә шуклык һәм шаянлык яшерелгән керфекләрен жем-жем иттереп тирбәндереп алды да күзләрен шарландырып мина карады.

— Йоклый инде Резидә. Ә-ә-ә итә. Бөтен кешеләр йоклый хәзер, бәбиләр дә йоклый, әбиләр дә ә-ә итә, абыйлар да ә-ә итә, әтиләр дә, әниләр дә ә-ә итә, маэмайлар да, мияулар да, — дип, матур сүзләремне борчак урынына сиптем мин.

— Әти дә ә-ә-ә, — диде Резидә, уяу тавыш белән аермачык итеп.

— Резидә дә ә-ә-ә итә, — дидем мин, сабырсызлана төшеп.

— Ау-ау да ә-ә итә, — диде Резидә һәм жәһәт кенә урыныннан сикереп торып утырды.

Мин аны көчләп диярлек мендәренә яткырдым.

Монысы бер дә ошамады Резидәгә. Иреннәрен кыстыбыйландырып шыншырга тотынды. Шул гына кирәк иде, шул гына житмәгән иде, туктатырга иде эш зурга киткәнче, ничек тә туктатырга иде.

— Резидә ә-ә итми, Резидә мәми ашый, — дип ычкындырып ташладым мин каушавым белән.

Шым булды Резидә. Тик шул минутта ук аваз салды:

— Мәми, мәми! Әпис мәми!..

Әфлисун сорый бит бу вәсвәсә, әфлисун сорый. Әфлисун бирмәсән, йоклатып булмаячак хәзер моны. Менә бәла, менә авыртмас башка тимер тарак.

Әнисе кайдандыр бәйрәмгә дип юнәткән иде дә сон әфлисун. Аны эзләп табып кергәнче, йокысы тәмам ачылып бетәчәк бит әле бу коткының.

Караватында олы кызым астыртын гына пырхыллап куйды.

— Әле син дә йокламыйча ятасынмыни? — дип, жен ачуларым кузгалып, урынымнан сикереп тордым мин.

— Нигә кычкырасың, әти, шулкадәр? — диде олы кызым, сару кайнаткыч сабырлык белән.

— Йокла! Ичмасам, син нервыма тиеп ятма. Шушы төнгә кадәр йокламыйча ятырга жүләр түгелсеңдер.

Минем әфлисун алып кергәнемне Резидә аяк өстенә басып, кечкенә тәпиләрен мендәргә батырып, йөзенә түземсезлек билгеләре чыгарып көтеп тора иде.

Мин ана әфлисунны әрчеп бирергә теләгән идем дә, кая ул — секунд эчендә, «мәми, мәми» дип, йөз генә мәртәбә кычкырмагандыр. Жиде жил чатында үскән усак яфрагы да алай еш леперданмәс.

Урынына яткыргач, ак чәчәк тажлары сыман нәфис бармакларын жәеп кысып тотты да бу, кояш кебек түгәрәк әфлисунны иреннәренә якын китерде, һәм анын кабыгыннан, каз бәбкәсе чирәм өзгәндәй, тавышсыз гына бер чеметем элпә тешләп алды, табышын мина сузды.

— Әти, таша.

— Ташлыйм, кызым, ташлыйм, — дидем мин, анын бармак очында күренер-күренмәс ябышып торган элпәне элэктерергә тырышып. — Ә син йокла инде, йокла, ә-ә ит.

Резидәнең коньяк жимешеннән алты-жиде чеметем элпә тешләп биргәнен анымоны дәшми генә көтеп яттым, аннары, ничек кирәк, алай алдаштыргалап, эт булып өреп, мәче булып мияулап дигәндәй, әфлисунны үз кулыма алу бәхетенә ирештем һәм, минуты-секунды белән кабыгын әрчеп, кычкырып елау өчен авызларын бөргәләп репетиция ясый башлаган нәни артистканың кулына тоттырдым.

Ах Алла! Болай да бик озакка сузылачак икән әле бу. Әфлисунның унике бүлкәсе бар. Бүлкә саен йөзләп күзәнәк. Ә кызым әле фәкать беренче бүлекнең беренче күзәнәгеп генә суырып маташа.

Ничек итсәм иттем, алдап-йолдап китереп, кызым күрмәгәндә, әфлисунның унбер бүлкәсен, чәйнәми-нитми генә, үзем кабып йоттым.

Резидә дә, ниһаять, беренче бүлкәне чүбекләндереп, калдык-постыкларын мина сузды.

— Эти, таша!

— Ташлыйм, кызым, ташлыйм. Менә үскән кыз ул, менә мәми ашады ул, инде хәзер йоклый ул, тыныч кына ә-ә итә.

Резидә беркавым мина тасраеп, шикләнеп карап ятты. Аннан соң, урыныннан күтәрелә төшеп, кечкенә кулларын мендәр өстендә йөртергә керешге.

— Тая?

— Нәрсә, кызым?

— Мәми тая? Әпис тая?

— Бетте, кызым. Үзең ашадың ич. Үзең ашап бетердең.

— Мәми! Әпис мәми!

Кызым аяк-кулларын чәбәләндереп еларга керешге.

— Ә-әпис, әпис мәми!..

— Ах, син алаймы әле?! — дип, сабырлыгымны җуйдым мин, ниһаять. — Әле син тәти әтиеңне тынламыйсыңмы? Алайса, менә сиңа, мә сиңа!..

Йомшак җиренә берне чәпелдәтеп алгач ук, Ходайның рәхмәте, керфекләре йомылды кызнын, сулышы тигезләнде. «Шулай менә, ата кулы шифалы була, — дип уйладым мин, эчемнән генә сөенеп. — Баланы гел-гел иркәләп-сөеп кенә торырга ярамый шул, бераз катырак торырга кирәк».

Аяк очларыма гына басып бүлмәдән чыктым. Әмма ишекне ябып та җиткермәдем, эчке якта башта олы кызымның тыелып кына пырхылдаганы, аннары Резидәнең ярсу катыш нәфрәт белән тәтелдәгәне ишетелде:

— Эти җүлә... Җүлә эти...

Әнисе ишетмәсә ярар иде, дигән идем, ишеткән икән. Килеп җиткән тизрәк. Үзе авызын ерып көлә, үзе кыз белән сөйләшкән була. Нишләп алай әйтәсең, кызым, әтиеңә алай әйтмә, янәсе. Эти тәти була ул...

## Абитуриентлар

Әй, жаныкаем, хәзер институтка керүләре! Аны бер Алла да үзебез генә беләбез инде. Узган ел керәлмәдек без. Галимҗан Сабирович белән дә сөйләшеп куйган идек канә. Имтихан вакытында чирләп китте, гөнаһ шомлыгы. Күрәләтә тарихтан икеле алдык.

Кызым Индирә үзе ник бер бөртек яшь чыгарсын! Ә мин, тинтәк, юл буе акырып елап кайттым. Гарьлек бит, җәй буе хәзерләнеп йөреп...

Син тагын болар институтка блат белән керергә йөриләр икән дип уйлый күрмә. Аллам сакласын. Безнең кадәр күп укучы, безнең кадәр тырышучы, безнең кадәр әзерләнүче булса, юләр... Безнең белем белән бер кыюрагы институтка түгел, академиягә барып керер иде. Юаш шул без. Белгәнне дә чатнатып әйтеп бирә алмыйбыз. Тик торабыз шунда авыз эченнән боламык болгатып.

Быел ныгытып, бик ныгытып әзерләндек инде анысы. Сөйләп бирә алмасак, кәгазьгә язып бирербез. Тарихны су урынына эчәбез быел. Кызым Индирә, хәер, программадан әллә ни читкә чыкмады. СССР тарихын гына укыды. Ә мин борынгы заман тарихын да, урта гасырын да кырып-себереп бардым. Белмәссең, сорадылар-куйдылар. Имтихан бит ул. Әйткән бер сүзең гамәл дәфтәреңә теркәлеп бара.

Имтиханга икебезне дә кертсәләр, иллә мәгәр яхшы булыр иде дә ул,

малайкачым. Юк шул, узган ел да Индирәне генә керттеләр. Үзем коридорда ут йотып йөрдем. И андагы галәмәтне, андагы мәхшәрне күрсәң! Чәчләре агарып беткән генераллар килгән, жаныкаем. Һәркайсы бала кайгысын кайгырта, һәркайсы баласын югары белемле итәсе килә...

Узган ел тарихтан януыбызның сәбәбе шул: әдәбият белән артыграк мавыгып киткәнбез. Кызым, төн йокыларын калдырып, Толстой, Тургенев романнарын укыды. Ябыкты мескенем, суырылып керде. Мин, ана кеше буларак, Белинский, Добролюбов, Чернышевский, Герцен кебек корырак талканлы әдипләргәябышып яттым. Ми тартмалары ярылганчы укыйм-укыйм да соңыннан эчтәлеген Индирәгә сөйлим. Ә ул: «Бигрәк кызык икән, әни», — дип исе китеп, сөйләгән бер китабымны хәтеренә бикләп бара. Әнә шулай тырыша торгач, тарихны бөтенләй онытып жибәргәнбез, жаныкаем...

Быел алдатмадык, шөкер. Укыдык, бик ныгытып укыдык тарихны. Кызым үзе дә күп укыды. Мин дә укыганымны бәйнә-бәйнә сөйләп бардым. Тарих дигән фән бик әкәмәт нәрсә икән ул, малайкачым. Без укыган чагында бер дә алай кызык түгел иде, чын әгәр. Әй анда Ганибалның туганы Гасдрубалның, жинелә башлагач, дошман гаскәрләре арасына бер үзе атылып керүен укысаң, юләр... Ул чагында филләр белән сугышканнар, малайкачым. Ганибал чак кына Римны алмый калган... Аннары безнең эрага кадәр бишенче гасырларда галлар чынлап торып Римны ала. Шәһәрнең бөтен затлы кешеләре Капитолий дигән кирмәнгә кереп бикләнә. Менә шунда инде төннәрдән бер төнне галлар яшерен юл белән Капилолий стенасына менә башлыйлар. Ә Юнон храмында йорт казлары яши икән.

Менә бер заманны төн уртасында тавыш куптаралар, мин сиңа әйтим, казлар, түзеп кенә тор. Марк Манлий дигән бик гаярь бер кеше эшне сизеп ала да римлылар галларны стенадан мәтәлдереп төшерәләр...

Әллә ниләр сөйләр идем дә мин сиңа, жаныкаем, ашыгам. Имтихан бирәбез бүген. Уникедә башлана. Кызым шунладыр инде. Әле эштән дә рөхсәт сорап кына киттем. Бөтен эчем яна, башым әйләнә. Көне дә эссе бит аның. Чаптым мин, чаптым... Цезарь әйтмешли, жирәбә салынды, унышлар телә...

Автобус китсән инде... Әй, жәяү лутчы тизрәк барам ла мин... Фемистокл Саламин сугышында Ксеркснын мен кораблы флотын тар-мар итә... Сципионга, Ганибалны жингәч, «Африканский» дигән титул бирелә...

Әллә, Ходаем, башланган да инде?! Галия, Галия дим, кара, ишетми дә... Башы-күзе тонган. Кая безнеке, Галия... Индирә кайда? Икеле алды?! Ничек икеле алды? Кайчан? Исәнме үзе?.. Галимжан Сабирович, туктале, Ходай өчен. Безнең кыз ничек?.. Без тагын керәлмибез булып чыгамыни инде?..


Булмас, булмас, Галимжан Сабирович. Кызым көне-төне тарих укыды. Әллә теге... Наполеонны Бөек Карл белән бутарга! Ничек, ничек? Кит аннан! Нишләп Гай Гракх Колчак генералы, ди? Борынгы Римда халык трибуны булган ич ул. Рус-япон сугышы егерме өч ел дәвам иткән диме? И, жаныкаем, беренче Пуни сугышы белән бутаган инде ул алайса, и, жаныкаем!..

Кайда соң әле үзе? Брут хатыны кебек, утлы күмер йотып кына үлмәсә ярар иде...

Индирә, кызым, бәгырькәчем, тагын керәлмәдекмени соң, ә? Нигә авызыңны ерасың? Еларга кирәк, еларга! Күпме укып, күпме төн йокыларын калдырып. Малайлары үтерелгәч, Корнелия дә бу кадәр хәсрәт кичермәгәндер...

Индирә, кая киттең әле? Соң, акылсыз, киногa йөрер вакытмы хәзер. Кайтып укырга утырыйк. Бер ел үтә дә китә ул. Өченчесе — көч дигәндәй, киләсе елга барыбер керәбез шушы институт дигәннәренә!..

# ОСТАЗ



*Миркасый Госманов. 2000 елның 1 ноябре (Госмановларның гаилә архивыннан).*

Май айлары җитте исә, күңелдә бер монсулык хисе туа: остазым Миркасыйм абыйны юксыну хисе ул. Май аенда аның туган көне, исән булса, быел 80 яше тулыр иде. Җаны якты иде, туң бәгырьләрне җылытырлык күңел җылысы бар иде, сагынырлык, юксынырлык шәхес, чын татар, татарның да егет солтаны иде Миркасыйм абый.

Туган халкына фидакарь хезмәт итүнең матур бер үрнәген бирегез, дисәләр, мин зур галим Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның (1934-2010) тормышын һәм күпкырлы эшчәнлеген күрсәтер идем. Тарих һәм әдәбият галиме, археограф һәм тюрколог, талантлы педагог һәм фәнни-иҗтимагый лидер, гомерен татарлыкка, төркилеккә багышлаган, шул ук вакытта башка милләтләргә дә хөрмәт хисе белән караган, фикер офыгы гаять киң булган олпат акыл иясе иде ул. Илле еллык фәнни эшчәнлеге чорында М.Госманов Алтын Урда тарихы белән бәйле дөньякүләм әһәмиятле хезмәтләр язды, хан ярлыклары, «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек тарихи чыганакларны анализлап бастырды, Пугач явы кебек конкрет тарихи вакыйга һәм күренешләргә объектив бәя бирде, рухи мирасыбызның әһәмиятле проблемалары турында уйлануларга нигезләнгән кыйммәтле публицистик әсәрләр иҗат итте. Тематик һәм хронологик яктан галимнең диапозоны XIII гасырдан үз чорыбызга кадәрге вакыйгаларны биләде. Татар фәненең тулы бер юнәлеше аның исеме белән бәйле: Миркасыйм абый Казан дәүләт университетында археографик экспедицияләр оештырып, киң Рәсәй төбәкләреннән иске язмаларны җыю, лабораториядә өйрәнү эшен озак еллар алып барды. Бу экспедицияләрдә бихисап кулъязма әсәр һәм иске китап тупланып, мәдәни мирасыбызны баетты, XVII-XIX гасырларга караган халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм әдәбиятыбызның аз билгеле язма материаллары халкыбызга кайтарылды. Онытылган-оныттырылган татар зыялыларының, дин һәм мәдәният әһелләренең, мәгърифәтчеләренең исемен һәм мирасын яңадан халыкка житкерү эшендә Миркасыйм абый башлап йөрүче булды.

Ул, татар әдәбиятының беренчел чыганакларына мөрәҗәгать итеп, текстология фәненә үзеннән зур өлеш кертте, Мифтахетдин Акмулла, Габделҗаббар Кандалый кебек шагыйрьләребезнең кулъязма мирасын барлап бастырды. Х.Фәезхановка багышланган монографиясе бу күренекле шәхеснең беренче гыйльми биографиясе булып фәнгә кереп калды. 1980-1990 елларда язылган хезмәтләрендә Мөхәммәдьяр, Г.Утыз-Имәни, Г.Кандалый, Х.Фәезханов, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, С.Вахиди, Һ.Атласи, Ж.Вәлиди, Г.Исхакый, М.Худяков, К.Фукс һ.б. хакында фәндә яңа фикерләр әйтелде. Татар зыялылары вәкилләренең тормыш юлларына багышланган

әлеге хезмәтләре белән XXI гасыр башындагы милли күтәрелеш чорында уникаль бер проектка ныклы нигез салды: татар мәдәнияten үстерү максатын күз унында тоткан «Жыен» фондынын идарә рәисе Миркасыйм абый «Шәхесләребез» сериясендә халкыбызның атаклы затларына багышланган җыентыклар чыгаруны оештырды, ике дистәгә якын китапны үзе исән чагында татар җәмәгатьчелегенә һәм Рәсәй галимнәренә тәкъдим итү бәхетенә иреште. Ике телдә хәзерләнгән бу тарихи-документаль жанрдагы җыентыклар билгеле бер шәхес хакында биографик характердагы мәкаләләр, архив документлары, мемуарлар, хезмәтләренен библиографиясе һәм сөземтәләре, иллюстрация һәм фотоматериаллардан тора. М.Госмановнын зур һәм катлаулы коллектив эшен оста итеп оештыра белүе, таләпчәнлеге, гыйльми өслүбне саклап калырга омтылуы «Шәхесләребез» сериясендәге китапларнын югары сыйфатлы, бердәм рухлы булып чыгуын тәэмин итте. Миркасыйм абый бу проектның фәнни житәкчесе генә булып калмады, вакытлы матбугат һәм радио-телевидениедә анын асыл концепциясен аңлату, серия кысаларында чыккан китап-җыентыкларны халыкка танытуда да зур эш башкарды. Иншалла, Миркасыйм абыйдан калган бу игелекле эш алга таба да дәвам итәр һәм бик якында анын үзенә багышланган җыентык та дөнья күрер дип өметләнергә кирәк.

Миркасыйм Госманов кебек олуг остазнын гап-гади бер шәкерте булу бәхете без фәкыйрегезгә дә тәтеде, бу — тәкъдирнен изге бүләге иде, әлбәттә. Ике өлкәдә — тарих һәм татар әдәбияты буенча тигез дәрәҗәдә кыйммәтле хезмәтләр калдырган галим булса да, шәкертләр тәрбияләү өлкәсендә ул күбрәк тарихчы иде, мина кадәр анын әдәбият буенча аспирантлар алганы булмаган, шуна күрә 1987 елда тарих фәннәре докторынын әдәбият буенча аспирант алырга карар бирүе үзенә күрә бер яналык, хәтта бер эксперимент булды диярга мөмкин. Миркасыйм абыйнын шәкерте булып, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләремне анын житәкчелегендә язсам да, анын белән һәркөн очрашып, ингә-ин бергә эшләгән дусларыннан, хезмәттәшләреннән, экспедицияләргә йөргән укучыларыннан мин «читтән килгән» булуым белән аерылып тордым. Студентлык елларым Казан университетында узмады, Миркасыйм абый лекцияләрен тулысы белән тынларга туры килмәде. Тик көн саен күрешеп торган кешенен кыйммәте кайвакыт сизелми бит ул, ә мена минем кебек, сирәк кенә күрешү бәхетенә ирешкәннәр, Миркасыйм абыйнын кадерен ныграк белә идек бугай. Житмәсә, аспирантурада укыган елларым Миркасыйм абыйнын университет проректоры булып эшләгән чорына туры килде: шулкадәр зур уку йортында никадәр хәл ителәсе мәсьәлә һәм көндәлек эш йөри иде анын башында! Мин боларны ике-өч атнага бер проректор кабинетынын ишек төбендә ана керергә чират торганда, секретаренын телефоннан сөйләшүләреннән һәм алдында өелеп торган тау хәтле кәгазь эшләреннән генә чамалый идем. Ничектер татар галимнәре арасында шул вакытта бер сүз ишеткәнем булды: «Миркасыймны, фәндә артык алга китмәсен өчен, махсус шундый җаваплы идарә эшенә куйдылар». Монда күпмедер күләмдә хаклык булгандыр, күрәсен, танышларым арасында анын фәнни эзләнүләренен тукталуыннан куркып уфтанучылар юк түгел иде. Чынлап та, Алтын Урда тарихы буенча язган хезмәтләре дөньякүләм танылган бер дәвердә, гыйльми фикерләвенен иң югары ноктасына ирешкән, көче-куәте ташып торган чорда ул идарә эшләренә шактый күп вакытын сарыф итте. Ләкин шул ук вакытта, нәкъ менә Миркасыйм абый проректор булып торганда, Казан университетынын татар бүлегенә, татар галимнәренә һәм студентларына карата фикер унай якка үзгәрде, татар фән белгечләре өчен шактый күп мөмкинлекләр туды, күп кенә ябык ишекләр ачылды, моны да инкарь итеп булмый. Проректорлык эшеннән киткәннән сон да, «татарлык проблемалары» белән ана килү гомере буе дәвам итте. Вакытынын гаять тыгыз булуына карамастан, һәр кеше белән ашыкмыйча сөйләшеп, мәсьәләнен нигезенә төшенеп, бөтенләй кителмәгән яссылыкта, тирәнлектә-киңлектә үз фикерен белдерә иде. Милли хәрәкәтнен, Татар иҗтимагый үзәгенен искиткеч актив чорында да ул үзенен саллы сүзе

белән кайбер кайнар башларны «суыта», акыл белән эш йөртергә чакыра белә иде. Миркасыйм абыйны беркөнлек унышлар, баш әйләндергеч дан-шөһрәтләр кызыксындырмас, ялагайлыкны, елаклыкны җене сөймәс иде. Мәскәү һәм Казанның күп академиклары, зур түрәләре белән якыннан дус-таныш, тик бу танышлыкны үз мәнфәгате өчен куллану аның холкына хас нәрсә түгел иде.

Миркасыйм абыйның җор һәм үткен, кайвакыт усал, «чәнечкеле» телле булуын аның белән бер күрешеп сөйләшүдә аңлап була иде. Ул һәр сүзен үлчәп-уйлап куллана белде. 1980 еллар азагында Казанга килгән бер төркем төрек галиме каршында ясаган чыгышын тыңлап хәйран калган идем. Ул вакытта төрек телен белүче аз, Миркасыйм абый да төрек телендә сөйләмәде, ләкин гомумтөрки телнең бөтен мөмкинлекләрен искиткеч оста кулланып, бар төрек аңларлык итеп, бер кәлимә русча кушмыйча, су кебек агызып, гаять тә шома итеп, саф татар телендә сөйләде, минем бүтән беркемнән дә мондый «татарчаны» ишеткәнем булмады: монда Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман» гәҗитенең чыгтайчаның аһәңнәре дә ишетелеп-ишетелеп киткәндәй булды. Гомумән, татар телен аның кадәр мөкаммәл кулланучы башка бер язучыны белмим, моны инкарь итәргә теләүче булса, аның «Үткәннән — киләчәккә» (1990), «Гасырдан — гасырга» (2004) исемле фәнни-публицистик җыентыкларын укып баксын! Фикернең тирәнлеге белән сүз осталыгын камил дәрәҗәдә бергә берләштерә белүнең иң югары үрнәкләре булып тарихта калачак әсәрләр болар, минемчә.

Гыйлем дәрьясына керергә ният итүчеләрнең сәләтен, мөмкинлеген үлчәп белер, шуңа карап һәрберсенә аерым таләп куяр иде. Тулай торакта торганда күрә идем: башка аспирантлар һәр атна фәнни җитәкчеләре янына консультациягә йөриләр, сәгатьләр буе сөйләшеп-киңәшеп утыралар, хәтта өйләренә баралар иде. Миркасыйм абый исә шәкертләре белән бик демократик эш йөртә, аларны артык «борчымый», проректорлык һәм кафедра мөдирлеге вазифаларын башкару чиктән тыш күп көчен һәм вакытын алса да, гыйльми эзләнүләрен дә актив рәвештә дәвам иттерергә тырыша иде. Аннан соң, шәкерт үзе эзләп йөрергә тиеш остазны, бу да бер хакыйкать. Үзконтроле булмаса, аның ягыннан шәкертләргә контроль юк иде дияргә була. Шуңа күрә Миркасыйм абый белән киңәшәсе сүзем булганда, иртәдән проректор кабинетына чират алып, ул көндезге ашка яки берәр җыелышка киткәнче, бер ун минутка кереп, сөйләшеп чыга идем. Миркасыйм абый игътибар белән тыңлый, мина бирелгән тема аның өчен дә яна һәм кызыклы иде булса кирәк. Гел тарихчы егетләр белән җитәкчелек иткән остаз беренче хатын-кыз (җитмәсә, әдәбиятчы!) аспирантына искәрмә ясамады: үземчә тырышам, эзләнәм, ләкин мактау сүзен ишетеп булмый. Тора-бара Миркасыйм абыйның кырыс холкына мин дә өйрәндем: «кызый» дию — яратып эндәшүе, «маржа» дию русча яхшы гына «сукалавым» өчен икәнен аңлый башладым. Мактавының иң югары ноктасы булган: «Кызый! Чыбыркыласаң, син әйбәт эшлисең икән!» — дигән җөмләсе гомер буена үз-үземне «чыбыркылап» эшләргә өйрәтте. Миркасыйм абый шул сирәк кенә күрешкән чакларда да фәнни эштә бик әһәмиятле моментларга игътибар итәргә күнектерде: күпсанлы гарәп алынмаларында, аеруча исемнәрдә унификация мәсьәләсе, текстны кабат-кабат редакцияләүдә иренмәү, хезмәткә исем сайлаганда, уннан да ким булмаган вариант тәкъдим итеп, бер фикергә килү һ.б. Шәкертләренең дә бу мәсьәләдә фикере бер иде: юк-бар нәрсә язып кына диссертация яклап булмаячак, шуңа күрә җиңел юл белән карьера ясарга теләүчеләр Миркасыйм абый кафедрасы тупсасын бик таптамадылар. Бәлки шул сәбәпле, профессор М.Госмановның укучылары арасыннан чыккан фән кандидатлары яки докторлар саны дистәләп санарлык түгел. Шулай да Миркасыйм абый үзен бәхетле остаз саный иде, юбилейларында берничә тапкыр әйткәне булды: шәкертләрем арасында төрле язмышлы, фәндә төрле дәрәҗәдә унышка ирешүчеләр бар, ләкин мин бер нәрсәдә тулысынча тынычмын, алар арасыннан явыз, ялганчы, начар кешеләр чыкмады. Бу чынлап та шулай: ул тәрбияләгән тарихчы егетләргә мин гел сокланып һәм хөрмәт белән карыйм, әдәбиятчы



*Профессор Миркасыйм Госманов хезмәттәшләре һәм шәкертләре – Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы әгъзалары белән. 2004 елның 25 октябре.*

булсам да, алар белән арабызда ниндидер туганлык хисе тоям: без бит бер «ата балалары», дип горурланам.

Бөтен авырлыкларга карамый, татар әдәбияты кафедрасыннан М.Госманов җитәкчелегендә XIX йөз татар шигърияте буенча кандидатлык диссертациямне 1990 елда уңышлы яклап, Алабугага кайтып киттем. Берничә елдан соң Миркасыйм абыйның өстәленә өр-яңа темага язылган бер китап кулъязмасы куйгач, ул аптырап калды. Суфичылык темасы әле ул вакытта «модага кермәгән» иде. Миркасыйм абый язмама күз йөртеп чыкканнан соң, кереш сүз язарга теләвен белдерде. Моны ишеткәч, мин үземне җиде кат күктә хис иттем, Миркасыйм абый минем китабыма кереш сүз язачак! Димәк, эшем начар түгел, дөрес юлдан барганмын! «Суфичылык серләре» (Казан, 1998) китабыма остазымның язган кереш сүзе миңа «аванс» булуын аңлый идем, хәер, ул бу турыда үзе дә турыдан-туры әйтә: «...татар җирлегендә суфичылык тәгълиматының үзенчәлекләрен ныклап өйрәнү таләп ителә. Бу олы бурычны башкару юлында мин Ә.Сибгатуллина үзе дә тырышлык, зәлеклелек күрсәтер дип өметләнәм. Дөресен әйткәндә, бу китап автор тарафыннан тәгалләнәчәк зур хезмәтнең беренче өлеше генә». Мин ул өметне акларга тырыштым: 1999 елда докторлык диссертациямне, кем әйтмешли, өстәленә салдым. КДУның әдәбият кафедрасында эшемне тикшерү вакытында Миркасыйм абый: «Турысын әйтергә кирәк, шундый зур темага тотынгач, Әлфинә бу чиксез диңгездән йөзеп чыга алырмы икән дип шикләнеп торган идем, тәки ерып чыкты бит», — диде. Моннан да зуррак мактау сүзе минем өчен була алмас иде!

Алабугада яшәгәнгә, Миркасыйм абыйны сирәк күрә идем, Казанга эш белән килгән чакларымда янына керсәм, «Ә-ә-ә, килденме, кызый, ни хәлләр?» — дип, якты чырай белән каршылый, кабинетында хәл-әхвәл сораша, яңа чыккан китаплар булса, бүләк итеп җибәрә торган иде. Мин аны юк-бар белән борчымаска тырыштым, ләкин бик четерекле вакыйгалар килеп чыгып, җитди карар бирергә кирәк булганда, аның киңәше минем өчен гаять әһәмиятле иде. Мәсәлән, 2005 елда гаиләм белән Мәскәүгә күчәргә уйлагач, иң элек аның хәер-фатыйхасын алырга бардым. Өендә Салисә апаның җимеш салынган чәен эчә-эчә озак кына сөйләшеп утырдык һәм ул вакытны Миркасыйм абый биргән киңәш һәм ул күрсәткән юл минем Мәскәүдәге тормышымда ифрат файдалы һәм кыйммәтле булды. Моның өчен үземне аның каршында гомер буе бурычлы саныйм. Мәскәүдә язган беренче китабыма Миркасыйм абый уңай рецензия бирде, бу инде аның миңа тулысынча ышануы иде. Кызганыч ки, хезмәтнең китап булып басылып чыкканын гына күрә алмады...

Ун елга якын инде Рәсәй Фәннәр академиясенең Шәрыкны өйрәнү институтында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр булып эшлим. Еш кына Мәскәү дәүләт университетының Азия, Африка илләрен өйрәнү институтында төрек әдәбияты буенча диссертация яклауларда рәсми оппонент булып катнашырга туры килә. МДУны бетергән галимнәрнең психологиясе үзенчәлекле: алар Рәсәй гыйлем дөньясындагы кешеләрне икегә генә аерып карыйлар: МДУны тәмамлаганнар һәм башкалар. Бу ике төркем арасында, аларга күрә, зур аерма бар: икенче төркемгә караган күпчелек — йомшак һәм «җитлекмәгән» галимнәр. Беренче тапкыр оппонент булып чыгыш ясаганнан соң, яклау тәгәлләнгәч, диссовет рәисе миннән болай дип сорады: «Сез МДУны кайчан тәмамладыгыз?» Бу сорау мин фәкыйрегезне «үзләренеке» итеп кабул итәргә теләүнең бер билгесе иде. Мин исә, горурланып: «Юк, мин МДУда түгел, Татарстанда укыдым», — дип җавап биргәч, гаҗәпләнү катыш кәефсезләнү хисе йөзенә бәреп чыкты. «Чыгышыгыз буенча мин сезне бездән дип уйлаган идем», — диде. Әлбәттә, гыйлем иясенең кайда белем алуы, нинди шартларда җитлегүе бик мөһим, ләкин кешенең үз тырышлыгы һәм аны тәрбияләгән остазларының да роле кире кагып булмастай әһәмиятле факторлардан, минемчә. МДУның дәрәҗәле факультетында укып та галимлеккә ирешеп бетә алмаучылар булган кебек, провинциаль вузны тәмамлап та, уңышка ирешкәннәр аз түгел бу дөньяда. Мин дә Алабугада һәм Казанда белем алуым, академик Миркасыйм Госмановның укучысы булуым белән горурланып яшим.

Миркасыйм абыйның үлемен татарлык хәятендә олуг бер чинар агачының үлеме белән тиңләр идем. Үз әтрафына никадәр шәкерт һәм фикер иясен туплаган, җил-яңгырлардан саклаган тагын шундый «чинарлар» бар микән? Татарны дөньяга танытырдай аның дәрәҗәсендәге зыялы галимнәр бездә күпме? Ул бөек булырга омтылып яшәмәде, ләкин бөек булып кала белде. Миркасыйм абыйның әйткән сүзләреннән берсе гел истә калган: «Китә белеп китәргә кирәк». Татар тарихы кафедрасы мөдирлегеннән үз теләге белән киткән чорда әйткән иде ул аны. Тик бу якты дөньядан гына иртәрәк китте: аның фикерләренә, киңәшенә, карашларына ихтыяҗыбыз зур. Икенче яктан, хатыны Салисә апа әйткән сүзләрдә дә хаклык юк түгел: «Казан университетында соңгы елларда барган авыр үзгәрешләр, аеруча ул ачкан татар факультетының ябылуы кебек ямьсез хәлләрне күргән булса, бәлки Миркасыйм инде биш тапкыр «үлгән» булыр иде». 2012 елда Миркасыйм Госмановка Татарстан Җөмһүриятенең фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясен бирү, үлгәннән соң булса да, аның милләтебез каршында куйган зур хезмәтен тану булды. Бүген Татарстан Фәннәр академиясе Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге М.Г.Госманов исемен йөртә. Татарлыкның, Татарстан тюркологиясенең, алтынурдачылыкның, татар тарихының, әдәбиятының әйдәп баручысы, башлыгы, алыштыргысыз җитәкчесе булуын күпләребез соңлап аңлады. Фәндә һәркемнең үз урыны бар, тик миңа Миркасыйм абыйның юклыгыннан пәйда булган бушлыкны тутыру бик авыр...

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы, профессор.*
*Мәскәү*

# ӘДӘБИЯТ ГАМЕ — ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ

Көн саен аралашып йөри торгач, еш кына төрле гыйльми утырышларда, ачык лекцияләрдә, әдәби мәҗлесләрдә һәм көндәлек тормышның тагын күп төрле хәл-әхвәлләрендә янәшә атлый-атлый, кешене җентекләп өйрәнәсең, аның нәрсә турында ничек итеп әйтәсен, нинди мохиттә үзен ни рәвешле тотасын алдан беләсең кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай тоела. Шәхесне, бигрәк тә олуг галим кешене, тулысынча белеп бетерү һич мөмкин түгел. Ул һәр очракта нинди дә булса яңа ягы белән ачыла, җәмәгатьчелекне монача мәгълүм булмаган карашлар, фикерләр белән җәлеп итә, аның эш-адымнары, иҗат итеп яшәве, шул рәвешле, җәмгыять ихтыяҗлары белән билгеләнә.

Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловны бик күпләр яшәешебезнең хәзерге чорында зарур булган фикер чыганагы, аксакалларга хас төпле акыл иясе, абруйлы шәхес буларак бәялиләр һәм кабул итәләр икән, моның сәбәпләрен аның шәхси сыйфатларыннан һәм ул башкарган эшләрнең мөһим нәтиҗәләреннән күреп була. Беренче карашка, аның һәр сүзе, кешеләр белән мөнәсәбәте, йөреше-торышындагы һәр деталь нәкъ аңа гына хас, ул гына булдыра алганча, бик гади генә кебек. Кайчандыр аңарда укыган Рифә Рахман да остазын барыннан да элек гап-гади кеше буларак хәтерендә тота. «И-и-и бу гомер дигәнең... Себер сулары кебек тын гына аксачы. Ә бит Хатыйп абыебыз, әллә ни олыгаймады да. Безне, укучыларын, хезмәттәшләрен аптырашта калдырып, сокландырып, һаман да яшь күңел белән яши бирә. Матур сүзне, җылы сүзне кешеләрдән кызганмый. Аның миңе үпкәләткән чаклары да юк түгел. Мәңге эндәшмәслек хәлгә килгәнемдә күзләремне йомам да ул миңа җиләк җыеп ашаткан тау буйларын күз алдыма китерәм. Аның, үзе кебек озын тап-тар каекка безне утыртып, мыш-мыш килеп, чакрымнар буе каршы аккан тау елгасы буйлап каек эткәннәрен күз алдыма китерәм. Ә бит без аны да шаярткан. Мөгаллим булса да, кичергән, безне шул шуклыкларыбыз аркылы аңлаган, яраткан димен» *(Хатыйп Миңнегулов турында. Казан, 2009)*. Рифәнең бу уйлануларын матур бер хикәя укыган кебек кабул итәсең. Ул Казан университетының бу мактаулы профессорын, аңа бик тә табигый фәнни мохиттә гәүдәләндерүдән бигрәк, гап-гади кеше буларак ача, әдибәнең җор сүзләре, шаян һәм гамьле күзәтүләренә үзебез белгәннәрне дә кушкач, коллегабызны тагын да тирәнрәк аңлый төшәбез.

Югары уку йорты мөгаллиме булу ул аудиторияләрдә лекцияләр уку, гамәли-лаборатор дәресләр уздыру, көннәр буе китапханәләрдә утыру гына түгел. Студентларны илнең төрле почмакларына археографик, фольклор, диалектологик практикаларга алып барулар да аның вазифасына керә. Әле сиксәненче елларга кадәр шулар өстенә студентларны авылларга бәрәңге казуларга алып барулар да еш була торган иде. Андый эшләргә гадәттә яшьрәк ир-атларны җибәрәләр. Хатыйп кордаш ул елларда нәкъ шундый вазифаларны үтәү яшендә иде әле. Дөрес, безнең буын кешеләрен мондый гына мәшәкатьләр куркыта алмый иде. Рифә әйткән «каршы аккан тау елгасы буйлап каекларны чакрым ярымнар буе» безгә күп тартырга туры килде. Миннән ике генә яшькә олы булган Хатыйп Йосыф улы — сугыш чоры балаларының язмышын үз җилкәсендә татыган, бите күз яшьләре һәм маңгай тирләре белән юган буын вәкиле. Аңа карыйсың да уйга каласың: каян килә бу кадәр эшлеклелек, ныклык, фәнгә, халкына тугрылык? Бернәрсә дә юктан бар була алмый бит. Х.Миңнегуловта да бу асыл сыйфатлар халкыбызның гасырлар түреннән күчкән затлы тамырларыннан, нәсел-нәсәбенең күркәм нигезләреннән килә.

Зәй якларындагы туган авылы Апачның үткәндә кичергән фаҗигаләре дә монда аз роль уйнамагандыр. Вәхшиләрчә алымнар кулланып чукындыру сәясәте бу авыл кешеләренең дә холык-фигыль кодларына үзенең эзләрен салмый калдырмаган, әлбәттә. Халык моңа каршы бөтен рухи һәм җисми көчен куеп көрәшкән, ислам

диненең пакь, саф һәм якты нигезләренә корылган яшәү рәвешен саклап калу юлында нинди генә җәфалар кичерелмәгән? Ә бу кешеләргә тагын да ныклык сыйфатлары гына өстәгән. Кеше организмы шундый үзлеккә ия бит. Әйтик, берәр йогышлы авыру кичерсә, анарда алга таба бу төр чиргә каршы торырга мөмкинлек бирүче көч-сәләт тупланып кала. Һәм ул инде алга таба аның белән беркайчан да авырмаска мөмкин. Бу чыннан да шулай. Халыкта нык холык, максатка ирешүдә ихтыярлылык сыйфатлары тәрбияләнеп калган. Әнә шулар ничә буыннар аша бүгенгегә кадәр килеп җиткән. Әнисе ягыннан руханилар чылбырыннан килгән нәсел өчен бу афәтләр аеруча шыксыз булып кабул ителгән дип уйларга кирәк.

Зирәклек, тормыш яңалыкларын табигый кабул итеп, яшәешкә үзләреннән дә өлеш кертә бару кебек хасиятләр әнә шулай ерак ата-бабалардан килә. Хатыйпның әтисе Йосыф та колхоз чыкканда егерме-егерме бер яшәр егет була. Мона кадәр ат янында китмәгән егет, беренче тракторлар кайту белән, яңа һөнәргә өйрәнә — авылдашларын хәйран калдырып, «атсыз арба» йөртә башлый. Чыбыклы МТСының иң гайрәтле тракторчыларыннан була. Комбайнын да иярли, машина-тракторлар докторы — механиклык эшен дә булдыра. Әмма аталы матур тормышны сугыш харап итә, биш баласын калдырып, Йосыф абый 1944 елда һәлак була.

Гайнелхәят апа бөтен тырышлыгын балаларын аякка бастыруга туплый, нәтиҗәдә аларның чын мәгънәсендә затлы кеше булып чыгулары ананың тормыш максатына ирешүдә эзлеклелек саклавын раслый. Кайсы диңгез корабы капитаны, кайсы атказанган укытучы, кайсы галим булган балалар Йосыф абый белән Гайнелхәят апаның өметләрен аклаулары белән үзләрен бәхетле итеп тоялар икән, бу инде аз нәтиҗә түгел. Иреннән биш бала белән калган (берсе яшьли үлә) Гайнелхәят апа аларда кешелек сыйфатларының иң затлыларын булдырырга тырыша, улы Хатыйпның Татарстанда иң абруйлы галимнәрнең берсе булып җитешүе дә ана күңелен ихлас сөендергән, әлбәттә.

Кайчакта шундый сүзләр дә ишеткәләргә туры килә: Хатыйп Йосыф улы артык кыю, үзенең карашларын яклаганда, әллә ни тәкәллефлек саклап тормый, турысын ярып әйтә. Димәк, бу шәхес — яхшы сыйфатлар җыелмасы. Мин аның ни өчен мондый холык-фигыльле булып формалашуын да аңлыйм. Ул, әйтелгәнчә, сугыш чоры баласы. Ата назын, ата кулларының җылысын ике яшькә кадәр генә татып калган. Хатыйп әтисен бөтенләй дә хәтерләми. Аның өчен бердәнбер кайгыртучы кеше — әнисе.

Әтисез малайның хәлен яхшы аңлыйм мин. Ник дигәндә, үзем әтидән тагын да иртәрәк — өч ай тулгач аерылып калганмын. Әтием 1941 елның декабрендә Мәскәү янында салкын карда ятып калган. Бәхетле малайларның әтиләре сугыштан кайта алды. Аларның бездән ничек аерылып торуларын күреп үстек. Аталы балаларны кыерсытырга да базмадылар, тамаклары да чагыштырмача тук булды. Ә безнең ишегә, колхоз эшенә чыккач, атның да иң үшәнен, яки көчкә аягында басып торганын бирделәр, эшнең дә иң пычрагына, башкалар риза булмастайларына куштылар. Карап-карап торасың да, ачу чыга һәм карыша башлыйсың, бригадирга үзеңнең дә кеше баласы икәнлегеңне сиздерәсең. Ягъни тышкы яктан ясалган басымга эчке каршылыгыңны куясың. Еллар буе шулай итә торгач, шартларга ярашлы холкың да формалаша, үзеңне якларга күнегәсең. Аның каравы, үз көчең белән ирешелгәннәрне кадерләргә, бәяләргә өйрәнәсең.

Хатыйп Йосыф улына исә барысына да үз көче белән ирешергә туры килә. Шулай да урта белемне кеше рәтендә алу тормышта ачыграк күз белән атлап китәргә нык бер нигез була. Әмма аны да кемдер җайлап торган әзер юллар көтми. 1957 елда Иске Кәшер урта мәктәбен тәмамлау белән, аның алдында да иртәгәдән башлап нәрсә эшләргә дигән сорау туа. Ул елларда колхозда эшләгән кешегә тәүлеккә бер хезмәт көне язып куюдан башка түләү юк иде. Елына кимендә өч йөз хезмәт көне дигән минимумны үтәгән колхозчының йөзе җитәкчеләр алдында ак булуын була, әмма аңа көз көне уныш булгандә, ничә килограмм яки грамм ашлык тиячәге, кем әйтмешли, Ходай кулында. Шуңа күрә киләчәккә карап эш итәргә омтылучылар язмышларын колхоз белән бәйләмәскә тырыштылар. Колхоз эшенә бер керештеңме, аннан ычкынып китүе, ай-һай, бик авыр була торган иде. Кулына паспорт бирмиләр,



*Татарның күренекле шәхесләре арасында. 1976 ел*

ә ансыз сине беркайда да кабул итмиләр. Хатыйп алдына да кая барырга дигән сорау килеп баса. Миргалим абыйсы Таҗикстандагы заводта эшләгән чак иде. Шул туганы аны үз янына дәшә. Әнисе белән уйлашканнан соң, яшүсмер ерак юлга чыга. Татар егетләре кайда да сынатмыйлар бит, аның абыйсы да көньяктагы бу төбәктә яхшы эшләве белән күзгә ташланырга өлгергән. Аның энесенә дә эш табалар. Хатыйп хәтта техник белгечлек буенча укырга да урнаша. Абыйсы, күрәсең, бирелә үзен бик кирәкле кеше итеп таныткан, яше житүгә карамастан, ике-өч ел рәттән аны армия хезмәтенә жибәрүдән котылдырып барганнар. Хатыйпның монда килеп эшли башлавына ел да тулмый, абыйсын көтмәгәндә солдатка алалар. Миргалим Йосыф улы, укый-укый, хәрби юл белән китә, хәтта океан киңлекләрендә йөзгән корабльнең капитаны дәрәжәсенә житә. Бүген дә Севастопольдә хәрби диңгез белгечләре әзерли торган югары уку йортында доцент булып эшләвен дәвам иттерә.

Ихтимал, Хатыйп бирелә укуын ахырына житкерер, тиешле әзерлекле техник-инженер да булыр иде. Әмма әнисе аны үз янына чакырып кайтара. Яңа гына балалыктан чыгып барган улының кайдадыр ялгыз каңгырап йөрүен теләми. Менә Хатыйп яңадан туган якларында. Кулында паспорты булган урта белемле егет колхоз эшенә күңелен салмый. Аны авыл клубына мөдир итеп куялар. Әмма күпмедер дөнья күреп кайткан егетнең күңеле тагын каядыр талпына, тормыш киңлекләренә омтыла. Шушы рухлану Казан дәүләт университетына алып килә. Белем иле аны гомерлеккә үз кочагына ала. Милләтебезнең сүз сәнгатен, телен вә тарихын рус һәм дөнья халыклары рухи байлыгы чолганышында өйрәнү ана үткәнебезгә, бүгенгегә карата булган карашларын фәнни нигездә формалаштыру мөмкинлеген бирә. Уй-фикерләренә, шәриктәшләре генә түгел, остазлары да игътибар итә башлый. Бу егетнең киләчәге фән белән бәйләнәчәгенә өметләре зур була.

Әмма, дүртенче курска житкәч, иң әзерлекле студентларны сайлап, «халык арасына», ягъни мәктәпләргә эшкә юллау шау-шуы кузгала. Авыл мәктәпләрендә яшь буынга белем бирүне шәһәрдәге дәрәжәгә житкерү юнәлешендәге бер кузгалыш ясау була бу. Әдхәт Синугылга — Пермьга, Рәдиф Гатауллинга — Буага, Хатыйп Миңнегуловка исә Пенза өлкәсенә юллама бирәләр. Х.Миңнегулов әлеге өлкәнең Белинский районындагы Качкару авылы мәктәбендә бер кыш укытып та кайта. Әлеге яшьләр бу эштә бик яратып, милләтебез өчен файдалы, кирәкле гамәл үтибез дип,

күтәренке күнел белән катнашалар. Шуннан әйләнеп кайтып, дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, кулларына университет дипломы алалар. Кафедра мөдире, күренекле галим Х.Госман һәм профессор Н.Юзиев Хатыйпка Мәскәүдәге Дөнья әдәбияты институтына аспирантурага китәргә мөмкинлек булуын әйтәләр. Әмма ул мәктәпкә балалар укытуга баруга өстенлек бирә.

Хатыйп кулына Сарман районы Теләнче Тамак мәктәбенә эшкә юллама тоттыралар. Бирегә кайтып төшүе аның күнелендә үзе бер гомерлек истәлек булып калган. Эш шунда: Хатыйп Чаллыга кадәр пароходта кайта. Бу Мәскәү-Уфа арасындагы туристлык теплоходы икән (ничек бу көяз кешеләр генә ял итеп йөри торган су көймәсенә гади кешеләр өчен билет сатканнардыр, монысына хәзергә кадәр гаҗәпләнеп йөри). Биредә университеттагы укытучысы Әнвәр Ахунҗановның да Мәскәүдән үк ял итеп килеше икән. Ул Хатыйпны шунда ук күреп ала, үзе белән баручылар мохитенә ала. Бергә тукланып, табигать белән хозурланып, музыка тыңлап баралар. Ә ул чагындагы музыка, хәзергечә әйтсәк, бары тик тере хәлдә генә уйнала. Биредә унбиш-егерме кешелек оркестр юлның буеннан-буена туристларга затлы әсәрләрне яңгыратып кына торалар. Ул чор кешеләре белә: Әнвәр Мәхмүт улы татар һәм рус телләреннән тыш, чит телләрне дә су кебек эчә, мәдәниятлелеге, аралашырга осталыгы белән аерылып тора. Ул оркестрантлар, бигрәк тә дирижёр белән уртак тел тапкан. Чаллыга килеп җиткәч, оркестрда уйнаучылар, трапның ике ягына тезелеп басып, Хатыйп Миннегуловны җиргә дәртле музыка уйнап төшерәләр. Пароход, Чулман суы өстендә музыка дулкыннарын тибрәтеп, китеп бара. Безнең югары белемле, әмма кесәсе буш яшь укытучы аны офыкта күмелгәнче карап кала. Аның күнелендә алдагы тормышын шушы матур музыкага аваздаш итеп кору хыяллары канатлана.

Чыннан да, Теләнче Тамакта укытучы, Чукмарлыда мәктәп директоры булып эшләгән елларны галимнең үткәнендәге иң романтик вакыты дип карарга мөмкиндер. Бигрәк тә А.Гыйләҗев туган авыл булган Чукмарлыда мәктәп салуны башлап йөрүләр, моның өчен хәтта Казандагы югары даирәләр бусагаларын шактый таптарга туры килсә дә, аның хәтерендә куелган максатка ирешү юлында канатланып эшләү еллары булып һаман да саклана. Әлбәттә, әле яңа гына егерме бишен тутырган, ул вакыттагыча әйтсәк, «перспективалы кадрны» тиешенчә бәялиләр. Район фирка комитетына эшкә алулары шуны күрсәтә. Аңа мәгариф бүлеге мөдире итеп күрергә теләүләрен дә белдерәләр. Хәтта «Нөркәй» совхозына директор итеп билгеләнү мөмкинлеге дә була. Әмма Хатыйп күнеленнән хөрмәтле галимнәрнең ана фән юлыннан китү мәгъкуль булганлыгын әйтүләре һич тә чыкмый. Аның алдында хәтта райкомның идеология буенча секретаре булу юлы да ачылырга тора. Ләкин, күрәсең, алга таба язмышы фән, мәгариф белән бәйләнгән, тумышыннан ук шушы юл «ләүхелмәхфүз»дә язылып куелгандыр кебек. Юкса, хатыны һәм ике баласы була торып, көйләнгән тормышын калдырып, ассистент хезмәт хакы бәрабәренә, гаиләсенең яшәү шартларына зур кимчелек китереп, Казанга күчмәс иде. Шулай итеп, Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында егерме сигез яшәр ассистент барлыкка килә. Дөресендә бу яшьтә инде югары уку йортындагы яшь галимнәр кандидатлык диссертациясе яклаган була, шуңа күрә өлкән укытучы яки доцент вазифасына дәгъва итеп йөриләр. Әмма үз тормышын башыннан ук үзе корырга өйрәнгән, эшчәнлеген оештыруда төгәл һәм нәтиҗәле була белгән Х.Миннегулов бу юлы да чын егет булуын раслый — 1972 елда, XIV гасыр шагыйребез Сәйф Сараи иҗатын өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклый. Берничә елдан соң университет нәшриятында аның әлеге урта гасыр шагыйренең тормышы һәм иҗатына багышланган монографиясе дә басылып чыкты. Әйтергә кирәк, бу хезмәт әдәбиятыбыз тарихын өйрәнүдә ул еллар өчен зур бер табыш буларак кабул ителде. Коллегасы Әнвәр Шәрипов бу унай белән болай дип язды: «Халкыбыз күренекле шагыйрь турында бик аз белә. Бу, әлбәттә, аның иҗатының әле җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуыннан һәм С.Сараи турында бөтендөнья фәнни әдәбиятны тирәнтен өйрәнеп язылган махсус гыйльми хезмәтнең, шагыйрь турында кулга алып укырлык китапның булмавыннан да килә иде. Шушы авыр һәм җаваплы эшне Хатыйп Миннегулов башкарды» *(Шәрипов Ә. Сәйф Сараи иҗатын өйрәнү юлында // Казан утлары. 1978. — №1. — Б.155).*



*«Чыңгыз Айтматов һәм хәзерге төрки дөнья» темасына багышланган халыкара фәнни конференциядә катнашучылардан бер төркем. Уңнан сулга: профессор Рәмиз Әскәр (Баку), Хатыйп Миңнегулов, Төрек Фәннәр академиясе президенты Шакир Ибраев (Астана), Азәрбайҗан Фәннәр академиясе вице-президенты Иса Хәбиббәйле (Баку), профессор Фоат Галимуллин (Казан). Астана, 2013 елның 6 ноябре*

Алтын Урда чорының ин олы шагыйре иҗатын өйрәнүдән башланган эзләнүләр аны татар әдәбиятының Шәрык классик әдәбияты белән тарихи бәйләнешларын тикшерүгә алып килә. Бу эш тагын унтугыз ел вакытны ала. Ниһаять, 1991 елда шушы хезмәте докторлык диссертациясенен нигезенә ятты. Әлеге темага язылган монографиясе («Татар әдәбияты һәм Көнчыгыш классика» (рус телендә), 1993) фән-техника өлкәсендә Татарстан дәүләт премиясенә лаек булды (1995). Мондый унышка бик сирәк галимнәр генә юлыга. Әлеге хезмәт белән җентекләп танышкач, ерак һәм якын үткәннәргә карашыбыз ачыклана төшә, зыялы кеше үзен бимазалаган байтак сорауларга җавап таба. Монография әдәбият тарихын өйрәнү җәһәтеннән генә түгел, бу эшне алып баруга кагылышлы методологик фикерләре белән дә кыйммәтле.

Әйе, халык язмышы һәм аның әдәбияты бер-берләреннән аерылгысыз. Әдәбияты зур булсын өчен, халыкның үз тормышы да бай булырга тиеш, дип әйтүче Х.Миннегулов хаклы. Шәрык халыкларының күпчелеге арасында ерак дәверләрдәге татар әдәбияты үзәк урыннарның берсен алып тора икән, аның ул вакытлардагы чынбарлыгы да шуңа бәрабәр булган. Менә ни өчен Х.Миннегулов хезмәтенең беренче бүлеге «Татарлар һәм Шәрык» дип атала. Татарларның Шәрык дөньясындагы урынын билгеләми торып, аның әдәбияты турында да төпле фәнни сүз алып барып булмый. Бу мәсьәләләр хакында соңгы унъеллыкларда байтак хезмәтләр пәйда булды. Х.Миннегулов нәтиҗәләре алар янында үзләренең эзлеклелеге, фәнни колачлылыгы һәм гаять күп чыганакларга нигезләнүләре белән игътибарны җәлеп итә. Хезмәт алдына куелган төп бурыч — Урта гасырлар татар әдәбиятын Шәрык сүз сәнгате белән үзара бәйләнештә карау. Тикшеренүләрдән килеп чыга торган фикер сөземтәләренең иң мөһиме шул: үзара мөнәсәбәтләрдә милләтләр ирекле эш итәргә тиеш. Фарсы, гарәп, төрки халыклар һәм аларның әдәбиятлары белән нык керешеп яшәгәнбез икән, бу бернинди ирексезләүләрдән башка булган. Мәҗбүр ителү беркайчан да ихлас аралашуларга китерми. 1917 елдан соң урнашкан идеология безгә Шәрык ягына борылып карамаска кушып килде. Х.Миннегулов хезмәте безнең сүз сәнгате тарихын чын асылына кайтаруда бик мөһим бер этап буларак бәяләнде.

Аның мондый хезмәтләре, бәхетебезгә, болар белән генә чикләнми. Х.Миннегуловның галимнәр өчен бик тә кирәк булган бер сәләте бар: ул татар әдәбият белемендә әлегәчә кеше күзе төшмәгән яки шушы эшкә алынырга куллары җитмәгән мәсьәләләрне күреп ала белә һәм шуларны, зур хезмәт куеп, сыйфатлы итеп башкарып чыгуда эзлеклелек, ихтыярлылык күрсәтә. Шулай фидакарьләрчә эшләп, фәнебезне чын объектив хезмәтләре белән баета.

Аның «Котб иҗаты», «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар», «Чит илләрдәге татар әдәбияты», «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» дигән монографияләре, Ш.Садретдинов белән берлектә әзерләнгән «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре», «XIX йөз татар хрестоматияләре» кебек хезмәтләре һәрберсе әдәбият фәне үсешебездәге җитди баскычлар буларак кабул ителделәр. Шулар өстенә ул төзегән «С.Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан», Г.Исхакый. «Ислам мәмләкәтләрендә», Котб.

«Хөсрәү вә Ширин» кебек хрестоматияләр үзләре генә дә никадәр зур эш булды. Аларны гарәп графикасыннан бүгенге язуыбызга күчерү, комментарийларны, кереш мәкаләләрне язу кебек эшләрнең никадәр катлаулы, бөртекләп башкаруны таләп итә торган хезмәт икәнлеген фән дөньясына якын булган һәркем күз алдына китерә ала.

Менә ничә дистә еллар инде урта мәктәпнең IX сыйныф укучылары урта гасырлар һәм XIX йөз татар әдәбиятын ул төзегән дәреслек һәм хрестоматияләр ярдәмендә өйрәнәләр. Шуны ук рус мәктәпләренең X сыйныф укучылары турында да әйтергә мөмкин. Һәр дүрт ел саен янадан басылып килгән ул әсбапларның тулыланып, янартылып торуын тәэмин итү өчен, даими рәвештә шул гамь белән яшәргә, укыту-методика өлкәсендәге һәр яналыкны үзләштереп бару таләп ителә. Бу үзе генә дә шактый көч сорый.

Галимнең фәнни казанышлары хакында әдәбият фәнендә үзләре дә, Г.Тукай әйтмешли, ат уйнаткан Шакир Абилов, Хәләф Курбатов, Фатих Урманче, Рамил Исламов, Резеда Ганиева, Әлфинә Сибгатуллина, Равил Әмирхан, Әлфәт Закиржанов, Азат Ахунов һәм башкалар матбугатта, фәнни конференцияләрдә әтрафлы чыгышлар ясадылар һәм бу хезмәтләрнең чын бәясен күрсәттеләр.

Университетның Х.Й.Миңнегулов эшләгән фәнни-педагогик мохите һәрвакыт бик затлы галимнәрдән торды. Ул Х.Госман, И.Нуруллин, А.Әхмәдуллин, М.Госманов, Н.Юзиев, Т.Галиуллин, Р.Ганиева, М.Бакиров, М.Мәһдиев кебек шәхесләр чолганышында булды. Даими рәвештә аларга тиңләшергә омтылу үзе үк аның фән югарылыкларына күтәрелә баруына уңай йогынты ясады.

Хатыйп Йосыф улының студентларга укыган лекцияләре — аерым бәяләүне сорый торган үзенә бер махсус эш юнәлеше. Аларның бер үк темага булганнары да берсе икенчесенә охшамый. Аудиториясенә, тыңлаучыларның әзерлек дәрәҗәсенә һәм кызыксыну үзенчәлекләренә карап, ул теге яки бу теманың төрле аспектларын сайлап ала, материалны аңлаешлы итеп җиткерүнең иң үтемле алымнарын куллана һәм чыгышын шуларга карап кора. Әмма ахыр нәтиҗә бер булырга тиеш — мәүзугның төп асылын тыңлаучыларга мөмкин кадәр тулырак һәм ачыграк җиткерү. Ягъни лекция уку аның өчен үзе бер иҗади халәт. Болай эшләү өчен тыңлаучыларга җиткерергә теләгәннәренне аркылысын буйга гына түгел, бөтен тирәнлегенә төшеп белү таләп ителә.

Укытучылар белемен күтәрү курсларында да ул даими лектор. Әлеге аудитория тагын да таләпчән. Чөнки андагы тыңлаучыларда югары белем, уку-укыту өлкәсендә бай тәҗрибә бар. Алар лектордан яңа сүз, фәннең соңгы казанышларын бәян итүне көтәләр. Х.Й.Миңнегулов бу аудиториянең дә үз кешесе. Республикадагы укытучыларны ул ничә тапкыр гына үзенең лекцияләре аркылы уздырмагандыр да аларның күпмесе өчен остаз булып әверелмәгәндер. Укуның бу төренә Татарстаннан читтәге өлкәләрдән дә күпләп килүләрен искә алсак, аудитория тагын да киңәя. Аны Төмәндә дә, Оренбургта да, Чувашстанда һәм бик күп якларда яхшы беләләр һәм хөрмәт итәләр. Эшчәнлегенең бу тармагы гына да аны мөгаллимнәр укытучысы итеп танытты.

Чын галимнең шәкертләре, ягъни эшен дәвам иттерүчеләре булырга тиеш, диләр. Х.Й.Миңнегуловның эшчәнлеге бу яктан да нәтиҗәле. Ул дистәләрчә галимнәр әзерләде, аның җитәкчелегендә язып, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклаган затлар да бүген халкыбызның рухи байлыгын өйрәнү, иске мирасны яңа буыннарга кайтару өлкәсендә тырышлык күрсәтәләр. Ул аларга хәзер дә остаз булып кала, аның белән киңәшәләр, ярдәм сорыйлар, ул, киң күңеллелек күрсәтеп, алар алып барган эш юнәлешләре буенча консультацияләр белән булыша.

Галимлекнең тагын бер билгесе — ул да булса аның башка төбәкләрдә һәм чит илләрдәге коллегалары арасында да танылуы, хезмәтләренең билгеле булуы һәм шуларны башкаларның да үз эзләнүләрендә ниндидер таяну ноктасы итеп алулары. Х.Й.Миңнегулов ерак һәм якын чит илләрдә еш була. Төрле фәнни конференцияләрдә төпле докладлары янгырый, теге яки бу мәсьәлә тирәсендә барган бәхәсләрдә, мәслихәтләшү җыелышларында чыгышлар ясый. Татар әдәбиятын дөнья халыкларына танытуда армый-талмый эшли. Әнкарада «Төрки әдәбиятдар тарихы» дигән утыз томлык зур хезмәткә татар әдәбиятына караган күп кенә сәхифәләрне әзерләде. Астанадагы «Төрки академия»дә дә ул үз кеше. Мин моны 2013 елның октябрь аенда Казакъстан башкаласына Ч.Айтматовның 80 еллыгына багышланган халыкара симпозиумга баргач, ачык аңладым. Ул бу форумның үзәгендә кайнады дисәк, бер дә

арттыру булмас. Әлеге халыкара фәнни үзәк, киң тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, ел саен калын-калын томнар чыгара. Аның «Төрки тәрбия», «Төркиләр дөньясы» дип аталган энциклопедия рәвешендәгеләре фәнни җәмәгатьчелек карамагына җиткерелде инде. Аларда Х.Й.Миңнегуловның мәкаләләре дә урын алган. Шушы сериянең өченче томына ана төрки әдәбиятларның барлыкка килүен, формалашуын, үсешен күрсәтүгә багышланган гомумиләштерү характерындагы зур күләмле хезмәт язуны тапшырганнар иде. Ул соңгы айларда шушы бик тә җаваплы эшне җиренә җиткереп башкарып чыгу юнәлешендә тикшеренүләр алып барды. Автор үзе әйткәнчә, бу бик катлаулы бурыч булып чыкты. Чөнки төрки кавемнәрнең сүз сәнгате күп төрле булып, аларның кайберләренең тарихы мең еллар белән исәпләнә. Галим кан кардәшләребезнең гаять катлаулы үткәне, язу культураларының тарихы белән бәйле рәвештә, фольклор һәм мифология катламнарыннан алып язма әдәбиятның үсеш юлын шактый эзлекле күзәтә алган. М.Кашгарыйның «Диване лөгат эт-төрк» дигән хезмәтендә, «Коман мәҗмугасы» сүзлегендә теркәлгән халык авыз иҗаты әсәрләре, «Угызнамә», «Идегәй», «Манас» кебек әсәрләр аша урта гасырларның төрки әдәбиятларын бергә җыеп карауга килә. Й.Баласагунлының «Котадгу белек» әсәренең сүз сәнгатьләребез үсешенә ясаган тәэсирен билгели. Бу юлда ислам диненең, изге китабыбыз «Коръән»нең тәэсирен күрсәтүгә аерым игътибар итә. Хуҗа Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Низами Ганҗәви һәм Шәрыкның башка бөекләре иҗатларының замандашларына, үзләреннән соңгы шагыйрьләргә булган йогынтысы күп кенә мисаллар белән ачыклана.

Әлбәттә, татар әдәбияты галиме буларак, Х.Й.Миңнегулов үз шагыйрьләребез Кол Гали, Харәзми, М.Болгари, Х.Кятиб, С.Сараи, Ә.Үргәнҗи һәм башкаларның иҗатын Шәрык сүз сәнгате мохитендә карауга аеруча игътибар итә. Автор күләм мөмкинлек биргән дәрәҗәдә төрек классик әдәбиятының бөек әдипләре иҗатын шәрехли. Аларның татар милли рухына үтеп керүләренең әһәмиятен ассызыклый. Әдәби тәэсир-йогынтының XIX йөз — XX гасыр башындагы торышына иркен игътибар ителү хезмәтнең отышлы ягы диясе килә. XX йөздә дә төрки халыкларның мәдәни аралашлыгы хакында сүз алып бару өчен күпмедер җирлек барлыгын күрсәтеп бирүен дә уңышлы дип кабул алабыз. Әлбәттә, галим төрки халыклар әдәбиятларының барлык чорлардагы үсеше гарәп, фарсы сүз сәнгатьләре белән нык керешкән булуын искәртеп барырга онытмый. «Төрки сүз сәнгате» дигән әлеге хезмәтен март урталарында аерым бер китап хәлендә ул коллегаларына да җиткерүгә ирешне. Аның бу өлгерлеге һәм кулына алган эшен ахырына кадәр җиткерүдәге үҗәтлеге барыбыз өчен дә үрнәк булып тора.

Соңгы көннәрдә генә галимнең тагын бер яңа китабын кулга алып сөендек. Ул «Төрки-татар, антик һәм рус әдәбиятларының үсеш адымнары» дип атала. «Ихлас» нәшриятында рус телендә чыккан уникиде табаклык бу китап күп мәгълүмат сыйдыруы белән игътибарны җәлеп итә. Хәзер бездә дә, дөнья әдәбиятларында да әдәби үсешне чорларга бүлеп карау мәсьәләсе тирәсендә бәхәсләр бара. Хәтта бу турыда махсус халыкара сөйләшүләр дә уздырыла. Х.Й.Миңнегулов Казакъстанда шундый форумда махсус доклад белән дә чыгыш ясаган иде. Аның бу мәсьәләләргә ачыклык кертергә омтылышында нинди җирлеккә таянганлыгын да әлеге китаптан ачык күрәбез. Конференцияләрдә ясалган доклад ул галәттә галим күңеленнән узган фикер агымының бер өлеше генә була. Бу очракта без айсбергның күренми торган өлешләре белән дә танышабыз. Икенче бүлекнең исеме үк авторның төрки әдәбиятлар үсешен билгеле бер эзлеклелектә күрсәтергә теләвенә ишарәли. «Йосыф Баласагунлыдан Чыңгыз Айтматовка кадәр» дип аталган бу бүлек «Төрки сүз сәнгате» дигән хезмәтнең нык кинәйтелгән һәм үстерелгән варианты буларак кабул ителә.

Кыскасы, галим, мөгаллим, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Хатыйп Миңнегулов 75 яшьлек юбилеен яраткан хезмәте белән мәшгуль булып каршылый, якыннарының, хезмәттәшләренең, йөзләрчә шәкертләренең, фикердәшләренең җылы карашы, ягымлы мөнәсәбәте аны бәхетле итә. Бусы — иң мөһиме.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Хәтер. Язучылар һәм җәмәгатьчелек вәкилләре Муса Җәлил һәйкәле янында. Үткән гасырның 70нче еллары.*



*Хәйретдин Мөҗәй (1901-1944), язучы, хәрби эшлекле – полк командиры. 1944 елны Дахау концлагеренда җәзалап үтерелә.*



*Нәби Дәүли (1910-1989) – шагыйрь, публицист, язучы. Ватан сугышы чорында әсирлек газапларын кичергән шәхес. Н.Дәүли шигъри митингта чыгыш ясый. 1983 елның 26 апреле.*



*«Казан утлары» журналының редколлегия әгъзаларыннан бер төркем. Алгы рәттә (сулдан уңга): Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Әмирхан Еники; басып торалар – Рафик Нәфиков, Атилла Расих, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Гали Халит. 1968 ел.*



*Ватан сугышында катнашкан соңгы могиканнарның берсе, Татарстанның халык язучысы Хисам Камалов (1926). 2004 елда төшерелгән фото.*



*1976 елда Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган бәйрәм бөтен ил күләмендә зурлап уздырылды. Шул тантаналарда катнашкан кунаклар һәм татар язучылары Пушкин һәйкәле янында.*

# УЛ КУРГАШЫН СОЛДАТ БУЛМАГАН



29 мартта отставкадагы полковник Зәки Минабетдин улы Низамов дөнья куйды.

Кем соң бу полковник? Дөньяда аның нинди эзе калган? Моны аңлар өчен нәкъ житмеш ел артка чигәргә кирәк безгә... 1944 елның 11 маенда Сталин Дәүләт Оборона комитетының Кырым татарларын сөрү турындагы карарына кул куя. Һәм 18 майда тулы бер халыкны товар поездларына төйи башлыйлар. Тиз арада җыенырга һәм бик аз әйбер генә алырга кушыла сөрелүчеләргә.

Бу хәлләрне без хәзер мәшһүр «Хайтарма» фильмы аша да күз алдына китерә алабыз. Фильмда кайгылы ыгы-зыгы эчендә кайнаган халык массасы булып артистлар түгел, халык үзе — теге афәтне балалар яки үсмерләр килеш кичергән кардәшләребез һәм аларның балалары, оныклары уйный. «Хайтарма»ны «фильтрлы» залда («закрытый показ») мәскәүләр дә карый. Журналист Е.Ардабацкая болай дип язган: «Люди, пережившие депортацию, принесли с собой на съемки вещи, которые тогда были с ними. В кадре мелькают то швейная машинка, то Коран, завёрнутый в полотенце...» *(«Электронное периодическое издание... «МК.ru»)* Тегү машинасына «Комсомольская Правда» журналисты Г.Сапожникова да дикъкать иткән: «Один кадр тронул меня до слёз: во всеобщей суматохе старик тащит на плече швейную машинку — оказалось, ту самую, которую успела в самый последний момент схватить его мама, и которая их в Узбекистане спасла от голода!» *(2013, 18 июнь)*

Журналыбызда «Кырым татарлары фаҗигасе» дигән мәкалә чыгарган *(2013, №5, 6)* Х.Исмәгыйлевкә шушы ананың оныгы белән сөйләшү насыйп була. «Картәниләрне алып китәргә килгән солдат бик яхшы кеше булган, — дип сөйли Зиләрә ханым. — Картәнигә әйткән: «Әби, бик алама эшләр. Сезне хәзер бик еракларга алып китәчәкләр. Шуңа күрә тормыш көтәргә иң кирәкле һәм иң кыйммәтле әйберләрегезне алырга тырышыгыз», — дигән... Картинәм теге солдатка гомере буе рәхмәтләр укыды...»

Могҗиза инде бу: исемен беркем белмәгән «теге солдат» исән булып чыкты һәм аның белән Казанда ук күрешеп сөйләштем мин! Әңгәмәбез узган елның сентябрь санында басылды. «Бер калерле нәрсәгезне дә калдырмагыз, тегү машинасын обязательно алыгыз!» — лейтенант Зәки Низамов шулай дигән теге вакытны. Башка хәрбиләр алган әйберне приклад белән суга-суга ташлатканда бит бу. «Бик уңайсызланып килдем мин бу авылга, — диде Зәки агай. — Сталиннарның юньсезлеге өчен дә, үзем өчен дә оялып». Партиягә кандидатлыкны да ташларга тели ул хәтта, ләкин тыелып кала — сугыш барганда, мондый эш өчен аны стенага терәп аткан булырлар иде. Әмма, инде 60нчы еллар башында бу, тагын бер гаделсезлеккә тап булып, партиядән барыбер чыга ул. «Әҗере» зурдан була моның: башта төрмәгә үк тыгып, аннан 9 ай психбольницада яткыралар.

Хәрби вазифасын бик шәп башкара Зәки агай. Киев хәрби округы командующие аңа хәтта шәхси «ТТ» пистолетын да бүләк итә. Ләкин һәр кушканны сукырларча үти торган кургашын солдат та булмый ул, погонында йолдызлар саны арту-артмауга да исе китми аның. Ике тапкыр: «Мине кую дөрес түгел!» — дип, хәтта шәп акчалы югары постлардан да баш тарта әле. Бармы хәзер түрәләр арасында шундый затлар?

Зәки абый туксан яше тулып, ярты ел үткәч дөнья куйды. Әңгәмәбез чыккан санны *(2013, №9)*, «Хайтарма»ны карау белән, аның режиссёры Әхтәм Сәйтаблаевка тапшырдым мин. Тик Кырымдагы кардәшләребездән сәлам алып, аларга ялганып өлгермәде шул агаебыз...

**Рәфикъ ЮНЫС**

# «САГЫНУ»НЫ САГЫНЫП...



Мөнирә Булатова... Бу исемне ишетүгә, үсмер малай чагымнан бер күренеш җанлана...

...1945 елның көзе иде булса кирәк — яңа арыш ярмасыннан ботка пешереп, сугыштан кайткан туганыбыз Әхмәтсафа абзыйны ашка алдык...

Без аны «шәкерткәй» дип йөртә идек. Ни өчен алай атауның сәбәбен белмим. Тик шунысы хак: холкы һич кенә дә «шәкертләрчә» түгел иде. Үзе гармунда уйнап җырларга ярата, аракысын да эчә, тәмәкесен дә тарта, ишеткән һәр сүзен бәхәс аша уздыра. Кыскасы, «холыксыз Сафа» дигән икенче кушаматына бик тә тәңгәл холыклы иде.

Сугыштан нык үзгәреп кайтты ул: күкрәге тулы орден-медальләр, гармун уйный торган уң кулы кашык тотарлык та түгел — яралангач, бәрәнге төя торган тукмакка охшап калган; сул күзен кара төстәге күн белән каплаган, борыны да китек, өстәвенә аксый да.

Кыяфәте үзгәрүенә күрә холкы да үзгә: ни сөйләсә дә, соңыннан елау һәм җырлау белән тәмамлана. Гармун уйный алмавын бик авыр кичерә.

— Бераз хәлләнгәч, сул кул белән уйнарга өйрәнмәсәм, исемем Сафа булмасын! — дип әнкәйләргә сүз бирә дә җырларга тотына. Озак утыра ул шыңшып, сызланып. Әткәй дә, әнкәй дә бер-берләренә карашып, туктатмакчы булалар. Ә шәкерткәй анын саен репертуарын төрләндерә генә бара.

Күбрәк русча җырларга тырышуы хәтердә. Арада татар көйләренә охшаганнары да ишетелгән кебек була. Әмма кайсы көй икәнен танырлык булмый иде. Анын шулай утыруына бераз вакыт дәшми түзсәләр дә, ахырда әнкәй әйтергә мәҗбүр була:

— Әхмәтсафа, җырласаң, кеше тыңларлык җырлар да җитәрлек бит, үзебезнекеләрне җырла! — ди.

Шәкерткәйнен йөзе ничек үзгәрүне тасвирларлык сүзләр табалмыйм: сыңар күз карашы, мылтык көпшәсенең мушкалы башын хәтерләтеп, атарга төбәлгән кебек. Кемгә икәнен генә белми шикелле иде. Шул белмәве безне коткаргандыр да — ул тагы шыңшый, тагы сызлана.

Аннары кинәт тукталып:

— «Тёмная ночь» үзебезнеке түгелме? «Землянка» ошамыймы? «Сагыну» безнеке түгелме? Ә? Ешшу как безнеке әле! Әйтсәм әйтим: беләсегез килсә, «Сагыну» мине үлемнән алып калды!

*Бик сагындым, дустым,*
*Бик сагындым сине,*
*Әле дә ничек түзам мин...*

Түлке калган сүзләрен белмим... Самолёт улавы аркасында ишетмичә калынды, отып кала алмадым...

— Бездә анын тәлинкәсе бар, Әхмәтсафа, патефуны гына күптәнге, энәсе беткән, гыжлый, чыжлый...

— Давай монда! — энәсен үзебез эшләп уйнатабыз! Машина энәгез бардыр бит: кисәбез дә куябыз!

— Юк шул, машинаны ачлыкта... саттык...

— Патефонын саклагансыз, молодцы.

— Алучы булмады. Патефун кирәк идеме ул чак...

— Үзем алам! Чыгарыгыз! «Сагыну» өчен күпме сорасагыз да жәл түгел! Ул минем коткаручым!

Шунда ул үзе белән булган бер хәлне сөйләде...

— Каты яраланып госпитальгә эләккәч, 1944 елның августында булса кирәк, «Татарстан артистлары концерт куярга килгән», — дигән хәбәр таралды дип башлап китте Әхмәтсафа абый. — Ул чакта безнең санчасть Эстониянең Выру шәһәре янындагы урманда урнашкан иде...

Концерт, йөк машинасының кузовында гына узды. Төрле частьларны бергә жыймыйлар, конспирация, һәр часть өчен аерым концерт. Бу күчтәнәчне III Балтыйк буе фронты солдатлары өчен генә диделәр.

Гарипләнгән булсам да, үземне үзем йөртә алам, рөхсәт алып, урман аланына артиллеристлар өчен оештырылган концертка киттем. Аннары танкистлар өчен була диделәр концертны. Анысына да бара идем, тик мин бу концертны тыңлаганда, бомба төшеп, яральілар белән тулы госпиталь һәлак була. Аларның барысын диярлек күреп белә идем.

Йөздән артык кешенең гомере өзелә шунда. Әгәр мин ул кич сорап, концертка китмәгән булсам, палаткамда калган булсам, бүген монда кунак булып, ботка ашап, бал эчеп утырыр идемме?! Юк! «Сагыну»ны мин шунда ишеттем. Понял? Аны туган ил исеменнән, әниләребез, сеңелләребез, кәләшләребез исеменнән Мөнирә Булатова дигән артистка жырлады:

*Бик сагындым, дустым,*
*Бик сагындым сине,*
*Әле дә ничек түзәм мин...*

— Сүзләре алай гына түгел, — диде әнкәй, әлеге жырны белгәнлеген сиздерергә теләп...

— Сагышны аңлату өчен сүз кирәкми, жинги, йөрәк кирәк, йөрәк!...

Озак яттым мин лазаретларда күз белән. Берсеннән икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә күчереп тагы өч ай йөрттеләр. Өч ай эчендә мин бу жырны өч йөз ярапыга өйрәттем. Сүзләрен һәркем үз телендә үзе язып жырлады. Марилар — марича, чувашлар — чувашча, руслар русча. Ихластыр, әйбәт чыга иде. Лазареттан терелеп китүчене хор белән жырлап озата идек.

Гомерем булып, Казанга барып чыксам, ул жырчыны күреп, фронтовиклар исеменнән рәхмәт әйтергә тиешмен. Аның жырын тыңлап, исән калуымны ул белергә тиеш!

...Бара алмады Әхмәтсафа абзабыз Казанга, сул кулы белән гармун уйнарга да өйрәнә алмады — сугышта алган яралары аны мәңгелек йортка алып китте.

Муса Жәлил сүзләренә Заһид Хәбибуллин язган «Сагыну» жыры фронтовик татарлар өчен генә түгел, гомумән, солдатлар өчен музыкаль символ ролен үтәгән. Мөнирә Булатованың патефон тәлинкәсенә язылган бу жырының фронттагы роле турында генерал Фатих Булатов менә нәрсә дип яза:

*«...1944 елның августы, сугышның Польша жирендә барган чагы иде. Безнең дивизия Острув-Мозовецкийны алгач, дошман чигенә башлаган вакыт. Шунлыктан дивизия штабы да, бер урында озак тормыйча, алга баруын дәвам итә иде. Менә шунда һич көтелмәгән бер вакыйга килеп чыкты. Таш гаражда, карта буенча фронттагы хәлне тикшергәндә, адъютант Котов миңа кәгазьгә төргән бер түгәрәк*

*әйбер бирде. Төргәкне ачсам, патефон пластинкасы. «Мөнирә Булатова башкаруында Заһид Хәбибуллинның «Сагыну» җыры. Муса Җәлил сүзләре... — дип язылган. Үзем дә сизмәстән бу бүләкне күкрәгемә кыстым. Шатлыгымның чиге юк иде.*

*— Каян таптың бу хәзинәне?*

*— Мина аны поляк кызлары китерделәр...*

*Бу пластинканың Польшага килеп чыгуы мине шактый гаҗәпләндерде. Ул кызларның аны каян алганнарын белергә уштым. Адъютант кире чыгып йөгерде, ләкин кызлар киткән иде инде.*

*— Иптәш генерал, бу пластинка Польша татарларыныкы микән әллә? — диде Котов. — Хәтерегездәме, Польша җиренә килеп кергәч, сез гарәпчә язылган бер дини китап бите тапкан идегез? Димәк, аларның диннәре дә мөселман дине, телләре дә татарча булса кирәк. Ихтимал, бу пластинканы Казаннан алдырганнардыр.*

*— Әйе, булган иде шундый хәл. Мин, чыннан да, ниндидер бер дини китап бите тапкан идем. Ихтимал, Котов хаклы булгандыр. Югыйсә, татар пластинкасы монда ничек килеп эләксен, ди?*

*...Ничек кенә булмасын, ул пластинканың кулга төшүе минем өчен бик зур шатлык иде һәм мин Котовка тизрәк патефон табарга куштым да тагын алга юнәлдек...*

*Кечкә бер урманда землянкага урнаштык. Немец генералы яшәгән һәм шуннан Острув-Мазовецкийны сакларга боерыклар биреп яткан землянка иде ул. Өч бүлмәдән торган шул землянканың өсте биш кат юан бүрәнәләр белән капланган, һәр бүлмәгә үзенә аерым төстәге чуар кәгазьләр ябыштырылган һәм ишеге төбенә клумба ясалып, анда чәчәкләр утыртылган иде.*

*Әйе, немец генералына Польша табигате, аның нарат урманнары, кин елгалары бик ошаган булса кирәк. Ул фашизм теләгенә тиңдәш булырлык барлык кабахәтлекләрне эшләгән һәм, җинелмәм дип уйлап, киләчәк «бөек» Германиясе белән хыялланган. Биредә ул «Атла кояш чыгышына» дигән җырны тыңлаган һәм шуңа куанып утырган. Ләкин ул җентекләп җиһазландырылган шушы зур землянкасына татар генералы кереп, аның патефонында татар җырчысы Мөнирә Булатова башкаруында татар көен тыңлар дип бер вакытта да уйламагандыр...*

*Менә трофей патефонда «Сагыну» көе ишетелә башлый:*

> *...Бик сагындым, дустым,*
> *Бик сагындым сине,*
> *Әле дә ничек түзәм мин...*

*Бу һич көтелмәгән куанычлы җырны мин генә түгел, барлык иптәшләрем йотылып тыңлый башладылар. Украин, рус, чуваш, мари егетләренең барсының да моңнары уртак иде, күрәсең. Пластинканы ничә мәртәбә әйләндергәнбездер, белмим, санамадык. Аны әле һаман, һаман тыңлыйсы килә иде, ләкин, вакыт беткәнгә күрә, патефонны ябып куйдык.*

*Польша урманнарында фашист гаскәрләре белән сугыш алып барган көннәрдә танылган композитор һәм күренекле артистка башкаруында татар халкының яраткан моңнарын ишетермен дип кем уйлаган?! Ә бит шулай булды һәм бу минем өчен зур шатлык иде.*

*Шул көннән башлап «Сагыну» пластинкасы юлдашыма әверелде. Хәтта сугышның беренче көненнән үк минем адъютантым булып йөрүче булдыклы, батыр һәм житез украин егете Иван Петрович Котов та ул көйне аккордеонда уйнарга өйрәнде»... («Совет әдәбияты», 1964 ел, №6, 109 бит)*

Җыр — үз вазифасын үтәрлек чын җыр икән — ул милли-сәяси чикләрне дә, телдәге аермалыкларны да тикшереп тормый — адресатына барып ирешә: җырлана да, тыңлана да, яратыла да.

...Муса Җәлилнең соңгы көннәре турында материаллар табу максатында 1967 елда шагыйрь Сибгат Хәким Германиягә сәяхәт кыла. Герой-шагыйрь турындагы кыйммәтле бер ядкәр-истәлек буларак, немецлар Сибгат Хәкимгә шул «Сагыну» пластинкасын куеп тыңлаталар...

Бу турыда шагыйрь:

*Берлинда дуслык йортында*
*Уйлап-уйлап таң калдым.*
*Тагын да көчлерәк яңгырый*
*Җыры читтә татарның.*
*Җырда ул илаһи бер көч,*
*Җырга икән сал моңын...*
*Тыңлый немецлар Мусаның*
*Пластинкада «Сагыну»ын.*

*Муса да тыңлый: җырлый бит*
*Булатова Мөнирә...*
*Очраштылар, елаштылар*
*Карамыйча бернигә.*
*Мондый бәйрәм сирәк, бәйрәм*
*Ничә елга бүген бер.*
*Очраштылар, елаштылар,*
*Кыска икән бу гомер...*

— дигән тирән эчтәлекле шигырь язган.

Сибгат абыйның «Кыска икән бу гомер» дигән фикере белән килешмәү мөмкин булмаса да, кайбер иҗади шәхесләр әсәрләрендә яшәүләрен дәвам итсәләр дә, җырчылар турында «алар пластинкаларда яши» дип кенә әйтү дөреслеккә бик үк туры килми. Җырчының сәнгатьчәнлеге аның җырында гына түгел, ә җыр аша тудырган образында. Җыр — образның бер канаты булса, икенче канаты — опердагы партиянең, ягъни рольнең «сверхзадача»сы — максаты. Ә «сверхзадача»ны дирижёр да, режиссёр да, кайчан куелуга карап, кайда куелуга карап, җырчының үзе белән бергәләп билгелиләр. Опера җырчысының сәнгате, гомумән, артист сәнгате буларак, бары тик тамашачы белән турыдан-туры контактта гына туа һәм яши. Ул мизгелләр көнелләрдән көнелләргә генә күчә ала. Аларны тотып калу, дәвамлы итү ихтималы юк. Аларны бары тик тоеп кына, тәэсирләнеп кенә була. Аңлау да, аңлату да, кирәк булса, икенче мәсьәлә.

Тамаша залы белән сәхнә арасындагы тәэсирсез җырланган җырлар — алар тавыш белән ясалган сурәтләр. Сурәтләрнең матурлары була, бердәнберләре, кабатланмас даһи ясалганнары да очрый. (Эскизлар һәм копияләр турында сүз бармый.) Сакланган материаллардан күренгәнчә дә, шаһитларның истәлекләреннән чыгып та шуны әйтеп була: Мөнирә Булатованың уникаль тавышы белән иҗат ителгән «рәсемнәре» сокландыргыч оста эшләнгәнлекләре белән дә, җырлау технологиясенең «безупречный», ягъни тел тидергесез булуы белән дә алыштыргысыз оригиналь җыр үрнәкләре булып калалар һәм шулай сакланырлар да.

Әгәр безнең буын тамашачысы Мөнирә Булатованы радио аша тыңлап яисә телевизорлардагы язмаларын күреп кенә белә икән, опера артисты турында фикер йөртергә хакы бармы соң дигәндә, фикер йөртергә хакы булса да, бары тик җырның һәм җырлаучының үзенчәлекле кайбер сыйфатлары турында гына; артист иҗаты турында да, образлары турында да сүз алып баруның нигә мөмкин булмавы алда әйтеп узылды.

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Мөнирә Булатова замандашлары өчен кем булган да хәзерге буын тамашачысы өчен кай ягы белән үрнәк шәхес буларак кадерле? Шәхсән мин аның опералардагы партияләренең кайберләре белән таныш булсам да, кызганыч, спектакльләрдә күреп,тыңлый алмадым.

1957 елның җәендә, декада вакытындагы хушлашу концертында һәм, Казанга кайткач, төрле юбилей концертларында гына күреп тыңлау насыйп булды миңа җырчыны.

Репертуарында, нигездә, Көнбатыш классик опералардан арияләр булса, милли композиторларыбызның романслары һәм музкомедияләре белән операларыннан үзе башкарган рольләрнең арияләре иде алар.

Дөресен әйтергә кирәк, опералар тыңлап үсү эләкмәгәнлектән, концертларда ишетеп кенә Мөнирә Булатова сәнгатенә профессиональ бәя бирүдән бигрәк, мин аның җырлавын ишеткән һәм залның ничек кабул итүен күргән бер шаһит буларак кына әйтә алам: концертларда бер иш халык шашып кул чапса, нигә кул чабалар икән, дип аптырап утыручылар да була иде.

Хәзер аңлавымча (минем карашка), сәбәбе — башкарылган ариянең «Сабагыннан өзелгән гөл» булуында. Икенчесе — опера сәнгатенә безнең милләттә чын мәхәббәт кабынып китә алмавындадыр. ...Ни өчен опера сәнгатенең мил-

ләтебездә ерактан килгән кунак кебек кенә каралуын Тукаебыз болай аңлата: *«...Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бер төрле хосусият бар кеби. Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп вә авызны бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәкъбүл түгел. Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы һәм бераз уен коралы авазына охшашрак булуы вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы кабул ителгән һәм күркәм күренә. Мәсәлән, мин дөм чукрак булып та, җырлап утыручы бер татарның авызына карасам, мин аны җырлый дип белмәс, бәлки бернәрсәне кызу-кызу сөйли икән дип хөкем итәр идем. Әгәр дә шул чукрак хәлемдә бер русның җырлап утырган хаӆенә карасам, мин аның авызының ертылганчы ачылуыннан вә үзенә көчлек килүеннән, шиксез, бу җырлый дип уйлар идем. ...Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, аллә ничек шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көебезнең алтынын кояр шикелле тоела».*

Шагыйребез турыдан-туры опера җырчыларына карата әйтмәсә дә, аның бу сүзләрен милләт сүзләре дип кабул итүебез бик табигый. Безнең җырыбыз да, җырлавыбыз да үзгә. Опера сәнгате, бик гүзәл сәнгать булса да, чыгышы белән безнең милләтнеке түгел. Ул — килгән сәнгать.

Алай карасаң, рәсем сәнгате дә читтән кергән, сынчылар да татарда XX гасыр уртасында гына үзләренең барлыгын сиздерәләр...

Ә опера турында узган гасырның беренче чирегендә генә сүз алып барсалар да, 1926 елда, ягъни революциянең 10 еллыгына инде беренче опера язылып куела да! Шуннан башлана да инде. Нәҗип Җиһанов җиде опера иҗат итә, Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Хөснул Вәлиуллин, Салих Сәйдәшев белән Александр Ключарёв опералары сәхнәгә менә. Боларның барсында да һәм әле тагын музыкаль комедияләрдә дә Мөнирә Булатова җаваплы партияләрне башкаручы! Моннан тыш актрисаның Европа классикасы һәм рус опералырындагы партияләре: «Кармен»да — Кармен, «Риголетто»да — Маддалена, «Фауст»та — Зибель, «Чио-Чио-Сан»да — Сузуки, «Евгений Онегин»да — Ольга, «Пиковая дама»да — Полина һәм Графиня һәм башкалар...

«Концертларда тамашачының бер өлеше Булатованы алкышлар белән каршыласа, икенче өлеше моңа гаҗәпсенеп карый иде», — дидем дә хәзер уйланып утырам: артистның максаты алкыш алумы, әллә тамашачыны уйга салумы?Бу соравыма җавапларны мин артистканың иҗатын күреп сокланган сәнгатькярләрнең хатларыннан табам: уйландыру! Мөнирә Булатовага адресланган хатлар күп булса да, аларны әлеге язма кысаларына сыйдырып булмый. Шулай да ике бөек шәхеснең хатыннан өзек китерми булдыра алмыйм. Бакый Урманче яза: *«Калерле Мөнирәкәй! Сезгә хат язуны бер зур шатлык итеп һәркөн күңелемдә ташыйм. Кайвакытта хәтта язылачак җөмләләремдә бөтен сүзләре белән күңелемдә әзер була, ләкин теләгемне эшкә иңдерә алмыйм. Һаман кичектерәм, хат бик озын булыр төсле күренә. Аны кайда язармын, кайчан язып бетерермен? — кебек вак-төяк сәвальләр комачаулый. Янә язмый калам. ...Аннан соң әлеге «курку» да мине һич ташламый. Ул «курку»ның мәгънәсе... бик катлаулы... Ихтимал, кайчан булса да, ул курку турында мин сезнең белән бүлешә алырмын...»*

Бу — Булатованың Тугзагын тыңлагач язылган хат.

Мондый хатны гашыйк булган кеше генә язар кебек. Әмма Бакый Урманче — сынчы-иҗатчы. Актрисаның үзеннән бигрәк, аның сәнгатенә, иҗатына гашыйк! Даһи рәссам, бәлки, тагы нindidер хатлар язгандыр — аларын белмим, әмма шунысы шаккатыра: ул Мөнирә Булатованың портретын хәтердән ясый. Бу инде, концерт карагач, кул чабу гына түгел, хөрмәтле укучым. Бу — сәнгать! Могҗиза!

Икенче хат Нәҗип Җиһановтан. Дөресен әйткәндә, бер-берсе белән көн дә диярлек очрашып торган кешеләр арасында хат язышу — сирәк очрый торган хәл. Бу — бер кечкенә генә язу кисәге. Әмма ләкин бик «характерлы язу»: *«Мөнирә ханым! Бу пустякны минем иҗат кичәсендә җырласаң, бигрәк яхшы булыр иде. 21.11.1956 ел. Нәҗип һәм шуна өстәп ноталар белән җыр тексты».*

Бу — галилек, дуслык, эшчәнлек, ышаныч символы булырлык язу. Даһи композитор җырчыдан үзенең яңа язган «Сиреньнәр хуш ис тарата» җырын башкаруны үтенә. Яхшы булачагына ышанып сорый. Бу романс соңыннан Мөнирә Булатованың



Иҗади очрашудан соң. Уртада — Мөнирә Булатова

«фирменный» жырына әверелә.

Гаҗәп бу «сәнгать» дигән тылсымлы дөнья: татар опера һәм балет театрының музеенда бер картина саклана. Анда алты композитор арасында бер жырчы — Мөнирә Булатова сурәтләнгән. Композиторлардан Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарёв, Җәүдәт Фәйзи һәм рояль артында Нәҗип Җиһанов утыра. (Жырчының иң якын сердәше һәм фикердәше композитор Рөстәм Яхинның ни өчен юклыгын бүген сиземләсәк тә, рәсми документлары булмагач, әйтә алмыйбыз.) Картинада Мөнирә Булатованың композиторларыбыз уртасында ялгыз булуы — композиция таләбе генә түгел, ә чынбарлыкның реаль чагылышы ул. Шулай барган ул чак музыкаль тормыш. Булатова сораган, композиторлар аның һәр соравын, һәр үтенечен жиренә житкереп үтәргә тырышканнар һәм үзләрен бәхетле санаганнар. Рәсемдә шул чорның шагыйрьләре дә булган булса — бу бүген иң кыйммәтле полотнолардан саналыр иде. Шагыйрьләргә никтер урын тапмаган сурәтче. Ә жыр бит башлап шагыйрь күнелендә ярала!

*Күгемдә җемелди йолдызлар,*
*Таңнарым алсулы, зәңгәрле.*
*Тик берәү, тик берәү аңлар күк*
*Миндәге ярсулы хәлләрне,*

— дигән юлларга имзаны Мөнирә Булатова орбитасында әйләнгән һәр шагыйрь куяр иде. (Бусы да кул чабу гына түгел!) Жырчы-артист репертуарындагы күп жырлар һәм романсларның шигырь авторлары Әхмәт Ерикәй белән Мостафа Ногман булуын белсәләр дә:

*Кич утырып сиңа хатлар язам,*
*Йолдыз яна минем күгемдә.*
*Балкып янган йолдыз таңда сүнә,*
*Ә син һаман минем күгемдә.*
*Гомерлеккә ярым булмагачтын,*
*Нигә сөйдем сине, акыллым?*
*Нинди сулар сибеп сүндерим соң*
*Йөрәгемнең янган ялкынын?..*

— дигән юлларга авторлыкны дәгъвалап, Мөнирә Булатова жырлавын тыңлаган күп ир-егетләр көрәшкә чыгар иде.

Ирләрдән генә торган иҗат төркемендә бер талантлы жырчы хатын-кызның үз булып, аралашып йөрүе, онытылмас жырлар, романслар тууга турыдан-туры йогынтылы сәбәп булса да, үзара мөнәсәбәтләре саф дуслык кысаларыннан читкә



Бертуганы Суфия һәм кызы Дания белән. 1971 ел.

чыкмаган. Мәхәббәт булган, яшәгән, яшәткән, иҗат иттергән, берләштергән. Кавышу, кавыштыруларны гына чит иткән ул мәхәббәт.

Эшенә, профессиясенә ничек тугрылыклы булса, мәхәббәттә дә Мөнирә Булатова «однолюб» булып калган, хисләр ташкынын иҗатына хезмәткә юнәлтә алган.

Аларның Бакый Урманче белән булган озын гомерле ихлас дуслыгы талантларның үрнәк мәхәббәте дип аталырлык мөгамәләләр рәтеннәндер.

Ә инде Рөстәм Яхин белән Мөнирә Булатова дуслыгы турында, аерым әсәрләр иҗат ителсә дә, гаҗәп булмас иде. Чөнки заманыбызның даһи композиторы җырчыга ихластан ышана, ана таяна, аны тыңлый. Романсларын иң элек аннан гына җырлата. (Кул чабу түгелме бу?) «Киек казлар», «Дулкыннар», «Күңелемдә яз», «Китмә, сандугач», «Оныта алмыйм» кебек җәүһәрләр шул иҗади дуслык җимеше булу гаҗәп түгел.

«Күңелемдә син», «Аңлыйм, дустым», «Серле кичләргә», «Ни сөйли урман», «Иделкәем минем», «Күңелем өзгәләнгән минутларда» җырлары туганда, җырчы белән композитор хезмәттәшлеге сәнгатькә җаваплылыкның күргәзмә дәресләре булырлыклар.

Композитор Рөстәм Яхинга карата Мөнирә Булатова: «Минем өчен кадерле һәм якын дус кына түгел, миңа кирәк булуын белеп туган талант ул», — дигән.

Мөнирә Булатованың бүгенге җырчыларга үрнәк булырлык сыйфатларыннан берсе — авторларына карата булган тирән хөрмәтедер.

Шигырь авторларын түгел, көй авторларын да әйтмичә, үз исемнәрен генә калкытып күрсәтүче замана җырлаучылары эстраданы тутырган гамьсез һәм комсыз бу чорда Мөнирә Булатованың композиторга да, шагыйрьгә дә партнёр-иҗатчы дип кенә түгел, ә рухи туганы, имандашы итеп каравы соклангыч. Чыгышында катнашкан һәр иҗатчыга үз тиңе итеп караган, сүздә дә, җырда да, тормышта да рухи тугандашларына «җил-янгыр тидертмәскә» тырышкан, яклаган, саклаган.

«Бары-югы уртак» мәкале — Мөнирә Булатованың холык ачкычы, ягъни «пароле» булгандыр кебек.

*Үткәндә кичергән*
*Кайгылар, газаплар*
*Барысы да онтыла.*
*Барсы да җуела.*
*Төн үтеп, күңелле*
*Көн тугач, азактан*
*Берсе булмаган*
*Шикелле тоела.*

*Ах, ләкин онытылмый*
*Гомергә, гомергә*
*Электә татыган*
*Шатлыклар, рәхәтләр —*
*Яндырып йөрәкне,*
*Саклана күңелдә*
*Кадерле минутлар,*
*Бәхетле сәгатьләр.*

Әлеге романсны аеруча яратып башкарган ул. Аның «бәхетле сәгатьләре»н дә, бәхетсезләрен дә җырчы узган сикәлтәле тормыш юлларында күрәбез.

Талантлы шәхесләрнең халык мәхәббәтен яулау юлын өйрәнгәндә, тәрҗемәи хәлләренә тукталгач, иң элек аларның ата-аналары кем булуга, кайда туып-үсүләренә игътибар ителә.

Мөнирә Булатова — күп балалы, эшләп үзләрен-үзләре туендырган һәм киендергән гаиләдән. Әтисе Закир белән әнисе Шәфикамал Бикбулатовлар

чыгышлары белән Казан-Мәскәү тимер юлының Төрләмә станциясеннән ерак булмаган Кармыш авылыннан. Хәзер ул авыл «Янгилде» дип аталып, Чувашстанның Козловка районына керә. Җирләре Яшел Үзән районы җирләре белән чикләнсә дә, Кармыш халкы Татарстан авыллары белән аралашуда чикләргә карамыйча, Шырдан, Ачасыр, Күгәй халкы белән кыз бирешеп, кыз алышып-туганлашып яшиләр. Закир абзый да, Шәфикамал апай да эзләнүчән, тынгысыз җаннар булганнардыр, күрәсең, бәхет эзләп, тимер юл узган күп җирләрдә кәсеп итәләр алар. Вятка (хәзерге Киров) белән Архангельск шәһәрләрендә дәвамлыракка тукталып эшлиләр. Шул ерак Архангельск шәһәрендә гаиләнең биш баласы туа.

Закир абзый оста итеп гармунда уйнап, җырга сәләтле булса, Шәфикамал апа исә тегү, чигү эшләренә һәвәс була.

Архангельск шәһәрендәге татар мөһаҗирләре вәкилләреннән Газиз Айдарский оештырган үзешчән театраль труппада артист буларак төрле спектакльләрдә катнашып, Закир Бикбулатов танылуга ирешә. Әмма ул, төп кәсебе — сәүдәгәрлекне ташлап, сәнгатькә генә хезмәткә күчә алмый...

...Коммерциядә эчкерсез, гадел кеше буларак, ул партнёрларына артыграк ышанып, «ярык тагарак»ка утырып кала, ягъни алдана; башлаган эшләре уңышсызлыкка очрый, шул чордагы «НЭП»чылар телендә әйткәндә, «Закир Бикбулатов ширкәте яна». Театр җене, музыка чире кагылган Закир Бикбулатов, сәүдә-коммерция өлкәсендә сагалаган һөҗүмнәргә әзер эшмәкәр булмаган, күрәсең, Шәфикамалны биш бала белән тол калдырып 1925 елда вафат була.

Мөнирә — 1914 елда туган өченче кыз бала. Әтисе үлгәндә, ана нибары 11 яшь, бер энесе Госманга 3 яшь, төпчек энесе Шамилгә әле бер яшь тә тулмаган була.

Биш баланың бишесен дә ятимлекләрен сиздерми үстереп, җәмгыятьтә үз урыннарын тапкан гражданнар итеп тәрбияләп, укытырлык мөмкинлекләрне ничек һәм каян табуы турында уйланганда, Шәфикамал апа Ана Даны орденына лаек. Ике улы да Ватан сугышына үз теләкләре белән китәләр. Ана ризалыгы белән, әлбәттә. Шамил «Советлар Союзы Герое»на тәкъдим ителгәч, герой исеме килеп өлгергәнче, самолёты һавада икенче самолёт белән бәрелешеп, һәлак була.

Мөнирә апаның һәр туганы — аерым китап язылырлык бай тормыш юлы үткән шәхес. Бу язмада сүзебез халык артисты Мөнирә Булатова турында гына. Артистлык оеткылары Мөнирәгә әтисе Закирдан күчкән булса, һәр эшне җиренә җиткереп һәм яхшы сыйфатлы итеп башкарырга кирәклек геннары әнисе Шәфикамалдандыр. Тол калган Шәфикамал кара хәсрәткә салган Архангельск шәһәрендә озак яши алмасын сизенеп, туган авылына кайтып төпләнә. Авылда йорт-җирне ныгытып, мал-туар булдырып, гаилә үзен-үзе карап яши башлагач кына, илдә күмәк хуҗалыклар төзү компаниясе башлана. Көчле ихтыярлы эш сөяр гаилә башы Шәфикамал беренчеләрдән булып «колхозга языла», язылып кына калмый, озакламый аны яна төзелгән «Карл Маркс» күмәк хуҗалыгының беренче рәисе итеп сайлыйлар.

1927 елда ук республика хатын-кызларының I съездына тавыш бирү хокукы белән сайланган делегатның 1929 елда рәис итеп сайлануын авыл халкы хуплап каршылый. Аны туры сүзле, гадел, вәгъдәле булуы өчен хөрмәт итәләр. Ләкин Шәфикамалга балаларын үстереп, олы юлга чыгаруы мөһимрәк. Ул Казанга күченү ягын карый. Сәбәбе дә бар: Янгилдедә дүртенче классны тәмамлагач, ана кеше Мөнирәне элекке «Казанский» санаториесе тирәлегендәге интернатка урнаштырган була. (Соныннан ул берничә приютны берләштергән «Балалар шәһәрчеге»нә әверелә.) Шәфикамал балалары хакына Казанга күчеп, калган гомерен балаларын тәрбияләүгә багышлый.

«Балалар шәһәрчеге»ндә кызчык музыкага тартыла, җырларга ярата, үзешчән спектакльләрдә катнаша. Аның сәләтлелеген күреп, тәрбиячеләр һәм педагоглар чыгарылыш тәзкирәсенә, ягъни свидетельствога өстәп, имтихансыз музыка техникумына керергә юллама бирәләр. Шатланып, рәхмәт әйтеп, музыка буенча белемен чарларга китәме кыз? Юк! Ул үзенең музыкаль сәләтенең чынлыгына ышанмый. Барлык үзен белгән-күргән кешеләрне таң калдырып, гаҗәпләндереп, Вахитов исемендәге Җиркомбинатка, киез итек басу фабрикасына химик-лаборант булып урнаша. Алты ел эшли ул анда. Эшләп тапкан икмәкнең тәмен шунда



*«Алтынчәч» операсында Түгзак Ана. 1960 еллар.*

татый. Шунда — Жиркомбинатта, тагы жырга, музыкага тартыла. Ләкин бу тартылу инде вакытлы мавыгу гына булмый.

1934 елдан Мөнирә Булатова — көнчыгыш музыкаль техникумында кичке бүлек студенты. 1936 елда укытучылары аны Мәскәү консерваториясенең опера студиясенә укырга җибәрергә дигән карарга киләләр. Профессор Райский — комиссия әгъзасы — Булатованың тавышын сирәк очрый торган меццо-сопрано («чудесный, бархатный голос») тавыш икәнен һәм аны Мәскәү педагоглары гына укытырга тиешлегенә республика җитәкчеләрен ышандыра.

— Бармыйм! — ди Мөнирә. — Мин әле яңа гына 95 сум хезмәт хакы ала башладым, аны югалтасым килми! Миңа Казанда кичке техникумда уку да бик җиткән! — ди.

Анасы Шәфикамал апа ризалашырга, барырга куша. Мөнирә исә: «Ярты ел укып карыйм да, бер эш тә барып чыгарлык булмаса, комбинатыма кире кайту шарты белән генә барам», — ди. Ризалашалар! Китә Мәскәүгә Мөнирә Булатова. Укый. Концертларда катнаша. Яңа ачылган опера театрының җырчы артисты булып Казанга кайта. Эшли! Җырлый!

Нинди операларда нинди рольләрне башкаруын, нинди партияләрне җырлавын, ничек җырлавын тасвирлаган мәкаләләр бик күп. Мондый язмада олы талант иясенең тәрҗемәи хәленнән иң мөһимнәрен сайлау бик авыр. Чөнки мәшһүр артистканың озын иҗади гомерендә булган вакыйгаларның һәркайсы әһәмиятле. Алар ниндидер хәлиткеч роль уйнаган очраклар.

Сүземне Мөнирә Булатованы фронтта очраткан туганым хатирәләреннән башлавым да тиккә түгел. Фронтовик сугышчылар каршында 77 концертта катнашуы белән ул үзе дә сугышчы-фронтовик. Үзе катнашмаса, җыры белән катнашуын артистканың фамилиядәше — генерал Булатов та раслады.


Алдымда Мөнирә Булатова катнашында опера театры сәхнәсендә куелган спектакльләрнең афишалары, программалар, театр адресына, артистка исеменә килгән йөзләгән телеграммалар, котлаулар, чакыру хатлары. Аларны акыл иләге аша үткәргәндә, гади татар авылы кызының опера сәнгатендә ирешкән уңышлары, гомумән, татар милләте, татар хатын-кызлары ирешкәннәргә җанлы мисал икәнен аңлап була.

Милләт аның хезмәтләрен онытмасын өчен, варислары бүген нинди гамәлләр кыла? Әллә инде кыла алмаудан гаҗизләрме? Аның дәрәҗәсендәге сәнгатькярләрнең исемнәрен мәңгеләштерү максатыннан, урамнарга бирәләр, җыр сарайларын алар исемнәре белән атыйлар. Булатова фамилиясе беркайда да мәңгеләштерелмәгән.

Ә бит ул халык артисткасы гына түгел — заманында берничә чакырылыш депутат та, театр директоры да, ВТО председателе дә булган олы шәхес. Мин — аның ВТО председателе чагында артистлар йортын төзү өчен көрәшеп йөргән чакларын, тиешле оешмалардан тиешле имзаларын алуга ирешкәч, шатлануларын күргән кеше. Бүген ул төзеткән Актёрлар йорты гөрләп эшли һәм ул башка кеше исемендә. Шик тә юк, лаеклы кеше исемендә. Әмма Актёрлар йортын төзүгә дә, төзетүгә дә аның катышы ни дәрәҗәдә? Алар икесе дә күптәннән мәрхүмнәр. Намуслы кеше буларак, Актёрлар йортына исеме куелган шәхес тә, исеме куелмаганы да гүрләрендә рәнҗеп яталардыр кебек. Бу хакта уйлансак иде...

**Әхтәм ЗАРИПОВ,**
*режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

# МӘСКӘҮДӘ ТУГАН ҖЫР



Муса Җәлилнең үз кулы белән язылган «Сагыну» шигыре. 1936 ел, сентябрь. *Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 10 ф., 1 тасв., 236 сак.берәм.*

1934 елда татар опера театрына кадрлар әзерләү максатында Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе ачыла. Татарстаннан җибәрелгән композитор, музыкант, җырчылар янына ул вакытта Мәскәүдә яшәгән Муса Җәлил һәм Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы училищеда укыган Заһит Хәбибуллин да кушыла (чыганакларга караганда, студиягә кадәр алар аралашмаган). Якыннан аралашу, уртак дәресләр, зур максатлар – иҗат кешеләрен берләштерә, табигый бәйләнешләр туа. Мәгълүм булуынча, нәкъ студиядә укыган чорда Муса Җәлилнең байтак шигырьләренә Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин җырлар яза. Кайбер шигырьләрне композиторларга Җәлил үзе тәкъдим иткән булса, кайберләре, киресенчә, алар үтенече белән языла. «Сагыну» җыры – күпсанлы җырларның берсе, шуңа да аның эзенә төшү бик үк җиңел булмады, студиянең төп максаты опералар иҗат итү булганга, Муса Җәлил архивында да, музыка белгечләре язмаларында да бу чор күбрәк «Алтынчәч», «Ирек», «Качкын», «Галиябану» әсәрләре язылу тарихы аша күзаллана.

«Сагыну» җырының сүзләре 1936 елның сентябренә карый, шигырь Җәлилнең «Җырлар» дәфтәренә кергән, аның төп нөсхәсе бүген Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында саклана. Бер кульязмада икенче строфадагы «иртән» сүзе урынына «тиздән» дип язылган. Шигырь турында башка мәгълүматлар юк. Аның язылу тарихы да, кемгә багышлануы да билгеле түгел. Әдипнең биштомлыгын басмага әзерләүче галим Зөфәр Мөхәммәтшин безнең сорауга: «Сагыну» шигыренә бәйле фактлар юк дәрәҗәсендә. Шигырьнең язылу датасына карап, Әминәгә багышланган булуы ихтимал, дип әйтергә мөмкин. Ләкин аның бу елларда шактый хатын-кызлар белән аралашуы, аларга атап күп кенә мәхәббәт шигырьләре язуы да мәгълүм», – дип ассызыклады. Шигырь илһамчысы төгәл ачыкланмаса да, музыка язуга этәргеч биргән хатын-кыз билгеле. Ул – Уфа кызы Мәрьям Карамышева. Заһит Хәбибуллинның беренче хатыны, замандашлары күзаллавынча, тәүге мәхәббәте дә. Опера студиясендә укыган вакытта композитор гаиләсе янына еш кайтып йөри алмый, чакрымнарны әнә шул җыр якынайта.

Ләкин эзләнә торгач, «Сагыну» җырына кагылышлы башка фаразларга да юлыктым. «Муса Джалиль и татарская музыка» китабында Йолдыз Исәнбәт болай дип яза: «Октябрьнең 20 еллыгы унаеннан, студиялеләргә иҗади заказлар бирелә.

Җәлил композиторларга 9 яна шигырь иҗат итә». Музыка белгече фикеренчә, «Сагыну» – әнә шул тугыз әсәрнең берсе. Җырчы Халидә Зәбирова истәлекләрендә «Сагыну» җырының дөньяга килгән мизгелләре сурәтләнә: «Студиядә укыган вакытта без Кызыл мәйдан янындагы тулай торакта яшәдек. Табигый инде, ашарга үзебез, чиратлашып пешерә идек. Көннәрнең берендә, Заһит Хәбибуллин дежур көнне, янына Муса килде, композитор плитә яныннан китмичә генә ниндидер җыр көйли, дустына туктаусыз нидер сөйли. Ләкин артык мавыгып китеп, ашның ташуын сизми калалар, мин орышам. «Халидә, аш кайгысымыни монда? Заһит нинди матур җыр язган, тыңлап кара әле! Миңа калса, ул меццо-сопрано өчен!» – дип аклана Муса. Аннан безнең бүлмәгә кереп, Заһит пианино артына утырды, ә Муса тәрәз янына басты. Мәскәү кичкә кергән мизгел. Җырны тыңлап бетергәч, Муса: «Миңа калса, текстка бераз үзгәрешләр кертергә кирәк», – диде, һәм әкрен генә җырны үзе суза башлады. Мин дә кабатлауларында аңа кушылам. Икенче көнне Муса текстның эшләнеп беткән вариантын алып килде. Заһит Хәбибуллинның иң популяр әсәре нәкъ шулай туды».



Заһид Хәбибуллинның Муса Җәлилнең «Сагыну» шигыренә язган көй ноталары.
*Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан.*

Халидә Зәбирова әлеге җырны сәхнәләрдән башкаргандырмы, юкмы, истәлекләрдә бу турыда язылмаган. Ләкин «Сагыну»ны бөтенсоюз киңлегендә беренче булып яңгыраткан, тамашачы күңеленә сукмак салган җырчы – Мөнирә Булатова. «Счастье сцены» китабында моң иясенең әлеге җырга кагылышлы мондый сүзләре бар: «Студиядә укыган вакытта концерт, очрашулар еш үтә иде. Аларның күбесен Муса Җәлил оештыра иде. Ул вакытта сәхнәгә чыгу минем өчен зур сынау, мин бик каушый, ояла, курка идем. Шундый кичәләрнең берсендә «Сагыну» белән чыгыш ясыйм. Ничек җырлавымны хәтерләмим, ләкин пәрдә артына җиткәч, тамашачы алкышлар белән кабат сәхнәгә чакыра башлады. «Беркем дә мине кабат чыгарга мәҗбүр итә алмаячак», – дип калтыранып торганда, сәхнә артындагылар этә башладылар, мин – карышам, нәтиҗәдә, сәхнәгә артым белән чыктым... Бу минем иҗатымдагы беренче «бис»ым булгандыр...»

«Сагыну» җырчы биографиясендә башка «тәүге»ләр белән дә бәйле. Мөнирә Булатованың Бөтенсоюз радиосында беренче тапкыр чыгыш ясавы да нәкъ менә «Сагыну» җыры белән була. Җырчының 1938 елда чыккан тәүге пластинкасында да – «Сагыну». Әлеге пластинканың үз тарихы. Пластмасса тәлинкә аша «Сагыну» Бөек Ватан сугышында һәрбер өйнең, һәрбер парлының төп җырына әверелә, символ дәрәҗәсенә күтәрелә.

Еллар уза... «Сагыну» җырына кемнәр генә мөрәҗәгать итми, кайсы җырчылар репертуарына гына керми... Нечкә моңы, лирикасы белән җәлеп итә ул, күпләр аны халык җыры дип атый. Ирексездән немец композиторы Рихард Штраус сүзләре искә төшә: «Композитор өчен иң зур бәхет – биш-ун елдан җырның халыкныкына әйләнүе, авторларның онытылуы». «Сагыну» – «ике кешенең күңел тавышы»ннан туып, халыкныкы булып яшәгән, бүгенге көндә татар музыкасының алтын фондын тәшкил иткән бәхетле әсәрләрнең берсе.

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА,**
**филология фәннәре кандидаты**

# ИКЕ ХАЛЫКНЫҢ БЫЛБЫЛЫ

Житмешенче елларда Алматыда миңа анын белән ике мәртәбә очрашып, озаклап сөйләшеп утырырга насыйп булды. Ә узган гасырның илленче елларында мин Актүбә шәһәрендә дүрт ел укыдым. Шул дәвердә исә аның җырларын, симфоник әсәрләрен, опералардан арияләрен радиодан еш тыңларга туры килгән иде. Ул шәһәрдә яшәүче күп санлы милләттәшләребез аны, «үзебезнең кеше» дип, еш искә алырлар иде. Шуннан соң композитор белән Казанда да күрешкән идек. Опера театрында узган ниндидер тантаналы кичәдән соң якташым Җәүдәт ага Фәйзинең, җитез хәрәкәтле, юкарак гәүдәле юлдашына күрсәтеп: «Латыйф Хәмиди агаң булыр», — дип, аның белән таныштыруы хәтеремдә. Шул вакытларда әле ул туган-үскән якларына еш кайтып йөрде. Якын күргән, Мәскәүдәге опера студиясендә бергә укыган дусларыннан Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин һ.б. әле ул вакытта сау-сәламәт, ныгытып иҗат итәләр. Музыкаль әсәрләре сәхнәдән төшми уйнала. Халык күңеленә якын булган җырлары һәр кичәдә диярлек башкарыла килде.

Л.Хәмидинең берничә әсәрен дә Казанда оештырылган әдәби-музыкаль кичәләрдә бик еш кабатладылар. Тамашачылар аеруча аның татар һәм казакъ моң, аһәнен бергә кушып иҗат иткән «Былбыл» җырын яратып кабул итәр иде. Ул җырны бездә иң оста башкаручы Нажия Теркулова, соңгы дәвер казакъ илендә Бибигөл Теләгәнева була. Муса Җәлил сүзләренә язылган «Уныш җыры» («Беренче вальс») белән казакъ совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган Сабит Муканов шигыре нигезендә иҗат ителгән «Казакъ вальсы» да заманында бик популяр иде.

Латыйф Хәмиди бик тә үзенчәлекле композитор. Балачак гомерен Урта Азиядә, татар, казакъ һәм үзбәк арасында үткәргән. Аның татарча яңгырашлы көй-моңнарына тугандаш казакъ һәм үзбәк кардәшләребез аһәңнәре дә кушылып, көйне баетып җибәрә. Шундый күренешнең үзенчәлекле чагылыш үрнәге буларак әлеге шул мәшһүр «Былбыл» җырын, «Казакъ вальсы«н һәм «Беренче вальс»ны атап үтәргә кирәктер. «Татар бию көйләре сюитасы» да бик үзенчәлекле әсәр. Ләкин 90нчы еллардан соң ул бездә башкарылмый шикелле.

***

Казакъстан ССРның халык артисты Латыйф Хәмиди белән Алматыда беренче очрашуыбыз көтелмәгәнчә килеп чыкты. Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге 1974 елның октябрь урталарында мине Казакъстан язучылар оешмасына эш белән җибәрде. Үзара арадашлык җепләрен ныгытырга, татар язучыларының әсәрләрен Казакъстанда, казакъларныкын Татарстанда бастырып чыгару мөмкинлекләрен ачыклый төшәргә дип. Октябрь ае ул елларда матбугатка әбүнәчеләр туплау-барлау чоры да бит. «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян» журналларына андагы кардәшләребез ничек языла, ул республикада әбүнәчеләребез саны күпме — шуларны да ачыклап кайтырга кушылган иде. Ул дәвердә казакъ кардәшләребез илендә дүрт йөз мең чамасы татар кешесе яшәде. Матбугатка язуны оештыручы идарәгә бардым. Анда: «Сезнең якташлар газета-журналларга бик теләп язылалар. Безнең үзәк идарәдә дә, өлкәләрдәге идарәләрдә дә татар хатын-кызлары байтак эшли, подписка чорында алар сезнең матбугатны таратуда бик актив катнашалар. Татар журналлары бездә казакъ телле журналлардан ким таралмый», — дип, бик сөендереп җибәрделәр. «Казакъ әдәбияты» газетасында «Казан утлары»ның киләсе ел эшчәнлегенә багышлы кыскача язмам да урнаштырылды.

Ул заманда казакъ, үзбәк кардәшләр мәмләкәтләрендә гомер итүче милләттәшләребез

*Ахыры. Башы узган санда.*

әле туган-үскән илләре белән тыгыз элемтәдә яши, газета-журналларны да ярыйсы ук арзан хакка алдыра ала иде. Әйтик, житмешенче елларда «Казан утлары»на язылу хакы жир читендәге Владивостокта да, Казандагы кебек үк, алты сум гына тора иде шул...

Әлбәттә, Алматыга баргач та иң әүвәл Язучылар берлеге йортына юнәлдем. Берлек идарәсе рәисе Әнүәр Әлимжанов белән элегрәк Мәскәүдә бер очрашкан идек. Ул башлыча тарихи эчтәлекле әсәрләр язды. Котлымөхәммәт Тәфкилевне баш каһарманнарның берсе итеп сурәтләгән «Хәбәр китерүче» (русча «Гонец» исеме белән басылды) романын бүләк тә иткән иде. Шул ук елларда мин аның Һиндстанны яулаган Бабур нәселе вакыйгаларын да чагылдырган «Отрар хатирәсе» повестен тәржемә дә иттем. Димәк, ул мина бераз таныш кеше иде.

Әнүәрнең киң, иркен эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Иң элек ул хатынының да безнең милләт вәкиле булуын, шуна күрә татар мәдәнияте, татар әдәбияты белән аеруча нык кызыксынуын бәян итте. Татарстан белән Башкортстаннан килгән бер генә артистның да чыгышын карамыйча калмыйбыз, Илһам Шакиров белән Ренат Ибраһимов жырлавын бигрәк тә үз итеп тынлыйбыз, Мәскәүгә барган саен берәр татар китабын алмыйча кайтмыйм, дигән иде.

Сонрак, казакъ дуслар белән якыннанрак аралаша башлагач, Совет чоры зыялы катламының байтагының теге яки бу рәвешле үз халкым вәкилләре белән кан-кардәшлек дәрәжәсендә икәнлеген дә ачыклаган идем. Бер-беребезне дус күреп йөрешкән күренекле язучылардан Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Сатимжан Санбаев, Морад Әүэзов, Әнәс Сараев шундый шәхесләрдән иде. Аларның, үз жәмәгате булмаса, анасы яисә әбисе безнең милләт вәкиле. Ә картрак буын зыялылары арасында андый кушма канлы гаиләләр тагын да күбрәк. Социалистик Хезмәт Батыры исеменә лаек булган язучы Габит Мөсреповның жәмәгатен дә Мәскәүдә үскән татар кызы дип әйтәләр иде. Галимнәр, композиторлар, артистлар арасында да андый кушма канлы гаиләләр ишле иде ул елларда.

Әлбәттә инде, Әнүәр белән язучылар оешмалары эше, китап, журнал нәшриятлары эшчәнлеге турында да сүз булды. Сөйләшә-сөйләшә озаграк та утырганбыз, ахрысы. Чәй касәләре тотып бүлмәгә кабат кергән секретарь ханым:

— Сезне анда Композиторлар берлеге рәисе көтеп утыра. Керсенме? — дип сорады. Әнүәр:

— Керсен. Безнең яшерен сүзебез юк, — диюгә бүлмәгә бик сөйкемле бер ханым килеп керде. Зифа буйлы, мөлаем кыяфәтле, уртача яшьләрдәге бу ханымга Әнүәр минем кем булуымны әйтте:

— Лирон Хәмидуллин. Казаннан...

— Газизә Жубанова, — диде ханым күрешкәндә.

Әхмәт Жубанов дигән композиторны ишетеп белә идем. Ул Актүбәдән ерак булмаган Тимер станциясендә туган. Л.Хәмиди белән бергә берничә опера язган шәхес.

— Композитор Әхмәт Жубанов турында ишетеп тә, укып та белә идем. Ул бит Актүбә өлкәсеннән... Сез дә шул нәселдәнме? — дидем. Ханым елмаеп торган арада Әнүәр болай диде:

— Әйе, мәрхүм Әхмәт ага Газизәнең атасы була. Хәзер ул атасы вазифаларын башкара — композиторларның житәкчесе һәм данлыклы консерваториябез ректоры.

Газизә дә сүзгә кушылды:

— Сез композитор Латыйф Хәмидине беләсезме? — диде.

— Беләм. Казанда бер күрешкән дә идек. Ул бит сезнең әтиегез белән бергә берничә опера язган...

Газизә минем ничә көнгә килүемне, кайда тукталуымны белеште.

— Ерактан килгән кунак, үзәктә, Опера театры янәшәсендәге кунакханәгә урнаштырдык, −дип, минем өчен Әнүәр җавап бирде.

— Бүлмә номерыгызны да әйтмәссезме?

Ни өчен сораганын ачыклап тормастан, мин ул ханымга бүлмә номерын әйтеп бирдем. Һәм, ике житәкченең сөйләшер, киңәшер сүзләре бардыр дип, саубуллашып чыгып киттем. Ә кичен, тамак ялгап, бүлмәмә кереп утыруга, кемдер шылтырата:

— Лирон Хәмидуллин буласызмы сез? Хәзер мин килсәм, сөйләшеп утыра алабызмы? Латыйф Хәмиди аган булам, — ди.

Димәк, Газизә Жубанова минем кунакханә номерын Латыйф агасының күңелен күрү өчен сораган булган икән. Фамилиямне дә кат-кат белеште: Хәмидуллин белән Хәмидинең үзара якынлыгын да истә тотуы булгандыр, күрәсең.

Латыйф ага кунакханәгә бик тиз килеп житте. Кулында төргәк-төргәк йөзем, алма...

— Мин бит Опера театрына янәшәдәге Түләбаев урамында гына торам. Моннан ерак түгел. СССРның халык артисты мәрхүм Мукан Түләбаев белән дә иҗатташлар, дуслар идек. Казакъстан гимнын да бергә эшләдек. Өченче автордаш итеп соңрак Брусиловскийны беркеттеләр...

***

Латыйф ага Татарстанның хәзерге Кайбыч районына кергән бер авылда 1906 елда туган. Жиде яше тулмастан үзбәк кардәшләребез иләндәге Каттә Курган шәһәрендә яшәгән. Шунда укыган елларында ул — мандолина, 1917 елдан соң ачылган музыка мәктәбенә йөргәндә, фортепьяно уйнарга өйрәнә. Тиздән илдә зур үзгәрешләр башлана. 1918 елның апрелендә Ташкентта Хәмидуллиннар яшәгән төбәктәге милләтләр мәнфәгатен кайгыртырга тиешле Төркестан Совет Автономияле Республикасы оештырыла. Ана хәзерге казакъ иленең көньяк-көнбатыш өлеше, үзбәкләр яшәгән жирләрнең төньяк төбәкләре кергән. Дөрес, тиздән барлыкка киләсе СССР жирлегендә иң беренче булып оешкан бу автономияле республиканы совет хакимияте соңрак никтер сирәк искә алды. Чөнки ул «кирәгеннән артыграк» үзбаш булды сыман. 1940 елда басылган «Страна социализма» исемле калын рәсми белешмәлектә ул да, 1920 елда оешкан Казакъ автономияле республикасы да телгә алынмыйлар. Моның сәбәбен, бәлки, Төркестан милли мохтариятен оештыручыларының, шул исәптән аның рәисе «милләтче» Турар Рыскуловның да 1937-38 елларда юк ителүләре белән бәйләргә кирәктер.

1919 елда Төркестан республикасының Мәгариф халык комиссариаты житәкчесе итеп татар язучысы Шәһит Әхмәдиев билгеләнә. (Башка бик күп житәкче оешмаларга да безнең милләттәшләр килә. Әйтик, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укып житлеккән Кәрим Хакимев тиздән Төркестан АССР коммунистлары башлыгы булып китәчәк.) 1920 елда автономиянең башкаласы Ташкентта төрки милләтләрне берләштергән Белем йорты эшли башлый. Татар, үзбәк, казакъ бүлекләре булган Халык мәгарифе институты ачыла. Латыйф Хәмиди дә әлеге институтка укырга керә һәм аны 1926 елда тәмамлый. Институт укытучылары арасында безгә мәгълүм шәхесләрдән Габдерахман Сәгъдине, Гыйбад Алпаров, Кәбир Бәкер, Зариф Бәшириләрне очратып булган. Һади Такташ та берара ул тирәдә күренеп ала.

Әлеге Мәгариф институты белемгә сусаган яшьләрне дә әллә кайлардан үзенә тарта. Бервакыт бу Белем йортында Мохтар Әүэзов та күренгәли башлый. Оренбургта оешкан казакъ мохтарияте житәкчеләренең берсе бу. Кызыклы хикәяләр дә язучы «комиссар Мохтар» белән шушы еллардагы танышлыгы яшь музыкант Латыйфның киләчәк язмышында зур эз калдырачак.

Л.Хәмиди өчен әлеге Белем йортында узган еллар ижади чыныгу, аякка басу еллары була. Шул дәвердә ул кайбер сәхнә әсәрләрен музыкаль «бизәү»дә катнаша. Шунда аның беренче көйләре туа. Мәдәният-сәнгать кичәләрендә аларны ул сәхнәдә үзе дә мандолина һәм фортепьяно уйнап күрсәткәли. Монда таратылган жилем басма «Белем йорты» журналында үзбәк Гафур Голәм, казакъ Мохтар Әүэзов, Һади Такташ һ.б. шагыйрьләрнең шигырьләре белән янәшә Л.Хәмидинең язма ижат үрнәкләре дә урын ала. Әдәбият укытучысы Габдерахман Сәгъди аның киләчәктә шагыйрь буларак танылалуына шикләнми.

Әйе, шушы институтта укыган һәм шушы үзенчәлекле мохиттә яшәгән чорда Л.Хәмидинең тәүге жырлары жырлана башлый. Ул монда татарча «Беренче вальс» көен ижат итә. (Соңрак ул көй Муса Жәлил сүзләре белән Мәскәүдә, «Октябрь баласы» журналында «Уңыш жыры» исеме белән басылып чыгачак.) Муса Жәлил белән алар беренче тапкыр Казанда, 1924 елның жәй башында очрашачаклар. Латыйфның ижади үсешен күзәтеп торган милләттәшләре ана Казанга барырга, яңа ачылган Шәрекъ музыка техникумына укырга керергә киңәш итәләр. Институт житәкчесе, унынчы еллардагы «Шура» журналында байтак шигырьләре басылган

ижади фикерле Габдулла Мостакаев та ул тәкъдимне хуплый. «Бар, тәвәккәллә», — дип киңәш итә. 1924 елның язында Латыйф ерак юлга җыенып чыгып китә. Ләкин сәфәре уңышлы булмый, аны техникумга кабул итмиләр.

***

Институтны тәмамлау таныклыгы алганнан соң, ул Мәскәү музыка техникумына керергә ният кыла. Бу вакытта инде аның Кәттә Курган музыка мәктәбендәге укытучысы, мандолиначы да булган остазы Гыймад Тимербулатов та Мәскәүгә кайтып төпләнгән була. Латыйфны ул Мәскәүдә якын күреп кабул итә. Мәгълүм Әсәдуллаев йортындагы үз фатирына урнаштыра. Беренче Мәскәү музыка техникумының композиторлар әзерләү бүлегенә кабул ителеп, тулай торакка күчкәч тә, Латыйф Гыймад агаларына бик еш килеп йөри. Көз көнендә бер килүендә ул шушы йорт тирәсендә Муса Җәлил белән кабат очраша. 1927 елда Муса да Мәскәүгә укырга дип килгән, Әсәдуллаев йортында яшәүче элекке танышы Дәүләтшиннарга фатирга төшкән икән. Ике күренекле шәхеснең иҗади дуслыгы шушы көздән башланып китә. Һәм дистә еллап дәвам итә.

Алар шул чорда популяр булган берничә җырның көен һәм сүзен бергә язалар. Башлыча яшьләргә һәм укучы балаларга багышланган «Комсомол җыры», «Көз җитте», «Күңелле яшьләр», «Ленин турында җыр»ны. Аларны яшьләр урамда да, уку йортларында да бик яратып җырлыйлар. «Кызыл очкыч җыры» да, марш буларак, күпләр күңеленә хуш килә, ә «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы?» романсы татар көенә яңалык алып килүе белән истә кала. Латыйф Мәскәүдә яшәүче Әхмәт Ерикәй шигырьләренә дә берничә көй иҗат итә. Ул җырларның күбесе Муса Җәлил редакцияләгән журналларда басылып та чыга.

Л.Хәмиди 1931 елда техникумны тәмамлый. Әмма эшеннән һәм дусларыннан аерыласы килмичә, Мәскәүдә яшәп кала. Бу вакытта инде ул «Октябрь баласы» журналының музыка бүлеге мөдире була. (Журнал 1932 елның декабрендә ябылганчы.) Шул ук Әсәдуллаев йортында урнашкан татар мәктәбендә җыр дәресләре дә алып бара, милли телләрдә китаплар бастыра торган «Центриздат» белән дә хезмәттәшлек итә. Казакъстанга эшкә билгеләнгәч кенә аның Мәскәүдәге дуслары белән арасы бераз сүрелә төшә.

Беренче мәртәбә Казакъстанга эшкә билгеләнүенең сәбәпләрен Латыйф ага миңа болайрак аңлаткан иде. Бердән, ул элек Урта Азиядә яшәгән, андагы төрле милләт вәкилләре белән аралашкан. Шундагы халыкларның гореф-гадәтен, телләрен белә. Латыйф ага, шул сүзләрен раслагандай:

— Казакъ дуслар хәзер дә әле: «Ташкентка барып төшү белән үк, үзбәккә әвереләсең», — дип шаярткалыйлар, — дип әйтеп куйган иде.

Икенчедән, үзәк тарафыннан казакъ мәдәниятен торгызуга зур әһәмият бирелгән чор була бу. Утызынчы еллар башында Казакъстанның Алма-Ата, Кызыл Урда, Семипалатинск кебек эре шәһәрләрендә бер-бер артлы берничә милли театр оештырыла. Опера театрын нигезләү турында карар кабул ителә. Һәм ул 1933 елда ачыла да.

— Казакъ иле өчен мондый тизләтелгән чаралар нилектән килә? Белмисез шул сез... Мондагы утызынчы елгы ачлык афәтен дә, халык күтәрелешен дә Рәсәйдә белүчеләр юк. Бездә дә ул хакта берни дә язмыйлар. Аларны язарга да, сөйләргә дә ярамый. Боларны мин сиңа сер итеп кенә әйтәм...

Әйе, казакъ, кыргыз халкының 1916 елда патша Россиясенә каршы баш күтәрүе турында әз-мәз хәбәрләр бар. Ләкин ул хәбәрләр дә узган гасырның егерменче еллары чигеннән чыкмый диярлек. Соңгы дәверләрдә нәшер ителгән «Большая Советская энциклопедия» томнарында миңа андый мәгълүмат очрамады. Бәлки, ул кузгалышка багышлы мәкалә атамасын дөрес билгели алмаганмындыр. Ә инде 1930 елгы киң таралган баш күтәрүләр турында әйтәсе дә түгел. Бу хакта фәкать ул вакыйгаларга катнашып, тиешле җәзасын күргән, соңрак елларда акланган кайбер билгеле шәхесләрнең биографияләрен укыганда гына беркадәр чамалый аласың. Дөрес, бер-ике әсәрендә мәрхүм Әнүәр Әлимҗанов та ул вакыйгаларны белгән кешеләр аңларлык рәвештә генә кинаяләп әйтеп киткәләде бугай.

Шунысы хак халык күңелен, бигрәк тә әз-мәз кыерсытылган милләт вәкилләре

күнелен кузгатмас, учларын корал тотарга ымсындырып тормас өчен, житәкче түрәләр безгә андый фактларны мөмкин кадәр житкермәскә тырышканнар. 1980 еллар ахырында Лев Толстойның «Хажи Морад» романын кабат нәшер итәргә ниятләгәч тә, үзебезнең үк түрәләрнең «планга кертмәскә», дип әйтүләре хәтердә. Хәзер дә тыныч булмаган Кавказ төбәгендәге «тау халыклары»ның Советка каршы оештырылган, 1954 елга кадәр дәвам иткән кораллы көрәшен кем белә? Яки соңгы елларда гына «чечен бандаларының Дагыстанны яуларга омтылуы» нигезендә ни-нәрсә ятканын кем аңлатып бирә ала? Дагыстан вакыйгаларының башлыча Яңа Лак районында барганын һәм шул хәлләрдән соң лак халкының чикле мөстәкыйльлеге (кече мохтарияте) өчен көрәшүче кайберәүләрнең юкка чыгуын истә тотканда — анда да ниндидер «сер» ята.

Әйе, казакъ халкының бер өлешенең 1930 елдагы баш күтәрүе хакында бездә бернинди дә мәгълүмат басылмаган. Чит-ят жирләрдә бәян ителгәннәре дә онытылгандыр, мөгаен. Әмма шул вакыйгалардан соң совет хакимиятенең казакъ халкы тормыш-көнкүрешенә карашы төптән үзгәрә. Иксез-чиксез булып яткан казакъ иленә яңа сәнәгать корылмалары төзелеше тизләтелә. Илнең төрле тарафыннан монда тәжрибәле белгечләр жибәрелә. Ирекле килүчеләр белән бергә «сөрген срогын» үтәргә тиешле бихисап сандагы галимнәр, профессорларга да урын табыла. Миңа калса, шул ук дулкын безнең Латыйф агабызны да үзе белән өереп алып китә...

***

1933 елда А.Затаевичның «Казакъстан татарларының илле жыры» жыентыгы «Центриздат»та дөнья күрә. Аның мөхәррире Л.Хәмиди була. Китапны казакъ зыялылары да хуплап кабул итә. Алар Л.Хәмидине Алма-Атада эшли башлаган Казакъ драма театрының музыка бүлеген житәкләргә чакыралар. Мохтар Әүэзов әлеге театрны оештыручыларның берсе икән. Аның шул театрда сәхнәләштереләчәк берничә пьесасын музыкальләштерү бурычы Латыйфка йөкләнә. Шулар арасында «Абай» драмасы да була. Шул рәвешле ул монда беренче мәртәбә Абай тормышы һәм ижаты белән якыннан таныша. М.Әүэзовның «Кобланды батыр» дастанына нигезләнгән пьесасыннан соң ул «Абай» драмасын музыкальләштерә. Бер үк вакытта Л.Хәмидигә Казакъстан ССР радиокомитеты карамагында хор коллективын оештыру бурычы да йөкләнә. Шушы ике-өч еллык дәвердә аның казакъ халкы моң-аһәңнәренә яраклаштырып ижат иткән беренче казакъ жырлары да туа. Ильяс Жансыгуровның Кызыл Армиягә багышлы шигыре «Кызыл кыран»га (Кызыл бөркет, Кызыл лачын) нигезләнгән жыр бик тә уңышлы килеп чыга. Аны һәр жирдә мактыйлар, жырлыйлар...

Бу елларда әле Латыйф Хәмиди Казан һәм Мәскәүдәге ижатташларыннан бөтенләйгә аерылып өлгерми. Казакъ илендә вакытлыча гына эшләп, тәжрибә туплармын да туган ягыма кайтырмын дип хыялланып яши. Мәскәүдә уку елларында аралашкан Муса Жәлил, Мансур Мозаффаров һ.б. белән хәбәрләшеп тора. Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе оешканлыгын да белә. Аңа да ул студиягә кабул ителеп, югары музыкаль белем алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итәләр. Һәм 1936 елда ул янә Мәскәүгә килеп төшә. Монда элекке һәм яңа дуслар, ижатташлар белән бергә житди музыкаль әсәрләр ижат итү серләрен үзләштерә башлый. Бу чорда аның «партадашлары» Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Жәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Фәрит Яруллин, Нәжип Жиһановлар була. Нәкъ шушы елларда Латыйф ага татар халкының яраткан көйләреннән «Галиябану», «Каз канаты», «Ком бураны», «Су буйлап», «Сарман», «Шомыртым» һ.б.ны, хор өчен эшкәртеп, нотага сала башлый. Сонрак та ул эш белән шөгыльләнүдән бизми һәм, тулы бер китаплык мая жыелгач, 1964 елда аларны Мәскәүдә бастырып та чыгара. Студияне тәмамлаганда, диплом эше итеп «Татар бию көйләренә сюита»ны нотага сала. Житәкче укытучысы профессор Г.Литинский ул симфоник сюитаны бик уңышлы әсәр дип кабул итә. Ижатташ иптәшләреннән кемнәрдер балет, кемнәрдер опера яза.

1938 елның жәй башында укулар тәмамлана. Эшкә билгеләнү көннәре килеп житә. Кемнәрдер алдан ук Казанда тиздән ачылачак Опера театрына эшкә билгеләнгән була. С.Сәйдәшев элекке эшенә — Дәүләт драма театрының музыкаль бүлеген житәкләргә

дип кайтып китә. Л.Хәмидигә һәм тагын кемнәргәдер республиканың мәдәният идарәсеннән киләсе чакыру кәгазе һаман күренми. Нәкъ шул вакыт Ленинградтан кайтып килүче казакъ артистлары һәм М.Әуэзов Мәскәүдә пәйда булалар. Мохтар һәм әлеге таныш артистлар аны Алматыга кайтырга димлиләр. «Бездә халык музыка уен кораллары оркестры эшли башлады, аңа дирижёр кирәк. Син ул эшкә бар яктан да килешле зат», — ди М.Әуэзов. Шулай итеп, язмыш талантлы татар композиторын тагын үз иленнән читкә алып китә. Дөрес, Аламатыда аны бик зурлап каршылыйлар. Гаилә белән яшәрдәй фатир бирәләр. (Бу вакытта Казанга кайткан студиячеләр гаиләләренең күпчелеге кунакханә бүлмәләренә урнаштырылган була.) Шул көздә үк ул әлеге оркестрның баш дирижёры һәм сәнгать житәкчесе итеп тәгаенләнә. Хәзер дә уңышлы эшләп килгән, дөнья буйлап сәяхәт кылудан туктамаган, унтугызынчы йөз көй чыгаручысы һәм оста кубызчы-скрипкачы Корманғазый исемен йөрткән ул Дәүләт оркестры белән якташыбыз биш ел житәкчелек итә. (Соңгы тапкыр бу оркестр Казанга 2003 елда килде. Якташыбызның берничә әсәрен дә башкарды.) Шул чорда аның гомерлек дан китерердәй әсәрләреннән «Казакъ вальсы» (1940), чак кына соңрак «Былбыл» (1945, Н.Баймөхәммәдев сүзләре) жырлары туа. Якташыбызның казакъ илендә иҗат иткән җырларының саны өч йөзгә якынлаша. 60нчы еллар башында Казакъстанда татар әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре һәм тиздән шундый ук чара Казанда уздырылуы унаеннан, Латыйф ага татар шигыренә нигезләнеп тагын берничә көй яза. Шулардан иң танылганы, сәхнәдән еш кабатланганы, мөгаен, «Иртәләрен, кичләрен» җырыдыр (Хәсән Туфан сүзләре).

***

Казакъстанда яшәгән дәвердә Латыйф Хәмидинең өч опера, бер оперетта, берничә сюита һәм халык яратып кабул иткән дистәләгән казакъ җырын иҗат иткәнлеге мәгълүм. XIX йөз казакъ көйчеләреннән Корманғазый, Дәүләтгәрәй, Биржан һ.б. әсәрләрен оркестр өчен эшкәртә. «Балалар өчен фортепьяно әсәрләре», «Балалар өчен җырлар», «Думбрада уйнау мәктәбе» һ.б. уку-өйрәнү әсбапларын төзи һәм бастырып чыгара.

Мохтар Әуэзов «Абай» драмасы җирлегендә тиздән опера либреттосын әзерли. Шуны чын опера рәвешенә китерүне янарак оешкан композиторлар берлеге рәисе Әхмәт Жубанов белән опера студиясендә укып кайткан Латыйф Хәмидигә йөклиләр. Бу нәкъ авыр сугыш көннәренә туры килә. Халык уен кораллары оркестрында да эшне дәвам итәсе, сугыш батырларына багышлап җырлар да язасы, операга да җан өрәсе бит. 1942 елдан ул музыка училищесында, 1944 елдан яна ачылган консерваториядә дә укыта. Шәрәфле доцент.

— Ул елларда көн-төн эшләдек. Кичләрен Опера театрында да эшләр чыгып тора... Өйгә кайтуга ястык өстенә аварлык кына хәл кала иде. Авыр сугыш чоры кешеләренең күңелен күтәрүгә өмет ителгән дистәләгән җыр язганмын. Совет иле каһарманы Маншук Маметовага, Панфилов дивизиясе батырларына, партизаннарга багышлы җырларым әле хәзер дә радиотапшыруларда кулланыла...

Бик күп тырышлык куелган, байтак сынаулар үткәннән соң, ниһаять, «Абай» операсы язылып бетә. Мәскәү, Киев, Ленинградлардан эвакуацияләнгән музыка, сәхнә белгечләре ярдәмендә сәхнәләштерә башлыйлар. 1944 елда тамашачы операны дәррәү алкышлап кабул итә. «Абай» — җирле милли кадрлар тарафыннан иҗат ителгән беренче милли опера. Дөрес, аңа кадәр, 1934 елда ук бер тәҗрибә булып ала. Опера сәхнәсендә «Кыз жибек» (Ефәк кыз) дастаны нигезендә эшләнгән музыкаль әсәр уйнала. Ләкин аның музыка авторы башка милләт вәкиле — Евгений Брусиловский була.

«Абай» операсы — казакъ опера сәхнәсенең иң уңышлы әсәре. Аның әлегәчә куелмый, уйналмый калган елы юк. Мәскәүдә уздырылган казакъ мәдәниятенә багышлы чараларда да «Абай» сәхнә түрендә йөри. Ул операда баш рольләрне башкаручы Күләш Байсәетова, Роза Жаманова, Бибигөл Төләгәнева, Ирмәк Серкебаев, бертуган милләттәшләребез Ришат һәм Мөслим Абдуллиннар дөнья күләмендә танылган артистлар дәрәҗәсенә ирештеләр.

1945 елда өч композитор тарафыннан Казакъстан ССРның үз гимны иҗат ителә.

Бер үк вакытта Л.Хәмиди акын Жамбулның үз яшенә багышлап бер актлы «Жамбул белән Айкуныс» операсын да эшли (1946). Соңрак, 1949 елда, опера, тулыландырылып, «Жамбул» исеме белән кабат эшләнә һәм 1952 елда сәхнәләштерелә. Сугыш барган көннәрдә үк башланган һәм төрле сәбәпләр белән бераз тоткарланган «Теләгән Туктаров» операсы да, ниһаять, 1947 елда төгәлләнә һәм сәхнәләштерелә. Сугыш батырына багышланган бу опера да Латыйф ага белән Әхмәт Жубановның уртак җимеше.

— Әхмәт белән без утызынчы еллар ахырында Корманғазый исемендәге оркестрда бергә эшли башлаган идек. 1939 елда композиторлар оешмасын да бергә нигезләдек. Беренче көннән башлап анда идарә әгъзасы булып торам. Музыка сәнгатенә багышлап язылган мәкалә, очерк язып бастырдым. Музыка фонды рәисе булуыма да дистә еллар инде. Төрле музыкаль чараларда жюри рәисе яки әгъзасы булган очраклар да еш кабатлана. Үпкәләр жаем юк. Читкә тибәрергә теләгәннәрен тоймыйм.

Хак әйтә Латыйф ага. Казакъ илендә аның абруе зур булды. 1942 елда аңа «Казакъстан ССРның атказанган артисты», 1966 елда «Халык артисты» дигән мактаулы исемнәр бирелә. 1978 елда ул Күләч Байсәетова исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Берничә орден, медаль белән бүләкләнә. Әдәбият, сәнгать өлкәсендә хезмәт итүчеләр өчен Казакъстан ССРның дәүләт бүләкләрен булдыру карары 1944 елда кабул ителә. Әдәбият өлкәсендә эшләүчеләр өчен ул хәзер — Абай, музыка, театр осталары өчен Күләч Байсәетова исемендә йөртелә. Күләч — казакъның танылган беренче опера җырчысы. Ана инде 1936 елда ук (егерме дүрт яшендә) «СССРның халык артисты» исеме бирелә. Хәер, казакъ опера сәнгатендә һәм музыка өлкәсендә Дәүләтнең андый иң югары исемен яшьли алучылар байтак. Роза Жаманова, Мукан Түләбаев, Ирмәк Серкебаев «СССРның халык артисты» исеменә — 1959 елда, Бибигөл Теләгәнева белән Ришат Абдуллин 1967 елда лаек дип табылалар. Шундый зур дәрәҗәле исем бирелгәндә Розага — утыз бер, Ирмәккә утыз өч яшь була. Талантлы, сәләтле иҗат кешеләрен шулай иртә бәяли белүдән үрнәк алырга кирәктер, мөгаен.

Өстәп шуны да әйтик: Күләч Байсәетова Латыйф аганың «Казакъ вальсы» белән «Былбыл» җырын иң беренче һәм үзенчәлекле моң вә күтәренке рух белән башкаручыларның берсе санала.

— Арабыздан иртә китмәсә, без бергә тагын күп нәрсәләр иҗат иткән булыр идек әле, — ди композитор, аның белән иҗатташ булу елларын искә төшереп. — Ул 1957 елда вафат булды. Әмма җырлары, арияләре хәзер дә радио, телевидение репертуарыннан төшмичә башкарылалар.

Латыйф Хәмиди 1948 елда Н.Баймөхәммәдев либреттосына «Балбулак» опереттасын иҗат итә. Бу әсәр — аның шушы юнәлештәге соңгы хезмәте. Мирасында тагын берничә күләмле симфоник әсәре — сюиталары бар. Казакъстанда элегрәк даими башкарылган «Татар бию көйләренә сюита»дан тыш, иҗатташлары һәм музыка сөючеләр тарафыннан югары бәяләнгән «Кобланды» һәм «Алматы» сюиталарын атап үтәргә кирәктер.

Латыйф Габделхәй улы Хәмиди 1983 елда, житмеш жиде яшендә Алматыда вафат булды. Ике-өч ел элгәре генә бергә гомер иткән карчыгы Сания дә гүр иясе була. Аңа чаклы әле без тагын бер мәртәбә шул ук кунакханәнең иркен бүлмәсендә иркенләп сөйләшеп утырган идек. 1980 елның июнь башларында, замандашы Сабит Мукановның сиксән еллык юбилее билгеләп үтелгән көннәрдә. Латыйф ага миңа житмеш яшенә атап чыгарылган буклетын (иҗат биографиясе язмасын) бүләк итте. (Аның юбилей тантанасы 1976 елның 8 декабрендә Абай исемендәге Опера һәм балет театрында бик зурлап уздырыла.) Шул очрашуда Латыйф ага Әхмәт Жубанов белән икесенә багышлап повесть иҗат ителүен, ләкин хәзергә ул әсәрнең үзендә юклыгын белдергән иде. Блокнот битенә: «Повесть авторы Лия Жаһанова», дип язып куйганмын. Музыка белгече А.Юсфин — 1964 елда Мәскәүдә, Б.Ерзакович 1978 елда Алматыда «Латыйф Хәмиди» исемле хезмәтләрен нәшер иткәннәр. «Казакъстан ССР энциклопедиясе»нең 4нче томында да якташыбызга багышлы төпле мәгълүмат бар. Ә «Татар энциклопедия сүзлеге»нең 727 битендә кыскача таныштыру мәкаләсе урнаштырылган.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

# БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫНДА АЛМАНИЯДӘ МӨСЕЛМАН ӘСИРЛӘРЕ

## 4. Әсирләр арасында пропаганда чаралары

Берлин янында урнашкан ике «махсус» лагерьда тупланган мөселман хәрби әсирләре Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында алман җитәкчелеге өчен үзенә күрә тәҗрибә материалы булып торган, һәм мөселманнар интенсив пропаганда объектына әверелгәннәр. Пропаганда рухы һәм максаты белән лагерьларда уздырылган һәрбер чара сугарылган булган.

Бу әһәмиятле мәсьәләгә алманнар баштан ук бик зур игътибар биргәннәр, аның теоретик нигезләре һәм принциплары лагерьлар барлыкка килгәндә инде ачык була — без аларны инде Макс фон Оппенһайм төзегән документларда күрә алабыз, бу очракта ул, әлбәттә, читтә кала алмаган.

Мәсәлән, М. фон Оппенһайм пропаганданы түбәндәге юнәлешләрдә алып барырга тәкъдим иткән һәм, нигездә, ул китерелгән сюжетларны истә тотып алып барылган да: изге сугыш — «җиһад» зарурлыгын нигезләү; татар әсирләрендә русларга карата гомумән нәфрәт хисләрен уяту; Алманиянең ислам диненә дустанә мөнәсәбәтен күрсәтү; ярдәм җиңүнең Алмания һәм мөселманнар өчен китерәчәк өстенлекләрен исбатлау; мөселман халыкларының идеологик һәм сәяси бердәмлеген яклау; Алманиянең төрле яктан — сәяси, икътисади һәм мәдәни — бөеклеген күрсәтү һәм шул нигездә мөселман әсирләрендә Алманиягә ихтирам хисләрен тәрбияләү.

Шулай да планлаштырылган яки алып барылган пропаганданың баштан ук бер зур җитешсезлеге булганлыгын искә алырга кирәк — алманнар сугыш барышында мөселманнар өчен ачык һәм тәгәл перспектива куя алмаганнар. Ягъни җиһад, мөселманнар тарафыннан изге гамәл булып саналса, алар Антанта илләренә каршы кан түксәләр дә, киләчәктә, сугыш тәмамлангач, аларны нәрсә көткән? Алмания аларга бергәләшеп яулап алган җиңүдән соң нәрсә тәкъдим итә алган? Бәйсез дәүләт төзүдә ярдәмме? Нинди сәяси яки икътисади ташламалармы? Бу җитди һәм мөселманнар өчен, һичшиксез, бик әһәмиятле сорауларга Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында алман сәясәтчеләреннән яки хәрбиләреннән беркем дә ачык җавап бирә алмаган һәм бирмәгән. Шуңа күрә пропаганда алып баруда шактый күп көч куелса да, аның зарурлыгы турында алман түрәләре армый-талмый сөйләнсәләр дә — ул нинди дә булса тәгаен нәтиҗәгә китермәгән.

Мисал өчен, 1915 елның октябрендә Вайнберг лагере коменданты биргән күрсәтмәдән пропаганданың төп юнәлешләрен атарга мөмкин: «1. Сугыш беткәннән соң, Алман империясе өчен сәүдә һәм сәясәт өлкәсендә өстенлекләр яулап алу өчен, әсирләрдә алман яклы карашлар тәрбияләү; 2. Мөселманнарның «изге сугышта» Төркия ягында катнашуы; 3. Төркиягә барлык мөселманнарның яклаучысы булу омтылышларында ярдәм күрсәтү». Әгәр дә без бу юнәлешләрне иң әһәмиятлеләре дип санасак, алар арасында мин бары тик бер тәгаен фикерне күрәм — мөселман әсирләрен яңадан сугышта катнаштыру, ләкин бу юлы алман-төрек

*Дәвамы. Башы 2, 3, 4 нче саннарда.*



*Әсирләр лагерь китапханәсендә*

ягында. Алман җитәкчелеге мөселман әсирләре алдында шундый гына «перспектива» куйган...

Баштан ук мөселман әсирләре арасында пропаганда алып бару өчен тагын бер мөһим кыенлык яки каршылыкны да искә алыйм. Антанта илләренә каршы «җиһад»ны Госманлы солтан игълан иткәч, пропагандистик чаралар алман мәнфәгатьләрен генә түгел, ә бәлки, беренче чиратта, төрек мәнфәгатьләрен якларга тиеш булганнар, чөнки төрек солтаны рәсми булмаса да, барлык дөнья мөселманнарының рухи башлыгы саналган. Алмания һәм Госманлы империясе сугыш вакытында хәрби һәм сәяси союзник булсалар да, алман җирендә һәм алман акчасына оештырылган лагерьларда төрекләр файдасына пропаганда алып бару кайбер алман җитәкчеләре өчен, йомшак кына әйткәндә, сәер күренеш исәпләнгән. Бу каршылык та әсирләр арасында оештырылган пропаганданың гомум уңышсызлыгына китергән.

Шулай да Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында пропаганда юнәлешендә Алмания шулкадәр үзенчәлекле адымнар ясаган, мин аларның кайберләре турында сөйләргә телим — лагерьлар очраклы рәвештә генә «пропагандистик» дип аталмаган бит.

Алман документларыннан күренгәнчә, пропаганда чаралары дип лагерьларда түбәндәгеләр исәпләнгән: дини тәрбия, төрле тематик сөйләшүләр уздыру яки чыгышлар ясау, дәрес бирү, әсирләрне төркемнәргә бүлеп, алар өчен алман авылларына яки шәһәрләренә экскурсияләр оештыру. Ниһаять, пропаганда уңышлы барсын өчен, лагерьларда уңайлы тормыш шартлары һәм тыныч, җайлы эчке атмосфера тудырылырга тиеш булган — мин аны үземчә милли атмосфера, милли мохит дип тә атар идем.

Соңгы максатка ирешү өчен, мәсәлән, лагерьда тынлы кораллар оркестры оештырылган — ул төрле бәйрәмнәр, тантаналы вакыйгалар вакытында милли көйләр яңгыратып торган. Шулай ук бирелә хор һәм бию түгәрәге булганлыгын да әйтеп узыйм — бию түгәрәге җитәкчесенең «һәр атнада ике төрле танцы өйрәтәм», дип әсирләр арасында реклама ясавы да билгеле. Беренчеләрдән булып Алманиядә татар әсирләре язмышына игътибар иткән Мөхәммәт Мәһдиев заманында хәтта: «Вюнсдорфтагы татар әсирләренең барысы да бальный танец өйрәнеп кайта», — дип язып чыккан иде. Ял йортыннан кайткаННар диярсең...

Лагерьда татар театр труппасы эшчәнлеген дә искә алырга мөмкин (Мөхәммәт Мәһдиев бу турыда да язган иде) — бер-бер артлы әсирләр тарафыннан ике театр труппасы оештырылган булган. 1916 елда «Ярдәм» дип аталган труппаның атна саен җомга көнне әсирләргә спектакльләр күрсәтүе билгеле. 1917 ел язында әсирләрнең күпчелеге төрле эшләргә җибәрелү сәбәпле, әлеге труппаның эшчәнлеге туктатылган. Һәм шундук диярлек Каюм Рахманкулов җитәкчелегендә «Ан» труппасы барлыкка килгән. Лагерь баракларының берсендә тамаша өчен сәхнә корылган. Әсирләр беренче спектакль итеп Г.Камалның «Бәхетсез егет»ен сәхнәләштергән. Премьераны күрергә алман тамашачылары Берлиннан ук килгән, һәм алар спектакльдән бик канәгать калганнар, артистларны тамашадан соң алкышларга күмгәннәр. Соңрак лагерьда башка спектакльләр дә куелган, төрле концерт, чыгышлар оештырылган. Спорт ярышлары — йөгерү, көрәш, акробатика һ.б., милли бәйрәм — Сабантуй да онытылмаган.

Китап укырга яратучылар да читтә калмаган — лагерьда сугыш елларында шактый зур китапханә җыелган — китапларны күбрәк Төркия аша алдырганнар. Бу эштә пропагандист һәм имам вазифаларын үтәгән Габдерәшит Ибраһим актив катнашкан: китапханә фондына алман пропагандасы өчен яраклы һәм файдалы төрек, татар, рус телләрендә китаплар алдыра башлаган. Бу эшне ул Төркиягә күчеп киткәнче, ягъни 1915 елның октябренә кадәр дәвам иткән — нәкъ октябрь аенда Истанбулдан лагерь китапханәсенә тагын 205 китап кайтып төшкән. Һәм инде 1918 елда китапханә фондында 1265 татарча һәм 218 русча китап булганлыгы билгеле — бер дә кечкенә сан түгел. Китапларны әсирләр бушлай файдалана алган, аларны алган вакытта бары тик расписка соралган.

Әлбәттә, пропаганданы, гомумән, «күңел ачу»га яки унай психологик атмосфера тудырырга омтылышларга гына кайтарып булмый. Аның алдында җитдирәк һәм катлаулырак максатлар куелган, әсирләр ахыр чиктә алман кулында дошманнарга каршы кулланырлык инструмент булып каралган. Шуңа күрә аларның рухын «эшкәртү»дә башка ысулларны да күрәбез.

Алманиянең мөселман дөньясы белән җылы һәм дустанә бәйләнеше төрле дини чараларда ачык күрсәтелергә тиеш булган. Шуңа күрә иң зур мөселман бәйрәмнәре аерата тантаналы рәвештә уздырылган. Бу хакта документлар шактый күп сакланган, һәм, мәсәлән, лагерь коменданты хисапларында бәйрәмнәрнең барышы турында әһәмиятле детальләр китерелә.

1915 елның 20 августында ике махсус лагерь өчен оештырылган Ураза гаете хакындагы хисапка күз салыйк. Комендант фикеренчә, бу бәйрәм әсирләрнең Төркия һәм ислам дине яклауда тәэсирле бер чара булып узган. Ачык һавада уздырылган гаеттә 11 меңгә якын әсир катнашкан, шуларның абсолют күпчелеге — татарлар. Бәйрәмдә катнашыр өчен лагерьга зур кунаклар килгән — Төркиядән шәех Хәсән Фәһми, Алманиядәге төрек илчесе Ибраһим Хакки-паша, төрек һәм алман офицерлары һәм дипломатлары, «Шәрекъ дөньясы белән кызыксынучылар» һ.б. күпсанлы кунаклар.

Бәйрәм башланыр алдыннан комендант хәрби парад кабул иткән, аннан соң гает намазы укылган. Кунак төрек шәехе вәгазь укыган. Ниһаять, рәсми өлеш тәмамлангач, әсирләрне бәйрәм ризыгы көткән, аларга шулай ук чәй, шикәр, тәмәке өләшкәннәр. Көн ахырында исә мәдәни чаралар уздырылган — биюләр, спектакль күрсәтелгән, теләүчеләр спорт ярышларында да катнаша алган.

Алман җитәкчеләре бәяләвенчә, бу чара бик зур тәрбияви роль уйнаган. Бәйрәмнең төп «казанышлары» дип түбәндәгеләр аталган: әсирләрне «җиһад»ка чакыру, солтан-хәлифәгә ихтирам хисләрен уяту һәм көчәйтү һәм, иң әһәмиятлесе — Алманиянең мөселманнарның иң «якын дусты» икәнлеген исбатлау.

Бәйрәмнәр үз вакытында уздырылган, алар елына ике-өч тапкыр гына булган бит, ләкин әсирләр арасында төп пропаганда эше, әлбәттә, көн саен өзлексез алып барылган.

Бу эш өчен җаваплы пропагандистлар да билгеләнгән — төрле юллар белән, төрле вакытта Алманиягә килеп эләккән яки вакытлыча хезмәткә чакырылган мөселманнар. Татар әсирләре арасында бу җаваплы эшне русча яхшы белгән алман чиновнигы Һаралд Козак җитәкләгән, татарлардан аның иң якын ярдәмчеләре булып түбәндәге шәхесләр торган: Габдерәшит Ибраһим (1915 елның октябренә кадәр), Госман Кади, имам Хөрмәтулла, Галимҗан Идриси, Сәет Әфәндиев, Шамил Сәфәров, Мәхәммәт Казаков, Мөстәкыймов, Ишморатов һ.б.

Вайнберг лагеренең беренче имамы Габдерәшит Ибраһим атнасына гадәттә дүрт тапкыр лагерьга килгән, әсирләр белән даими рәвештә сөйләшүләр уздырган, башка пропагандистлар эшен җитәкләгән. Лагерьга килгән саен, ул барлык баракларны йөреп чыккан һәм әсирләрдән тормышлары турында сорашкан.

Пропагандистлар еш кына әсирләр алдында чыгыш ясаган. Мәсәлән, андый махсус пропаганда җыелышы Вайнберг лагеренда 1915 елның 13 июнендә уздырылган. Алман документлары раславынча, бу чарада 3 меңнән артык әсир катнашкан, һәм төп чыгышларны пропагандистлар Мөстәкыймов белән Ишморатов ясаган.



*Лагерьда милли бәйрәм – Сабан туе. 1920 елның 14 марты.*

Ишморатов үз чыгышында мөселман халыкларының колониаль дәүләтләр изүе астында авыр тормышлары турында сөйләгән, аларның Русия, Англия һәм Франция кулы астында никадәр авыр шартларда тормыш итәргә мәҗбүр булганлыгын исбатларга тырышкан һәм бигрәк тә алман җитәкчелегенең гаделлеге хакында сүз йөрткән — имеш, ул, мөселманнарны азат итү максатыннан, хәрби әсирләрне махсус лагерьларда туплаган. Мөстәкыймов исә әсирләрне бар көчләрен куеп Алмания һәм Төркияне якларга өндәгән, чөнки «бары тик шушы ике дәүләт кенә мөселманнарны инде 300 елдан артык барган колониаль изүдән азат итәргә омтыла». Ул мөселманнарны «алга барырга, барлык дошманнарны юк итәргә» һәм яһүдләрдән үрнәк алырга чакырган — имеш, алар бөтен дөньяда бердәм яшиләр һәм бер-берләренә ихлас булышалар. Алман телендә бу җыелыш беркетмәсен төзегән офицер Мөстәкыймовның «гомум мөселман эше өчен барлык мөселманнар армый-талмый тырышлык күрсәтергә, Ходайдан бу изге эштә көч-куәт бирүен үтенергә тиеш», дигән сүзләреннән соң күп кенә әсирләрнең күзендә яшь тә күреп алган.

Әсирләр өчен оештырылган уку курслары да аларны кирәкле рухта «тәрбияләү»дә зур урын алып торган. Башта лагерьда дин дәресләре бирү каралган була — 1915 елның июленнән төрле матди кыенлыкларга карамыйча, татар пропагандистлары мондый эшне башлап җибәрә — лагерьда үзенчәлекле мәктәп барлыкка килә. Биредә шулай ук алман һәм татар телләре курслары да оештырыла. 1915 елның көзендә инде 500дән артык әсир — татар теле, 40 кеше алман теле дәресләрендә катнашкан була. Бу дәресләр җомга һәм якшәмбедән тыш көн саен уздырылган. 1916-1917 елларда әлеге курсларның да, аларда белем алган әсирләрнең дә саны арта. Шунысы кызык: курсларда укырга теләк белдергән әсирләр төрле эчке лагерь эшләреннән, хәтта строевой әзерлектән дә азат ителгәннәр — күрәсең, бу очракта дәресләрнең рухи, идеологик әһәмияте беренче планга чыккан, чөнки курслар тел дәресләре булып торса да, аларда укытучылар сәяси, милли, хәрби мәсьәләләр турында да фикер йөрткән, Алманиядәге тормышның өстенлекләре хакында сөйләгәннәр.

Пропаганда алып баруда әсирләр өчен үз телләрендә чыга торган газета һәм башка басмаларның нинди зур урын алып торганы аңлашыла, әлбәттә. Пропагандистик лагерьлар барлыкка килгән вакытта ук алман сәясәтчеләре бу мәсьәлә буенча актив шөгыльләнгән — 1915 елның гыйнварында инде газета чыгару проекты оеша. Газета өчен табигый рәвештә «Әл-җиһад» дигән исем сайлана, аны биш телдә бастырырга планлаштыралар — гарәп, татар, рус, урду һәм һинди телләрендә.

Күптән түгел «Әл-җиһад» газетасының татар басмасы хакында тарихчы Ләлә Гатауллина «Гасырлар авазы» журналында мәкалә бастырган иде — укучыларыма ул кызыклы материал белән танышырга тәкъдим итәм. Шуңа күрә биредә кайбер әһәмиятле моментларга гына тукталып узам.

Газетаның төп максаты итеп сугыш хакында хакыйкать сөйләү билгеләнгән. Ул шартларда «хакыйкать» нинди була алганлыгы көн кебек ачык — аны, әлбәттә, алман файдасына борып җибәргәннәр. Сугыш вакытында башкача була да алмый бит. Газета материаллары бу фикерне раслап тора — саннан-санга алман җиңүләре һәм рус-инглиз-француз «хыянәтләре» һәм «вәхшилекләре» турында сөйләнгән.

Газетаның параллель рус һәм татар басмалары беренче тапкыр 1915 елның 5 мартында чыккан. Ана телендә укуга сусаган әсирләр табигый рәвештә бу басмаларны көтеп алганнар һәм яратып укыганнар. Газета битләрендә чыккан материаллар катгый контроль астында булган — алар барысы да башта алман телендә әзерләнгән, эчтәлекләре Генераль штаб һәм Тышкы эшләр министрлыгы вәкилләре тарафыннан житди тикшерелгәч, аларны татар һәм рус телләренә тәржемә иткәннәр. Тәржемә итүдә Габдерәшит Ибраһим



الجهاد

Berlin

EL DSCHIHAD

Zeitung für die mohammedanischen Kriegsgefangenen

*«Әл-жиһад» газетасының татар телендә 2нче саны. 1915 елның 25 марты.*

үзе (ул шулай ук актив газета авторларыннан да булган), Сәет Әфәндиев, Мөхәммәт Казаков һәм башка пропагандистлар катнашкан. Төрле сәбәпләр аркасында «Әл-жиһад» газетасы даими чыкмаган, гәрчә ул атналык газета булырга тиеш булса да, кайвакыт аның яна саны ике-өч атна басылмый торган. Шуна күрә дә газетада басылган «өр яңа» хәбәрләр еш кына актуальлеген җуйган. Шулай да газета әсирләр арасында бик популяр булган — башта татар һәм рус басмалары икесе дә 1500әр данә бастырылса, сонрак татар телендәге басманың тиражы 3 менгә кадәр житкерелә, ә рус телендәгесе, киресенчә, кечерәк тираж белән чыга башлый — бары тик 500 данә. 1917 елның гыйнварында рус басмасы бөтенләй туктатыла, татар телендә газета 1918 елның октябренә кадәр чыгып килә. Газетаның бастыру сыйфаты әллә ни югары булмаган — аның татарча һәм русча вариантлары башта кулдан язылган, аннан соң ташбасма (литография) рәвешендә ишәйтелгән.

Минемчә, бу газета эчтәлек ягыннан безгә күбрәк алманнарның пропаганда өлкәсендәге омтылышларын һәм ысулларын, пропаганда механизмын яхшырак анларга мөмкинлек бирә, ә менә газета материалларына нигезләнеп, әсирләрнең көндәлек тормышын, аларның уй-тойгыларын, кичерешләрен күзаллау шактый авыр.

Саф пропаганда коралы булган «Әл-жиһад» газетасыннан тыш Алманиядә татарча чыккан башка басмаларны да искә алырга мөмкин. 1918 елның декабрендә, инде сәяси һәм хәрби шартлар үзгәреп беткән вакытта, «Яңа тормыш» газетасының берничә саны дөнья күрә, аннан соң «Татар иле» газетасы да чыгып ала. Менә бу басмалар инде әсирләрнең реаль тормышына, һичшиксез, якынрак булган — алардан без, мәсәлән, татарларның мәдәни тормышы, Совет хөкүмәтенә мөнәсәбәтләре, шәхси гамьнәре һәм хыяллары турында күбрәк белә алабыз. Кызганыч ки, әлеге газеталар бик аз арада гына чыккан һәм аларның бары тик бер-ике саны гына сакланып калган. Шуна күрә эчтәлекләре турында фикер йөртү мөмкинлегебез дә чикләнгән.

Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында алман пропагандасының тагын бер бик гыйбрәтле ягы — әсирләр өчен оештырылган экскурсияләр.

Гадәттә, алар алман шәһәрләренә һәм авылларына Алманиянең «бөеклеген», аның икътисад, мәдәният өлкәсендәге казанышларын, алман халкының мул һәм тыныч тормышын күрсәтү максатыннан оештырылган. Әлбәттә, барлык әсирләргә мондый мөмкинлек бирелмәгән — экскурсияләрдә катнашучыларны пропагандистлар яки алман офицерлары сайлап алган. Алар әсирләр арасында укымышлырак, пропаганданы анларга, кабул итәргә әзер, яраклы кешеләргә өстенлек биргән. Шулай ук алман телен өйрәнүчеләргә дә шундый «бәхет» насыйп булган. Экскурсантларга фабрикалар, сәүдә үзәкләре, музейлар, авыл фермалары, мәктәпләр күрсәтелгән



*Вайнберг лагереның татар тынлы кораллар оркестры*

— гадәттә, экскурсияләр тематик яктан уйланылып оештырылган.

Бер бик кызыклы экскурсия турында жентекләбрәк сөйләргә телим. Бу — 1918 елның сентябрь башында әсирләр арасыннан 16 татар укытучысы өчен оештырылган алман мәктәпләренә экскурсия. Алар Галимҗан Идриси житәкчелегендә Берлин тирәсендә берничә алман мәктәбендә булган. Катнашучыларның берсе, Әхмәткәрим Бикташев, экскурсия тәмамлангач, үзенең тәэсирләрен кәгазьгә салган, үзенә күрә отчёт төзегән. Бу документ Берлин китапханәсендә саклана.

Документта автор мәктәпләрне һәм алман мәгариф системасын мактау өчен сүз жәлләмәгән, аларның татар яки рус мәктәпләре белән чагыштырганда, күп мәртәбә «мөкәммәл вә мөнтазыйм» икәнлеген исбатларга тырышкан.

Ул сүзне мәктәпләрнең тышкы күренешләреннән башлап җибәргән: «Мәктәпләр һәр яктан жиренә житешкән, биналар зур, эчләре якты, һавалары яхшы, безнең мәктәпләрдә очрый торган тузан, туфрак вә начар исләрне монда күрергә мөмкин түгел. Киң бинаның эчендә бездәге кебек йөзләп түгел, 25-30лап кына бала утырган, һәр суладыкларында яна яки яхшы һава сулыйлар, урыннар гаять унайлы. Менә бу эшләр балаларның сихәтенә, аларның рух вә зәкяветләренә никадәр яхшы тәэсир итәчәге табигыйдер».

Авторны бигрәк тә сугыш шартларында укыту системасын шундый төзек, тәртипле хәлдә саклап калу сокландырган: «14нче елларда мин Русиядә татар мәктәпләренең игъдади сыйныфларында мөгаллим идем». Сугыш чыккач, «балаларның рухлары төште, зиһеннәренә тарлык килде, ниндидер куркыныч вә изгеч бер куәт аларны жинде дә төшенке күңелле вә трагедия алдында торучы кызганыч адәмнәр кеби, юк кына бер эш өчен дә артык әсәрләнеп, күзләре яшьләнә торган булып калды. (...) Табигый ки, бу зур сугышның матди вә мәгънәви зарарлары хисапсыздыр, бинаән галия, мин бу сугыш алман мәктәпләренә дә начар тәэсир иткәндер, андагы укучылар да кызганыч бер халәт кәсеп иткәндер, дип уйлый идем. Инде исә мин ул уйларымда ничаклы ялгышканымны белдем».

Күрәсең, экскурсантлар төрле дәресләрне күзәткәннәр — ботаника, химия, география, музыка, гимнастика һ.б. Һәрберсен Ә.Бикташев элек күргәннәре, үзенең тәжрибәсе белән чагыштырып караган һәм һәрбер очракта алман мәгариф системасының, алман мәктәпләренең өстенлеген күргән. Өстенлекне ул техник әсбаблар белән тәэмин итүдә генә түгел, ә, гомумән, дәрес бирү тәртибендә, укытучыларның әзерлек дәрәжәсендә, балаларның үзләрен тотышында күренә дип язып калдырган.

Бу экскурсия авторга шулкадәр көчле тәэсир иткән ки, китәр вакытлары житкәч, ул мәктәп алдында туктап уйланып торган: «Күз алдыма андагы уку әсбабы, булдыклы мөгаллимнәр, аларның тора торган урыннары, шәкертләрнең гүзәл тәрбия ителүләре, жыр вә тәнәфес өчен хосусый хәзерләнгән бүлемнәре һәм андагы жыр вә гимнастикалар килде. Сонра мин шундый мәктәпләрдә мөгаллим булмавым өчен яки мөтәгалим булып та, шулар кеби гүзәл тәрбия ала алмавым өчен менләрчә тәэсиф итсәм дә, гомеремдә бер генә мәртәбә булса да шул мәктәпләрне күрә алуым өчен үземне бәхтияр саныйм вә моның өчен чын күңлемнән шатланам».

Әлеге кыска гына өзекләрдән шунысы ачык: алман пропагандасы һәрхәлдә бу очракта теләгән максатына ирешкән. Тәгаен бер хәрби әсир алман тормышының бер ягы белән танышып, соклану хисләре кичергән, аның өстенлекләрен күргән. Димәк, ул хатирәләр аның күңелендә киләчәктә дә саклануында шик булмаган. Әхмәткәрим Бикташевның язмышы турында минем төгәл мәгълүматларым юк, ләкин минем уйлавымча, ул сугыштан соң ватанына әйләнеп кайткан булса, ватандашларына, милләттәшләренә, хезмәттәшләренә алман мәктәпләрендә күргәннәрен сөйләгән. Һәм шулай итеп, ихтыярсыз булса да, алман пропагандасын тараткан — бу конкрет очракта әсирләр арасында уздырылган пропаганда чарасы нәтиҗәле һәм уңышлы булганлыгын күрәбез.

Мәкаләмнең ахырында алманнарның Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында тагын бер үзенчәлекле пропагандистик уңышы турында сөйли торган шигъри текст китерәсем килә. Авторы билгесез, ләкин аның әсир булганлыгы ачык. Күрәсең, ул кеше әсир чакта шулай ук төрле экскурсияләрдә катнашкан яки лагерьдан читтә эшләгән. Ничек кенә булмасын, Алман иле аны бик нык сокландырган, үзенең фикерләрен ул шигъри юлларга салган һәм шигырьне «Германия тормышы яки сәяхәт файдасы» дип атаган. Һәм ул, чыннан да, алманнарның тагын бер кечкенә генә пропагандистик уңышы булып каралырга мөмкин.

## Германия тормышы яки сәяхәт файдасы

Бар икән дөнья йөзендә падишаһ, кайсар дигән,
Милләте — нимес милләте, белсәңез, гирман дигән.
Шул икән анларда гадәт — күбесе сакал кыра.
Һич юк икән анларда фәкыйрь, алар бик бай тора.
Дәхи шул икән гадәт: алар мыекны үстерә.
Юк икән җәяүле, анда йөри виласипедта гына.
Бәгъзе алтун, бәгъзе көмешдән йөри сәгать киеп,
Ул тагы кемләре нәфис йөри шиблит киеп.
Мин күрәм: киң карьяләрдә өйләре ташдан икән,
Гөлләре, бакчалары, бар чишмәләре фантал икән.
Сахраларда юллары төзелгән тип-тигез ташдан тагы,
Төшми кояш, юл күләгә, алмагач-каштан бары.
«Тар-тор» идуб арба илән йөрүче анда сирәк,
«Түт-түт» идуб тик йөрүче афтамабил күбрәк.
Җирләре иген илән тулган тирәсе алмагач,
Бер кеше итми хыянәт, үз иясе булмагач.
Карьяләрдә бән күрәм, җомга саен анда барам,
Кечкенә генә балалар — сүзенә колак салам.
Курыкмыйдыр, һич шашмыйдыр, балалары янга килә,
Елмаеп кына көлә дә саулык сорый, сәлам бирә.
Диярсең: ул таный сине, ул нигәдер якын күрә.
«Сез — Русия татарлары», — ди, әллә нигә безне белә.
Ә, беләмен, ник таный алар, шулай зирәк икән,
Аскан аркаларына букча тулы китаб икән».

*Дәвамы киләсе санда*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор*

# КАР КЕШЕЛӘРЕ — АРАБЫЗДА...

## ӘМИР ӘМИНЕВНЫҢ «КАР КЕШЕСЕ» КИТАБЫНА БЕР КАРАШ

1990 еллар башында, яшәешебезнең барлык өлкәләре кебек үк, әдәбият та катлаулы хәлдә калды. Социаль заказ, идеологик бертөрлелек юкка чыгу белән, күнегелгән әдәби кануннар да җимерелде. Көнбатыштан кергән тенденцияләр йогынтысында, әсәрләрдә чынбарлыкны реалистик күзлектән чагылдыру урынына, дөньяны сәнгатьчә кабул итүнең мең төрле «изм»лы ысуллары калкып чыкты. Хәер, «дөнья» төшенчәсен әйләнә-тирә чынбарлыкка гына кайтарып калдыру да дөрес булмас хәзер. Чөнки бүгенге көн әдәбиятында объектив чынбарлыктан бигрәк, субъектив — авторның аңында, фантазиясендә генә яшәгән иллюзор чынбарлык ешрак чагылыш таба, «сәнгатьчә дөреслек» төшенчәсе бөтенләй диярлек югала, чынбарлык белән миф, өн белән төш, фани дөнья белән ахирәт, әдәби әсәр белән фән кушылып, гади акыл белән аңлашылмаслык ниндидер катлаулы синтез тудырыла. Мондый әсәрләр фәндә «постмодернизм әдәбияты» дигән төшенчә белән билгеләнә. Алар укучының күңеленнән бигрәк акылына мөрәҗәгать итә, идея-эстетик эчтәлекләре ягыннан да, башваткыч кебек катлы-катлы булулары белән дә аерылып тора. Автор фикерен аңлау өчен, укучының да әзерлекле булып, фәлсәфә, тарих, дин, әдәбият гыйлемнәрен су кебек эчүе сорала.




Турысын әйтергә кирәк, язучының җан җылысы бөркелеп торган, бер тында укылган, геройларның язмышлары һәм кичерешләре күзләргә яшь китергән яисә рәхәтләнеп көләргә мәҗбүр иткән әсәрләрне бүгенге әдәбияттан табу шактый кыенлашты. Ул гына да түгел, әдәбиятларның милли йөзе дә югалып бара. Бу аеруча рус әдәбиятына кагыла һәм, мина калса, аның тирән кризис кичерүенең бер күрсәткече булып тора. Мәсәлән, Виктор Пелевин, Владимир Сорокин, Людмила Улицкая кебек бүгенге көн язучыларының әсәрләрендә рус халкының традицион мәдәнияте, фольклоры, менталитеты, яшәү үзенчәлекләре бернинди чагылыш тапмый диярлек, алар үзләренең космополитик характеры — миллияттән, рус телендә сөйләшүче халыктан бөтенләй читләшкән булулары белән аерылып тора. Узган гасыр башында барлыкка килгән «сәнгать — сәнгать өчен» шигаре бу язучылар иҗатында җиренә җиткерелеп тормышка ашырыла, чөнки әлеге әсәрләр киң катлам укучылар өчен иҗат ителмәгән, аларның адресаты да, максаты да билгесез. Мина калса, бу күренеш зыялыларның халыктан тәмам аерылуын, тулаем милләтнең дә рухи упкынга якынлашуын кисәтеп тора кебек.

Шөкер, татар әдәбиятында хәлләр куанычлырак. Язучыларыбыз нинди генә сәнгатьчә метод белән иҗат итмәсеннәр, дөньяны нинди генә күзлектән гәүдәләндерергә омтылмасыннар, барыбер мәшһүр Мәҗит Гафуриның инде йөз ел элек әйтелгән «Бер адым алга атлыйм да әйләнәмен артыма, / Кая басканнар икән дип, күз саламын халкыма» дигән сүзләренә тугры калалар. Каләм әһелләре халык алдында зур җаваплылык

тоеп, үзләренең милләтнең йөзен, аның рухи кыйбласын билгеләүче көч икәнлекләрен аңлап эш итәләр. Чынбарлык белән тыгыз бәйләнеш, халкыбыз тарихына, мифологиясенә тирән игътибар, милли гамь белән сугарылганлык — татар постмодернистик әдәбиятының үзенчәлеген билгеләүче төп сыйфатлар булып шулар тора.

Күренекле башкорт язучысы Әмир Әминевның күптән түгел Татарстан китап нәшриятында татар телендә дөнья күргән «Кар кешесе» исемле повестьлар һәм хикәяләр җыентыгына карата да шушы ук сүзләрне кабатларга мөмкин. Әлеге китап «Каләмнәр туганлыгы» сериясендә дөнья күреп, язучының Башкортстанда киң танылу яулаган «Усман ташы», «Кытай-город», «Йолдызак», «Бер көймәдә», «Танкист» повестьлары һәм «Кар кешесе», «Сукбай», «Алдану», «Бүре балалары» кебек хикәяләре белән Татарстан укучысын да таныштыру максатын куя.

Төп сыйфатлары белән постмодернизм әдәбиятына караган әлеге әсәрләрендә язучы заманча иҗат алымнарын башкорт халкының гасырларга сузылган чал тарихы, милли менталитеты, рухи кыйммәтләре, фольклоры белән табигый рәвештә бәйләү осталыгына ирешә. Бу хикәя-повестьларда хыялый, иллюзор вакыйгаларга зур урын бүленсә дә, аларның нигезендә бүгенге тормыш чынбарлыгы, чорның актуаль проблемалары ята. Мәсәлән, «Усман ташы», «Кытай-город», «Бүре балалары» әсәрләрендә автор, гиперреалистик алымнар кулланып, авылларның һәм шулар белән бергә милләтнең дә юкка чыгу проблемасын күтәрә; «Бер көймәдә», «Кар кешесе» хикәя-повестьларында Табигать һәм Кеше арасындагы бәйләнешләрнең өзелүе, җир-суларыбызның үз гаебебез белән юкка чыгуы, экологик һәлакәт алдында торуыбыз хакында оран сала, адәм затының рухи бөлгенлеккә төшүен, аның табигатькә мөнәсәбәте үзгәрүе аша ача. Рухи экология — матди байлык бәрабәренә күңелләрнең хәерче хәлендә калуы — язучының «Танкист» повестенда гаять калку итеп гәүдәләндерелә.

Шушы проблемаларның берсе дә чишелеш тапмаса, безне «Йолдызак» повестенда тасвирланган, бүгенге чынбарлыкка аеруча якын һәм шуның белән тагын да куркынычрак киләчәк көтә. Рухи кыйммәтләрнең, җәмгыятьнең терәге булган гаилә институтының юкка чыгуы, илхалык белән кешеләрдән бигрәк җансыз автоматларны хәтерләткән иминлек структуралары вәкилләренең идарә итә башлавы, шуның нәтиҗәсендә, гади халыкның рухсыз сарык көтүенә әверелүе, «ирек» төшенчәсенең тормыштан тәмам сызып ташланып, кешенең һәр адымы, әйткән һәр сүзе, хәтта уйлаган фикерләренең дә бертуктаусыз күзәтү астында булуы — бу куркыныч киләчәкнең төп хасиятләре шулдыр. Автор укучыларын гамьсезлек йокысыннан айнырга, бары тик коллыкка корылган җәмгыять системасыннан баш тартып, халкыбызның меңьеллыклар дәвамында тупланган күңел хәзинәсенә таянырга чакыра. Мәшһүр инглиз язучысы Джордж Оруэллның 1948 елда тәмамланган «1984» романы белән әлеге повесть арасында тәңгәллекләр шактый. Икесендә дә үзәк геройлар үзләрендә тоташ концлагерьга әверелгән илне үзгәртерлек көч тапмый, аларның көрәшкә омтылышы нәтиҗәсез тәмамлана.

Шуны да әйтергә кирәк: Әмир Әминев геройлары — кешеләр арасында, җәмгыятьтә яшәсәләр дә, постмодернизмга хас булганча, күңел һәм акыл дәрәҗәсе ягыннан кардәшләреннән бер баш өстен торучы, төп халык массасыннан аерылган ялгыз шәхесләр. Бу геройлар акчага, сорыкортларча яшәүгә, гамьсезлеккә корылган бүгенге җәмгыятьне кабул итә алмый, аны үзгәртү өчен көрәшкә чыга, кешеләрне гамьсезлек йокысыннан уятып, алар күңелендә миһербанлылык, шәфкать, кешелекнең киләчәге өчен җаваплылык хисе, матурлык тойгысы тәрбияләргә өметләнә. Кызганыч ки, бу якты хыяллар чынбарлыкта якташларының таш бәгырьләренә бәрелеп ватыла. Чөнки халыкның төп өлеше, «массалар» өчен, мондый затлар «ала карга»ларга, ул гына да түгел, куркыныч Кар кешеләренә тиң.

«Бер көймәдә» повестеның үзәк герое Габит — Табигать-Ана белән үзенең бәйләнешен югалтмаган, ата-бабалар рухын күңелендә саклаган «соңгы могикан»нарның берсе. Сода заводына чимал кирәк дип, ата-бабаларыбызның изге урыны — исеме борынгы мифларда, легендаларда мәңгеләштерелгән Торатауны җимерүче, туган якның күрке булган коралай-боланнарны атып юкка

чыгаручы замана байларына, җансыз чиновникларга берүзе каршы чыга ул. Теләктәшләрне дә кешеләр арасыннан түгел, ә табигать дөньясыннан — кошлар, хайваннар арасыннан таба. Үзенең һәм кайчандыр үзе һәлакәттән коткарган бөркет баласы гомере хакына җаһил бәндәләрнең чираттагы һөҗүмен кайтара. Ләкин бу җиңүнең нәтиҗәсез булуы да ихтимал, чөнки таш бәгырьле буш җаннарның саны көннән-көн арта гына бара, ә Габит кебек «ала каргалар»ның үзләрен тиздән «Кызыл китап»ка кертергә кирәк булачак...

Китапка исем биргән «Кар кешесе» хикәясендә әлеге зат Урал тауларына үтеп кереп, үзен табигый яшәү мохитеннән мәхрүм итүче, урман-кырларны, җанварлар дөньясын аяусыз рәвештә кыручы кешелек җәмгыятеннән үч алучы дәрәҗәсенә күтәрелә. Аларның ишәеп, район үзәгенә һөҗүм итүләре дә шуның белән бәйле. Баксаң, без үзебез дә, әлеге Кар кешеләре кебек үк, яшәү даирәбезне киңәйтү өчен җирдәге башка тереклекне кысрыклап чыгарырга тырышабыз бит! Табигатьтә һәркемнең, шул исәптән адәм баласының да үз урыны, үзенә җитәрлек ризыгы бар. Башкалар өлешенә кул сузуның, дөнья гармониясен бозып, ахырзаман-апокалипсиска китереп җиткерүе мөмкин дип кисәтә автор. Нәтиҗәдә кешелек тә тәмам юкка чыгачак.

Кешелек җәмгыятенең үз тарихына, хәтта ата-анасына игътибарсыз, акча автоматларын хәтерләтүче рухсыз, бәгырьсез көтүгә әверелүен Әмир Эминев ышандырырлык итеп «Танкист» повестенда сурәтли. Аның үзәк герое — дәүләтнең ваемсызлыгы, балаларының хыянәте, оныкларының таш бәгыре аркасында йорт-җирсез сукбай хәлендә калган сугыш ветераны — үзенең соңгы тәяген, гамьсезлек илендәге соңгы плацдармын шәһәр уртасындагы мәйданда постаментка куелган танк эчендә таба, хыялында булса да шуның белән дөнья гаделсезлегенә, яшәү мәгънәсезлегенә каршы көрәшкә күтәрелә.

Гомумән, постмодернизм әдәбиятына хас булганча, Әмир Эминев әсәрләрендә дә реаль тормыш һәм иллюзор вакыйгалар, чынбарлык һәм миф, фани дөнья һәм ахирәт бергә үрелеп килә. Хыялый вакыйгалар чынбарлык фаҗигасен тулырак ачу өчен ярдәм итә. Мәсәлән, автор туфан вакытында, Аллаһы Тәгалә кушуы буенча, дөньядагы бар тереклекнең парлы вәкилен үз көймәсенә тутырып саклап калган Нух пәйгамбәр турындагы дини мифны «Бер көймәдә» исемле повестена кертеп җибәрә. Ләкин шушы энә күзеннән үткәреп сайлап алынган җанварлар арасында да бер хәсисе табыла: тычкан кимереп, көймә төбен тишә. Шулай булгач, кешелек дөньясындагы көнчеллек, бер-берсен күрә алмау хисләре әлмисактан ук килә, дигән фикерне үткәрә язучы. Тәмам бозылып беткән адәм затын рухи һәлакәттән, рухи туфаннан коткару өчен, яңа Нух пәйгамбәрләр — Габитлар кирәк. Шул рәвешле, миф белән чынбарлык табигый берлеккә ирешә.

«Йолдызак» повестенда дәүләтнең иминлек хезмәте вәкилләре тарафыннан читкә алып китеп, бер ялгыз йортка бикләп куелган Рәуфнең тимер рәшәткәле тәрәзәләре алдыннан әле 1812 елгы башкорт амурлары үтә, әле аның каршында патша гаскәрләре Салават батыр белән аның әтисе Юлайны җәзалый. Рәуф, йорт астыннан юл казып, тоткынлыктан котылырга тырышса да, бу нәтиҗәсез тәмамлана: кеше сөякләре өстендә утырган йорт нигезе ишелә һәм юлны баса. Гасырлар дәвамында халыкны изгән, азатлык даулап көрәшкә күтәрелгән ил батырларының сөякләре өстендә корылган империяне символлаштыра түгелме соң бу йорт?! Төрмә-өй эчендәге бердәнбер мәгълүмат чыганагы булган аклы-каралы телевизордан Петросянның юмор кичәләре, эстрада җырчыларының шундый ук концертлары, күңел, акыл үсеше өчен берни дә бирмәгән Америка боевикларының туктаусыз агылуы бүгенге чынбарлыгыбызга туры килми дип кем әйтә ала?! Халыкның уен-көлке, шау-шу, спорт тамашаларына исереп, тарихын белмәүче, иртәгәсе көне турында уйлап та бирмәүче, тамак хакына көн күрүче сарык көтүенә әверелә баруы — бүгенге чынбарлыгыбыз түгелме соң?! Ә бит башкорт тарих дәвамында үз сөякләрендә корылган шушы империяне яклап, илбасарларга каршы көрәшкән, аның өчен кан койган! Һәм аның сөякләре янә шушы үзе яшәгән төрмә нигезенә кереп яткан. Өй тәрәзәсе каршыннан башкорт атлыларының французга каршы яуга китеп бару детале шуңа ишарәли,

минемчә. Иң аянычы: тоткын өчен бу төрмәдән котылу юлы да юк — көннәрдән бер көнне, сакчылар могжизалы рәвештә юкка чыгып, ишекләр үзеннән-үзе ачылса да, рәшәткәләр коелып төшсә дә, Рәүф белән Рәүфә иректә үзләренә барыр юл табалмыйлар, төрмә-йортка кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр булалар. Чөнки җаннарында инде көрәш рухы сынган, төрмә инде аларның күңелләренә күчкән, рухи тоткынлык — аларның тормыш асылы, төрмәдән башка киләчәкләрен күз алдына да китерә алмыйлар. 1990 еллар башында яулап алынган азмы-күпме азатлык белән сынауны күтәрә алмыйча, халкыбызның кабаттан Сталин төрмәләрен сагынуына ишарәле түгелме соң бу деталь?! Рәүф белән Рәүфәнең улы Салават та ата-анасының язмышын кабатлый, аны да дәүләт иминлеген саклаучылар, гаиләсеннән аерып алып китеп, шундый ук йорт-төрмәгә биклиләр. Шулай итеп, чылбыр кабатлана...

Милләт инкыйразы, беренче чиратта, аның гасырлар дәвамында күнегелгән тормыш рәвешеннән, ата-бабалар төягe — туган җирдән баш тартудан башлана. Башкортның яңа заман таләпләренә авыр яраклашуын, самимилеге, беркатлылыгы аркасында, йөз еллар элек тә, әле дә, үз түрәләре тарафыннан да, чит төбәкләрдән, хәтта чит илләрдән килгән алыпсатарлардан да җиңел алдануын язучы аеруча тәэсирле итеп, гиперреалистик алымнар белән «Кытай-город» повестендә ачып сала. Артта калган «Алга» колхозы җирләрен, шунда урнашкан Сыбай авылы белән бергә, Кытай бизнесмены Чжан Си әфәнде сатып ала да монда яшәүчеләрне үз исәбенә шәһәргә күчереп куя. Бушаган җирләрдә исә бер ел эчендә яңа кала — Кытай-город калкып чыга. Шәһәрнең «җиңел» тормышына кызыгып, Фәйзулла кебек аек фикер йөртүче аксакалларның кисәтүләрен ишетмичә, төп байлыгы — җирдән колак каккан авылдашлар азактан терсәкләрен тешлиләр дә, тик соң була. «Инвестор» дип аталучы килмешәкләрнең чынлыкта бары тик үз кереме хакында гына кайгыртуын, гади халкының мәнфәгатьләре алар өчен берни булмавын — заман чынбарлыгын язучы ачынып тасвирлый. Шунда ук үз халкының үшәнлегенә, читләрнең өлгерлегенә таң калып та куя: дистә еллар дәвамында артта калганнар исемлегеннән чыга алмаган колхоз җирләрендә кытайлылар ел эчендә гөрләп торган шәһәр төзиләр...

Милләт инкыйразының икенче бер сәбәбе — башка тел, башка мәдәният вәкилләре белән катнаш никахларда икәнлеген ачу өчен, Әмир Әминев «Бүре балалары» исемле хикәясендә кешеләр һәм хайваннар дөньясы арасында уңышлы параллель китерә. Аналары — эт, аталары бүре булган көчекләр, бераз үсә төшкәч, көчлерәк кан чакыруы буенча, авыл йортын ташлап, урманга качып китәләр. Ул гына да түгел, бүреләрне чакырып китереп, үз әниләрен — Актырнакны да талаталар.

Тамбов өлкәсеннән Уралга «командировочный» булып килгән Иван да, Сәкинә исемле башкорт кызын ансат кына авырга калдыра да, «тиздән килеп алырмын» дип, ташлап кача. Билгеле инде, башка милләт вәкиле белән гаилә корырга ул үзе дә, ата-анасы да теләми. Алай гына да түгел, урыс-башкорт «никахыннан» туган Альберт исемле малай, әнисе тәрбиясендә уналты яшен тутыру белән, аны авыру хәлендә ташлап, урыс әтисе янына китә. «Кеше — шул ук җанвар» дигән Ницше тәгълиматы (ә бу фәлсәфә постмодернизм мәдәниятенең нигезендә ята) биредә җиренә җиткереп тормышка ашырыла.

Әмир Әминевның әлеге повесть-хикәяләре турында озак сөйләп булыр иде. Аларның һәркайсы катлы-катлы сюжетлы, һәр катламда тирән сер, фәлсәфә яшерелгән. Бу әсәрләрне тулы хокук белән интеллектуаль проза үрнәкләре исемлегенә кертеп була. Алар укучыдан да тиешле әзерлекле булуны таләп итәләр, кешене уйландыру, аңа фикер орлыгы салу максатын куялар. Минa калса, Әмир Әминев иҗаты мисалында башкорт прозасы үз үсешенең яңа этабына аяк басты. Бу мәртәбәле иҗатка җентекле анализ бирү, аның үзгә хасиятләрен ачыклау — тәнкыйтьчегалимнәребез алдында торган көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

**Иллус ФАЗЛЕТДИНОВ,**
*Башкорт дәүләт университеты доценты,*
*«Тулпар» әдәби-нәфис журналының*
*җаваплы сәркатибе*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Габделҗаббар КАНДАЛЫЙ**

***

*(Имди назланган кызлардан әйтелгән)*

— Чүсәнә, абзый, чүсәнә,
Кысыбрак яхшы сөйсәнә,
Сөйгәчтин күңелем үсә лә, —
Диеп уйнар матур кызлар.

— Чү, абзый, тимә имигә,
Имием сиңа тими лә!
Тигәчтен кадере кими лә, —
Диеп уйнар матур кызлар.

— Чү, абзый, шаярып ятма,
Буыннарынны катырма,
Уңайсыз булыр ятырга, —
Диеп уйнар матур кызлар.

Моны язды ки бер талиб,
Укыган булмасын галиб,
Соңра булмасын гаиб, —
Мәгъшукымдин җөда булдым!

*1850 ел.*

**Һади ТАКТАШ**

## Мәхмүд Максудка

*(Хатлардан юллар)*

Мәхмүд!

— Кояш көлми дә, елмаймый да.

Чөнки ул, синең кебек вечный шоколад ашап, авызын ерып йөрергә вакыт тапмый.

Анын, күзгә-күз карашып, утырып чәй эчкәндә көләргә хатыны да юк.

Ул ялгыз һәм көлми. Анын эше дә юк.

Мәхмүд!

Ә без синең белән, ике ачык авыз, көләбез. Шунын өчен дә мин сине өзелеп яратам. Син мәнге ачык — йөрәктән көлеп йөрисен. Шунын өчен дә мин синең

хатларынны яратып укыйм. Синен хатларынны уку минем өчен матур бер шигырь уку белән бер. Шунын өчен дә мин сина хат язам.

Шунын өчен дә...

— Тьфу! Тәкрарлау киткән. Картая башладым.

[...] Үзем әле авырып кына тордым.

Шунын өчен баш кәбестә кебек таралган.

Казан үз эшендә.

[...] Казан — төкерми дә Мәскәвегезгә. Сездә булган нәрсәләр бездә дә бар. Анысы белән ялындырмасагыз да, хатларыгыз белән моңайтасыз.

Кышлар килгәч, гыйнвар булгач, каникулга кайта торган иден. Сөйләшәдер идек. Акча сорап ала торган идем, үзенне дә яратадыр идем. Бу ел кайтмадын. Көткән булсам да, кайтмадын, усал. Язлар килер. Бер кайтырсын әле, Алла боерса.

*1926-1927 еллар.*

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Ренат Хариска

Лирик шагыйрь белән дөнья тулган,
Тиле-миләләр дә житеп арткан.
Кайчан туып, кай арада өлгерәләр,
Уйлап-уйлап торамын да шаклар катам.

Ренат Харис ләкин бары берәү генә —
Дөрес шагыйрь! Логикалы һәр фикере.
Ул бит чөнки... Ул бит, әйтсәм әйтим,
Татар шигъриятенең кәмпитере.

**Разил ВӘЛИЕВ**

## Мәйдан

Сабантуйда карап тордым
Татар-башкорт көрәшен.
Татар, башкорт аста калды,
Өскә чыкты керәшен.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Әй, татар кешесе

Гәрәй Рәхимнен «Татар кешесе» дигән шигыренә язылган жыр заманында бик таралды. Үзен-үзе изәргә яраткан татар аны рәхәтләнеп жырлады, ләззәтләнеп тынлады.Жырда мондый юллар янгыраганын хәтерлисездер: «Болгарында болганган, Суварында сызланган, Сараенда саргайган — синдер, татар кешесе... Себергә себерелгән, Чиләбедә чиләнгән, Ырымбурда орылган — синдер, татар кешесе...

Истанбулда ысланып, үзбәкләрдә үзгәреп, Кырымнарда кырылып, беттен, татар кешесе...

Уралында уралган, Касыймнарда кысылган...»

Разил Вәлиев бу жырны азагынача түзеп тынлап бетергәч, салкын су эчеп, хәл алган да Гәрәйгә:

— Татарны интектерү буенча син зур көч куйгансың, — дигән.

Мондый да мактау сүзеннән күңеле тулган Гәрәй Рәхим очынып китә:

— Мин әле үзебезнең республика районнарын да санап чыкмакчы идем. Әйтик: Азнакайда — азынган, Бөгелмәдә — бөгелгән, Буасында — буылган, Арчасында — арчылган...

Разил Вәлиев аны бүлдерә:

— Артыкка китә. Ышандырмый башлый. Масштабта тарая, — ди. — «Касыймнарда кысылган», дисең бит әле. Шуңа бер җөмлә генә өстәп куй: «Чукоткада чукынган», дип. Шул җитә.

## Ямаулы янчыктан

***

Шаян сүз — көлүнең имезлеге.

***

Әңгәмә вакытында сүзне мөгезеннән эләктерә алмыйча азаплану п а у з а дип атала.

***

Кеше хатыннары хыянәт итә, ә минеке — һичкайчан! дигән астыртын ышаныч һәммә ирне кабергәчә озата бара.

***

Телевизордан Валуевның самими йөзен күргәч, Шандыбинны сагынып куйдым. Экранда чын руслар күзгә кырып салырлык кына күренә шул.

***

Җир шары язмышын кайгыртып барган Шагыйрь, бозга таеп егылган әбине дә искәрмичә, өстеннән атлап чыгып китте.

***

И башлы да бит син! Башсызлыгыңны белеп, шуны яшермичә йөрүең белән башлы...

***

Президентлар буш булырга мөмкин, әмма Вакыт буш булалмый, чөнки Вакыт һәрчак вакыт белән тулган була.

***

Сайрыйм дип уйлый бытбылдык та, сөйлим дип уйлый бытылдык та.

***

Миләш әчесеннән балан көлгән ди.

***

Тигәнәк ябышкан сакалын вәкарь белән селкетеп, сәхтиян иреннәрен кыйшайтып, сагыз чәйнәп торган кәҗәдә «чихал мин сезгә...» дигән мут горурлык бар.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

Руслан Рәүпов

# БУЛГАНДА — КАДЕРЕН БЕЛ, ЮГАЛТКАЧ — ЕЛАМА

БӘЯН

### Икенче бүлек

### Бер ай үткәч

Илнар урамда мотоциклында иптәшен көтеп утыра иде. Шулвакыт каршына Алсуның группадаш кызы килде.

— Сәлам, Илнар, — дип исәнләште кыз. — Кемне көтәсең?

— Син Алсуның кайда икәнен белмисеңме? Менә ничә көн аны эзлим инде, — диде Илнар.

— Ә ул китте, — дип җавап бирде кыз.

— Китте? Кая?

— Америкага, — дип кыска гына җавап бирде кыз. Илнар аптыравын яшерә алмады.

— Америкага?

— Юк инде, — дип көлде кыз. — Чаллыга гына. Практикага.

Илнар җиңел сулап куйды, рәхәтләнеп елмайды.

— Ну, син. Кайчан кайта соң?

— Өч атнадан.

— Өч атнадан?!

— Озак, әйеме?

— Әйе, — диде дә Илнар мотоциклын кабызды. — Рәхмәт, бик зур рәхмәт сиңа яхшы хәбәрең өчен.

— Уңышлар!

Илнар туры өенә кайтып китте. Әтисе әле йоклый иде. Шуңа күрә Илнар пышылдап кына әнисеннән акча сорады. Әнисе акчасын кызганмады, сораган биш меңен чыгарды да:

— Шулкадәр акча нигә соң ул? — дип кызыксынды.

— Миңа китәргә кирәк, әни, — дип җавап бирде Илнар.

— Китәргә? Казаннанмы? — дип аптырады әнисе.

— Мин тиз әйләнеп кайтырмын, әни.

— Әтиең белсә?

*Дәвамы. Башы 3нче санда.*

— Берәр нәрсә уйлап табарсың инде.

— Син Алсу белән бергә барасыңмы? — дип кызыксынды әнисе. Илнар кәефсез генә башын селкеде дә:

— Юк, аны эзләргә барам, — диде.

***

Дүрт-биш сәгать эчендә Илнар автобус белән Чаллыга да килеп җитте. Алсуны кайдан эзләргә белмәде ул. Кемнән сорарга? Кая барырга?

Ләкин бер кешедән моны сорап, икенчесеннән тегене сорап, Алсуның шәһәрнең үзәк больницасында эшләгәнен ачыклады.

Илнар такси белән шул больницага юнәлде. Аның эченә кергәч, каршыга ак халатлы кешеләр очрый башлады. Берсе дә Алсуга охшамаган иде. Шулвакыт палатадан чыгып килүче, йөзеннән нур балкыган кызны күреп алды. Бу — Алсу, аның яраткан Алсуы иде.

Алсу да аны күреп алды. Барган җиреннән туктап калды да Илнарга төбәлде. Илнар аның янына ашыкты, Алсу — Илнар янына. Якынлашкач, Илнар түзмәде, Алсуны кочаклап алды.

Алсуның күзендә яшь иде:

— Нишләп шулай озак килмичә тордың? — диде ул.

— Мин синсез яши алмыйм. Бер генә көн дә синсез яши алмыйм, — дип җавап бирде Илнар.

— Минем өчен син нәрсә эшләргә әзер соң? — дип сорады Алсу, һаман күз яшьләрен тыя алмыйча.

— Әйдә, поезддан сикерәбезме? — диде Илнар. Аның да күзе яшьләнгән иде.

— Әйдә, язылышыйк, — диде Алсу. — Ләкин әти-әниләр янында яшәп калабыз. Беркемгә дә бернәрсә дә әйтмибез, — дип өстәде.

Илнар елмайды.

— Беркемгәдәме?

— Вакыт җиткәч кенә әйтербез, — дип җавап бирде Алсу.

***

Чаллыдан кайтканга өч көн булды инде. Алсу да үз өйләрендә, Илнар да үз өйләрендә яши бирделәр. Алсу белән Алия бик матур гына киенгәннәр. Бүген Илнар белән Алсу, әти-әниләренә әйтмичә генә, язылышмакчылар. Шуңа иң якын дусларын гына дәштеләр.

— Нәрсә булды? — дип сорады Алия Алсудан.

— Мин бик куркам, Алия, — дип җавап бирде ул.

— Курык, ләкин кияүгә чык, — дип үзенекендә торды Алия.

— Мин шаяртмыйм, — диде Алсу пышылдап. — Мин чыннан да куркам.

Әти-әнисе күрмәгәндә генә, Алсу белән Алия өйләреннән чыгып киттеләр. Илнар да, тиз генә өеннән чыгып качты.

Ярты сәгатьтән алар Казанның төп ЗАГСы каршында җыелыштылар. Алсу да, Илнар да бик матур киенгәннәр иде. Илнарның кулында кызыл розалар. Ул аны шундук Алсуга бирде. Алсу, җавап итеп, матур гына елмайды. ЗАГСка кереп киттеләр дә беркадәр вакыттан соң чыктылар. Илнарның кулында «Язылышу турында таныклык» та бар иде.

Тукталышка килеп җиткәч, алар бер-берсеннән аерылырга мәҗбүр булдылар, чөнки Илнарларның өе Казанның бер башында, Алсуларныкы икенче башында иде.

Саубуллашыр алдыннан Илнар Алсуны бик каты итеп кочаклап алды. Сүзләр әйтү артык булып тоелды аларга. Бүген Илнар белән Алсуның иң бәхетле көннәре иде.

Илнар өенә кайтып җиту белән Алсуга шалтыратты. Илнарның иң беренче җөмләсе мондый булды:

— Хатыным китте — кулыма таныклык калдырып, — дип көлде ул.

— Көт инде әзрәк, — дип җавап бирде Алсу. — Башта Алия кияүгә чыксын әле.

— Әйт, чыксын, — дип аның фикерен куәтләде Илнар. — Әйдә киләсе атнада ук аңа егет табып, туйларын ясап куябыз?

Җавап булмады, чөнки Илнарның фикере, әлбәттә, башка сыймаслык иде. Алиянең әле йөргән егете юк. Кая инде ул туй турында уйлау.

***

Эшенә барырга ашыкканлыктан, Алсу тизрәк автобуска утырырга тырышты. Үзенә буш урын алды да, иркенләп утырып, китап укый башлады. Шулвакыт артыннан Илнар килеп утырды.

— Сәлам, хатын, — диде Илнар, аны кочаклап. Аны күргәч, Алсу шаккатты.

— Кулларыңны ал инде, безгә карап торалар, — диде Алсу пышылдап.

— Шуннан ни? — Син минем законлы хатыным! — Илнар сумкасыннан таныклык алып, аны Алсуга күрсәтте.

— Нишләп син аны үзең белән йөртәсең? — дип сорады Алсу.

— Нишлим соң инде? — дип елмайды Илнар. — Хатынымны күргәнем юк, шуңа күрә шушы таныклыкны булса да кулымда йөртәм инде.

— Син акылдан язгансың, Илнар, — дип көлде Алсу. — Ал инде кулыңны! — диде ул, тавышын күтәребрәк.

Аларның артында утыручы олы яшьтәге бер апа, боларны күреп, Илнарга:

— Әй! Нишлисең?! Хатыныңмы әллә ул синең? — диде.

— Юк, — дип җавап бирде Илнар. — Ул — минем бөтен киләчәк гомерем.

Алсу елмайды.

— Син җәмәгать урынында. Әйбәт кенә утыр, — дип өстәде теге апа.

Илнар кулын Алсуның аркасыннан алырга мәҗбүр булды.

— Апа, — дип дәште Илнар. — Ә сез кияүдәме?

— Әйе! — дип җавап бирде ул апа. — 15 яшьтә кияүгә чыктым!

— Ай, җәллим инде ирегезне, — дип өстәде Илнар. Алсу шунда ук аңа терсәге белән төртеп куйды.

— Нәрсә?! — бик үк аңлап бетермәгәнлектән, кайтарып сорады теге апа.

— Юк, берни дә түгел.

Илнар белән Алсу юл буе көлешеп бардылар.

***

Бер атнадан соң Алсуларга кунаклар килде. Ул гаилә дә, алар кебек, урта хәлләләр иде. Егет, аның әнесе һәм әти-әнисе Алиянең кулын сорарга килделәр. Алия бик нык дулкынланды. Ә Алсу аны һәрьяктан да мактады. Алсу бәхетле иде, гел елмаеп кына торды.

— Син аны алырга ризамы? — дип сорады егетнең әтисе улыннан.

Егет, уйлап та тормыйча:

— Әлбәттә, риза, — дип җавап бирде.

Шунда егетнең әтисе болай дип өстәп куйды:

— Минем кече улым, кече кызыгыз Алсу кебек үк, медицина хезмәткәре булырга укый.

Алсу аңлап алды: аның үзен дә кияүгә бирергә уйлыйлар бит болар! Бу сүзләрне ишетү белән, аның йөзеннән елмаю качты. Алия дә каушап калды.

Алсу торды да, кунак бүлмәсеннән чыгып, әнисенең әйткән сүзенә:

— Нәрсә сөйлисең син, әни?! — диде.

— Бу бик үк мәҗбүри түгел инде, әлбәттә, — дип аның хәленә кергән булды арттан чыккан әнисе. — Ләкин нәрсәсе начар инде моның?

— Йә, ни инде бу?! Бер кызны ал, икенчесе бушка?! — Алсу нишләргә дә белмәде.

— Ни сөйлисең син? Без сезне сатмыйбыз бит. Ул малайның югары белеме дә бар, сиңа туры да килә бит.

Аннары шкафыннан матуррак күлмәк алды да, Алсуга бирде.

— Мә, киен. — Ләкин Алсу каршы килде.

— Нишләп? Бу киемемнең нәрсәсе начар? Минем кабат киенәсем килми! Минем кияүгә чыгасы килми! — дип каршы килергә тырышты Алсу.

Менә шул сүзләрдән соң әнисе дә үзенең катылыгын күрсәтте.

— Син нәрсә, Алиянең дә туен бозмакчы буласыңмы?! — Алсуга киемнәрен атып бәрде. — Киен!

Алсу киенергә мәҗбүр булды. Кунак бүлмәсенә кергәндә Алсу, әлбәттә, кәефсез иде. Ә әнисе, киресенчә, үзен бик бәхетле итеп күрсәтте.

Башкаларга:

— Тагын бер туй буласын ишеткәч, кызым каушабрак калды, — дип әйтте.

— Бар да яхшы, — дип белдерде егетләрнең кечесе. — Мин дә каушап калдым әле, — дип өстәде. — Аның: «Әйт әле, Алсу, әгәр дә син риза булсаң...» — дип башлаган җөмләсен Алсу үзе бүлдерде.

— Үтенәм синнән, — дип, егеткә карап елап җибәрде ул. — Мин... — Мин кияүдә инде.

— Н-нәрсә?

Көтелмәгән бу хәбәрдән Алсуның әти-әнисе аптырашып калдылар. — Мин, әти-әниемнән яшереп кенә, бер егеткә кияүгә чыктым. Алар... берни дә белмиләр, — дип, күз яшьләрен һаман тыя алмады Алсу.

***

Алсу үзе кирәкле әйберләрен чемоданына тутыра, үзе елый иде. Янында Алия дә бар.

Бүлмәгә әнисе килеп керде дә:

— Син түгел, Алия еларга тиеш монда! — диде. — Синең аркада аның туе бозылды!

— Минем кияүгә чыгасы килми иде, — дип, сеңлесен яклады Алия.

— Әлбәттә, нишләп син чыгарга тиеш әле? Аның чыгасы килде бит әнә, түзмәде!

Алсу тагын да ныграк елый башлады. Ул таш кебек авыр чемоданын алды да, чыгып китешли әнисе янында туктап калды. Ә әнисе, зәһәрләнеп:

— Ычкын моннан! — дип кенә әйтә алды. — Синең өчен урын юк монда хәзер!

Алсу чыгып китте. Ишек янында әтисе очрады. Нәрсә дияргә дә белмәде Алсу. Әтисе Алсуның чемоданын алды да, урамга ук болгап атты, һәм кызының артыннан кычкырып та калды әле:

— Кит моннан! Бүтән күземә күренәсе булма!

Алсуга ни кала инде? Китәсе генә. Тышка чыгып чемоданын алганда каршысына Илнар очрады. Аның кулы да буш түгел иде. Кечкенәрәк булса да, сумкасы тум-тулы иде. Аны да өеннән куып чыгарганнар икән.

*Дәвамы киләсе саннарда*



*Мин, **Светлана Гыйләҗева**, Башкортстан Республикасының Бүздәк районы Әмир авылында туып-үстем. Мәктәп елларында ук Казан шәһәре, университет турында хыяллана-хыяллана, бер-бер артлы Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов, Хәсән Туфан, Һади Такташ әсәрләрен укый идем. Хыял тормышка ашты: бүген мин Казан федераль университетының II курс студенткасы. Мин матурлыкка гашыйк, ә аны һәрнәрсәдә табып була, бары тик күрә белергә генә кирәк.*

# ҺАВА ТОРЫШЫ

Диләне тиз генә уятырмын димә! Кеше шулай йокласа да йоклар икән. Татлы йокысыннан уятуның бердәнбер чарасы – телевизор. Әнисе моны яхшы белә – пульт төймәсенә басып, телевизорны кабызуы булды, Диләнең юрганы кымшанып куйды. Кыз иренеп кенә киерелде дә күзләре йомык килеш юыну бүлмәсенә атлады. Телевизорда иртәнге тапшыру бара иде. Юынып чыгып, шуны карарга утырды. Әнисенең аш бүлмәсеннән тавышы ишетелде:

— Кызым, чәең суына!

— Хәзер, әни, хәзер! Һава торышын гына тыңлыйм! – Дилә, тагын бер кат киерелеп, авызын ачты.

Һава торышы. Кирәк иде ди сиңа! Тагын биш кенә минут булса да черем итеп булмасмы дип утыруы иде Диләнең. Барыбер анда әйткәнчә булмый ул һава торышы, дигән фикере ныклы иде кызның. Бер колактан керсә, икенчесеннән чыга ул мәгълүмат. Иртәнге тапшыруның рәсми иганәчеләрен әйтер өчен уйлап тапканнар ахрысы ул һава торышын! Дилә диктор хатынны ирештереп, авызларын кыйгайта төшеп сөйләргә кереште.

— 14 май Казанда көндез температура +18, төнлә +15, атмосфера басымы терекөмеш баганасының 756 миллиметрын тәшкил итә, җил көньяк-көнчыгыштан, көннең аяз булуы көтелә. Һава торышының рәсми иганәчесе «Яңалыклар җиле» компаниясе...

Ул тагын бераз экранга карап утырды, аннары күзе өстәлдә торган фоторамкага төште. Абыйсы белән аның кечкенә чакта төшкән фотосы иде анда. Шундый кызыклар алар монда! Диләгә өч-дүрт яшьтер, ә абыйсына ун яшьләр чамасы. Ярата Дилә бу фоторәсемне. Әнисе дә ярата. Шуңа күрә иң күренеп торган урынга куйган ул аны. Ә абыйсы ярата микән?

Дилә аш бүлмәсенә чыкты. Әнисе, өстәлгә ризык тезүеннән туктамыйча, кызына дәште:

— Ну, һава торышлары белән эшләр ничек анда? – диде көлемсерәп.

Ул Диләнең һава торышын тыңламаганын яхшы белә иде. Кызының калган шуклыклары кебек, монысы да аның өчен сер түгел.

— Әнии, — дип сузды Дилә, — башка сөйләр сүз юкмы әллә?

— Ник алай дисең, кызым?

— Кешеләр, башка темага сөйләшергә сүз тапмасалар гына, һава торышы турында фәлсәфә саталар. Таныш түгел кешеләр яки күптән түгел таныш булганнар өчен аралашып китәр өчен менә дигән! Ә без инде синең белән башкалар турында сөйләшик, яме?

Кемгә генә охшап шундый шук булды икән? Үзем бер дә андый түгелмен дип уйлап куйды Зөһрә ханым, кызына сокланып.

— Ярый алайса, әйдә уку турында сөйләшик. Мәктәптә хәлләр ничек? Алгебрадан контроль эш ничек үтте?

Эләктем! Һава торышы турында сөйләшеп утырсак, ни булыр иде, дип үз-үзен эченнән сукте Диләкә. Озак та уйламады:

— Әәә... Әлфия Кәримовна авырып киткән әле. Контроль эш булмады, – диде дә, тиз-тиз генә чәен йоткалап, урыныннан тора башлады.

— Ничек инде? Майдамы? Чирлиме?

— Әйе, әнием, әйе. Май аенда гриппның иң котырган чагы. Үз-үзеңне сакламыйча, киенмичә йөрсәң, шулай була ул. Шуңа күрә мин дә киеним әле. – Диләкә әнисен битеннән үпте дә җәһәт кенә күздән юк булды. Зөһрә ханым аңламый да калды. Их, бу Диләне! Артыннан өлгерермен димә! Бөтерчек кебек кенә әйләнеп йөри бит.

Автобус тукталышында ул үзенең сыйныфташы Гөлшат белән очрашты. Ул күрше йортта гына яши, мәктәпкә дә гел бергә йөриләр иде. Диләгә сәлам биргәннән соң да Гөлшат кулын сузып тора иде.

— Ник кулыңны суздың? – диде аптырап Диләкә.

— Кара син! Кара! Миңа апам бүләк итте! – Кулын Диләнең йөзенә үк терәде Гөлшат. Куанычы эченә сыймый иде кызның.

— Ой, бу көмеш балдакмы?

— Әйе, көмеш! Матурмы?

— Матуууур! – дип сузды Диләкә.

— Шулай шул! Апаң булгач рәхәт ул!

— Ә нинди уңайдан бүләк итте?

— Болай гына! Апа кешегә сеңлесенә бүләк ясар өчен сәбәп кирәкме әллә? – дигән булды Гөлшат, боргаланып.

Әй, кыланчык та инде үзе! Унда гына укыса да, зурлар кебек сөйләшә белә бу Гөлшат!

— Матур булган, матур! – дип тагын бер тапкыр хуплап куйды Диләкә.

Уку көне гадәттәгечә үтеп китте. Озакламый җитәчәк имтиханнар турында һәр дәрес саен кабатлап тордылар. Булган икән куркыр нәрсә! Кеше биргәнне без генә бирербез әле дип уйлады Диләкә. Дәрестә дә абыйсы турында уйлап утырды ул. Сагынды ул аны. Инде ярты ел күрешкәннәре юк. Абыйсы Питерга күчеп киткәннән бирле кайтканы юк, Диләләрнең дә аның янына барганы юк.

Гөлшатның бүген көне буе авызы ерык. Класстагы бөтен халыкка балдагын күрсәтеп чыкты. Кешенең апасы янында... Бүләгеннән бигрәк янда булуы белән бәхетле Гөлшат! Ә Диләнең абыйсы ерак. Бер кайтып та әйләнми ичмасам. Эше күптер инде. Якынрак та түгел шул.

Мәктәптән чыгып барганда, Диләнең кесә телефоны шалтырый башлады. Кем икән? Мәктәптә чагында аңа шалтыратучы булмый иде гадәттә. Дуслары белән кич хәбәрләшә иде дә. Мәктәптән чыккач, ул үзе әнисенә шалтыратып өлгерә. Бераз сәерсенеп, кесәсенә үрелде. Телефон экранында «Абыем» дигән язу күренде. Абыйсы шалтырата! Әллә ул да Диләне сагынды микән? Берәр кеше турында уйласаң, ул да сине исенә төшерә, диләр бит, шул дөрес, ахыры!

— Алло, сәлам!

— Сәлам, Диләкә! Хәлләрең ничек?

— Яхшы, абый! Үзеңдә ни хәлләр бар?
— Әйбәт кенә. Укулар ничек?
— Әйбәт. Синең эштә бер килешме?
— Әйбәт... Һава торышлары ничек соң сездә?
— Жылы. Җәй җитә бит. Ә сездә?
— Бездә дә җылытты. Бу җәй коры булыр, ахыры. Шуңа охшап тора. Күптән инде яңгыр да яуганы юк.
— Алай икән.
— Әйеее. Ярый, Дилә, хәлләреңне генә белмәкче идем. Чакыралар.
— Ярый, рәхмәт шалтыратканың өчен!
— Хуш!
— Сау бул, абый!

Дилә телефонының төймәсенә басты да кесәсенә салып куйды. Көннең болытсыз булачагы турында иртәнге тапшыруда вәгъдә бирүләренә карамастан, көтмәгәндә коеп яңгыр яварга тотынды. Кызлар тукталышка таба йөгерделәр.

---



*Мин, **Алинә Садертдинова**, Тәтеш шәһәрендә туганмын. Татар мәктәбенең IX сыйныфында укыйм. Табигатем буенча шаян, кайчак шук, ачык күңелле, энкерсез. Яраткан шөгылем – әдәби әсәрләр уку, шигырьләр, әкиятләр иҗат итү; җырларга, биергә бик яратам.*

## Ана өмете

Июнь таңы... Күпме аналарның
Тынычлыгы кинәт югала...
Сугыш башланды, дип хәбәр итә
Радиолар бөтен дөньяга.

Фашист гаскәрләре бәреп керде
Тыныч кына яткан ил чиген.
Шомлы хәбәр бөтен авыл буйлап
Шакып йөрде һәркем ишеген.

Аналарның йөрәк парәләре
Китеп барды Ватан сугышына.
Төннәр озын, башта төрле уйлар,
Газиз ана улын сагына.

Хатлар килми озаграк торса,
Ана түзми: елый, борчыла.

Соңгы хатын улының, кат-кат укып,
Аны үбә, кыса учына.

Түз, түз, ана, тиздән сугыш бетәр,
Улың кайтыр синең янына.
Җиңү алып кайтыр уллар, кызлар,
Күмелер илебез алар данына.

---



*Мин, **Фирүзә Гыйздәтуллина**, Мамадыш районы Норма авылында тудым. 2012 елда XI сыйныфны тәмамладым, хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты психология һәм педагогика факультетында II курста белем алам. Мәктәп елларыннан шигырьләр язам, күп кенә конкурсларда катнаштым, шигырьләрем район газетасы битләрендә басылып чыкты.*

## Чишмә моңы

Талга кунып сандугачлар сайрый,
Су буйларын сарган куе томан.
Челтер-челтер көмеш чишмә ага,
Чишмә моңы – бишек җыры сыман.

Гасырларны узып аккан чишмә
Үз эченә күпме хәтер җыйган.
Күпме шатлык, сагыш иңгән аңа,
Чишмә моңы – кеше күңеле сыман.

Ничә буын сабыйларның үсеп,
Читкә китүенә шаһит булган.
Җылылыгын, назын югалтмаган,
Чишмә моңы – кояш нуры сыман.

Тирә-ягын матур җырга күмеп,
Авылымның ямен саклап торган,
Хәтерләрдән мәңге югалмаслык,
Чишмә моңы – әнкәй җыры сыман.

## Бар сукмаклар туган якка илтә

Чит җирләрдә күпме йөрелсә дә,
Йөрәк һаман кайтыр көнне көтә.
Урау-урау юллар, еллар үткәч,
Бар сукмаклар туган якка илтә.

Көмеш сулы чишмә челтерәгәне
Күңелләргә керә, жанга үтә.
Шул сулардан сафлык инсен өчен,
Барлык юллар туган якка илтә.

Җәйге җилдә ак каеннар шаулый,
Вакыт әкрен генә йомгак сүтә.
Сагыналардыр, кайтмый калмаслар, дип,
Туган авыл һаман безне көтә.

## Ышан

Кояш сүнгән кебек булса күк йөзендә,
Хәлең бетсә тормыш йөген тарта-тарта,
Ышанычың кими барса үз-үзеңә,
Тормышыңны кара болыт каплап алса,

Син ашыкма кулларыңны төшерергә,
Беркемгә дә җиңел генә килми бәхет.
Һич ярамый сабырлыгың югалтырга,
Ярдәм сора өмет белән күккә дәшеп.

Ходай күрә барыбызны, Ходай белә,
Тиешенчә бирә шатлык, кайгысын да.
Тормыш – дәрья. Тигезлегең саклау кирәк
Шул дәрьяның дулкыннары арасында.

Ышан бары бар да яхшы буласына,
Карлар эрер, тиздән җылы язлар килер.
Янәшәндә якыннарың, туганнарың –
Шул чагында күк йөзендә кояш көлер.

---

## Халык әйтсә, хак әйтә

*Оялчан кыз — сөйкемле кыз.*

*Уналты яше тулган кыз әнә өстендә бии.*

*Егет булсаң, җилек бул, суда йөзгән сөлек бул.*

*Егет җиле белән йөрер.*

*Бакага гашыйк булсаң, күл буеннан кайтмассың.*

*Бирәү бар — үзе яратыр, бирәү бар — үзен яратканны яратыр.*



# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## БӘЙРӘМ ТАНТАНАЛАРЫ

Республикабызның киң җәмәгатьчелеге Татарстан Язучылар берлеге оешуга 80 ел тулуны билгеләп үтте. Бәйрәмдә төрки телле мәмләкәтләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән күренекле әдипләр һәм язучылар катнашты. 25 апрельдә Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында «Бүгенге этапта төрки әдәбиятларының бәйләнышларын камилләштерү буенча актуаль мәсьәләләр» темасына «түгәрәк өстәл» үткәрелде. Шул ук көнне «Корстон» күнел ачу үзәгендә Язучылар берлегенең 80 еллыгына багышланган бәйрәм тантанасы узды.

26 апрельдә Габдулла Тукайның туган көненә багышланган Шигърият бәйрәме алдыннан шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр салынды, чәчәк салуда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Г.Тукай һәйкәле янында халык бәйрәме оештырылды. Бәйрәмнең төп өлешендә «Илһам» яшь язучылар конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булды. Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясен бирү турында Татарстан Президенты Указы укылды. Әлеге мәртәбәле бүләк «Утлы дала» ике томлы тарихи романы өчен язучы Вахит Имамовка һәм каллиграфик композицияләре өчен Владимир Поповка бирелде. Шул ук көнне М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» дип тантаналы төстә игълан ителде.

***

25 апрельдә С.Сайдашев исемендәге Зур концерт залында ТӨРКСОЙ генераль секретаре Дүсен Касеинов Татарстанның мәдәният эшлеклеләрен медальләр белән бүләкләде. Медаль халыкара төрки мәдәният оешмасына 20 ел тулу уңаеннан гамәлгә куелган. Бүләкләнүчеләр арасында тарихчы һәм сәясәтче Рафаил Хәкимов, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш дирижёры Ренат Салаватов, Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов, ТР фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов бар. Моннан тыш, Казан дәүләт филармониясе солисткасы Регина Вәлиева, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, ТР фольклор музыкасы ансамбле коллективларына ТӨРКСОЙ оешмасының Рәхмәт хаты тапшырылды.

***

25 апрель көнне «Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» елы дип игълан итү тантанасына багышланган матбугат конференциясе узды. Конференция кысаларында Татарстан һәм Кырым республикалары Мәдәният министрлыклары арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Килешүне Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм Кырым Республикасы мәдәният министры Арина Новосельская имзалады.

## ОЧРАШУЛАР

1 апрель көнне Ауразия Язучылар берлеге рәисе, «Кардәш каләмләр» журналы һәм «Бәнгү» китап нәшриятының җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Якуп Өмәрогълу һәм Искешәһәр төрки дөнья мәдәниятләр башкаласы агентлыгы идарә комитеты әгъзасы Аһмәт Кот белән татар әдәби басмалары мөхәррирләре очрашты. Әлеге кичәне «Казан утлары» журналы оештырды. Очрашу барышында Төркиядә һәм Татарстанда китаплар чыгару, аларны тарату мәсьәләләре, язучыларның һәм әдәби басмаларның тормышы, үсеше турында сүз алып барылды. Кунаклар Казанга хөрмәт белән караулары, татар әсәрләренең төрекчәгә тәрҗемәсен яратып укулары турында сөйләделәр, төрек әдәбиятын да татарчага тәрҗемә итү хакында сүз алып барылды. Очрашуда «Татмедиа» ААҖнең генераль директоры Ф.И.Шәһиәхмәтов та катнашты.

***

6 апрельдә Казан дәүләт ветеринария академиясе студентлары «Казан утлары» журналы редакциясе вәкилләре белән очрашты. Очрашуда баш мөхәррир Илфак Ибраһимов, редакция хезмәткәре Ләйсән Солтанова һәм Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, ТРның халык артисты Гөлзадә Сафиуллина, юмор остасы Алмаз

Хәмзин катнашты. Кичә шигырьләр уку һәм җыр белән аралаштырылып, кунаклар белән студентлар арасында җылы рухта узды.

Шундый ук очрашу 11 апрель көнне Казан (Идел буе) федераль университетында татар бүлеге студентлары белән булды. Кичә шигъри диалог, журнал, әдәбият һәм яшьләр турында әңгәмә форматында үтте.

***

14 апрель көнне Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә, «Калеб» яңа буын җыены кысаларында, «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре белән очрашу булды. Әлеге чарада журналның баш мөхәррире, шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илфак Ибраһимов, филология фәннәре кандидаты Рамил Ханнанов, шагыйрәләр Гөлзадә Бәйрәмова һәм Ләйсән Фәтхетдинова катнашты.

## КОНКУРСЛАР

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе ТР Мәдәният министрлыгы, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә үткәрелә торган «Ел китабы — 2012» конкурсына йомгак ясалды. Татарстан нәшриятларында 2012 елда дөнья күргән, 2013 ел дәвамында иң күп укылган китапны билгеләүдә республикабызның 45 үзәкләштерелгән китапханәләр системасы катнашты. Конкурска 248 китап тәкъдим ителгән иде, шуларның 51е — чәчмә әсәр (проза), 50се — тезмә әсәр (шигърият), 46сы — балалар әдәбияты, 45е — рус телендә чыккан матур әдәбият, 31е — татар телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият, 24е рус телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият китаплары булды.

*Чәчмә әсәрләр:* I урында — Мәдинә Маликованың «Арыш тәме»; II урында — Халисә Ширмәннең «Ерактагы йолдызым»; III урында — Альберт Хәсәновның «Данәгөл» китаплары.

*Тезмә әсәрләр:* I урында — «Күбәләгем, түгәрәгем» (төзүчесе — Линар Закиров); II урында — Эльмира Шәрифуллинаның «Тамды яшем»; III урында — Роберт Миннуллинның «Татарларым» китаплары.

*Балалар әдәбияты:* I урын — «Тукай иленә сәяхәт — Путешествие в мир Тукая»; II урын — «Әкиятләр»; III урын — Булат Садретдиновның «Айда кунакта» китаплары.

*Рус телендә чыккан матур әдәбият:* I урын — Зифа Кадыйрованың «Сумбуль»; II урын — Светлана Сурчакованың «Амина»; III урын — Вакыйф Нуриевның «Седьмая палата» китаплары.

*Татар телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият:* I урында — Разил Вәлиевнең «Минем чорым — минем җырым»; II урында — Тәлгат Галиуллинның «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы»; III урында — Марсель Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» китаплары.

*Рус телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият:* I урында — Нияз Халитовның «Татарская мечеть и её архитектура»; II урында — «История Казани в документах и материалах. XIX век; III урында — Нурзия Сергееваның «Город Казань в картинках — Казан шәһәре рәсемнәрдә» китаплары.

***

14-19 апрель көннәрендә М.Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында Г.Тукай исемендәге Россиякүләм шигырь укучылар конкурсының финал туры узды. Шигырь укучылар проекты дүртенче тапкыр оештырылды. Быелгысы «Җәлилчеләр» дип аталган иде. Конкурс программасында каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең әсәрләре укылды.

***

24 апрель көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында ТР Язучылар берлеге, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Казан (Идел буе) федераль университеты тарафыннан оештырылган «Илһам» яшь язучылар конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы узды. Әлеге чарада ТР Премьер-министры урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов та катнашты. Ул «Илһам» яшь язучылар конкурсында катнашучыларга уңышлар теләде һәм мондый чараның ел саен уздырылырга тиешлегенә басым ясады.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Вакытлы матбугатка язылуның заманча формасы булдырылды. Газета-журналларга хәзер интернет аша да язылып була! Моның өчен нибары «Татмедиа» (http://tatmedia.ru) сайтына керергә һәм «Подписка» төймәсенә басарга кирәк.

***

15 апрель көнне Казанда гарәп язучысы Аббас Мәхмүт әл-Аккад һәм татар шагыйре Габдулла Тукайга монументлар кую тантанасы булды. Рәссам Усама әл-Серуи эшләгән ике сын КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгыш телләрне өйрәнү институты бинасының IV катында урнаштырылды. Аларны ачу тантанасы татар шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Тукайның вафатына 101 ел тулуга багышланган иде.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: З.ХУСНИЯР. Роман «Ураган» (начало); стихи Х.КАМАЛА, Д.ГАРИФУЛЛИНА, Т.ШАМСУАРОВА; рассказы А.ЕНИКИ, М.ВЕЛЛЕР.
«Конкурс на повесть малого формата»: Н.ГИМАТДИНОВА. «Нурулла»;
«Драматургия»: Р.МУХАМЕТШИН. Либретто по мотивам татарских народных сказок «Белый волк».
«Литературная критика»: А.ХАЛИМ. «Куда бежит наш добрый конь?»
«Наши юбиляры»: статья К.КАРИМОВА «Последний день юмора»; рассказы Ф.ШАФИГУЛЛИНА; статья А.СИБГАТУЛЛИНОЙ, посвящённая 80-летию со дня рождения М.УСМАНОВА.
«Искусство»: статья А.ЗАРИПОВА, посвящённая 100-летию со дня рождения М.БУЛАТОВОЙ; Г.САГИТОВА. «Песня, рождённая в Москве»; Л.ХАМИДУЛЛИН. «Соловей двух народов».
«История»: И.ГИЛЯЗОВ. «Мусульманские пленные в Германии в Первой Мировой войне».
Р.ЮНУС. «Он не был оловянным солдатиком».
«Книжное обозрение»: Рецензия И.ФАЗЛУТДИНОВА на книгу А.АМИНОВА «Снежный человек».
«Белый парус»: повесть Р.РАУПОВА; рассказ С.ГИЛЯЗОВОЙ; стихи А.САДЕРТДИНОВОЙ, Ф.ГИЗДАТУЛЛИНОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Действующая армия. Полевая почта. 19 сентября 1942 года; Праздник поэзии. 26 апреля 2014 года.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: Z.HUSNIYAR. Novel «Hurricane» (beginning); poems by H.KAMAL, D.GARIFULLIN, T.SHAMSUAROV; stories by A.ENIKI, M.VELLER.
«Competition for a small-format story»: N.GIMATDINOVA. «Nurulla»;
«Drama»: R.MUHAMETSHIN. Libretto on motives of the Tatar national fairy tales «The white wolf».
«Literary Criticism»: A.HALIM. «Where is our good horse running?»
«Our jubilees»: article by K.KARIMOV «Last day of humor»; stories by F.SHAFIGULLIN; article by A.SIBGATULLINA dedicated to the 80th anniversary of M.USMANOV.
«Art»: article by A.ZARIPOV dedicated to 100th anniversary of M.BULATOVA; G.SAGITOVA. «Song born in Moscow»;
L.HAMIDULLIN. «Nightingale of the two peoples».
«History» I.GILYAZOV. «Muslim captives in Germany in the First World War.»
R.YUNUS. «He was not a tin soldier».
«Book Review»: Review by I.FAZLUTDINOV on the book by A.Aminov «Yeti».
«White Sail» novella by R.RAUPOV; story by S.GILYAZOVA; poems by A.SADRETDINOVA, F.GIZDATULLINA.
From the photo archive of the magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: active army. Field Post. September 19, 1942;
Poetry Festival. April 26, 2014.

***Тышлыктагы рәсемнәр***

***Тышлыкның беренче битендә:*** Хәрәкәттәге армия. Фронтта – кыр почтасы. Сугышчыларга хатлар һәм газеталар өләшү күренеше. 1942 елның 19 сентябре.
Д.Чернов фотосы. *Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан.*

***Тышлыкның дүртенче битендә:*** Шигърият бәйрәме. 2014 елның 26 апреле.
Р.Якупов фотосы.

# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

## *2014 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) **Имамов Вахит Шәех улына** — «Утлы дала» ике томлы тарихи романы өчен, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2012 ел;

2) **Попов Владимир Александровичка** — «Тугра-шамаил-истәлек. Шиһабетдин Мәрҗани — күренекле тарихчы-галим, философ» (2013 ел), «Тугра шамаил-истәлек. Бакый Урманче» (2013 ел), «Тугра-шамаил-истәлек. Илдар Хановка» (2013 ел), «Тугра-шамаил-истәлек-шәҗәрә. Шакирҗан улы Әхмәтҗан Таһиров» (2013 ел), «Өч тапкыр хаҗ кылган Болгар хатын-кызы туграсы» (2012 ел); «Бөек Ватан сугышы музеен оештырган һәм Татарстан Республикасында өч зур сайт (ТР сәнгатенә, В. Попов иҗатына багышланган һәм ТР Дәүләт музее сайтлары) алып баручы Елена Сумгатова туграсы» (2013 ел), «Тугра» Низамеддин Мир Алишер Нәвои. Көнчыгышның бөек шагыйре. Философ» (2012 ел), «Шамаил. Галәмне Яралтучы. Саклау догасы» (2012 ел), «Шамаил. Басмалла» (2009-2012 еллар); Шамаил-триптихлар: «Тынычлык хакына» — үзәктә: «Иман, Мәхәббәт, Вөҗдан. Өмет», уң якта: «Каллиграфия», сул якта: «Әссәламе галәйкем» (2009-2013 еллар); «Аллаһы Тәгаләнең фарыз-нәсыйхәтләре» — үзәктә: «Басмалла», уң якта: «Гомер Касәсе. Яхшылык һәм явызлык кылучыларга», сул якта: «Яшәү Көче Касәсе. Изгелеккә өндәү — гамәлләрнең күркәме...» (2010 ел), «Аллаһы Әл-Кәрим» — үзәктә: «Аллаһ», уң яктагы текст: «Ходай Тәгаләнең нигъмәте һәм рәхмәте насыйп булсын», сул яктагы текст: «Хакыйкатьтә Аллаһ игелек кылучыларның савапларын кабул кылыр» (2012 ел) каллиграфия композицияләре сериясе өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ ана кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миннеханов**

*Казан, Кремль*
*2014 ел, 25 апрель*
*№ ПУ-426*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)